
ISSN 0206—418



# Казан утлары

12.1989





**Дәрдемәнд**

(1859—1921)

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАИ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1989

12

(806)


## Бу санда


ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ә. ГАФФАР. **Олы юлның тузаны.** *Роман* . . . 3
Рәш. ӘХМӘТҖАНОВ. **Карачкы.** *Поэма* . . . 109
АКЪЕГЕТ. **Тарала бөтнек исе.** *Шигырьләр* . . 120

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

А. ШАВКУТА. **Ахшам күләгәсе.** *Хикәя* . . . 125
Н. ГОДИНА. **Хикәят.** *Шигырьләр* . . . . . 140
А. ЛЕСИН. **Гитлерның соңгы эмере.** *Шигырь* . . 141
М. ҖОМАБАЕВ. **Җил.** *Шигырьләр* . . . . . 143
М. МИРЗАЕВ. **«Үзбәкләр эше».** *Шигырьләр* . . 146
Х. ГАЛИМҖАН. **Һәр йөрәкнең.** *Шигырьләр* . . 147
М. НАСЫЙБУЛЛИН. **Дуслык — зур байлык** . 150

ПУБЛИЦИСТИКА

Ә. РӘШИТОВ. **Без кемнән ким?** . . . . . . 154

ӘДӘБИ МИРАС

М. ГАТАУ. **Сәләмгә.** *Шигырь* . . . . . . . 159

СӘНГАТЬ

Ф. ХАТИПОВ. **Көйләребез, моңнарыбыз** . . . 160

ДӘРДЕМӘНДНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Н. ХИСАМОВ. **Дәрдемәнд** . . . . . . . . 165
М. МӘҺДИЕВ. **Рәмиевләр нәселеннән берәү** . . 176

НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ 90 ЯШЬ

Н. ИСӘНБӘТ. **«Сынатмаска кирәк, җегетләр!»** . 178

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

**Дүртенче дәрес** . . . . . . . . . . . . 182

**Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре** . . . . . . . . . . . . . . 185



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

«Казан утлары»нда 1989 елда басылган әсәрләр исемлеге . . . . . . . . . . . . . . 186

Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . 191

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙПОВ
*(җаваплы секретарь)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек редакторы)*
РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН
МӘХМҮТ ХӘСӘНОВ
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘУФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек редакторы)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 120066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор — 53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь — 53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Окончание романа А. ГАФФАРА «Пыль большой дороги».
Поэма Раш. АХМЕТЗЯНОВА, стихи АКЪЕГЕТ.
«Дружба народов — дружба литератур». Рассказ А. ШАВКУТА, стихи Н. ГОДИНА, А. ЛЕСИНА, М. ЖУМАБАЕВА, М. МИРЗАЕВА, Х. ГАЛИМЗЯНА. Статья М. НАСЫБУЛЛИНА «Дружбой надо дорожить».
«Публицистика». А. РАШИТОВ. «Мы не хуже других».
«Литературное наследие». Стихи М. ГАТАУ.
«Искусство». Статья Ф. ХАТИПОВА «Наши мелодии».
В номере отмечаются 130-летие классика татарской литературы поэта Дардменда и 90-летие писателя, драматурга и ученого Н. Исанбета.
Уроки татарского языка.
Навыки чтения на основе арабской графики.
Список произведений, опубликованных в 1989 году.
На наших обложках — татарское прикладно-декоративное искусство. Корама. Казанский трамвай. XIX век. Фоторепродукция старинной открытки.

*Бүлек редакторлары* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин
*Редакторлар* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миннуллин, Рәшит Әхмәтҗанов
*Техредакция:* Р. Вафина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибагатуллина, Р. Сөләйманова

Производствога бирелде 04.10.1989 ел. Басарга кул куелды 24.11.1989 ел. ПФ 05155. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 77049. Заказ Б-438. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1989 ел.

## Әхәт Гаффар

# ОЛЫ ЮЛНЫҢ ТУЗАНЫ

РОМАН

Кадрәкне менә шулай алып киттеләр. Яккан гаепләре коточкыч гаделсез иде. Бу хәлгә кадәр ике көн элек августның соңгы хәтәр яңгыры тегермән буасын алып китте. Түбән тугайны су басты, киптерергә дип әвен базы янына куелган арыш эскертен агызып китте. Имеш, кырчылык бригадасы бригадиры Кадрәк Наймушин эскертне су-ташу юлына махсус ташытып өйдергән. Аның бу эшен «терракт» дип атадылар. Соң, җәмәгать, Кадрәк адәм баласы гына, нинди террорчы булсын, хәтәр ташу төшәсен алдан каян белсен? Әвен базы Чаныш үзен-үзе белә-белгәннән бирле шул тугайда. Юк, Кадрәк, бала, моны раслый алмаган.

Чаныш башта үзе, аннан Рәхилә, тагын үзе Асылъяр белән кутузкага передача илтте. Алмадылар. Күрештермәделәр дә. Кая ул! Аның үзен исә, Шапалак янап чыгып киткәнчә, сорау алырга чакыртмадылар. Аның каравы, җыен ясап, тегермәннән чыгарып ташладылар. Төрле эшкә йөри башлады. Ни хәл итмәк кирәк. Буйсынды. Халык юатыр, юатмаса, аңлар дип көткән иде. Юк! Чумадан качкан шикелле читләштеләр, ят иттеләр. Дүртенчесендә тагын үзе генә барган иде. «Ублюдкаң монда түгел инде!» — дип кычкырдылар. Чаныш: «Кайда соң ул?» — дип ялварды. «Эзлә!» — диделәр. Эзлә, имеш! Шапалак белән суккан урында чебен эзе кала, ә бу Ш а п а л а к суккан кешеләр эзсез-хәбәрсез югалды. Чаныш Казанга ике барып эзләде — табалмады. Зур урында эшләүче сугышчан иптәшеннән эзләттермәкче иде, вәгъдәсен алса да, аның эзләргә кыймаслыгын аңлады. Эзләү — үзең дә югалу белән бер иде шул. Улы шулай югалды.

Кадрәк сугыш башланыр алдыннан гына хәбәр салды. Аннары фронттан язгалап торды. Хатларында әйтмәсә дә, хәтәр җирләрдә йөргәнен аңлыйлар иде. Иң мөһиме: хәбәрсез-нисез югалу урыныннан котылган — шунысы яхшы. Ул арада танк батальоны командиры — Сибгатләре һәлак булды. Төпчекләре хәбәрсез югалды. Сугыш беткәндә матрос уллары Тәлгатькә дә кара кәгазь килде.

Кадрәк җәй уртасы узгач, солдат киемендә кайтып төште.

— Бабай, эти кайтты!

Ревоның кояшлы җәй көнендә яңгыраган шатлыклы авазы Ча-

---

Ахыры. Башы 11 нче санда.

нышның күкрәгендәге яра җөенә яңа ядрә булып кадалгандай тоелды.

— Әби, эти кайтты!

Асылъяр, оныгының халык урак урган җиргә килеп җиткәнче кычкырудан карлыккан тавышын ишеткәч, бәпкә төбенә сыгылып төште.

— Әни, эти кайтты!

Рәхилә шул ук басуда агач кисмәктән чумырып алып, чүмечтән су эчә иде. Улының үзе янына якынаеп пышылдавын ишеткәч, кулы калтыранды, салкын чишмә суы кайнар күкрәгенә, аннан авыр эш ныгыткан корсагына акты. Әгәр шул вакытта караңгы төннәрдә кеше күзеннән качып, иренең язмышын юрап куркулык койдырган кургашларның һәммәсен яңадан эретеп агызсалар да, ул моны сизмәс иде шикелле.

— Эти кайтты, абыйлар-апалар, минем эти кайтты!

Халык эштән туктады. Кояш чагылдырган күзләрен кысып, Кадрәкнең улына, анасына, хатынына карадылар. Кайсы шатланып, кайсы битараф, күбесе көнләшеп, йөрәкләрендәге җөйләнмәс яраларының сызлануын тоеп карадылар. Алар эшләп калды. Ә солдат улы, анасы, хатыны, сулышларына буылып, авыл тарафына йөгерделәр.

— Мине каян таныдың, улым? — дип сорады ата улыннан.

— Бу күрешүне артык күп көткәнгә күрә.— дип җавап бирде улы.

Алла биргән ризык куелган табын янында гәпләшеп утыруның рәхәтен Чанышның һич онытасы юк. Утыруы рәхәткә рәхәт, ә менә сөйләшкән сүзләре хәтәр иде.

— Мин бит, эти, сугышның ахырына таба бер генералны машинада йөрттем.— дип сөйләде Кадрәк.

— Борчак сипмәле! — дигән булды Чаныш, улының һәр сүзен йотлыгып тыңласа да.— Синнән ниткән шофер? Анда апкиткәнгә хәтле Гришка янында буталудан узмадың ич син. Мытыес шоферын әйтәм.

— Нәкъ менә шул шөгыль үтә чыккан ярап куйды да инде, эти. Анда, яшисең килә икән, тырмашасың. Лагерьда дим. Җанны шул һөнәргә өйрәнү мәшәкате саклады да. Анда һөнәрсез кеше сагыштан харап була. Һөнәрсез булу — шөшле белән аш ашау шикелле. Өйрәнгәндә, алда гомер бармы-юкмы дип тормыйсың, бер кирәге чыгар дип уйлыйсың. Тормыштан туйганнар гына ни өйрәнмәде, ни башкаларны өйрәтмәде. Казна эшен, дөресен әйтим, беркем сөймәде. Костырырлык шакшы иде. Ә менә үз шөгылең — анысы җан азыгы. Караңгы төшкәнче апкайтып ябалар иде, ә ябып куйганнан соң нишләмәк кирәк? Аерата — кышын. Бүре булып уласаң да таман. Менә шунда сәндерә күршем Дорофей Саныч әкертенләп машина серләрен ачты... Берчакны стройга тезеп: «Кемнәр автомашина йөртә ала?» — дип сорагач, чыктым да бастым. Оторви да брось, мәйтәм, үлем ике килми. Шуннан алда гына шоферларның күбесен Себергә озатып бетергәннәр иде. Тимер юл салырга. Агач ташырга гына курслар бетермәсәң дә ярар дидем дә тәвәккәлләдем.

— Әтәчлек синдә барые инде!

— Ничава, анда да кикрикне төз тоттык. Кикриген шиңдеме — беттең. Бөтенесенә күнегәсең: юл читенә егылып калдың икән — конвой урманга сөйрәп кертә дә ташлап китә. Җаны кыл өстендә торганнарны илтеп ыргыта торган урынга хәтле бар иде, эти җаным! Үзең сорыйсың икән, анысы да — пажалысты гына! Ачуым килмәгәе, анда әтәчтән йомырка салдырсалар да ис китми. Андыйлар да булды. Шпанага анда ир дә — хатын. Кхм, кхм... Ә без татарлардан куркалар иде. Татар бит ул җиңелсә дә бугазга ябышыр, диләр. Безнең бабай — синең атаң Наймуш та шулай әйтә торган идеме? Әйтә

торган иде. Шулай булгач, сезгә ышанасы гына кала.

— Шуннан? — дип сорады Чаныш мондый сүзләрнең тизрәк бетүен дәгъва иткәндәй. Аны вак-төяк нәрсәләр кызыксындырмый иде. Хәер, тормыш итү — шул вак-төякләрнең чылбырдай тезелешеп килүе инде ул. Әмма ул үзе дә бер үлеп караган кеше. Шуннан соң тауларның түбәләренә генә басып йөрисең икән аны. Үзәннәрсез дә булмый, әлбәттә.

Моңа Кадрәк тә өйрәнгән икән. Шуңа күрә табын артындагы сүзен кыска тотарга тырышты.

— Шуннан — шул. Подъемнан отбойга тиклем баш күтәрми урман кисәбез. Фин кампаниясе башлангач, безне ул тирәләрдә тотудан шикләнделәр булса кирәк. Ник икәнен, кая икәнен әйтеп торалармы суң — алып киттеләр. Безнең этап Онежский күлгә килеп чыкты. Баржага төяделәр. Сыйган кадәребез сыйды, сыймаганнар ярда яңа баржа көтеп калды. Кичкә каршы кузгалдык. Ятыйм дисәң, аяк сузарлык түгел. Йокы атларныкы сыман инде — аягүрә. Валлаһи менә. Ашау дигән нәрсә юк инде. Тәгам-ризык заты калмаган. Ни булганы этап кичкәндә бетте. Аның каруы кашеварлар рәхәт чигә. Күбенгәнче эчәләр. Шул — безгә тиешле ризык хисабына инде. Авыл саен, безнең өлештән урлап, аракыга алмаштыралар. Сакчылар белән бер сүздә болар. Ә безгә — суган суы... Ну зәһ-һәр егетләр бар икән дә суң! Тегеләрне тора-бара аякларыннан тотып, чәчләрен суга чылаткан сымак кына иттеләр. Монысы соңрак булды — баржа комга терәлеп калгач. Әйе, икенче көнне сайлыкка утырып калдык. Кругом — су да су. Толкач алай иткән булды, болай иткән булды да, ташлап китте. Бер көн көтәбез, ике көн көтәбез — юк та юк бу. Әзе суынды. Шулай итеп, атна узды. Унөченче көн киткәндә буксир тартып чыгарды...

Чаныш Кадрәкне әле утырып, әле ишекле-түрле йөренеп тыңлады. Асылъяр белән Рәхилә самавыр арты самавыр яңартты, кагылучы булмаса да, өстәлгә йомыркалар тәгәрәтте. Хатын-кызның шул инде аның — аһ та ваһ итештеләр, тик куанычлары да май кояшы белән бер.

— Тилмергәнсез икән,— диде Чаныш.

— Тилмерү ише генәме суң, әти җаным! Кырылдык без. Көзге чебен урынына кырылдык. Байтагыбыз сары чәчле дә зәңгәр күзле — латышлар йә эстоннар. Безнең ише кара халык та бихисап — бессараблар. Күбебез урыс та татар. Ну, тагын хохол да грузиндыр. Баржа түгел, туганнар каберлеге инде менәтерә! Кырылдык, кырылганы берен баржа борынына өя бардык. Адәм баласын күрәләтә ничек суга атмак кирәк? Җавапка тарттырулары да бар бит әле. Әй, өйдек тә соң! Аннары нишләткәннәрдер — алла белсен. Шулай, тәгамнең ни икәнен онытты к. Аерата дизентерия кырды. Әйе, әти. Кырылып күрсәттек тә соң! Көзге чебен урынына кырылдык, әти. Чалгы да алай кыймый, чалгы да!.. Ә без, әти, яхшы кешеләр идек бит! Теге дүртбиш кашеварны искә алмаганда инде. Ахыр килеп, хәтта ки безнең сакчылар да алай адәм балалары каргарлык ук булмаганнардыр. Бу сугыш мәхшәреннән алар да исән чыкмагандыр... Әйе, әти: без яхшы кешеләр идек. Бездән дә гаепсезрәк кешеләр — сез дә халык кына. Без халыкка үпкәләмәдек. Бу дөньяда нинди генә әшәкелек, явызлык кылынса да, халык гаепле түгел... Без, әти, яхшы кешеләр генә түгел, яхшы хыяллы, яхшы ышанычлы кешеләр идек. А-а, кемнәр кырылды! Халыкның каймагы, көче. Нахакка кырылдык, ямьсез кырылдык, законсыз кырылдык, кайтмаска кырылдык. Безнең кемлегебез хакында халык дәшми калса, җир оран салыр әле, җир!

— Күрәчәгең булган инде,— диде Рәхилә.— Сине ни саклап калгандыр?

Асылъяр, күзен яулык почмагы белән сөрткәләп:

— Кешене кеше саклый аны,— диде.

Чаныш, улын әрнүләрдән, арындырасы килепме, аның шуннан соң тормышында якты көннәр булгандыр дип, шуларны исенә төшерергә ашыгып:

— Шуннан? — дип сорады.

— Шуннан... Шуннан — Себер. Шахты. Күмер чабуга куштылар. Чабабыз. Декабристларның нормасы көнгә өч пот булган, диделәр. Ә безнең дүрт йөз пот! Хуш... Бер көнне, сугыш ачыласы елның кышында, мине начальник чакырткан. Сак астында килеп керәм, шартына туры китереп рапорт бирәм. Теге аны-моны сораштыра, әйткәннәрне алдындагы кәгазь тегелмәсеннән тикшереп бара. Сүз беткәч, болай ди бу: «Син, Наймушин,— ди,— нигә язмыйсың?» «Нәрсә язмыйм?» — мәйтәм. «Аппеляция»,— ди бу. Безнеңчә әйткәндә, органнарга үтенеч сымаграк нәрсә инде. Шулай да шулай, минем эшне кабат каравыгызны сорыйм дип. Ә эчтә — шик. Соравын сорарсың да бит, ә өстәп чәпәсәләр?! Андый хәлләр дә булмады түгел. Анысыннан да без аң инде. Ну шулай да тәвәккәлләдем. Теге өйрәтеп торды, мин сырладым шунда. Гаҗәп, җавапны озак тотмадылар тагын. Бер көнне аклап кәгазь килеп төшмәсенме! Кем белә аны: гаделлек сакчылары бетмәгән, күрәсең. Башкача ничек булсын? Ә бәлки безнең эше вак-төяккә нар җитми башлагандыр. Анысы үз намусларында калсын. Әйе, шуннан: «Дүрт ягың кыйбла»,— диделәр. Туктале, мәйтәм, кыйбласын кыйбла да бит... Бигкә яккан корым алай гына бетми бит әле, димен инде үземчә. Кайтып төшәрсең,— халык ни дияр бит әле анда. Калып тордым. Ирекле булып. Андыйлар да күп иде анда. Начальник мине үзенә шофер итеп алды.

— И-и, җүләр! — диде Рәхилә.— Миең белән уйламыйча, ниең белән уйлагач, башында безнең кайгы булмагандыр шул инде, адәм страмы. Ни оятың белән шулай уйладың соң син? Мине уйладыңмы, газиз балаңны уйладыңмы дияр идем дә, тел әйләнми!

— Шул сине уйлап бит инде, сине уйлап! Синең кочагыңа йолкыш чебеш булып кайтып аварга кем дип белдең син мине? Аннары ул арада сугыш ачылды. Туп-туры ут эченә ташландык...

Рәхиләнең үпкәсе чын-чыннан ук бәреп чыкты:

— Юл уңгае кереп чыксаң, табаныңа сөял чыгар дигәнсеңдер. Синең гел шул инде: киреләнмәсәң, эшең эш түгел.

— Анысы инде аның, хатын, минем эш кенә түгел, вөҗдан эше. Белдеңме? Казанны без чажлап кына узып киттек. Без бит андыймондыйлар гына түгел. Без бит — авыз тутырып әйтүе үзе ни тора!— без бит Сибирски дивизия! Без бит Кызыл мәйданнан парад белән саф-саф булып үткән кеше. Кайдан диген — Ленин мавзолее каршыннан. Притом ап-ак туннар киеп, мылтык асып. Притом иптәш Сталин безгә үзе — үзе! — честь биреп калды!..

Кадрәк шушы урында тынып торды. Аннары, Рәхиләнең тетмәсе тетелгәнгә санап, тагын атасына сөйләргә кереште:

— Шуннан — туп-туры Мәскәү янына. Волоколамски шоссе... Без анда җиребез суынмасын өчен тоташ юрган булып яттык.— Нидер әйтеп җиткермәгәнен исенә төшереп, ул күкрәгендәге «Батырлык өчен» медален «Кенигсбергны алган өчен» дигән медаленә тидереп чыңлатырга тырышты да, тимгел-тимгел таплар чуарлаган йөзен тагын Рәхилә ягына борып: — Без бит артка борылып, Мәскәүне бинокльдән дә карый ала идек. Чөнки артка борылып карасак, Мәскәүне генә түгел, сезне дә күрербез дип уйладык,— дип өстәде.

— Күрергә бик ашкынып торгансыңдыр шул,— диде Рәхилә елмаеп. Аңа зарыгып көткән ирен бераз котырту ниндидер ләззәт бирә иде, ахрысы. Моны аның ире Кадрәк тә сизми түгел. Ләкин хатынының уенына кушылыр иде дә, буа булып ташыган хисләрен кая куйсын, ничек онытылсын соң?

— Суң бит, хатын, үзең фараз кылып бак: йә инде, сезне бинокльдән күрерлек булып чигенсәк, нинди Сибирски дивизия булыйк ди инде без, йә?! Без бит тавык муеннарын борып йөрмәгән. Без бит фельдмаршал Бок командалык иткән «Центр» гаскәрләренең, Манштейн, Паулюсларның үзләренең — үзләренең! — муеннарын борып йөргән кешеләр! — дип кайнап алгач, Кадрәк янә атасына карап: — Шуннан — Сталинград...— дип дәвам итте. Һәм, кискәндәй катгый төстә: — Булмаган җир калмады инде. Кенигсбергны алгач туктадык.— дип тәмамлады.

Бераз тын торгач, инде рәнҗеше, ярсуы, дулкынлануы, горурлануы — барысының да сүрелгәнен көтеп алгач, яңадан телгә килде: — Ахырдарак мин бер генералны машинада йөрттем инде. Корпус командиры. Ну атчаянный кеше иде дә соң! Менә, ул биргән отпуск белән генә кайттым бит әле.— Кадрәк Рәхиләсен юатырга да онытмады: — Син, Рәхилә, нитмә инде, яме... Үпкәли күрмә диюем. Әйләнеп кайттым бит әле. Тагын кайтырбыз. Инде озак тотмаслар, шәт.

Чаныш улыннан күзен алмыйча тыңлады. Тышта чыдап булмастай эссе. Урак өсте. Бар халык кырда. Кадрәкнең көтмәгәндә кайтып төшүе уңаеннан алар гына өйдә. Ярты ягы чолан белән бүленгән, чиллә вакытында да салкынча өйалдында утыралар. Баш өстендә — салам түбә. Саламы калын булганга күрә бөркү түгел. Монда күз дә ял итә: яктылык ян стенадагы ике бүрәнә тарлыгындагы тәрәзәдән генә төшә. Шуңа өстәп, мондагы тынлык та рәхәт. Әнә, пыялага бәргәләнгән чебен тавышы да ишетелә.

Рәхәт тә кебек: тыныч, озын-озак түзү артта калгач, авыр эштән соң гадәттәгечә утырган гына диярсең. Тик һәркайсының җанында авыр бер шик-шөбһә дә яши иде әле. Кадрәк яңа кайтып төште генә әле, әмма тиздән тагын аерылырга туры киләчәге һәркайсының күңеленә иңгән инде. Чиксез шатлык, гаепсез беркатлылык белән этисе дисәң этисе булып җитмәгән, ләкин шул кешедән килгән әллә нинди якынлык, җылылык, моңарчы иснәмәгән әллә нинди ят солдат исләре эчендә калган Рево әнә шул алга киләсе аерылышуның үзе кебек тоелды. Утыра малай, шат, атасының кочагына сеңгән. Тик ул этисенең әледән-әле: «Рево, әй, Рево!»... «Рево, менә син нинди булып җиткәнсең!» — дип ник кабатлаганын белми әле.

Чанышның каны йөрәген авырттырып кайный иде. Вакыт туктап калган кебек. Тынлык шундый тирән, чылбыры җитмәслек кое мыни. Ә аяк астындагы идән чак кына чайкала шикелле. Чаныш үзен ташудагы боз кисәгенә басып баргандай тойды. Әйтерсең лә ул бер ялгызы. Улы Кадрәк тә, Асылъяр да, килене Рәхилә дә, оныгы Рево да артта, караш иңләмәстәй ераклыкта. Әллә соң берни дә юкмы? Башында уй калмаган, ул бушлыкта адашкан сыман. Ә юк. Әнә, чебен безелдәвеннән туктады. Тәрәзә почмагындагы пәрәвезгә эләккән икән. Өн-тавышсыз тыпырчына. Пәрәвез җепләре калтырый, өзелердәй хәлдә тартыла, чебенне ураганнан-урый. Тик чебенгә ташланырдай үрмәкүч тә юк икән инде: ул, сыртына капланып, тәрәзә төбендә ята, үлгән.

Ә шулай да рәхәт иде! Улы Кадрәк кайтты. Көтмәгәндә кебек тоелса да, бер дә алай түгел. Сирәк хатлары килгәндә дә үзе кайтып төшкән сыман була иде. Көтмәделәрме соң?! Сызылып таңнар аткан да Чаныш йокысыннан дерт итеп уянып китәр иде дә, төшләренә һаман малай гына килеш кергән Кадрәк, калган уллары хакында уйланып ятар иде. Алар белән бергә йөргән урман юлларын, су буйларын күңелендә кабат-кабат яңартыр иде. Үзенеке кебек үк, Асылъярның да керфекләре ачык икәнен, зәңгәр күзе белән түшәмнең киң такталарындагы ботак эзләреннән улларының йөз чалымнарын эзләгәнен тояр иде. Иренең уянганын сизеп, ул таң шәүләсе кунган ак йөзе, ак ирене белән нәрсәгәдер гаепле сыман елмаер иде. Чаныш киенеп чыгып, абзардагы маллар тирәсендә булышканда,

«Нигә шулай елмая соң әле бу?» — дип уйлана иде. Бер төнне җавабын да тапты: әллә соң Асылъяр үзендә улларын тартып алган дошман солдатларының аналары гаебен тоямы? Җирдә күпме кеше елмая, әмма елмаюның иң чыны кайдадыр үтерелгән балаларының каберләрен күрмәгән аналар йөзендә генәдер. Җирдә күпме сагышмоң бардыр, тик сагыш-моңнарның иң ихласы шул балаларның кайтырына өметен өзмәгән аналар күңелендә генәдер.

Инде менәтерә Кадрәкләре исән-сау әйләнеп кайтты. Ул үзен ураган пәрәвез ятьмәсеннән азат. Шапалак юк инде. Үргән пәрәвезләрендә үзе үк буталды-буталды да, әлеге үрмәкүч сыман, әйләнде дә төште. Дөресрәге, әйләндереп төшерделәр. Чаныш сизмәде түгел. Кайдадыр, кемдер халыкның каргышыннан, нәфрәтеннән курка, кара эзләрне, кан тапларын, күз яшьләрен югалтырга кирәк. Чараның иң кулае — яман эшләрне шапалакларның үзләренә аудару, сылтау. Шапалакның юкка чыгуын Чаныш шушылай аңлады.

— Хәзер яшисе дә яшисе инде,— диде Чаныш.

Асылъяр белән Рәхилә чыгып торган бер мәлне Кадрәк:

— Ә үлгәнче бер эш бар әле, эти,— диде.

— Бер генәме соң, мең... Миллион эш бар әле.

— Башта — беренчесе.

— Йә?

— Шапалакны табасы иде бит.

— Ни нәрсәгә хәҗәт ул?

— Мин аңа күчтәнәчкә бер пуля алып кайттым. Генералдан рөхсәт. Ул: «Ат, мәгәр кеше алдында ат»,— диде.

— Дөрес әйткән.

— Син дә хуплыйсыңмы?

— Мин генә түгел. Совет власте да. Нәкъ генералың әйткәнчә булды.

— Ничек?!

— Шулай. Шапалак юк инде ул. Тончыкты.

— Кайда?! — дип, Кадрәк яралы ерткычтай кычкырып куйды.

— Тилергән эт идеме? Эт иде. Ә кеше канын койган тилергән этләрне аталар аны... Шапалакка хөкем булды.

— Алайса кабереиең кайда икәнлеген әйт. Җир белән тигезлисем килә.

— Тилергән этләрнең кабере булмый, Кадрәк,— диде Чаныш һәм сорыйсы итте: — Генералың, чыннан да, ат, мәгәр кеше алдында ат, дидеме?

Кадрәк аңа эндәшмәде, күтәрелеп кенә карады.

— Ник алай дигән соң ул?

Кадрәк:

— Ул үзе дә шундый ук Шапалак каһәренә эләккән, эти,— дип җавап кайтарды.— Өч кыш, өч җәй утырып чыккан.

— Юк, Кадрәк, хаталанасың,— диде Чаныш бераз уйланып торгач.— Син ул әйткәннең кабыгын гына күргәнсең, ә төшенә җитәргә акыл тешең үтмәгән. Күчән баш! Ул сине, малай актыгын, җаны чистарсын дип кайтарып җибәргән.

— Әллә минем чисталыгыма шикләнәсеңме?

— Ул сине, Кадрәк, шапалаклар канына буялсын дип җибәрмәгән. Монда хикмәт бүтәндә. Дөресрәге, ул сине эчеңдәге корттан арынырга дип җибәргән.

— Ниткән корт тагы?! — дип кычкырды Кадрәк.

— Үч корты. Менә ул корт кешене кимерсә кимерә инде. Ул сиңа мәет корты ише генә түгел, кешене терелә̆й черетә. Үч корты белән ботка пешми — аң бул.

— Шапалак кирәген алды дисең ич әле. Бу сиңа үч алу түгелмени!

— Түгел шул. Анысы бүтәнчә атала аның — гадел хөкем дип.

Кадрәк аллы-артлы йөренә башлады. Какча йөзе һични белгерми, карашы сәер, илтифатсыз, кулы салынкы. Болай да калку буе тагын да озынайды шикелле. Чаныш аның эчтән газаплануын һәм хәзер иң кирәкле сүзгә мохтаҗ икәнен аңлады. Тегенди-мондый сүз генә ярамас. Кадрәк күпне күргән, күпне ишеткән. Аның авыр уйларын таратырдай сүз дөньяда калмагандыр да. Шуңа карамастан, ул сүзне табарга кирәк.

Кичкырын Чаныш аны су буена алып төште. Ревоны да иярттеләр. Сугыш турында, авыл хәлләре, дөнья киләчәге турында сөйләшә-сөйләшә, инеш буйлап түбәнгә — ике чакрымдагы Благодатное дигән урыс авылына чаклы җиттеләр, чиркәүле тауга күтәрелделәр һәм елга ягындагы урыс зираты янына килеп чыктылар. Кадрәк бәлки сизмәгәндер, ә Чанышның монда юл тотуы очраклы булмады. Монда ул Кадрәкне юри алып килде.

Кояшның баюга таба юнәлгән чагы. Шәфәкъ кызарган вакыт. Зират тын. Анда агачларга караганда тәреләр күбрәк. Күз алды иркен. Сахра инде, сахра. Урыслар үз авылларына тикмәгә генә Благодатное дип исем кушмаганнардыр. Авыл урамнарын гына ал: Чанышлар авылының ике урамы сыярлык киң. Килгән шәпкә җирне кызганмаганнар. Татарларның күпкә кысылып утырулары җир әзлегеннән генә килеп чыкмагандыр, әлбәттә. Борынгыдан — Иван Грозный заманнарыннан ук кысрыкланган булганга, утырулары да кысан. Чабата белән басарлык та кысыр җир табалмассың. Кая анда благодать: авызың ачылганда үпкәң күренмәсә, бик хуш инде. Татарга һәр карыш җир — дөнья бәясе. Өй арты да тотып алынган. Урыслар нинди киң урамга да рәшәткә белән чыкмый: тәрәзә төбенә ышкылып йөриләр. Хәер, һәркем үз дөньясында үзенчә тереклек итә инде. Нәрсә аны, көнләшерлек ни бар? Татарның да, урысның да шул ук салам түбә, шул санча ук терлек-туар, кигән киемнәре дә хәлдән килгәнчә. Өстәвенә, син татармы, урысмы, чувашмы — ит, сөт, май, бәрәңгеңне чыгар да сал. Хет җир астыннан тап. Үзең җир астына керәсең килмәсә, ни кала? Кан төкерәсең, табасың. Тиешсең, мәҗбүрсең. Бетмәс-төкәнмәс шул налоглар, заем... Бар аерма — телдә, җырда, ашауда гына. Динне дә әйтер идең, ләкин, ахыр килеп, иман бер үк бит. Кайсы дин үтер дә урла дигән? Өстәп, кеше азатлыгын да дәгъвалаган булсалар, калган җыен тузга язмаганнан арынсалар, коммунистларча диярлек. Әйе, диярлек кенә анысы. Тик коммунистларның да арынырдай хаталары байтак. Әлбәттә, Чаныш моны кычкырып әйтергә җыенмый. Бар, кычкырып кара!.. Тик яшь арткан саен, дөньяда кешеләрне аерган нәрсәләр хакында түгел, бәлки берләштергән уртаклыклар турында уйланасың икән ул. Дөньяга килгәндә һәркем, ник тудым икән, дигән шикелле, үзе хакында елап аваз сала. Дөньядан киткәндә исә, еламас өчен, соңгы сулышынача яшәргә тырыша. Бөтен тарих әздән генә тора: кеше туа, тереклек итә, газап кичә һәм үлә.

Болар хакында Чаныш сөзәк тау итәгендә үзе генә калгач уйланды. Ә аңа кадәр улы Ревоны кочаклап утырган Кадрәк белән киңлекләргә юанып, күзләрен су аклыгында ял иттереп, кошларның соңгы авазларына колак салып, иркенләп сөйләштеләр. Сүз бетеп торган арада Кадрәк улын муенына атландырды да тау итәгеннән соң башланып киткән су буена таба китте. Чаныш аларның анадан-тума чишенгән килеш су чәчрәтә-чәчрәтә коенуларын, сары ком буенча куышуларын сөенечено сыя алмыйча дигәндәй күзәтеп утырды.

Кояшка арканы куеп, кайтырга чыккач, Чаныш зират ягына юнәлде.

— Монда сугылыйк әле,— диде ул.

— Безгә ни калган анда? — дип сорады Кадрәк.

Чаныш җавап бирмәде.

Зират таш коймa белән уратып алынган иде. Байтак өлеше җимерелгән инде. Шуның ишелгән төшеннән үттеләр. Чаныш аларны бер нарат төбендәге авыш агач тәре янына иярте килде.

— Туктале,— диде Кадрәк, әйләнә-тирәне танырга тырышкандай караныл.— бу төшкә син мәктәптә җыештыручы булып йөргән... кем әле... исеме хәтердән чыккан... Ә! Марфа түтәйне җирләгән идең түгелме?

— Җирләгән идем, әнә ул,— диде Чаныш, һәм тәресез, өсте иңгән бер кабергә ияген кагып күрсәтте.— Ә менә монысын минем әти, синең бабаң, ә синең, Рево, дәү бабаң Наймуш казыган. Монда, Кадрәк, минем үтерүчем полковник Кулунчаков белән мине үлемнән коткаручы Мария күмелгән.

— Сөйләгәнең булмады.

— Һәр нәрсәнең үз вакыты бар, Кадрәк. Минем атам Наймуш та миңа вәгадәсе җитте дип уйлаганнан соң гына сөйләде. Марфа түтәйне җирләгән көнне. Шуннан соң эти озак тормады инде... Әйе, һәр нәрсәнең үз вакыты бар.

— Миңа да, шулай, вакыт җитте дип сөйлисеңме?

— Ахрысы. Югыйсә Шапалак каберен таптырасың ич. Күм инде син аны. Хәтереңнең иң караңгы урынына күм. Башта үзен, аннары каберен үк. Дөньяда якты күрәсең килгән саен, син хәтереңдәге әнә шул караңгы урынга багарсың. Моннан ары яшәр өчен сиңа ш а п а л а к л а р н ы ң ике тапкыр күмелгәннәрен истә тотарга кирәк. Бер тапкыр җиргә күмелгәннәрен, икенче мәртәбә кешеләр хәтеренә каһәрләп күмелгәннәрен.

Кадрәк Шапалак белән тагын бер очрашырга бик теләгән иде. Сугыштан аны бәлки шул үҗәт теләк исән-сау чыгаргандыр да. Чөнки ул, Шапалак белән очрашмый торып, үзен үләргә хаклы түгел дип санады. Бу очрашу күренешен күп мәртәбәләр күз алдына китерә һәм аңында кабатлый торган иде. Шапалакка төбәлгән пистолет чемәгенә ул үз күңелендә күпме басты инде. Моннан тәмам гарык булгач, генералдан кыска вакытка кайтарып җибәрүен сорады һәм максатын әйтте. Ә хәзер, атасы Чаныш сүзләреннән соң, пистолеты чемәгенә чынлыкта басмаса да, көпшәдән бер ядрә атылып чыгуын күргәндәй булды. Ядрә беркемгә дә, шул исәптән Шапалакка да төбәлмәгән иде инде. Шулай да Кадрәкнең җаны бушанып, күңеле җиңеләеп калды. Аның җаны гынамы соң? Дөньяда бер ядрә юкка чыкты. Күпме үлгәннәрне кочаклап яткан зират тынлыгы сискәнмәде. Тугай ягыннан тезелешеп менеп килгән ак казлар куркынып кычкырмады. Кадрәк үзләре яныннан күз иярмәс тизлек белән очып киткән нинди бер кошның канат тавышын ишетте. Тугайның бер ягыннан икенче ягына җайдаклы ат чабып узды һәм офык өстендә җиз сәгать теледәй асылынып торган кояшка таба юл алды.

Чаныш Кадрәкнең күзенә карады. Ә алар, сыерчыкныкыдай чиста, дымлы күзләр, һични белгертмәде. Кадрәкнең җилдә, кояшта каралган йөзе купшы төстә бөтерелгән мыегы һәм чигә чәчендәге чал бөртекләрне тагын да көмешләтебрәк күрсәтә. Чаныш улын кызганды. Ләкин ул аның моңа мохтаҗ түгеллеген аңлый иде. Әнә ничек тора: аягын җәеп, нык итеп баскан, фуражка козырегы күләгәләгән йөзе кырыс, кулын артка кушырган, күкрәге горур киерелгән. Бер генә дошман да үзенә аның улы кебек дошман теләмәс иде, мөгаен. Ә Чаныш һәр дуска үз улы шикелле дус теләде.

Шунда ул Ревоның:

— Ник кыйшайган бу? — дип, иңбашы белән авыш тәрене турыларга тырышуына игътибар итте.

— Җилләр кыйшайткан аны, олан,— диде Чаныш. Сүзен дәвам итеп, уеннан: «Җилләр,— дип кабатлады,— җилләр...»

Чыннан да, жылы җил исеп куйды. Алар басып торган урында бөтерелде дә басылды. Әллә төпсез күккә чумды, әллә Чанышның күңеленә кереп эреде. Җил тынды, ләкин Чаныш тагын бер тапкыр: «Җилләр»,— дип уйлады. Һәм ул җилләрнең, күзгә коры яфракларны тузгытканы кебек, үз гомерен тәшкил иткән елларны актаруын күргәндәй булды. Менә җил кисәк туктады. Чанышның гомер китабы ничәнчедер бите белән ачылып калды. Әнә, шушы кабер төбендә нәкъ хәзергечә үк, өч кеше басып тора. Аның урынында — атасы Наймуш, Кадрәк урынында — ул үзе, Чаныш, Рево урынында — Кадрәк. Юк, ул боларны күз алдына китермәде. Боларның һәммәсе бер мизгелдә әлеге «җилләр» дигән сүзгә сыеп беткән кебек иде. Гүя гомер китабының кинәт ачылган битен шул сүз генә тутырган: «җилләр»... Йөз тапкыр, мең тапкыр кабатлап язылса да, мәгънәсе бер генә: җилләр. Ә шул сүздә, гүя, Чаныш язмышының бетмәс-төкәнмәс сөенечле хәлләре, куркынычлы вакыйгалары кайнап тора. Әгәр дә хәзер ниндидер кодрәт белән йөз еллык йокыга талса, шунда йөз елга җитәрлек төш күрсә, уянганнан соң әлеге йөз елның бер генә мизгелгә сузылганын белсә, Чаныш бу мизгелнең «җилләр» дигән сүз икәнен күрер һәм ишетер иде. Әллә соң бөтен дөнья шул сүзгә керер өчен генә яшиме?

Әнә, кемнеңдер, кайдадыр «җилләр, җилләр, җилләр» дип кабатлаганы ишетелә. Чаныш бу өннең үз күкрәгеннән чыккан тын икәнен тойды.

...Әнә Чаныш кычкырып куйды: аһ! Күкрәгенә килеп кергән кургаш ядрә аны бер адым артка алып атты һәм җиргә бәреп екты. «...вашсокородие! Революция!... Государь-император тәхетеннән ваз кичкән...» «Ишеттеңме?...— диде Чаныш,— инде... көт...» «Нәрсәне?» — диде полковник Кулунчаков. «Халык хөкемен».

Әнә, Чаныш ату алдыннан чигәсенә бәреп чыккан тир тамчыларының февраль салкынында боз бөртекләренә әверелүен тоймый кала һәм аңын җуя... Күзен яңадан ачканда үзенә төбәлгән зәңгәр күзләрдә үз йөзенең бәләкәй чагылышын күрә. «Мин кайда?» — дип сорый ул. «Лазаретта»,— дип җавап бирә зәңгәр күз. «Су!» — дип сорый ул һәм чигәсендәге боз бөртекләренең эреп, кипшенгән иренәнә тамуын тоя. «Син кем?» — дип сорый ул зәңгәр күздән. Коңгырт кашлы, ак йөзле, сары чәчле, дымлы иренле кыз: «Ася,— дип җавап бирә,— Шәфкать туташы». «Асия»... Аннары Ася-Асия Чанышны үз ахирәте Мария коткарганын сөйләде. Ул карьерга ире Кулунчаковка революция булганын әйтергә йөгергән, атарга хөкем ителгән сигез большевикны коткарырга теләгән. Ләкин соңарган. Шунда атылганнар арасында яткан бер прапорщикның — Чанышның үлми калганын күреп алган. «Ул, Мария, үзе кайда?» — дип сорый Чаныш. «Ә полковник атылды. Мария Севастьяновна аны туган җирендә күмәргә дип алып кайтып китте...»

Соңыннан, шәфкать туташына тотынып йөри башлагач, Чаныш Ася-Асиянең Ася Ярцева икәнен сорашып белә. Әнә шул тотынып йөрүдән башлап, алар алгы гомерләренә каршы янәшә атлап китәләр. Ася Ярцева инде Асия генә дә түгел, ә Асылъярга әйләнә. Тора-бара комиссар Чаныш Наймушинның дусты, хатыны, көрәштәше, дүрт ир баланың анасы...

Әнә, полковник Кулунчаковның анасы Марфа Петровнаны җирләгәч әйтелгән соңгы дога тавышы да тына. Атасы Наймуш Чанышка шунда башка каберләрдән киңрәк тә, калкурак та булган һәм өстендә яшь нарат үсеп утырган кабер янында күңелендә сигез ел йөрткән серен сөйли. Ул бирегә — полковник Кулунчаков каберенә — үз-үзенә кул салган Марияне дә җирләгән... Яннарында — киндер күлмәк-ыштанлы, сыерчыкныкыдай чиста һәм дымсу күзле Кадрәк. Җәй уртасы. Ярда суының эзен калдырса да, суда ярының эзен калдырмый

аккан елга. Тымызык җил исә. Кадрәк белән Чанышның су чәчрәтә-чәчрәтә коенганын, кайнар ком буенча куышып уйнаганын яшел үр битенә утырган Наймуш карт карап тора...

Җилләр, җилләр, җилләр... Беренче «әлеф»тән башлап, соңгы хәрефеннән ясалган барлык сүзләрнең бөтен мәгънәсен үзенә сыйдырган җилләр. Ком бөртегеннән алып, Җир шарын да әйләндергән җилләр. Кешеләр язмышыннан башлап, Галәм мәңгелеген урап искән җилләр... Кемдер: «Җилләр, җилләр, җилләр...» — дия сыман. Җил мәңгелектән мәңгелеккә аккан елга суын шадралатып, югары күтәрелә дә Чанышның керфек очларына эленеп торган күз яшьләрен киптерә, Кадрәкнең чигә чәчендәге чал бөртекләрне тарый, Рево турыларга азапланган агач тәрене авыштыра, чәчәк орлыкларын кабер өсләренә тарата, чиркәү манарасындагы кыңгырауның итәк астында бөтерелеп чыккач, Благодатное дигән урыс авылына сузылып кергән бәләкәй көтү исен җир астындагы төлке, әрлән ояларына тутыра, өйләренә кайтып барган өч кешенең уйларын бәбкәләрдәге бодай бөртекләренә пышылдый. Алдан Рево бара, уртада — Кадрәк, Чаныш арттан ияргән. Рево тегене дә моны сораша, Кадрәк җавап бирә: улын яшәргә өйрәтә.

Ә Чаныш эндәшми инде. Ул берзаманны улы Кадрәкне, оныгы Ревоны да у л ә р г ә ө й р ә т е р г ә к и р ә к[1] булачагы турында уйлый. Яшәргә өйрәтүнең иң олысы — кешене үлә белергә өйрәтү икәнен аңа һичкем әйтмәде. Моңа һәркем үзе төшенә. Чаныш уйлый һәм искән кичке җылы җилләрне тыңлый. Ә ишеткәннәрен хәтеренә сала.

Алар өйләренә кайтып баралар. Үр кашына күтәрелгәч, Кадрәк туктады. Чаныш узып киткәч, чалбар кесәсеннән пистолет чыгарды да артка — бушлыкка атты. Затвор ачык калды. Анда башка патрон юк иде.

Кадрәк анда — баржада н и л ә р булганын атасы Чанышка инәсеннән-җебенә кадәр җентекләп сөйләмәде. Ул анда к е ш е сыйфатын югалтмады — менә ни мөһим. Ахырынача кеше булып калу өчен кайбер очракларда дәшмәскә дә кирәк. Югыйсә ары таба яшәүнең мәгънәсе калмый. Башкалар белергә тиеш булмаган соң дәрәҗәдәге кешелексез г а з а п турында сөйләү — бала кулына кылыч тоттыру белән бер.

## VII

Балык койрыгын селкетеп алды. Әйтерсең лә Чаныш белән Кадрәкнең хәтерен истәлекләр сөлгесе буенча кире кайтарды. Сөлгенең бер очы аларның гомер бишекләренә ябылган, икенче очы каберләренә асылынып төшкән кебек иде. Чаныш моны бик ачык төстә күз алдына китерде. Ул сөлгенең баш-башлары, канга манып алган сыман, кызыл киҗедән тукылган. Чаныш хәтерендәге җилләр сөлге башларын байрак шикелле җилфердәтте. Чаныш белән Кадрәкнең күпме гомере шундый байраклар астында йөреп үтте. Сөлгенең кызыл башлары аларның вөҗданнары шикелле үк ак һәм керсез чуптар тукыма белән тоташкан. Чаныш тар, озын чуптарның нык киндер җепләрен аермачык күргәндәй булды. Киндер җепләрнең үзара аерылгысыз, ишелеп-ишелеп үрелеше аның һәм улының таза гомерләре, рухлары тукымасын тәшкил итә.

Ә хәзер ул үзен балыкка атланып, шул гомер сөлгесе буенча бар-

---

[1] Луций Анней Сенекадан (Борынгы грек философы).

ган улының артында тора дип түгел, бәлки аны соңгы чиккә житүдән саклап, аның каршысында тора дип күз алдына китерде. Шуңа күрә ул Кадрәкнең үз янына килеп житүенә шатланган сыман:

— Ничек суң? — дип сорады.

Кадрәк жиргә шуып төште, чалбар артын каккалады да:

— Күнекмәгәнгә күрә бераз арытты.— диде.

— Ярый, балык та ял итсен.

— Мондый кысанда ял итәрсең, бар! — Кадрәк балык кереп калган подвалга ымлады.

— Ул чагында аны иреккә җибәрергә кирәк.

Кадрәк балыкның зурлыгын чамалады.

— Көчебез житмәс лә шул.

— Бераз көчәнсәк житәр, житми ни... Әй синең уха ашыйсың килмиме суң?

— Килә дә бит... моны нәрсәгә салып пешерерсең? Безнең андый казаныбыз да юк. Подвалда гына килеш пешермәссең инде тагын. Шулай булгач, чалбарыңны сал, әти.

Улының сүзен аңламыйча, Чаныш житди төстә:

— Ник? — дип сорады.

Кадрәк коры гына көлеп җибәрде.

— Балыкны чалбарың белән сөзеп алабыз да суга җибәрәбез. Йөзсен әле туйганчы.

Чанышка улының болай шаяртуы ошады. Авызын ачып көләргә теләде, тик тавышы-ние чыкмады. Ул шулай гына көлә ала иде инде. Аның каруы шадра йөзе ачылып китте. Атасының көлүен, елмаюын Кадрәк карга миләше белән ышкып ялтыраткан җиз самавырга тиңли иде. Шадралары исә самавыр йөзендә ялгыш бәрелүләрдән калган чокырлар белән бер иш кебек.

— Ярый суң,— дип килеште Чаныш.— Тик менә чалбар балагының тез турысы ертылды бит әле — балык шуннан чыгып шылмас микән? Шулай булгач, балыкны суга кире җибәрүдән гайре чара калмый.

— Ай-һай!...— диде Кадрәк.

— Дәрман булмаса да, акыл бездә буа буарлык. Җаен тапсаң, кыр кәҗәсен дә савып була. Ничек уйлыйсың?

— Акыллылар белән хәзер дөнья тулган. Тик күбесе эш дигәндә кашык тотучылар,— диде Кадрәк кашын җыерып.— Без шаярткан арада балыкны кояш киптермәгәе.

— Алайса, тотыныйк. Аны җибәрергә вакыт. Йөзә бирсен. Хәер, аның бүтән яшисе килми, ахрысы.

— Ник?

— Үзеннән сорап белешмәсәң дә күренеп тора. Кара син — шәлперәеп төшкән. Корсагы буш. Капчык мыни. Уылдык чәчкән ул. Соңгы тапкыр. Шуңа күрә монда да. Аның бүтән яшисе килми, хак.

— Алайса шушында гына калсын. Югыйсә авыру кешене өйдән куып чыгарган эше була.

— Үз өендә үлсен. Зур суда. Аркан апкил.

Кадрәк аңа сынаулы караш ташлады.

— Әмин ат җигим.— диде Чаныш.— Безгә ул булышыр.

Аларның авыр сөякле карт атлары үлән утлап туйган, хәзер умарта күләгәсенә башын төртеп, ятып тора иде инде. Кыяфәте тыныч. Киң күңелле, зиһенле мал ул. Әй ябыкка ябык та инде. Кай ягы беләндер коргаксыган көймәгә тартым. Тиресе астыннан, көймәнең каркас шикмәләредәй, киң кабыргалары сизелеп тора, чукмар-чукмар тоякларын ябык аяклары авыр күтәрә инде. Бу карт атның фәкать арт тоякларындагы дагалары гына яңа. Аларны тимерчелектә Чаныш үзе койды. Дагаларның үлчәме бер сөямнән аша.

Ат Чанышны сизгер җаны чагылып торган шәмәхә күзләрен

зур ачып каршылады. Озынча башын күтәреп, чал төкләр үскән иренен кыймылдатты. Хуҗасына әкрен генә кешнәп дәшәсе килде ахрысы. Кешнисе урынга тирән итеп сулады гына. Чанышның кычкырып көлә алмаганы кебек үк, бу ат та кешни алмый инде инде.

Чаныш аның муенына шапылдаткалап:

— Тор әле, Тимер, эш бар,— диде.

Аның сүзләре белән килешкән сыман башын киң чайкап, ат җайлап кына аягына басты. Буыннары шыгырдап, сагалары чартлап куйды. Кыллары коелып, сирәкләнеп беткән койрыгын теләр-теләмәс кенә чайкап, бөҗәкләрне куды.

Тезгененнән тотып, Чаныш аны умарталык өе янындагы арбага таба җитәкләп китте. Атның сыртына сыерчык кунды, аның ябага йонын чукып алгач, Кадрәк эче куышлы агачтан ясап элгән оясына чумды. Арба янына килеп җиткәнче, сыерчык ат сыртына ике мәртәбә кунып өлгерде. Ат аны койрыгы белән кумады. Кошларның ябага йонын йолкуы атка рәхәт кенә иде.

Ат җигүне Чаныш бик ярата иде. Хәзерге яшьләр моны бар дип тә белми инде. Мал җанына караганда, машина моторын якынрак итәләр. Атка кайсы яктан якынаерга, җиккәндә нидән башларга кирәклеген сорасаң, көләләр генә. Ни хәл итәсең, атлар заманы узды шул. Шуңа күрә Чаныш һәммә атларга тиеш яратуны Тимергә бирергә тырыша, аны җигүне ифрат рәхәт бер эшкә саный.

Арба янында Чаныш атка камыт кигезде, ыңгырчак салды, арты белән тәртә арасына чигендереп кертте. Сул як тәртәне күтәреп, аңа камыт бавы эләктерде дә дуганы ат муенына салды; уң якка чыгып, аның очын тагын камыт бавына каптырды; аннары камытның кыскычларын чөелдерек белән тарттырып бәйләгәч, өзәңгене дугадагы бөҗра аша үткәрде; шуннан соң аркалыкны күтәрде; иң ахырдан дилбегә ыргакларын авызлык боҗраларына каптырды.

Кадрәк өйдән кара май сеңдерелгән сүс бау төргәге алып чыкты. Арба артын алар икәү күтәреп аердылар.

— Карале, Тимер балыкны сөйрәп чыгара алыр ич? — диде Чаныш.— Ләмнән майда шуган шикелле булыр.

Кадрәк ризалашып баш какты.

— Тимернең аңа гына көче җитәрлек әле,— диде ул.— Тартмый ни!

Алар атка сүзсез дә ышаналар. Бу сүзләре үзләрен җилкендерү өчен генә. Шуңа күрә балык янына төшеп җиткәнче дәшмәделәр.

Кадрәк арканны балыкның койрык астыннан үткәрде. Чаныш аны тарттырганда балыкның тәнен кысмаслык һәм тиресен зарарламаслык итеп бәйләде. Ул рус-япон сугышында чакта бәйләргә өйрәнгән диңгез төеннәрен гомере буена онытмаган иде. Онытмаган дип... болай төйнәү ипи кискән яки чалгы белән печән чапкан шикелле, гапгади бер шөгыль генә иде.

Алар балыкны арканлаган арада, ат, чит-ят җан иясен тоеп, колакларын шәңкәйтте, балыкка, койрыгының кыймылдавына, аның һәр сулаганы саен күтәрелеп-төшеп торган суга кырын-кырын карап алды.

Чаныш аркан очын арба кендеге тишегеннән үткәреп бәйләде дә, дилбегәне кулына алгач, иренен бөрештереп атка сак кына чөңгерде:

— Пчо, Тимер! Пчо әйдә!

Ат киң итеп алга атлады. Тоягы астында ләм чапылдады. Аркан сузылды, бөтен буена әйләнгәләп тартылды, йөк авырлыгыннан киерелде. Бу киерелү башта атның күкрәгенә, аннары алгы аякларына күчте, тәне артка таба сузылды, сырты киңәйде, алгы аяклары — алга, арткылары артка каерылды. Ат башыннан койрыгына кадәр киерелде. Янга авыша-нитә күрмәсен дип, Кадрәк уң яктан балык кой-

рыгының югарыгы сөягенә ябышты.

— Пчо, малкай! Пчо!

Атның киңәйгән борын тишекләреннән әчке көчәнү сулышы бәреп чыкты. Әмма балык урыныннан кузгалмады. Ат ышанычын югалтты. Башын игән һәм вак кына калтыранган көйгә ул үзенең киерелгән аякларын бушатмый басып торды. Үзен көчсез, эшкә ярамаслык карт итеп тойды. Моның белән килешәсе килмәгәндәй, тагын бер көчәнде, тик муенында әллә кайчан камыт сукканнан калган җөйләренең авыртуыннан һәм хәлсез буыннарының коры шыртлавыннан кала һични тоймады. Аның каравы ул үзен артка таба тарткан көчне тойды һәм калган бөтен гайрәте белән шуңа карышырга мәҗбүр булды, ләкин шундук моның файдасызлыгын сизенде.

Койрыгын сулга каерып, аны шулай балык артка таба сөйри иде. Арба алдының тәгәрмәчләре үзле ләмнән күтәрелде дә чайкалып тора башлады. Аркан чыдамас, менә-менә шартлап өзелер кебек иде: күрәсең, майланган булгангадыр инде, нык торды.

Аягына терәлеп, Кадрәк балыкның койрыгын үзенә таба тартып турыларга теләде, ләкин күнитекләре ләмдә тотнак тапмыйча, ялтыравыклы эз калдырып, үлән тамырларын шәрәләндереп шуды да шуды. Балыкның койрыгы җәя булып бөгелде. Аның көтмәгәндә бушавыннан һәм Кадрәкне чөеп атудан шикләнеп, Чаныш атны тизрәк арткарак чигендерергә теләде. Әмма ат тамырлары шартлап өзелерлек рәвештә көчәнеп киерелгән. Тешләре ыржайган, ирен арасыннан күе сары күбек сузылып чыккан, яңагындагы һәм корсагындагы кан тамырлары бүртенгән, муены тирләп каралган, аяклары калтырана иде.

Чаныш югарыга, кояш үтәли яктырткан сирәк болытларга күтәрелеп карады. Аңа үзләрен кемдер өстән күзәтеп торадыр шикелле тоелды. Аннары ул шуннан, кеше ышанмастай югарылыктан карагандай, аска, аяк астына текәлде. Әйтерсең лә монда, җирдә, аның белән Кадрәк басып тормый, балык белән ат тартышмый, бәлки ниндидер билгесез затлар кирәкмәс эш белән шөгыльләнәләр кебек иде. Ул карашы белән шул ук биеклектән җиргә якыная һәм үзен, Кадрәкне, балыкны, атны — бәләкәй, көчсез җан ияләрен таный башлады шикелле.

Балык үз койрыгын кайтарырга кереште. Бу юлы инде Кадрәк койрыкны үзеннән этеп каршы торды. Әгәр хәзер балык, койрыгын айкап, Кадрәкне ләмгә китереп сыласа, аны тере килеш һичкем кубарып алалмаслыгын ул белә иде. Аның күнитек табаннары элеккеге шома эз буенча кирегә шуа иде инде.

Ә балык үз көчен күрсәтергә теләмәде: койрыгын әкрен генә, тыныч кына турайтты. Ат ике адым артка чикте. Аркан асылынып ләмгә буялмасын дигәндәй, ашыкмый, кабаланмый гына чикте. Аннары туктады, яшьле керфекләрен какты, тәртә башы ирек биргәнчә, балыкка каерылып карады, гаҗәпсенгәндәй, пошкырынып куйды, аннары, бушанып калып, башын иде. Элеккеге көче юк, авыр йөк аты дигән даны аңа хыянәт итте. Бүгенге акылы да ярдәмче түгел икән инде. Аркан шалперәеп асылынып төште.

Маңгаендагы тирне сөрткән атлы кыланып, Чаныш күзен кулы белән каплады, якты дөньядан яшерде, бармаклары арасыннан Кадрәккә карап алды. Кадрәк балыкка суккалады, гүя аны тынычландыра, юата иде.

Чаныш аның балыкка:

— Зур балык, син нигә дип карышасың, ә? Аңлыйсыңмы, без сине олы суга җибәрергә телибез ләбаса, җүләр. Син безгә булыш, булыш, — дип сөйләнгәнен ишетте.

— Балык артка таба йөзә алмый шул, менә хикмәт нидә, — диде Чаныш. Аның атны яклыйсы, аклыйсы килде. — Җитмәсә авышлык

зур. Корсак канатының баскыч ташына терәлүе дә ихтимал. Шуңа якорьдагы шикелле тора да инде ул. Ә баш ягыннан Тимер аны тәгаен тарта ала. Беләсеңме нигә?

Кадрәк аркан төенен чиште. Чаныш каршы килмәде.

— Сиңайтәм, нигә икәнен беләсеңме? Алдый дип уйлыйсыңмы? Мин дөресен әйтәм. Ник дигәндә, ялганлый белмим, — диде Чаныш. Аның атка ышанганын раслыйсы килә иде. — Хикмәт балыкны якорь сымак тоткан ниндидер канатта түгел. Атка балыкның тәңкәләре комачаулый. Алар ләмне сука төрәне сыман сөреп бара, күрәсең. Сука булган җирдә трактор кирәк. Аңладыңмы, Кадрәк? Безгә трактор кирәк, белдеңме? Күр дә тор, трактор белән без аны тәгаен сөйрәтәбез. Күз ачып йомганчы. — Ул үз сүзләре белән канатланып, пинжәгеен җилпәзәк ачып салды.

Ул бу сергә төшенүенә шатланды. Атка чөңгереп, үләнле җиргә каулады. Трактор хакында әйткәндә атны кыерсытуын, аны, шиксез, картлыкка хөкем итүен аңлады. Тик атка хыянәт итүче кеше ул түгел бугай ла, тормыш үзе шундый карар чыгарды бит. Бөтен нәрсә кулыңнан килгәндә тормыш — иң ышанычлы нәрсә. Ә көчсез калсаң, ул сине бик түбәнгә төртеп төшерә.

Ни генә булмасын, балыкны көчле техникасыз гына сөйрәп чыгару кулдан килмәс. Авылга кайтырга, идарәгә кереп, трактор сорарга туры килер. Аның ике картка нигә кирәген әйтсәң, гозереңне кире кагулары да ихтимал әле. Чәчү вакыты. Иң әүвәл синең янына шундый зур балык йөзеп килгәненә ышанмаслар. Ышанган сурәттә дә, аны кире җибәрергә һичкем ризалашмас. Тотылган балыкны кире җибәрәләрмени, дип көләрләр генә. Ихласлыгыңа ышанмаслар. Элеккән балыклар үлемгә дучар, башкача булмый. Бу гаеп эш түгел — менә нәрсә ихлас санала, менә ни хак исәпләнелә. Кешеләр, нигәдер, шулай яши. Кешеләр — кеше, тормыш — тормыш булып кала бирә.

Әйе, ни генә булмасын, трактор хәҗәт. Барысы да элеккечә калыр, тик ул балыкны суга җибәрер өчен тырышлыгын кызганмас. Ярый, аны шайтан да ышанмаслык нәрсә уйлап чыгарган җиңел акыллы карт дисәләр диярләр, мәгәр ул балыкны суга җибәрәчәк, әйе. Бу нәрсә кешеләргә кирәк түгел, кешеләр алай итми. Бу нәрсә агачлар белән ташларга, су белән һавага, җир белән кояшка кирәк. Хәер, алар берни белми. Ярый, һәр нәрсә үзгәрешсез, элекке көенчә: кешеләр — кеше, тормыш — тормыш булып калсын. Ул балыкны коткарачак. Тик корыч аргамак кирәк.

— Киттек, Кадрәк. Арбаның артын күтәреп куярга булышырсың. Мин авылдан трактор апкиләм, — диде Чаныш, дилбегәне тартып атка чөңгерде.

Ат арган-талчыккан сурәттә урыныннан кузгалды. Кадрәк арттан иярде.

— Ә мин нишлим? — дип сорады ул.

— Балык янында кал. Каргалар күтәреп китә күрмәсен үзен.

— Андый каргалар буламыни? Көлмәле, эти!

— Көлмим. Моның ише зур балык булган дөньяда аны күтәреп апкитәрдәй каргалар булуы да бик ихтимал.

— Мин хәзер каргалар куарга гына ярыймдыр шул инде.

— Кемдер карга да куарга тиеш, — диде Чаныш кояшка карап. Кояшның үзенә караганда ул андагы тапларны ачыграк күрә кебек иде.

Чаныш артка борылып карады. Балыкның койрыгы янтайган. Чыннан да, җилсез һавада шәлперәйгән җилкәнмени. Җил юк иде. Шулай да елга суын вак дулкыннар шадралаткан. Су яктырып тора. Уйланып утыручы кешенең маңгае диярсең. Судагы дулкыннар уйланучы кешенең маңгай сырларын хәтерләтә.

Алар арба артын күтәреп, кендекне кигерткән арада, сыерчык,

атка кунып, тагын бер чеметем ябага йоны йолкып китте, бүтән күренмәс булды.

— Чәй эчеп алмыйбызмы соң? — дип сорады Кадрәк.

Җавап урынына Чаныш:

— Мылтык алып чык,— диде.— Балык күтәрерлек каргалар синең чал сакалыңнан гына курыкмаслар, шәт.

— Кирәксә корырмын. Миңа мылтыкка күнегәсе түгел.

— Әйе, без аны күп тоттык шул, улым. Бу дөньяның ирләргә мылтык тоттырмый калдырганы юк әле... Капчыклар җитмәсә, балыкка юрган ябарсың. Суны мул сип, мул!

— Ярый, сибәрмен.

— Мин кузгалыйм булмаса. Пчо, Тимер! — диде Чаныш атка чөңгереп.

Үр кашыннан алдагы үрләр, үзәннәр, утыртылган урман тасмалары, ерганаклар, елга аръягындагы офыкка тоташкан киңлек ачылды.

Авылга борылыш ясар алдыннан, сәрви һәм шомырт агачлары артта калды дигәндә, ачык кыр башланды, ерак үрдән сузылып төшкән асфальт юл ачылды. Шоссе, бормаланып, киң үзәнгә сузылып керә, бераздан Чаныш аны аркылы кистереп чыгачак.

Шоссеның соңгы борылышында Чаныш берничә автомашина төшеп килгәнне күрде. Колоннаның яртысы, юлдан яшел кырга чыгып, калган яртысы, аның артыннан чиратлашып, шулай ук юл читенә төшә башлады.

Чаныш илтифатсыз гына: «Нефтьчеләрдер инде», — дип уйлап куйды. Аларның эшләренә инде күпчелек очракта исе китмәсә дә, вакыт-вакыт елыйсылары килә. Бигрәк тә алар басуларның тишелеп чыккан чәчүлекләрен, өлгергән игеннәрен ерта-ерта траншея, канаулар казыганда. Әйтерсең, закон аларга «нипачум». Бозылган җирләр өчен колхоз-совхозларга тиешлесен түлиләр дә күздән гаип булалар. Чокырларга җыелган нефтьне ягуларын Чаныш бигрәк тә өнәми. Корымлы кара төтене бал кортларын куркыта, аларның ис тоюларын киметә, бал ташый торган юнәлешләреннән адаштыра. Нефть корымы, нефть көле чәчәкләргә куна, аны нинди яңгырлар да озак вакыт юдыра алмый.

Ә бу юлы яшел басу төсендәге бер үк төрле машиналарның хәрәкәте картны борчый калды. Аны аларның маневры сәерсендерде. Иң арттагы машина юл читенә төшү белән, алдагысы шундук туктады. Колонна янәшәсендә бик күп кешеләр пәйда булды. Ыгы-зыгыланмадылар, буталышмадылар. Хәрәкәтләре төгәл, бер үк төрле. Кешеләре дә бер үк төрле иде. Күзгә ерак булса да, Чаныш аларның солдатлар икәнен аңлады. Моны белгәч, картның кызыксынуы кимеде. «Ә-ә, сугыш уены уйныйлардыр, күрәсең», — диде ул үз-үзенә. Ул атын каулады, тик күзәтүен дәвам итте. Солдатлар машиналар янәшәсендә, йөзләре белән елгага карап тезелделәр, аннары, кыл урталай бүленеп, капма-каршы якка киттеләр. Арттагы солдатлар, йөз — йөз илле метрлар үткәч, туктый һәм туктаган урыннарында кала бардылар. «Кырны әйләндереп алалар бугай», — дип уйлады карт. Шунда колонна уртасыннан бәләкәй һәм елгыр машина килеп чыкты да күзлек буенча елгага таба элдерде. Ә анда, елга ярында, нәкъ юл буендагы машиналар төсле үк өч машина тора иде. Аларын Чаныш иртән, умарталыкка барышлый ук күргән, Кадрәккә дә күрсәткән иде. Һаман да шул җене сеймәгән нефтьчеләргә санап инде. Хәерлегә каршы, бу юлы ялгышкан икән. Бактың исә, хәрби уен. «Ярый, кирәк икән, уйнасыннар. Бу да эш», — дип тынычланды ул. Күзлекне таптауларын гына ошатмады. Түземсезләнеп дилбегәне какты: «Әйдә, малкай, ушәнләнмә әле!» Ат юыртып китте: тояклары җиргә авыр ята, сырты талгын гына чайкала. Арткы сул көпчәк какшаган,

аның эзе кыйгач-мыйгач булып калды.

Бүген юл озын тоелды. Картның моңарчы алай ашыгып йөргәне юк-югын. Ул ашыктырган һәр нәрсә артта калган инде, хәзер алар үзләре аның артыннан кусыннар. Әнә, ялгыз агачлар, юлның борылмалары, юл читендә онытылыпмы, кемдер ташлапмы калдырган тимер тырма, басулар арасындагы ызан, былтыргы салам эскертләре, телеграмм баганалары — һәммәсе аның каршысына таба килми, ә зур бер әйләнеш буенча аның тирәли хәрәкәтләнә кебек. Ул караш кына иңләрдәй киңлекнең кыл уртасында барды да барды, әле иңкүлеккә төште, әле үргә күтәрелде. Бөтен җир аны, арбаны, атны кояш астына элеп куелган бишектә тирбәтә сыман.

Чаныш уй уйламады. Күчәрдәге алкалар чыңлавын, үрәчә шыгырдавын, чикерткәләр зыңын, тургай сайравын тыңлады.

Олы юлда тузан заты юк иде. Ә Чаныш юл тузанында, яр комында, буразна туфрагында, чыклы үләндә үз эзен калдырып йөрергә яратып яшәде. Кешеләр эз калган җирдән барырга күнеккән. Белмиләр диярсең: башкалар эзеннән барганда һични тапмыйсың. Чөнки эзләмисең. Чаныш юл тузанында үткән еллар мәгънәсен, яр комында мәңгелек хәрәкәт бәрәкәтен, буразна туфрагында җан азыгын, чыклы үләннәр арасында меңнәрчә кояш таба иде.

Ә бүген Чаныш үзе күкләр астындагы, олы юл өстендәге тузан булып кына калган шикелле иде.

## VIII

Кабер эченә юл, ниһаять, ачылып бетте. Чокылган тишеккә сыгылмалы гәүдәле Солтан гына түгел, авыр сөякле һәм итләч тәнле Степан да сыярлык. Кем беренче булып керергә тиеш — бу сорау алдында алар икесе дә тигез иде әле. Алдан кергәне икенчесен дә ияртәчәк. Ниятләрен үтәмәстән чигенергә кызыксыну ирек бирмәде. Алар акыл һәм акылсызлык, ярамаган эш һәм яманлыкны сайлап алу каршында калдылар. Тып-тын диярлек иде. Аркалары кояш җылысын да сизмәс булды. Аларга тишектән үзләре сайлап алган чарасызлык салкынлыгы бәреп тора иде сыман. Хәзергә аларны саклык кирәклеге, шикләнү генә тотып торды. Бу тойгылары әкренләп сизгерлеген югалтты, аларны битарафлык һәм гамьсезлек җиңде.

Ком-ташларны кыштырдатып, дәшмичә генә Степан кузгалды. Солтан зур гаеп сизеп, хәтта җирәнеп, курку һәм борчылу белән кызыл кирпеч тузанына баткан, тирләгән дустының аяк табаннарын ялтыратып тишек караңгылыгына кереп киткәнен карап калды. Эчтән аның:

— Монда полковничек, монда! — дигән тавышы ишетелде.

Солтанның йөрәге кага башлады, тамагын сусау көйдерде. Әмма кешеләрнең үлгәннәр дөньясына кагылмаска кушкан мәңгелек тыюын читкә тибәреп һәм санга сукмыйча:

— Китсәнә! — дип җавап бирде.

— Әйе! Караңгыда күрмәгәнбез — монда табут та бар икән!

Солтан алга атлады да башын киртләчле тишеккә тыкты, йөзен кар сарган бәке суына тидердемени! Беренче тапкыр монда карап та, икенче тапкыр карамаска тиеш булган нәрсәләр артка чикте, ул Степанның күз карашы белән очрашты. Әнә, башын ия төшеп, иңе белән башка дөньяны терәтеп баскан. Солтанга ул сәер, бирердәге барлык үлеләрдән дә үлерәктер сыман тоелды. Әйтерсең лә Степан яңа гына каршысында яткан кара табуттан чыккан да, табут капкачы аның артыннан шапылдап ябылган...

— Нәкъ әби сөйләгәнчә! — диде Степан. — Шул табут бу, шул...

Ә монда бераү кергән инде. Башымны кисәргә бирәм — кергән.

— Каян беләсең? «Мин монда булдым» дип, язып калдырганмы әллә?

— Ә бу чибәркәй үзе кереп ятмаган ич инде! — диде Степан, таш идәндәге баш сөягенә ияген кагып. — Аны полковниктан соң иңдергәннәр. Бер вакытта күмсәләр, монысының да табуты булыр иде... — Шунда ул тавышын көчәйтеп: — Господин полковник! Сержант Степан Масленников без вашего вызова прибыл! По твоей душе соскучился, с-сука... Тор! Каршы ал! — дип кычкырды.

Солтанның хәтерендә китапка язылган сүзләр кыймылдашты да, мәгънәсенә карап, үз урыннарына тезелештеләр: «Мин Сингапур сазлыкларында маляриядән үлеп калдым...» «Ул, чыннан да, теге дөньяда булган, ләкин ялгызлыкны күтәрә алмыйча, кире әйләнеп кайткан иде. Ул полковник Хосе Аркадио Буэндия янына әйләнеп кайтты, чөнки Мелькиадесның җаны тере кешеләрне сагынган иде...»[1]

«Ә Степанның җаны үлеләрне сагынган, күрәсең...» — дип уйлады егет.

Ул чигенде, күзен йомып кояшка карады. Күзеннән кабер караңгылыгын кысып чыгарасы килде кебек. Аермачык итеп, үзенең кабергә мүкәләп кереп киткәнен күз алдына китерде. Шундук артыннан кемдер тишекне томалый да башлады сыман. Кирпечләре яңа, измәсе иң нык цементтан. Соңгы кирпеч кояшны каплар алдыннан, аңа, гүя, бер шешә сөт белән бер телем ипи сузарга өлгерделәр. Менә стенага соңгы таш салынды. Ә каберне караңгылык басмады: аны, неон лампасы кебек, сөтле шешә яктыртып тора, имеш. Ул салкын шешәне җылы күкрәгенә кысты. Салкын стаканга кайнар су салгандагы шикелле, шешә чатнап китте, һәм Солтанның тәне буенча суык сөт акты. Тик сөт нигәдер кан төсендә — кып-кызыл иде.

— Мыштырдама инде, кер, — дип кычкырды Степан, тик үзе тышка сузылды һәм: — Ә юк, керми тор, — дип, тишектән җиргә төште.

— Котың ботыңа җиттеме? Шулай, йөрмә тере килеш каберләрдә. Өлгерерсең әле.

— Шүрләп чыкмадым мин. Чукынып китим, ул табут пианино кадәр бар. Вәгъдә — иман. Полковникка барыбер егерменче гасырның соңгы чиреген күрсәтми калмыйм.

Степан шулай сөйли-сөйли тишекне зурайтты. Бер-бер артлы эчкә керделәр. Бер мәлгә караңгылык сукырайткан Солтан склепның кирпеч белән түшәлгән идәненә аяк басты. Кызыксынып, тиз-тиз каранды. Һич тә кабердә кебек түгел болай. Тишек турысындагы кирпеч ватыкларын исәпкә алмаганда, монда чиста. Нинди дер гадәти подвалга кергән ише генә. Солтанның гүргә мәет иңдергәне бар: анда, баш өсте ачык торса да, күпкә шомлырак була иде.

Уртада басып торырлык. Гөмбәзгә баш тимәс өчен бераз иелергә генә кирәк. Әңгер-меңгердә түшәм белән стеналар ачык күренми, тишектән бәреп торган яктылык комачаулый. Әкренләп күз ияләште. Идәндәге кием-салым калдыклары астында беленеп яткан сөякләр аша атлап, табут янына бастылар. Ул, дөрестән дә, кара пианиноны хәтерләтә, өстенә юка тузан әлпәсе кунган, уртасы буйдан-буйга күп урыннан череп, асылынып төшкән кара хәтфә белән каймаланган, капкачына бакыр тәре беркетелгән; почмаклары саен җиз бизәкләр. Табут зиннәтле, хәтта матур һәм игътибарны җәлеп итәрлек.

Солтан үзләрен читтән күзәткәндәй булды. Суйган да каплаган Мөнкир белән Нөнкир.[2] Бил тиңентен шәрәләр, тазалар, гайрәтлеләр. Аркаларында фәрештә канатлары гына юк.

---

[1] Габриэль Гарсиа Маркесның «Ялгызлык» дигән романыннан.

[2] «Теге» дөньяга килгән мәрхүмнәрнең гөнаһларын үлчәүче хөкемдар фәрештәләр (Коръән).

Әмма ният һәм шөгыльләренең башыннан ук яхшылык кылу хисе аларга хыянәт итте. Полковникның үткәне аларга әшәкелеге, явызлыгы ягыннан гына билгеле. Алар хәзер тереләр һәм үлеләр дөньясы очрашуы тыелган чикне атлап чыгып, үзләрен зур гөнаһка — бар кешелек законнарында вәхшилек дип аталган, ә гади генә итеп әйткәндә, явызлыкка дучар итүләрен уйламадылар...

Табутны баш-баштан күтәреп карадылар. Ул авыр иде. Аңламыйча, бер-берсенә караштылар. Черегән сөякләр һәм кипкән табут болай авыр булырга тиеш түгел бит! Әле генә төшереп куйганнармыни! Таш тутырмаганнардыр лабаса?

Гаҗәп: икесе дә бер төсле уйлаганнар икән. Сүз куешкандай, яктылык төшкән яктан капкачы белән яткычы арасын тикшерделәр. Какканнан соң кузгатылмаган, тыгыз беркетелгән иде.

— С богом! — диде Степан һәм табутны баш ягыннан күтәреп, тишеккә каршы бора башлады.

Солтан аяк башына тотынды. Борылырга ара җитәме-юкмы икәнен уйламаганнар иде. Табутның аяк башын почмакка этеп терәгәч, баш ягын күтәрә төшкәч кенә тишеккә туры китерделәр.

— Син чык,— диде Степан,— ә мин күтәрермен. Син кабул итәрсең, мин арттан этәрмен.

Тишеккә иелгәч, Солтан, озак авырудан соң һавага чыккан һәм үзенең көчсезлегеннән, шәүлә булып күренүеннән оялган кеше шикелле, әллә нишләп китте. Кеше авырып ятамы, үләме — дөнья бөтен, тулы кала. Үзгәрми. Шуның шикелле, Солтан үзенең а н д а — тышкы дөньяда бөтенләй хәҗәт булмавы ихтималын уйлап алды. Куркып, ул үзе басып торган кабер дөньясының һәм тышкы дөньяның бер генә мизгелгә аерып булмастай рәвештә кушылуларын, шәүлә генә төсле булып күренүләрен аңлады. Димәк, ул үзе дә шәүлә генә. Бу минутта аның хакында уйлаган кеше алдында да ул ш ә ү л ә генә булып чагыла түгелме соң? Ул яшәде, яши, ләкин бу шул ук вакытта бәлки кемнеңдер төшенә керүгә генә тиңдер?

Якты ярда кара күмер белән каймаланган учак сүнәр-сүнмәс калтырана; таш өстендә ике стакан, бер учма яшел суган кыягы, көрән ипи; бөтен буе белән җирне кочаклап, агач тәре ята; ара-тирә челтәр савыттагы балыклар кузгалышып куя... Елганың акканы сизелми диярлек. Фәкать ялгыз сары күбәләк кунган бер ботакның хәрәкәте генә суның акканын белгертә.

Солтан: «Минем тишектән карап торуым тыштан ничек күренә икән?» — дип уйлады. Гүя ахырзаман җиткән дә, әллә кайчан үлгән вакытыннан уянып, кабереннән кубып чыгышы!

Ул тыйнка чыкты. Табут очын көч-хәл белән тишеккә күтәрделәр. Баш ягын төшерергә бау кирәк булды, ул аны көймәдән алып килеп, эчкә сузды.

— Төшердек! — дип боерды Степан.

— Кушсалар, һич маташмас идек, ә? — диде Солтан һәм тезләре калтыравын басар өчен, табутка утырды.

Кара табут үзе дә кабер караңгылыгыннан арынып һәм вакыт авырлыгыннан алҗып, хәл ала кебек иде. Ул, чыннан да, кешеләрне куркыта торган мәетләр дөньясының кара бер кисәге иде.

— Юынасы иде, — диде Солтан һәм таркау гына кыяфәттә елгага таба атлады.

Степан да юынды.

Эндәшмәделәр.

Аннары читкә өргәләп һәм ухылдап, әзрәк аракы эчтеләр, кабымлык каптылар, тәмәке тартып алдылар.

Шуннан соң Степан, сак кыланырга тырышып, табутның капкачын каерды. Аны ниндидер куркыныч нәрсә янавы ихтималыннан шикләнгән һәм, кирәк калса, качып өлгерергә әзерләнгән шикелле,

икәүләп ачтылар. Икесе дә бер-берсенең карашлары белән очрашырга теләмәү, табут эчендә ачылачак өшеткеч күренешне карарга чиркану хисе кичерделәр.

Ә кара капкач астында тагын бер тоныкы капкач күренде. Анысы калай. Уртасы сыгылган, йөзендә батынкы эзләр бар. Ул кара кургаш булып чыкты.

— У-у, мамонт калдыгы! — диде Степан тамак төбе белән. — Төренгән дә соң! Дүрт кат броня астына качкан — җир, кирпеч склеп, агач табут һәм кургаш астына!

Ул кургаш капкачны буйдан-буйга балта белән кайтарып чыкты.

— Леопольд, выходи! Выходи, подлый трус![1] — диде ул кургаш капкачка суккалап.

Ялган көр тавыш белән Солтан кыланып җавап бирде:

— Ребята, давайте жить дружно...

Степан кургаш капкачны ачып җибәрде. Икесе дә телсез-өнсез карап каттылар. Кызыл җәймәдә хәрби киемнән мәет ята иде. Кичә генә табутка салынган һәм күмелгән диярсең! Гүя хатынымы, адъютантымы кофе хәстәрләгән арада бер генә минутка диванга ятып торган җиреннән, үзе дә сизмичә, тирән йокыга чумган, ләкин телефон зуммеры чыңлауга ук сикереп торырдай уяу калган!

Аны ялгыш уятудан курыккан шикелле, Солтан артка чигенде. Әйтерсең лә ул аның янына искәрмәстән килеп кергән дә, йоклаганын күреп, өстәвенә керфекләренең чак кына кагуын шәйләп, вакытсыз борчуына уңайсызланган.

Степан кургаш капкач белән мәшгуль иде әле. Ул иелгән җиреннән башын янтайтып Солтанга, аның агарып калган йөзенә, аннары табутка карады, шаккатып, ямьсез сүгенеп куйды.

Икесе дә тораташтай аңсыз, җансыз кебек иде.

М ә е т т е р е шикелле иде! Ниндидер кодрәт белән торып утырыр сыман. Аның борын очына ак күбәләк килеп кунды. Мәет кытыклауга түзмәс, тирән сулыш алып һәм борын яфракларын киереп төчкерер дә уңайсызланып елмаер, авыз-борынын угалап: «Прошу прощения, господа!» — дияр.

Аптырудан, сәерсенүдән айнып җитмәгән Степан әлеге күбәләкне куды:

— Көш-көш! — диде ул коры тавыш белән. Тегенең тыныч йокысын сакларга куелганмыни.

Суга төшкән тимер акчаның төпкә тонуы кебек, күбәләк кыек-мыек очып китте.

Мәет рухның үлем алдындагы өстенлеген тәкәббер һәм мыскыллы рәвештә раслаган сыман, үзенең үлгәннән соң да т е р е калганлыгын белеп ята иде шикелле. Балавыздай саргылт чыраена коңгырт таплар чыккан, чәче кап-кара, маңгае киң, нык ияге аның кайчандыр көчле ихтыярлы булганын белгертә. Тузан бөртеге дә кунмаган яшькелт кителе, көмеш погоннары, аеруча күкрәгендәге дүрт Георгий тәресе мәеткә карата хөрмәт, олылау, аяу таләп итә иде кебек. Бу таләп аннан кычкырып тормаса да, полковник белән егетләр арасында ниндидер дәрәҗәдә буйсыну кирәклеге сорала сыман. Буйсынасыңмы, юкмы, — бу мәетнең ымына, ишарәсенә, с ү з е н ә бәйле кебек иде!

Чынлык хисеннән мәхрүм калып һәм үз куркуларыннан оялып, дуслар ачык табут алдында тәмам югалып басып тордылар. Алар үзләренең җиңеп булмастай курку тамашачылары һәм үзләре үк китереп чыгарган тамашаның катнашучылары икәнлекләрен тойдылар. Фикер йөртүләренә караганда җитезрәк булган хәтер тойгысы белән алар үлем һәм т е г е дөньядан әйләнеп кайту ихтималына ышана калдылар. Күрәсең, кешене әйләнеп торган су чоңгылы шикелле суы-

[1] Мультфильмнан.

рып алучы ниндидер бер үзәк бар һәм анда үткәннәрдә ни булганның, ни буласының һәммәсе аермачык күренеп торадыр.

Шул ук вакытта үлеләр дөньясының мәңгелек икәнен Солтан белән Степан гына тойдымы соң? Нәкъ шушы мизгелдә полковник тереләр дөньясының фанилыгын тоеп кына түгел, бәлки белеп үк ятадыр? Кояш җылысы белән өретелгән һаваны, сүнеп яткан учак, кошлар сайравы, аяк астындагы ком-ташлар, елганың болганчык суы, чәчәкләр исен бер үк дәрәҗәдә тереләр генә түгел, бәлки үлеләр дә тоядыр? Гәрчә полковник Кулунчаковның гәүдәсе чынбарлыкны, тормыш мәгънәсен аңлатучы төшенчәләр ярдәмендә кабул итә алмаса да, Солтан белән Степан аның хакында үзләренә хас булган бөтен хис-кичерешләре ярдәмендә уйладылар бит. Шулай булгач, аның рухы моны сизеп тормый микән соң һәм яшәвен дәвам иткән кебек түгелме икән?

Әлбәттә, һәркайсы үзалдына тойган бу кичерешләр аларның аңында төгәл бер фикер рәвешен алып өлгермәде. Алар кичергән нәрсә бер мизгеллек кенә иде. Тоташ фикергә төйнәлгән сүзләрнең мәгънәсенә төшенер өчен аларга мең ел да җитмәс иде шикелле. Чөнки егетләр белән полковник Кулунчаков гәүдәсе арасында — җитмеш еллык вакыт белән чикләнгән я ш ә ү б е л ә н ү л е м. Суык — җылыта, кара — агарта, караңгылык яктырта алмаган кебек, яшәү белән үлем арасын теләк иисә фикер ярдәмендә генә үтү мөмкин түгел. Чөнки вакыт черүе тимәгән һәм караңгылыктан куптарып чыгарылган мәет үткән белән киләчәк, яшәү белән үлем арасын челпәрәмә китереп ватты. Әгәр дә полковник ниндидер могҗиза кодрәте белән җанланып, табутыннан җиргә чыгып басса һәм, күкрәгендәге тәреләрне чыңлата-чыңлата, үзалдына уйланып иисә ниндидер көй сызгыра-сызгыра елга яры буенча китеп барса, Солтан да, Степан да ул җимергән дөньяны төзәтерлек, ул бутаган вакытны тигез агышына кайтарырлык сүз таба алмаслар, киресенчә, телдән язарлар иде шикелле.

Һәм Степан кылган гамәленә һич тә үкенмәгәнен белгертәсе, куркыныч күренештән арынасы килгәнне сиздереп, телгә килде:

— Үлгән кебек йоклый, — диде ул.

Солтан аны:

— Юк, т е р е кебек уяу, — дип төзәтте.

— Тереләр белән үлеләр белгече шушы полковник инде! Күпме кешене теге дөньяга озаткан да, исән калдылармы икән дип, алар артыннан инспекция ясарга киткән. Әбинең сөйләгәне искә төште: нәкъ февраль революциясе көнне ул сигез большевикны аттырган. Шуларның берсе беләсеңме кем булган? Моның утарында управляющий булып торган бер татарның малае!

— Соң ул татар минем дәү бабайның атасы ич инде! Чаныш бабайның атасы! Бу полковник минем бабайны аттырган булып чыга түгелме соң?! Моны миңа әти дә сөйләгән иде...

Степан кычкырып көлеп җибәрде. Башта тыелып, ялгыш кытыкланган шикелле генә, аннары бөтен яр буен яңгыратып. Чырае салкында кабарынган кызылтүштәй кызарынып бүртенде. Үзе көлә, ә йөзе хәрәкәтсез, җансыз, тиресе киерелеп тартылган, ә зәп-зәңгәр күзе ачу чәчә. Көлүе күбрәк мыскыллауга тартым. Гүя ул полковникның тере кебек ятуына шулай мыскылланган, хурланган.

— Ну, яшьти! — диде ул. — Бәхетле кеше син!

— Бәхетле? Нәрсәне әйтәсең?

— Соң хәзер Чаныш картны чакырабыз. Кадрәк бабайны да. Күрсеннәр! Мин йөрткән БМПга гранатометтан аткан дошманны каршыма куйсыннар иде әле! Хет тере, хет үле килеш...

— Нигә син минем бабайны үлмәс борын кабергә кертмәкче буласың әле?

— Полковниктан куркып, йөрәкләре ярылыр дисеңмени?

— Полковниктан түгел. Синең белән миннән куркып, туган.

— Бездән?

— Бездән. Тик торганда кабер актарган кешеләр мәетләргә караганда да куркынычрак түгелмени, Степан?!

Степан дәшмәде. Йөзе сагайды. Инде ул көлми, очкылык тоткандагы сыман сулкылдап кына ала. Шуны басарга теләгәндәй, ташка утырды, калтыранган кулы белән аракы салып эчте, тагын Солтанга сузды:

— Эч.

Солтан кире какты. Саруы кайный иде. Эчсә, укшыр сыман.

— Соңыннан... — диде ул.

Степан ярсып урыныннан купты.

— Кайчан ул соңыннан, кайчан?! Шушының кебек, мәңгелеккә командировкага киткәчме? Ярый, үзеңә кара. Миңа бу полковник та җиткән. Шулаймы, полковник? — дигәч, ул стаканны мәеткә тоттырырга теләп, кителенең җиңеннән тарткан иде, материя ертылып китте. Аның кулы тәненә ябышкан иде, кымшанмады да. Степанның биреш әсе килмәде. Нидер чамалап торды. Ул үлгәннәргә мәрхәмәтсез, вөҗдан газабыннан ваз кичкән кебек иде. Бөтен кыяфәте киеренке, бөкре кешенеке шикелле. Һичнинди өн-тавыш ишетмәс диярсең. Фәкать эчке тавышына гына колак салган, шуңа гына буйсына.

Менә ул агач тәрене сөйрәп китерде, ярга сөяп куйды. Көтелмәгән кунак килеп төшкәч югалып калган, ләкин моны сиздерергә теләмәгән хуҗа сыман, ниш ләргә кирәген онытты, кабаланды, ашыкты.

— Булыш әле, — диде ул Солтанга.

— Нишлибез? — дип сорады Солтан ризасыз рәвештә.

— Каретасыннан чыгарып бастырыйк әле. Аннары күз күрер.

Алар башлаган эшләрен дәвам иттеләр. Чигенә алмыйлар иде инде. Әйтерсең лә кемдер аларга яманлык эшләргә боерган да, шуны кыләчәктә яхшылык дип язарга вәгъдә биргән.

Мәетне табутыннан торгызып, тәрегә сөяделәр. Полковник Кулунчаковның күзе йомык, кулын күкрәгенә кушырган. Ул нидер ялварган яисә ни өчендер кичерү сораган кебек. Бер адым алга атлар да тезенә чүгәләр сыман. Аны Степан шундый итеп күрде.

Ә Солтанга ул башкача тәэсир итте. Полковникның кыяфәте авыр яраланган, ләкин бирешмәгән, аягында баскан килеш үләр өчен соңгы тапкыр алга омтылган солдатны хәтерләтте. Күтәреп аягына бастырганда кайбер урыннарда ертылган кителе бу охшашлыкны тагын да көчәйтә иде. Уң чигәсендә чак күренерлек яра эзе...

— О-о!.. Калай әтәч! — диде Степан туры аңа карап.

— Нигә алай дисең?

— Хәзер менә шулай аттырган большевиклар алдында торса иде ул. Курыккан. Чигәсенә бер пуля — һәм мәңгелек тынычлык алган. Тик осечка, парин!

— Осечка?

— Осечка шул. Теге чакта большевиклар хөкеменнән котылган, тик дөньяга без киләсене исәпкә алмаган.

Аракы шешәсе алып килеп, Степан мәетнең кушырылган кулына кыстырды. Ул гына түгел, бармакларын каерып, учына стакан тыкты да аңа аракы салды, үзе дә стаканын күтәрде.

— Честь имею, полковник! — диде ул. — Синең исәнлегең шәрәфенә! — һәм аның стаканы белән чәкештереп, эчеп җибәрмәкче иде дә, тынлып калды, эчемлекне, селтәнеп, мәетнең йөзенә сипте.

Солтанның каны боз булып туңды диярсең. Аңа кинәт үзләренә кемдер карап тора кебек тоелды. Ул артка, ян-якка борылып каранды. Яр буенда алар икесе генә. Үр дә буш. Шулай да ул үзенә бораулап төбәлгән караштан арына алмады. Алда — чиркәү, зират, артта — елга. Ә җаны чит караш белән тулган, борчулы. Каядыр йөгереп

китәсе, качасы килде. Сулуы капканчы. Үргә, иң биек төшкә, кояшка якынрак җиргә. Тик аякларын җирдән аера алмас шикелле. Алда шулай ук Галәмдәге кара тишек сыман каралып торган склеп ярасы. Артта елга, әмма аргы яры йөзеп чыгалмастай ерак. Каршысында — полковник Кулунчаков. Тозакка капканмыни!

Кинәт ул:

— Степан! — дип кычкырды.— Карале!

Җитмеш елның теге ягыннан аларга төбәп, полковник Кулунчаков карап тора иде!

## IX

...Шәһәрчек ике тапкыр немецлар кулында калды. Кан коюлы алыштан соң менә тагын — икенче тапкыр — русларга күчте.

Төштән соң шәһәр өстеннән немец аэропланы очып үтә. Рус позицияләре аша узганда аңа барлык кораллардан — башлыча, винтовкалардан һәм туплардан шрапнель белән тәртипсез рәвештә дә, залп белән дә ут ачалар, ә шәһәр турысында ул, үз биләмәсендәге бөркет шикелле, иркенлектә, биектә оча. Кайчагында гына урамнардан, мәйданнан ачулары килгән офицерлар да, солдатлар да шәхси коралларыннан түзмичә атканда ул читкә янтая, ә бераздан түбәнәеп әйләнеп кайта. Очучы, үлем белән шаяргандай, башын чыгарып аска карый-карый, кешеләр күбрәк укмашкан урынга бер-ике бомба ташлап китә, туп сөйрәп барган атларга, биналарга зыян сала. Ә кешеләр, бомба төшеп җиткәнче, кайсы-кая чәчелергә посарга өлгерә. Фәкать шәһәрчеккә рус гаскәрләре кергән көчне генә немец очучысы бомба ташлап, яралылар белән тулы бөркәүле, ике тәгәрмәчле санитар арбасын туздырып ыргытты. Армиядә аңа каршы чыгарлык самолет юк иде, ә җирдән яңгыр булып очкан пулялар, шрапнель ярчыклары немец очучысына тими. Әйтерсең лә ул үзе дә, аэропланы да имләнгән. Өченче көн инде шәһәр өстендәге аяз, кояшлы күккә шул немец хуҗа. Аңа алдагы көннәрдәгечә җан ачуы белән карамыйча, игътибар да итми башладылар бугай инде.

Полковник Кулунчаковның эш бүлмәсе калкулыкка урнашкан төрмәнең өченче катында — комендатура бинасының шәһәрчеккә караган почмак ягында. Ул аэропланны бүлмә уртасына басып, аяк очыннан үкчәсенә чайкала-чайкала карап торды. Паркетка кушылып, хром итеге дә шыгырдады, авыр уйлары аңа моны ишетергә ирек бирмәде.

Ул күптән түгел генә армиянең хәрби кыр суды утырышыннан кайтып керде. Адъютанты аңа кайнар кофе ясап керткән иде, әмма ул аңа орынмады. Почмактагы карел каенынnan эшләнгән шкафта коньяк та бар барын. Ул, капитан чыгып киткәч, кофе чынаягын читкәрәк этәреп, шунда юнәлгән иде дә, тәрәзәдән аэропланны абайлап, шулай бүлмә уртасында басып калды һәм ирексездән суд утырышы турында уйланды.

Суд озак бармады — ярты сәгать чамасы. Сигез большевикны хөкем иттеләр. Катгый карар чыгарылды — һәркайсына үлем җәзасы. Ул дезертирлык, талау, шпионлык, үз-үзләренә атып зыян салган өчен чыгарылган күп санлы хөкемнәрдән бер ягы белән дә аерылмады. Россиянең бөтенлеге һәм бүленмәслеге хакына калкан белән кылыч хөкеме карарларын, намусына көч китермичә, полковникның байтак раслаганы бар. Бүген дә ышанычы какшамады. Ни хәл итәсең: сугыш вакыты законнары кырыс. Хаклык монополиясе аның кулында. Кулында гына түгел, йөрәгендә дә. Дәүләт һичкайчан булмаганча нык.ы тәртипкә мохтаҗ. Ул тәртип аның — полковникның көчле, каты йодрыгына да бәйле. Идея бөтенлеге таркалган заманда бигрәк тә. Дилбе-

гәне бушатырга ярамый. Һәрнәрсәгә курку авызлыгы кидерелергә тиеш. Өстә камчы уйнасын. Тиешсезне уйладыңмы — мә; кылганың яманмы — ал; кыйблаң янтайдымы — законга үпкәләмә. Кешенең табигате бер генә: аңа һаман нидер җитми, ләкин ул куркак та. Хәер, бүген хөкем ителгәннәр башка токымнан. Алар шәхсән үзләренә һични теләмиләр, әмма дөньяга нәрсә җитмәгәнен һәм ни кирәклеген аермачык беләбез дип саныйлар. Полковник алар хакыйкатенең асылын төптән күрә. Моңарчы да аерым кешеләр патшаларга каршы гына түгел, аллаларга да каршы чыккан. Ә болары андыйларны да уздырмакчы. Алар а ң л а г а н н а р һәм җиңәселәренә ышаналар. Полковник бүген ул ышанычның монархия өчен генә түгел, ә үзе өчен дә яшәү яки үлемгә тиң икәнлеген белеп эш итте. Шуңа күрә хөкемнең бердәнбер карарын чыгару авыр һәм озак булмады. Ул сигезнең өчесе күкрәкләренә Георгий тәреләре таккан. Да черт с ними! Хөкем белән алардан да мәхрүм ителделәр. Алар ихтыярларында булса һәм алар теләгәнчә килеп чыкса, — ходай сакласын! — полковник та үз тәреләреннән колак кагачак! Ә алар аның күкрәгендә — дүртәү. Аңа, полковник Кулунчаковка, вакытыннан алда соңгы — агач тәре астына кереп ятарга туры килмәгәе.

Ә боларның аллалары да, муллалары да юк. Бактың исә, үзләрен хаклык корбаннары дип уйлыйлардыр, үлемсезлеккә ышаналардыр әле. Юк инде! Аларны шәһәр читендәге таш карьерына алып чыгып атачаклар. Каберләрен дә табарлык булмас.

Шулай да полковникны үз фикерләренең бөтенлеген нииндидер икеләнү, шикләнү хисе кимерә башлавы тынгысызлый иде. Бу нәрсә аны кофе белән коньяк арасында гына туктатып калмады. Ул нәрсә үзенең эш бүлмәсе уртасында болганып, адашып йөрергә дучар итте. Кайчандыр берәү Голгофага менеп, үзен хакыйкать корбаны иткән. Һәм, яңадан туачакмын да хөкем итәчәкмен, дигән. Ул — ялгыз, ә хөкемен ярты дөнья күтә. Б о л а р исә бүген дә с и г е з, тик хәкемгә каршы хөкем белән янамыйлар. Шулай да алар үзләрен бөтен дөнья пролетариаты ишетәчәгенә һәм үзләренә иярәчәгенә ышаналар. Нинди тәкәбберлек!

Голгофага менгәне катгый кисәткән: «Мне отмщение и аз воздам».[1]

Б о л а р ы янамый, ә т е г е с е кисәткән...

Үз җанын икеләндергән сәбәпнең нәкъ шушы икәнен ачык сизсә дә, аңы белән шуны кире кага алмавын тою полковникны тинтерәтә, борчый, җавап эзләп, бүлмә буенча арлы-бирле йөренергә мәҗбүр итә. Аның бу борчуга төкерәсе дә килә: эш күп. Вак-төяге дә, зурысы да.

Тукта!

Полковник үз күңелендә аермачык тавыш ишеткәндәй булды һәм кадаклангандай туктап калды. Эш! Бөтен хикмәт — эштә. Б о л а р да, Христос та үзләрен эш һәм хакыйкать белән яратырга өнди, ә сүз яисә тел белән түгел. Аерма фәкать шунда һәм — зур аерма: Голгофага менгәне ү з е н яратырга куша, ә б о л а р ы — үзләренең ышанычларын. Беренчесе үзеңнең якыныңны ярат дигән, ә болары — үз-үзеңне, үзеңнең кешелегеңне ярат, хөрмәт ит диләр. Беренчесе синe үзенең колы итәргә теләгән, ә болары кешегә азатлык дәгъвалый.

Полковникны коточкыч моңсулык биләп алды. Аның кемнедер чакырып кертәсе, сөйләшәсе килеп китте.

«Әллә барысын да шайтаныма олактырып, Мария янына китеп барыргамы? — дип уйлады ул. Мария — аның никахсыз хатыны, сердәшчесе, киңәшчесе.

---

[1] Миңа үч вә мин дә алырмын (Библия).

Капитанны чакырып сөйләшсенме соң әллә? Мәгънәсе юк. Эт тугрылыгы белән хезмәт иткән солдафоннан «Чего изволите?» яки «Так точно!» дан гайре ни көтмәк кирәк?

Армия офицерлары арасында полковникның дуслары байтак. Аны хөрмәт итәләр, аның белән горурланалар да, ахрысы. Ләкин күбрәк шикләнәләр, хәтта куркалар да түгелме соң? Ә курку булган җирдә эчкерсезлекне көтмә инде.

Ул хөкем ителгәннәрнең берәрсен чакыртырга карар кылды. Кемнәр алар? Эчләрендә нинди Иблис ята? Чыннан да, алар, хөкем карарында әйтелгәнчә, немец тарафдары, шпионнары түгел ич инде!

Кулунчаков аларны берәм-берәм күз алдыннан үткәрде...

Большевикларны трибуналга армиянең төрле дивизияләреннән җыеп китерделәр. Алар, дөрестән дә, бер-берсенә охшамаганнар. Төс-битләре, холыклары белән генә аерылып тормыйлар, милләтләре дә төрле: хохол... поляк, яһүд... татар һәм, әлбәттә руслар. Так, кайсысын чакыртырга? Төрлечә булсалар да, полковник аларга рух какшамаслыгы хас икәнен күрде. Исем-фамилияләре дә авырлык белән генә искә төшә, ә менә Наймушин... әйе, Наймушин атлысы полковникның тел очына шундук килде. Яхшы, калганнарын тугачтын христианнарча чукындырганнардыр, ә бу «Казан князе» ничек аларга ияргән соң? Полковник татар халкын яхшы белә: алар җирендә дөньяга килгән, алар белән аралашып үсте, төнге ат саклауларга чыкты. Асылда хөрмәт итәрдәй акыллы, эшчән, тыйнак, чиста халык — гаделлек хакына моны танырга туры килә. Шул ук вакытта аңа мөселманнарның үз диннәренә фанатикларча бирелгәнлеге дә мәгълүм. Бу — аларның үз-үзләрен юкка чыгудан саклау, киләчәкләре турында кайгырту рәвеше булса кирәк. Башка диндәгеләрне кяферләр дисәләр дә, алар белән таныш-белеш булудан, эш йөртүдән тайчанмыйлар, киресенчә, башкаларга түзем белән багу — аларның көнкүрешендәге гадәти күренеш. Полковник ул халыкның тарихын да әйбәт белә: байтак суелганнар, кырылганнар; әйтергә кирәк, язмышлары фаҗигале. Ә бу, кем әле... Ә, әйе, Чаныш Наймушин үзен тыныч, гади һәм батыр тотты. Тик менә аны нәрсә йөртә? Иманы нинди? Җанында ни? Басынкы халыкның бу әһеленә фетнә рухы һәм горурлык каян килгән? Кызык түгелмени?

Кулунчаков адъютантын чакыра торган ак кыңгырауны шалтыратты.

Капитан керде. Аның үкчәсен үкчәсенә бәрүен һәм: «Тыңлыйм!» — диюен көтмәстән, полковник:

— Чаныш Наймушинны чакыртыгыз, — диде.

— Тыңлыйм, вашесокородие!

— Аннан чәй кертерсез. Икене.

— Яхшы.

Капитан чыгып киткәч, полковник, ниһаять, коньяк уртлап куйды һәм куе кызыл пәрдәле тәрәзә каршысына килеп басты.

Шәһәр йортларының түбәләрен калын кар баскан иде. Бөтен тормыш сугыш хәленә буйсындырылган. Алгы сызык юнәлешенә үзәк урамнан пехота чыгып бара. Тыл ягыннан урап килгән немец аэропланы, һичнинди тоткарлыкка очрамыйча, үз позицияләре тарафына оча.

«Чыпчык урынына бәреп төшерәсе дә бит... Кул кыска!...» — дип гарьләнеп уйлады полковник.

«Мисезләр! Көпә-көндез — марш-бросок! Бәлки генерал Шредерга гаскәрләрнең урнашу тәртибен дә хәбәр итәсегез калгандыр?! — дип, ул, түзмичә, йодрыкларын кысты. — Трибуналга менә кемнәрне бирергә кирәк! Шәһәрдән артка тибеп куып чыгарырлар микәнни?! К чертям собачьим... Эх, чабаталы Россия, чабаталы Россия!.. Сиңа кайчан акыл керер икән?!»

Кораллы сакчы сагы астында арестантны керттеләр.

— Безне калдырыгыз, — диде полковник адъютантына.

Капитан белән сакчы артыннан ишек ябылып, тынлыкта калгач, ул стена буендагы биек артлы, бөгелгән аяклы өч урындык тарафына ишарәләп:

— Утырыгыз, — диде.

Наймушин кузгалмады, эндәшмәде.

Полковник тәрәзә каршында басып торган җиреннән башын гына борып, аны баштанаяк күзеннән кичерде. Арестант яланбаш, погонсыз, хлястигын чишеп алганга бушап калган шинеленең барлык төймәләрен каптырган, аягында тузган, чистартылмаган калын табанлы немец ботинкасы (үтерелгән солдаттан мирас иткән, күрәсең), чолгавы керле, әмма пөхтәләп чорналган. Аннары ул карашын аның йөзенә күчерде. Аның янәшәсендә басып торса, астан өскәрәк карарга туры килер иде: Наймушин озын буйлы, нараттай төз сынлы. Артка таралган куе көрән чәчле, озын керфекле, калынчарак иренле, озынча иякле бу кешенең йөзе тыныч, һичнәрсә белгертми иде. Ул үз иңендә тау күтәреп йөртә аладыр, мөгаен.

«Татарга һич тартым түгел, — дип уйлады полковник, — хәер, хохолны — шаян, грузинны — кунакчыл, яһүдне — карун, татарны — астыртын һәм кысык күзле дип, без бик сай фикерләргә күнеккәнбез».

— Сез татармы, прапорщик? — дип сорады полковник, арестантның үзенә сынап каравын күтәрә алмыйча һәм тизрәк сүз башлауны кирәк санап.

— Прапорщик Наймушин! — дип, битараф кына җавап бирде ул. — Ә болай... мөселман.

«Әйе,— дип исенә төшерде полковник, — алар үзләрен мөселман яки болгар дип атыйлар. Татар дигәнне өнәмиләр, хурлауга саныйлар».

Гәрчә аның кай яктан икәнен «дело»сыннан белсә дә, ул:

— Тумышыгыз белән кайдан? — дип сорады.

— Казан губернасыннан.

— Якташ, видите ли!

— Беләм, — диде прапорщик тагын тыныч тавыш белән. — Сез Казан губернасындагы Благодатное авылыннан. Ялгышмыймдыр ич?

Полковник яңагының тартышып куюын сизде. Гадәттә, бу дулкынланганда яисә ярсыганда кузгала — күп санлы алҗыткыч сорау алулардан калган нәрсә. Яңагының калтыравын яшерергә һәм басарга теләп, коры гына йөткергәләде, кульяулыгы белән авызын, борынын сөрткәләде.

— Большевиклар армиянең югары чин офицерларына досье ачтымыни? — дип сорады ул. — Каян беләсез?

— Без сез уйлаганнан да якынрак якташлар, Арсений Завалишинович.

Полковникның сул кашы дугаланып маңгаена таба күтәрелде, ул арестантка каршы борылды.

— Безнең авыл сезнең утарыгыздан ике генә чакырымда, — дип өстәде Наймушин.

— Минем хакта ишеткәнегез бармыни?

— Минем атам сездә управляющий иде. Хәзер йорт-курагызны карый. Наймуш. Бәлки, хәтерлисездер.

Полковник бу кадәресен һич көтмәгән иде. Ул гаҗәпләнүен яшерергә тырышып:

— Шулаймыни? — димичә булдыра алмады. — Гадәттән тыш кызык, прапорщик! Мине күргәнегез дә булдымы?

— Мактана алмыйм — юк. Әмма сезнең ротмистр чагыгызны яхшы хәтерләп калдым.

— Йә-йә? — диде полковник коры тавыш белән һәм тагын тәрәзәгә борылды, аяк очыннан үкчәсенә авышкалап, беркадәр вакыт

чайкалып торды. — Кайсы еллар инде бу?

— Сез минем атам хакында губернаторга донесение язган еллар.

— Онытканмын. Әйе, онытканмын!

— Кирәк санасагыз, исегезгә төшерә алам: унберенче ел. Атам авылларны хуторларга таратырга чакырып чыккан Столыпин өндәмәсенең чын асылын крестьяннарга аңлатып, төшендереп биргән. Анагыз... гафу итегез, кем әле... әйе, анагыз Марфа Петровна яклап калмаса, ул, тәгаен, катор китәсе булган.

Бусы полковникка бер дә ошамады.

— Ялгыш! — диде ул, Наймушинны кырт бүлдереп һәм нык адымнар белән өстәле кырына барып утырды. — Ялгыш яклаган! Утырыгыз!

Арестант кымшанмады да.

Полковник катгый рәвештә:

— Утырыгыз, прапорщик! — дип кабатлады.

Арестант тыңламады, гәүдә авырлыгын бер аягыннан икенчесенә күчерде.

Полковник кирәгеннән артык озынрак итеп кыңгырау шалтыратты. Ишектә адъютант күренгәч, тавышын күтәреп:

— Чәй, капитан! — дип кычкырды. — Икене. Икене! Көттермәгез!

Адъютант, подноска куеп, ашыкмыйча гына көмеш савытка утыртылган ике стакан чәй кертте.

— Рәхим итегез, — диде полковник, ул чыгып киткәнче иелгән башын күтәрмичә.

— Менә бусыннан баш кагарга җөрьәт итмәс идем, — диде Наймушин һәм, стаканнарның берсен алып, үз урынына чигенде, бер йотып куйгач: —Чын кытай чәе! — диде.

— В ногах правды нет, прапорщик. Утырыгыз.

— Дөреслек күп нәрсәдә юк ул, полковник әфәнде.

Бер кавым эндәшмичә генә чәй эчтеләр. Полковник теләмичәрәк, Наймушин тәмләп эчте. Полковник портсигарын ачып, бармак очы белән өстәл почмагына таба этәрде.

— Рәхмәт, тартырга өйрәнеп булмады.

Папирос кабызып, полковник тирән итеп суырды да, кысылган күзләрен төтен аша арестантка төбәде.

— Менә ни өчен сез безгә каршы күтәрелгәнсез икән, большевик әфәнделәр! — диде. — Государь-императорга каршы димим, безгә каршы, безгә! Әйтик, миңа каршы! Шәхсән сез, прапорщик, — шәхсән миңа каршы. Сез — атагыз өчен үч алырга телисез. Ышандырып әйтә алам: ниятегезгә ирешкән очракта, — әмма юкка тырышасыз, һич тә чынга аша торган нәрсә түгел бу! — әйе, ниятегезгә ирешкән очракта, сезнең бездән бернинди аермагыз булмас. Нәкъ безнең шикеллегә әйләнәсегез шиксез. Власть — авыр йөк, бик авыр йөк.

— Килешәм, полковник: явызлык — авыр йөк. Сез ни кылганыгызны белмисез. Ә без ни эшләргә кирәклеген аңладык. Без кешеләрнең күзләрен яхшылыкка ачарга телибез.

— Дөньяны, кешеләрне үзгәртергә тырышып, юкка азапланмагыз. Сезнең эшләрегез үзегезгә гадел булып тоеладыр, ләкин алар бернинди дә түгел.

— Башкаларны үзгәртергә теләгән кешеләр иң әүвәл үзләре үзгәрә. Сез үзгәрергә теләмисез. Сезнең белән безне шул аера. Бәс, шулай икән, безгә сезнең шикеллегә әйләнү янамый.

«Берни әйтеп булмый — логикасы тимердәй нык, — дип уйлады полковник. — Мондый логика, җиде мең ел җәһәннәм утында кайнатсаң да, ныгый гына барачак. Аны юкка чыгаруның чарасы бер генә — үлем».

Повковник арестантның күзенә туры карап, аның һәр хәрәкәтен

барлап, йөз чалымнарыннан бөркелеп торган ышанычын абайлап тыңлады һәм а л а р н ы бүген үлем җәзасына хөкем итүнең һич тә ялгыш булмавына тагын бер кат инанды. Каршысында һәр сүзгә җавап кайтарырга әзер торган бу арестантның аяк астындагы ышаныч ташын тибеп аударасы, үз кулындагы власть бавында тыпырчынуын күрәсе килде. Әйе, үлем карары дөрес. Үлем, фәкать үлем генә! Ләкин полковникны иртәдән бирле борчыган икеләнү тойгысы тагын уянды. Әнә шул үлемнәре белән дә а л а р үз тарафдарлары санын ишәйтмәсләр микән соң, дип уйлады ул.

— Прапорщик, — диде полковник әле ни ачыкларга теләвенә төшенеп җитмәсә дә, — сез үз фикерегез корбаны булуыгызны аңлыйсызмы? — Үз тәгълиматының тантанасы хакына һич ризасызлык белдермичә Голгофага менгән зат турында баягы уйлануын исенә төшереп, ул, арестантның җавабын көтмәстән, тагын бер сорау бирде: — Сез — мөселман, ихтимал, белмисездер, әмма мин аңлатырга тырышып сорыйм: Иисус Христос та кешеләрнең күзен хакыйкатькә ачарга теләгән. Ә кешеләр ул хакыйкатьне мең ел эзли инде, ләкин тапканнары юк. Әлегә Христостан бер хакыйкать калган — аның тәрегә кадаклануы. Сез үзегезнең дә шундый хакыйкатьтән ары уза алмавыгызны аңлыйсызмы? Минемчә, әлегә аерма юк. Фикеремне аңлата алдыммы?

Наймушин мыек астыннан гына елмаеп куйды.

— Алдыгыз, полковник, алдыгыз. Сез рәхәтләнеп бәхәсләшердәй әңгәмәдәш. (Аның бу сүзләренә полковник та елмайды: «Менә каналья, ә?») Ни диим? Аерма бар, һәм ул шактый зур. Үз тәгълиматының нинди юл белән раслау яхшырак икәне хакында әйтеп тормыйм. Монысы — сыйфат ягы. Аерманың сан ягыннан булганына гына тукталам. Эш шунда: хәзер бер корбан гына җитми. Дөньяны сез кылган явызлыклардан чистартыр өчен хәзер күпләр каны, күп корбаннар кирәк.

Полковник үз күңелендәге икеләнү үлчәвенең тетрәп куюын сизде, үз ягындагы үлчәү тәлинкәсенең басарак төшүен күргәндәй булды. «Күпләр каны, күп корбаннар, — дип кабатлады полковник эченнән. — Димәк, Россия анакайны моңа дучар итмәс өчен ул канның һәм корбаннарның а з р а к кирәк чагын файдаланып калу фарыз. Б о л а р каны, б о л а р корбаны тулысынча аклана. Шулай икән, нинди икеләнү, нинди икеләнү, йа хода?!»

Шулай да баягы икеләнүенең соңгы мыскал юшкынын да күңеленнән кырып атасы, Мария янына үтәлгән бурыч хисе белән ч и с т а кайтасы килә иде. Әйе, ул хаклы, ул моңа ышанды инде. Хакыйкать аның ягында. Әмма ул бер үк хакыйкатьнең төрле төсмердә икәнен дә белә. Аның боегы, шатлыклысы, куркынычы, бөеге була. Полковникка боек һәм куркыныч хакыйкать хаҗәт түгел. Шатлыклысы, бөегенә ни җитә?

Ә мондые өчен ул бүген, менә хәзер, нәрсәдер эшләргә тиеш бугай. Язмыш диген: каршысында бар тормышы белән аның ихтыярына бәйле якташы басып тора. Мариягә сөйләрлек кызык вакыйга. Әгәр болай итсәм...

— Әгәр болай итсәк, прапорщик әфәнде, — диде ул үз уйларын җанландырып һәм «әфәнде» сүзенә кире мәгънә салырга тырышуын яшермичә. Ул төбенәчә янып, инде сүнгән папирос мундштугын кәлләвечкә куйды. — Әйе, әгәр болай итсәк... Без, ни әйтсәгез дә, якташлар. Сугыш вакытын, туган илдән еракта икәнебезне исәпләгәндә, туган диярлек. Килешәсезме? Аеруча Наймуш картның улы икәнегезне истә тоткан хәлдә. Ә ул — Наймуш карт — гонаһысына кермим, яхшы кеше, игелекле зат. Әгәр... иң киме шул карт хакына димме соң... мин сезгә чыгарылган хөкем карарына күпмедер төзәтмә кертсәм, ә?

— Төзәтмә? — дип кайтарып сорады Наймушин.
— Әйе, төзәтмә.
— Сез чыгарган үлем карарына төзәтмәне халык кертер.
Полковник, өстәл кырыена таянып, артка каерылды:
— Тиздәнме?
— Тиздән. Кызганычка каршы, моны миңа... безгә күрү насыйп булмас. Ә сез ул төзәтмәне күрергә өлгерерсез әле.
— Халык дисезме? Алайса — тиздән? Нигә халык, ә мин түгел? Нигә тиздән? Бүген үк мөмкин. Сез моны үзегез үк күрү бәхетен кичерә алыр идегез. — Полковник ашыкмыйча гына яңа папирос алып кабызды. — Шулай итеп, хөкем карарының сезнең язмышыгызга кагылган өлешен... әйтик, штрафбатка озату белән алыштыра алсак? Кан коярга, корбан булырга атлыгып торасыз икән, рәхим итегез. Юлыгызга ак җәймә! Ризамы? — дип, ул канәгать төстә арестантның йөзенә күтәрелеп карады. Прапорщикның киң яңак сөякләре уйнаклап алды. Күзләренә кара очкын йөгерде. Полковникка, ниһаять: «Ә ул барыбер тамгаланган: татар икәнлеге шул яңакларыннан кычкырып тора», — дигән уй килде.
Полковникның мыскыллы елмаюы һәм ул елмаюның ни белдергәне Наймушинның игътибарыннан читтә калмады.

«Бәлки, чыннан да, моны коткару ягын чамаларгадыр? — дип уйлады полковник. — Тик комендант взводы винтовкалары каршысында фикердәшләрең сафына басып үлүнең, штрафбатка эләгеп, газ атакасында тончыгып үлүгә караганда күпкә җиңел икәнен беләсеңме соң син, прапорщик?»
— Сез кыю кеше, полковник, — диде арестант һәм аңа таба ике адым атлады, кулындагы буш стаканын өстәлгә куйды. — Чәегез өчен рәхмәт... Тик сез җан һәм акыл кыюлыгыннан мәхрүм. Сүзегез тәмам икән, мине камерага — иптәшләрем янына илтергә боерыгыз.
— «Иптәшләрем»! — диде полковник үзалдына уйланып әйткәндәй әкрен генә. — Сез бер-берегез белән судта гына таныштыгыз лабаса. Шулар белән үлүне сайлыйсызмыни?
— Сайламыйм. Сайлар ирегем юк. Ә минә алар белән бергә үләргә риза.
— Аның каравы, минем сайлау ирегем бар: хөкем карарын көчендә калдыру яисә үзгәртү иреге.
— Андый ирек сезгә бирелмәгән. Безгә хөкем карарын сез түгел, самодержавие чыгарды. Аны бары тик самодержавиене бетереп кенә үзгәртергә мөмкин. Йә — сез, йә — без.
— Әлегә сез, — диде полковник.
— Әйе, әлегә. Дөп-дөрес сүз — «әлегә». Ә аннары, полковник? Аннары — сез. Әлбәттә, сез! Иртәме-соңмы, җавап бирергә туры килер. Һәммәсе өчен.
— Аннары бит әле ул, аннары! — диде полковник кычкырып. — Аннары! Моңа кадәр яшәү бар. Әзме-күпме — монысы ходай тәгалә кулында, әмма — яшәү.
— Юк, яшәү түгел. Үлем көтү.
— Ярый, ихтыярыгыз, — диде полковник кыңгырау кагып. — Һөнәрем миннән үз эшемне намус белән үтәвемне таләп итә. Намус колы булу — иң югарыгы ирек һәм бәйсезлек ул. Шул нәрсә миңа бүген хорафатлардан иркле һәм шәхси мөнәсәбәтләрдән бәйсез төстә хөкем карары чыгарырга хак бирде.
— «Иркле һәм бәйсез төстә» дисез инде. Кемнән иркле? Кемнән бәйсез? Халык ирегеннән тыш һәм халыкка бәйсез төстәме?
— Үз-үземнән.
— Сез миңа бик җөпләп аңлатырга тырышкан теге Голгофа корбаны бүтәнчә әйткән, полковник: «Не судите и судимы не буде-

те»[1]. Ә сез хөкем иттегез һәм хөкем ителерсез.

— Капитан!

Арестантны алып киттеләр. Полковник тагын тәрәзә каршысына барып басты. Пехота полкы шәһәрдән чыгып беткән һәм, боргаланып, үр буенча шуыша иде инде. Меңнәрчә кеше үз күңелләре тартмаган һәм үз ихтыярлары кире каккан э ш н е э ш л ә р г ә бара. Ике катлы тәрәзә эчкә һичнинди тавыш кертми: ни обозлар кылтыравын, ни артиллерияне тартып барган атларның көчәнеп кешнәвен, ни эскадрон иярләренең язгы боздай тоташ кыштырдавын, ни җәяүле гаскәр таптаган карның үлем җәрәхәте алган яралы кебек ыңгырашуын... Офык белән тоташкан үр сыртына җиткәч, колонна сына башлады, аның башы караңгылыкка чумгандай булды. Анда, үр артында, колоннаны ике юл көтеп тора: аларның берсе — яшәү, икенчесе — үлем.

Колонна, меңнәрчә язмышны үзенә ияртеп, күздән югалды. Ике катлы тәрәзә каршында карлы үрнең ак бушлыгы гына җәелеп калды.

Үзенә билгеләнгән фатирга кайткач, полковник Мария әзерләп куйган ризыкны ашады, тегене-моны сөйләште, әмма сигез большевикка чыгарган үлем карарын раславы һәм хөкем ителгәннәрнең берсе белән әңгәмә үткәрүе турында ләм-мим дәшмәде. Ут сүнгәнче, ул Мариянең чишенгәнен күзәтте, ә ут сүнгәч, аның сулаганын гына тыңлап ятты. Аның сулышыннан арганлыгы сизелә, көне буена алҗып, башка һич нәрсәгә көче калмый. Талчыгу аңа көндезге, чын мәгънәсендә кешелекле бетмәс-төкәнмәс авыр эшләр тавыннан кар шикелле ишелеп төшә. Тереләрнең чиксез газаплары, үлгәннәрнең мәңгелек йокыга талулары аның иңен һәм җанын таш авырлыгы белән бастырып куя. Аны шул хәлдә күргән һәр кичне полковник Кулунчаковны моңсулык били, андый чакларда Марияне үз итеп, яратып, күңеле нечкәрә, үзләрен шундый шартларда яшәргә мәҗбүр иткән дошманга карата нәфрәте тагын да көчәя. Т е л ә к ялкыны тәмам сүнә, сүрелә. Ул моны аклап булмаганны да аңлый. Марияне кызгану хисе аны чарасыз иткән, көчсезләндергән вакытта ул үзүзен күралмый башлый. Авыр бурычын үтәгән көннәрнең берендә очраткан, танышкан, яшәп киткән, хатыны иткән Мариясенең аягына егылып, хисләр, кичерешләр кочагына ташланасы иде дә бит... Мария, антик горур кыяфәтле, шул ук вакытта басынкы холыклы бу хатын, мәхәббәтнең асылы таләп иткәнчә, аның назына, иркәләвенә бик мохтаҗ лабаса. Дөрес, мөнәсәбәтләренең закон ягыннан берекмәвен искә алганда, Мария аңа бөтенләй үк хатын түгел әле түгелен. Дингә ышаналар, ә бу нәрсә аларның җан бердәмлегенә күпмедер зыян да сала. Сугышның пычраклыгы һәм күп мәхрүмлекләренә карамастан, аларның эчке тавышлары дөньяда акыл һәм әхлак барлыгын да искәртә. Тыныч тормышта алар тулысы белән акыл һәм әхлак таләпләренә буйсыныр лар иде, ә хәзерге көндәлек хәсрәт, авырлыклар ул таләпләрне онытып торырга да ирек бирә. Ходайның һәм шайтанның уртак тырышлыгы белән дөньяның асты өскә әйләнгән вакыт бит. Мәхәббәт һәм нәфрәт, чисталык һәм бозыклык аларның күңелләрендә үзара тартыша, көрәшә иде. Хәер, бер-берсен ярата лар икән, ир белән хатын буларак чиркәүдә теркәлмәүләре генә аларның мөнәсәбәтләренә салкынлык, оят иңдерә алмый инде. Йөрәк әшенә киртә юк, ул һәрвакыт акылдан көчлерәк...

Ай нуры һәм күләгәләр тынлыгында дәшми яту полковник Кулунчаковны зарыктырды. Ул папиросын сүндерде дә, уйларыннан арынып:

— Миңа таба борыл әле, Мария... — диде.

— Синнән бөтен солдатлар йөз чөергән көнне ме?

---

[1] «Хөкем итмәгез һәм хөкем ителмәссез» (Евангелиядән).

— Ни өчен?

— Әйтеп торасың тагын, Арсений! Бүген лазаретта сине сөйләштеләр. Биш солдат үлде. Үлгәндә телләрендә Ходай түгел, син булдың. Алар сине үзләре белән кабергә алып киткән шикелле.

— Мин үзем дә солдат, Маша. Мин Ватанны саклаучы закон солдаты. Минем алардан бер өстенлегем дә юк.

— Ай-һай... Корбанның аркасы булуга караганда, палачның камчысы булуы өстенрәк инде ул. Аларны дөрестән дә атачакланмы?

— Әлбәттә. Алар ярлыкау сорамадылар.

— Ярлыкау сорамас өчен бөек, гөнаһсыз идеяле булу кирәктер.

Нindидер серле кичереш полковникның чигәсен кысты.

— Бүген Россиягә идеянең хаҗәте юк. Солдатлар кирәк.

— Солдатлар кирәк булгач, аларны нигә аттырасың соң?

— Россиядә аларның идеясезләре дә җитәрлек.

— Син аларның ниндие соң?

— Ә сиңа ниндие кирәк, Маша?

— Ах, Арсений!.. — диде Мария һәм, кинәт талпынып, ирнең күкрәгенә капланды...

Алар бу мизгелдә Россия империясе киңлекләрендә язгы ташкын кузгалганын белмиләр иде әле. Бу ташкын тиздән аларның икесен дә үзенә бөтереп алды һәм мәңге чыгалмаслык шарламасыннан түбәнгә чөйде.

«Ничек инде ул: мин, үлемнән йолып калырга теләп, аны югары күтәрдем; ә ул, исән калу мөмкинлеген кире кагып, мине түбән төшерде», — дип уйлады полковник Кулунчаков икенче көнне иртән прапорщик Чаныш Наймушин белән кичәге бәхәсен яңадан уеннан кичереп. Ул үткән төнне керфек какмыйча диярлек үткәрде. Мариянең иртәнге чәй вакытындагы мөгамәләсе ничектер салкын булды. Тик ул моны күрмәмешкә салынды. Әле генә, күз әчетүе һәм тән оюы басылмасмы дип, ул коньяк эчте. Тәне җиңеләеп, каны таралгандай тоелса да, кәефе күтәрелмәде, йөрәге кагарга тотынды.

Моңарчы гаеплеләрне хөкем итү яки ярлыкау мәгълүм дәрәҗәдә аның ихтыярына бәйле иде. Һәм ул үзенең хаклымы, түгелме икәнен фәкать үзе тайпылышсыз кулланган законнар белән чагыштырып кына бәяләде. Сугыш шартларында законнарның иң кырысларына таянырга туры килә. Хәрби трибунал ярлыкауны белми диярлек, андый хәл бик сирәк. Полковник икеләнми иде инде.

Ә кичә ул үзе яклаган хакыйкатьтә беренче ярык хасыйл булуын тойды. Прапорщик Наймушинның гомере аның кулында иде. Ләкин ул үз язмышына үзе хуҗа булып калды. Үз язмышына гынамы соң? Хикмәт тирәндәрәк. Ул Кулунчаков язмышына да хуҗа төслерәк кыланды.

Хәзер полковник аны чакыртып сөйләшүенә үкенеп тә куйды. Хәер, инде эш эшләнгән, узган эшкә салават. Шул ук вакытта нәрсәнеңдер төенләнеп җитмәве аның эчен пошырды. Соңгы төен — большевикларның үләргә тиешлегеме, әллә яшәргә дә хаклары булумы? Нәрсә? Кем яшәргә теләмәсен? Ә, прапорщик! Ул теләмәде! Ул үз гомеренең дәвамын полковник кулыннан алырга теләмәде. Димәк, ул бу чынбарлык шартларында аның белән бергә үләргә теләр иде микән? «Хөкем карары чыгарып, мин дә үземнең аның белән бер кояш астында яши алмавымны расладым. Ә алар белән бергә үлүне сайлый алам микән?!»

Сораулары бәйләнчек, газаплы, ә анык кына җавабы юк иде. Полковник Кулунчаков җавапны өннәрендә генә түгел, төшләрендә дә эзләячәгенә төшенде, нигәдер большевикларның үлем белән очрашкан урыннарына тартылуын тойды.

Ул тагын коньяк салып эчте, шинелен, бүреген киде.

Шәһәрчек гарнизонының каравыл взводы тоткыннарны алып чыгып киткән иде инде. Кара «Роллс-Ройс»ка утырып, полковник карьерга ашыкты. Әмма килеп җиткәндә залп яңгырады.

Үле тынлыкка чумган карьерны күмәргә ашыккандай, эре, җепшек кар ява иде.

Каравыл взводы винтовкаларын «к ноге» куйган һәм унтер-офицерның яңа боерыгын көтә иде инде.

«Үлгәннәр терелми. Ләкин тереләрнең үләсе бар әле», — дип уйлады полковник Кулунчаков, үзләре аткан кешеләрдән бер яклары белән дә аерылып тормаган солдатларга югарыдан, карьер ярыннан карап. —Үлгәннәрнең күргән газаплары аларга күчте — бар аерма шунда гына».

Ул борылмалы сукмактан җәяүләп түбән төште, инде солдат та, кеше дә булудан туктап, инде фәкать хәрби трибунал хөкеменең җиренә җиткерелү фактына гына әйләнгән мәетләргә якынайды һәм берсенең әлегә исән икәнен, әмма үлем җәрәхәте алганын күрде. Яралы әлегә м о н д а, бер үк вакытта т е г е н д ә дә иде инде.

Ул — прапорщик Чаныш Наймушин иде.

Үзенә таба якынлашкан полковник Кулунчаковны абайлап, ул җайсыз яткан җиреннән кузгалды да артка каерылган терсәкләренә таянып тартылды һәм, аны танып, кар кунмаслык текә, ялангач упкын төбенә сөялде. Прапорщикның аяклары, кунган кар бөртекләрен кагарга теләгән төсле, җиңелчә генә дерелди иде. Полковник яңак итенең тартылып калтырый башлавын тойды. Моны яралыга күрсәтергә теләмәгән кебек, йөзен солдатларга таба борды.

— Ачыгавызлар, анагызны!.. — дип сүгенде ул аларга җиренә житкермәгән эшләре өчен һәм, карьер кашындагы кара автомобиль янына кар көртеннән аера алмастай булып күренгән ак ат килеп чыкканны күреп, сәерсенә калды. Җайдак, һавадан иңгән шикелле, җиргә сикереп төште дә, әле егылып, әле шуып, әле тагын торып, сөзәк урыннан турылай түбән томырылды. Полковник үзенең адъютантын танып алды. Ул яланбаш һәм мундирдан гына иде.

Полковник Кулунчаков аңа:

— Нәрсә, яңадан немецлармы?! — дип кычкырды.

Сулышы капкан капитан берара телен әйләндерә алмый торды.

— Күпкә яманрак, вашевысокородие! Революция!.. Государь-император тәхеттән ваз кичкән...

Әлегә аң һичничек кабул итеп өлгермәгән, ләкин инде үзләренә яшеренгән гадәттән тыш куркынычы белән хәйран калдырган бу сүзләрне арттан ишеткән шикелле, полковник, кырт борылып, прапорщикка текәлде.

«Полковник, син шуны кызганган идеңме?! Шуны коткарырга теләдеңме? Ә а л а р кызганмаган! Үз дигәннәренә ирешеп үлделәр — минә ни кызганыч!» — дигән уй аның күңеленнән елгыр кәлтә еланы сыман шуып узды.

Аны аңлаешсыз борчу басты.

— Ишеттеңме?.. — диде прапорщик, каны качкан иренен чак кыймылдатып. Сүзен әйтеп бетерә алмаудан курыккан шикелле, ул сулышын тыйды. — Үз-үзеңне хөкем итәргә... өлгермәдең... Инде көт.

— Нәрсәне? — дип сорады полковник.

— Халык хөкемен.

Прапорщик Наймушинның аягы дерелдәүдән туктады, ул йөзен читкә борды да тынып калды. Югарыга менгәч, полковник Кулунчаков карьер төбенә әйләнеп карады.

— Бәхетле кеше, шайтан алгыры! — диде ул үзалдына.

— Кем? — дип кайтарып сорады аның янәшәсендәге капитан.

— Синең белән мин түгел, — дип җавап бирде ул гамьсез төстә. — Прапорщикны әйтәм... Гомумән, бөтенесе!

Гүя тере кешеләр турында әйтте.
Һәм кинәт аңа барысы да киресенчә күренде.
Әйтерсең лә ул үзе аста ятып калган, ә прапорщик Наймушин монда, югарыда иде.
«Прапорщик үле, ләкин якын киләчәктә ни буласын белә иде. Мин тере, ә хәтта үткәннәрдә ни булганын да белмәгәнмен... Менә, басып торган җирем дә билгесез — упкын чите. Тик бу — нәрсәнеңдер кыл уртасы», — дип уйлады ул.
Ниһаять, ул бу урталыкның н ә р с ә икәнлеген аңлады. Ул хәзер прапорщикның үткән гомере белән үзенең киләчәк үлеме арасында басып тора иде. Калкан белән кылыч арасында. Ә хөкемдар кем? Һичкем түгел. Гомере буена государь-императорга, Ватан һәм Ходайга хак хезмәт итәм дип ышанган Кулунчаков үзенең судьялыгыннан ваз кичте: дөньяның тоткасы аның кулыннан ычкынды. Хәзер ул — гаепләнүче. Аның гаебен раслаучы факт бәхәссез инде — революция.
Карьер төбендәге солдатлар ком-ташлы җирне казырга тотындылар — атылганнарны күмәргә кабер әзерлиләр.
— Капитан, бар әле, боер: карьерны бозмасыннар.
— Барыбер түгелмени, Арсений Завалишинович?
— Үлүчеләр күп, карьер бераү генә. Кем җиңсә дә, карьер кешеләргә кирәк булудан туктамый.
Капитан баягы сукмагына борылмакчы иде, полковник аны туктатты:
— Нигә аяк итеңне ашыйсың, дурак?! Атыңа атлан!
Шунда ук автомобиль юлыннан менеп килгән җигүле атны күреп алды.
— Ни калган моңа тагын, анасын!... — дип сүгенде ул. — Хәер, яхшы: мәетләрне шуңа төят, капитан, аңладыңмы?
— Яхшы, Арсений Завалишинович!
— Үтә.
Яннарына санитар арбасы менеп туктады. Дилбегә тоткан обозчы солдат янынннан Мария сикереп төште.
— Арсений! Революция! — дип кычкырды ул.
— Ишеттем, — диде полковник сүлпән генә.
— Туктат!
Аның ни турыда әйткәнен аңлаган полковник Кулунчаков:
— Соң инде... — диде.
Шәфкать туташы карьер читенә барып басты, аска карады һәм карга чүкте.
— Арсени-и-ий!.. — дип ыңгыраашты ул. — Бәла! Полк комитеты сине атарга хөкем чыгарган!
Полковник җәяүләп үрдән төшеп китте. Аның артыннан, көпчәкле табут төсле булып, кара автомобиль иярде.

Эш урынына әйләнеп кайткач, ул шинелен салды, камин уты каршысында җылынып утырды. Күпмедер вакыт үткәч торды, иңбашын җыерып, бүлмә буенча йөренде. Аннары кулын күкрәгенә кушырган килеш тәрәзәдән кар сарган агач ябалдашларына карап торды. Калын кар каплаган йорт түбәләрен ни өчендер кабер калкулыкларына, ә кирпеч торбаларны кабер ташларына охшатты. Бу күренештән котылырга теләгән шикелле, әкрен генә тәрәзәләрнең чуклы кызыл пәрдәләрен япты. Бүлмә эченә кичке шәфәкъ нуры иңгәндәй булды. Шуннан соң, тәменә ләззәтләнеп, коньяк эчте.
Күпмедер вакыт үткәннән соң капитан кайтты, үзенең бирергә икәнлеген кереп әйтте.
— Мария Севастьяновна кайда? — дип сорады полковник аннан.
— Анда берсе исән калган, вашевысокородие. Шуны лазаретка алып китте.

— Кайсысы? — дип сорады полковник битараф кына.

— Прапорщик.

Ул, сүзе беткәнне белгертеп, кулын изәде.

Адьютанты чыгып киткәч, тагын коньяк эчте, ләкин бу юлы ни тәмен, ни кайнарлыгын тоймады. «Живуч татарин!» — диде ул үзалдына һәм аның хакында бүтән уйламады.

Аннары өстәл янына барып утырды, алдындагы чиста кәгазьгә нык кул белән тиз-тиз нидер язып куйды.

Сәгать суга башлады. Аның соңгы авазын үз күңеленә салып куйгач, ул:

— Әйе, вакыт, — диде һәм револьверының көпшәсенә карады да, козгын күзедәй кара тишеккә елмаеп күз кысты...

Язуы кыска иде:

«Ходил в свете, пока был свет во мне.[1]

П-к Кулунчаков».

Ату тавышына адьютант йөгереп керде, идәндә яткан револьверны күрмичә һәм ни булганын аңларга теләмичә, өстәлгә капланып яткан полковникның чигәсе турысындагы канны сөртеп алды. Күзе төшеп, язуны укыгач, ул полковникның гәүдәсен идәнгә сузып яткырды.

Полковник Кулунчаковның гәүдәсе салынган затлы табутны хатыны Мария ярты Россия аша үтеп, анасы Марфа Петровнага алып кайтып тапшырды. Кайчандыр тирә-юньне үз ихтыярында тоткан, әле хәзер дә тирән баткан күзендә боеру очкыннары чагылып киткәләгән, юка иренле, кылыч борынлы бу карчык Мариянең: «Анакай, табутны ачып карый аласыз, ул ачык платформаларда гына кайтты, бозылырга тиеш түгел», дигән кыюсыз тәкъдименә каршы калын кашын җыерып, карлыккан тавыш белән катгый төстә:

— Ни к чему теперь тужиться-то. Двух смертей не бывать, а одной не миновать. Чего себя обременять и его тревожить? Чай Бог даст, воскреснем в Судный день да и свидемся, — диде.

Нәсел склеплары тузган, мәгънәсен җуйган иде инде. Ләкин Марфа Петровна иркен итеп кабер казырга, аны яхшы кирпеч белән эчләргә — үз нәселләренең борынгыдан килгән гадәтенчә, склеп ясап җирләргә кушты.

Кызыксынып, ишек төбенә җыелган мужиклар таралырга кыймыйча таптаналар иде. Карт ананың иңенә нинди авырлык төшкәнен аңлыйлар, сыгылып төшмәвенә, аек акылда калуына беркадәр хөрмәт белән карыйлар. Моның ише хәсрәтне алар да кичергән — барысы да бер кояш астында яшиләр ләбаса. Әмма Марфа Петровнаның полковник улын таш кабергә җирләргә теләвен алар кабул итмәде: эше күп, бүгенге заман өчен артык мәшәкать кенә, дип гәпләштеләр. Кайсысы аяк астына төкереп, кайсысы сүгенеп кул селтәделәр дә байтагы кайтып китте.

— Өч аршын җир җитмәгәнме?

— Анысы да хәттин ашкан.

— Кешесе кешеме соң? Этләргә чыгарып ташласаң да харам.

— Һәм дә дөрес!

— Плуататорлардан нәрсә көтәсең тагын?

— Муенына таш бәйләргә дә — бәкегә!

— Өстәп, утарларына кызыл этәч җибәрергә — бетте-китте!

— Кызганыч, көне ул түгел.

— Ничава, бездән калмас...

---

[1] «Дөньяда үземдәге яктылык беткәнче йөрдем». Евангелиедәге: «Дөньяда үзегездәге яктылык беткәнче йөрегез», — дигәннән.

Болай ук ярып салырга кыймаганы, мәетне җирләр өчен, Мариянең басынкы гозерен генә тыңлап калдылар. Җитмәсә, мужикларның салкын карашларын күрмәмешкә салышкан Марфа Петровна үз теләген үтәтү чарасын да тапты. Йорт караучы итеп торткан Наймуш картка:

— Әйт аларга, Наймуш: поминка мул булыр. Хәзер саранланып торуның мәгънәсе юк инде. Кул белән бирмәгәнне, җанымнан суырып алачаклар. Аларныкы басты. Ә минем үземә өч аршын җир җитә, озак көттермәм. С Богом! — диде.

Вәгъдә үзенекен итте. Карчыкның гозерен шуннан соң аяк астына салып таптамаска булдылар, ул әйткәнчә эшләделәр. Дөресрәге, Наймуш карт оештырганча. Поминка, чыннан да, мул булды, өстәлләр сый-хөрмәттән сыгылып торды, аракы су урынына акты.

Шул форсаттан файдаланып, каннары кызган мужиклар утарны туздырып ташладылар, күтәрердәй мал-мөлкәтне ташыдылар, калганын ут төртеп яндырдылар.

Боларның барысын да Наймуш алдан ук белеп торды. Нәрсәнедер үзгәртү соң иде инде — язгы ташуны тыеп була димени? Урыс мужиклары үз ниятләрен аннан яшерүне кирәк тә санамадылар. Үзара пышын-пышын килүләреннән, астыртын карашларыннан, мәгънәле хәрәкәтләреннән ул барысын да аңлады: шешәнең бөкесе ачылган, гайрәтле гыйфрит ирекә чыккан, аны кире куып кертергә һичкемнең көче җитә торган түгел. Аннары соң Наймуш крестьяннарның хаклы, ә ниятләренең гадел булуы белән дә килешә, кирәк калса, якларга да әзер. Шуңа күрә ул үз авылындагы татарларга да хәбәр салдырды: алпут малын бүләчәкләр, авызыгызны ачып калмагыз!..

Картны сизгерлеге алдамады.

Мужиклар иң әүвәл поминкадан соң да аракы дәгъваладылар. Марфа Петровна бусын катгый тыйды: «Поминка улым рухына, ә исерек шабаш өчен түгел!» — диде.

Өстәлләрне аударып ташладылар. Хөррият, тигезлек, туганлык турында кычкырдылар. Һәм башланды мәхшәр!

Җәяүле буранга карамастан, атларын җигеп, якындагы үр артындагы каенлыкта көтеп торган татарлар да кузгалды. Урыслар башта аларны якын җибәрмәскә исәп тотканнар иде. Ләкин сәнәкләр, балта, күсәкләр тотып, аларның юлына каршы төшкән мужиклар, коры кул белән калу ихтималыннан шикләнеп, мир тапшырган вазифаларына кул селтәделәр дә гомуми шаукым өермәсенә ташландылар.

Баштанаяк карадан киенгән һәм кырыс монашкага охшап калган Марфа Петровна аларны мунча ишеге төбендәге утын пүләненә утырган җиреннән күзәтеп торды, әледән-әле чукынгалады. Ул үз өеннән берни алып чыкмады, фәкать Библия белән Евангелие китапларын гына калдырмады, кочагыннан төшермәде.

Наймуш карт чана башындагы салам астына атына дип бер капчык солы чыгарып куйды да үз авылына кайтып китәргә җыенды.

Чырае кара көйгән хуҗа хатыны аңа:

— Әйт аларга, Наймуш: тигез бүлсеннәр. Барысына да тиярлек булсын, — диде.

— Артып та калмас, — диде Наймуш.

— Тигезлек диләр лабаса!

— Кешеләр тигез булалмый, Марфа Петрауна. Кем биек, кем тәбәнәк, кем хәлсез, кем көчле.

— Син ник авыз ачып торасың? Нәрсә кирәк, ал — рәнҗемәм.

— Мин үземә ни кирәген белмим.

Марфа Петровна Наймушны гадел булганы өчен үз итә иде.

Аның кемлеге табышмак түгел. Утарга ул аны сынау белән алды. Чакыртып китерде дә, аның җигүле атка утырып килгәнен күргәч, үзе йортка узды, ә ишегалды юлының күзгә ташланып тормаган диярлек җиренә биш сумлык алтын тәңкә ташлап калдырды. Ә Наймуш, исәнлек-саулык сорашканчы, шул тәңкәне аңа сузды да әйтте: «Тәгаен сезнекедер, Марфа Петрауна. Тик бүтән болай итмәгез: мин мәкерне яратмыйм». Шуның белән хуҗа хатын аның өч сыйфатын барлады: ихласлыгын, эшчәнлеген (хәл-әхвәл белешкәнче, сүзне табылдыктан башлады бит), ниһаять, риясызлыгын. Хәзер ул, бу мәхшәргә исе китмичә, аңа катнашмыйча, комсызланмыйча, һәрвакыттагыча, үзенә генә ышануына һәм таянуына тугры калып: «Мин үземә нәрсә кирәген белмим», — дип әйтә икән, моның хак икәненә ышанырга була. Шулай да Марфа Петровна:

— Ә нәрсә беләсең, Наймуш? — дип сорады.

— Нәрсә беләмме? Кешеләрнең нәрсәгә ия икәнен... Тагын — кешеләрнең нигә яшәгәнен.

— Нәрсәгә ия соң бу кешеләр?

— Җир белән күккә.

— Ә нигә яшиләр?

— Үләр алдыннан җир белән күктән гайре бер нәрсәгә дә ия булмаганнарын аңлар өчен.

— Үлгәнчегә кадәр алар нидер эшли, алардан нидер кала бит?

— Нишлиләр? Яраталар, нәфрәтләнәләр. Нәрсәләре кала? Ярату-лары, нәфрәтләнүләре. Менә шул.

— Мин дә аларны ярата идем, Наймуш, — диде Марфа Петровна моңсуланып һәм анда-монда чабышкан, кычкырышкан крестьяннарга ишарәләп. — Ә хәзер яратудан туктадым. Нәфрәтләнмим дә. Шулай булгач, бу дөньяда миннән һични калмыймыни?

— Нигә калмасын ди? Каберең калыр.

Наймуш дилбегәсен кулына алды, атын боргач:

— Утыр, Петрауна. Кайтыйк, — диде.

Аның атын борганын күргәч, Марфа Петровна үзе күмеләчәк кабердә калган шикелле бөрешкән иде. Татар картының гади генә итеп: «Кайтыйк», — дигәнен ишеткәч, эсселе-суыклы булып китте, җан бушлыгы рәхәт ышаныч белән тулды. Ул, кипкән иренен көч-хәл белән кыймылдатып:

— Кая? — дип сорады да урыныннан калыкты.

— Кая булсын инде — безгә. Гомерең булса, торырсың. Үлсәң, җирләрмен.

— Тайбәң ни дияр соң?

— Диярлеге калмагач, пушшай дисен. Диясе булгач, әлгәрерәк дияләр аны!

Наймуш карт тукран тукылдаткан шикелле генә кеткелдәп куйды. Ирен чите белән генә Марфа Петровна да елмайды. Әлгәрерәк, инде әллә кайчан, хәзер булмаган да шикелле үткән-киткән заманнарда, аның ире Завалиша, ниндидер татар морзалары токымыннан булган кеше, мәкәрҗә ярминкәләрендә югалып йөргән вакытларда, сеңердән генә торгандай елгыр һәм чыдам Наймуш белән аның арасында нидер булгалаган иде шул, булгалаган иде...

Чанага утырган татар карты белән урыс карчыгын сары ат иркен ишегалдыннан караңгылыкка алып чыгып китте.

Ярты юлга җитәрәк, Марфа Петровна кинәт җилкенеп куйды, артка каерылып карады.

— Туктале, Наймуш! Мария хакында сорарга оныткамын. Ничек озаттың? — дип сорады ул.

Наймуш бияләенә капланып йөткергәләде дә атны каулады, бөкрәеп утырган хатынның иңенә толыбын салып каплады.

— Көне дә килде соң!.. Ә Мариягә әйбәт булыр. Мин аны Чистай

юлына чыгарып куйдым. Аракы олавына туры килде.

— Иренең тугызына[1] да калмады,— диде карчык үпкәләгән тавыш белән.— Никахсыз торсалар да, хатыны булган лабаса!

Наймуш карт, үзе генә белгән хәтәр серне уйлап:

— Ашыкты шул,— дип килеште.

— Нишләтәсең инде? Шулай язгандыр. Законсыз хатын... Минем Арсением кем аңа?.. Ә Мария яшь, чибәр әле. Бар гомере алда. Үз дигәнен тапмый калмас.

Дилбегәне аерып, Наймуш ике яклап ат сыртына тамызды.

— Но-а! — диде ул буранлы караңгылыкны сискәндереп.

Ләкин ат үз җае белән генә атлый бирде.

...Ә Мария моннан әллә ни ерак түгел иде. Ул араның күпме икәнлеген Наймуш карт байтак гомер фәкать үз күңелендә генә бикләп тотты.

Ире — полковник Кулунчаковның үлеме, әйтергә кирәк, чын ирләрчә үлә белүе Мариянең дөньяда яшәү мәгънәсен аңыннан да, җаныннан да төбе-тамыры белән йолкып алгандай итте. Ул, гимназияне яңа гына тәмамлаган кыз, күңелендәге барлык илаһи ашкынуын туплап, үз-үзен раслыйсы килү сусавын басарга, билгесезлеге белән серле, гаҗәеп дөньяда таяныр нокта эзләргә һәм табарга, күбрәк укыган саен, бушый гына баргандай тоелган эрсез рухын яңа кичерешләр белән тутырырга теләп, сугышка чыгып киткән иде. Башта ул, чыннан да, вокзалдан фронтка кадәрге озын юлда күзенә яшь китерердәй туганлык, бердәмлек, бөеклек хисе белән очрашты. Озакламый ул — хәрәкәттәге армиянең шәфкать туташы — үзенең кемлеген, кайдалыгын, ни эшләгәнен онытырган гавам хәсрәте белән күзгә-күз калды. Аның, кулын югары күтәреп, кемдер алдына тезләнәсе, кешеләрнең бер-берсен канга тончыктырган, газ белән буган, бары тик кабер генә туктата алган чиксез газапларын үзенә күчерүләрен сорап ялварасы килә иде инде.

Аны һичкем ишетмәде, күрмәде, юату сүзе әйтмәде, ярдәм кулы сузмады. Киресенчә, боларның һәммәсен аның үзеннән көттеләр. Дөнья хәсрәте, бәла-казасы, кешеләрнең ирексез гаебе аның күңеленә җыелды. Һәм ул боларның һәммәсен өмет яктысы, ышаныч җылысы итеп, кешеләргә юнәлдерде. Моның хакына ул үзен корбан итәргә әзер кебек иде. Кешеләр белгән барлык ялвару һәм догаларга һәммә диннәрнең барлык аллалары берьюлы колак салып, солдатларның бер-берсен чәнчегән штыкларын, бер-берсен тураклаган кылычларын, кайнар ядрәләрен яшен итеп, снарядларын күк күкрәү итеп аңа — Мариягә юнәлдерсәләр һәм шуның бәрабәренә җирне кирәкмәс газаплардан, вакытсыз үлемнәрдән арындырсалар, ул моны бөек түбәнчелек, ихлас ризалык белән кабул кылыр чиккә җиткән иде инде.

Ләкин моны аннан һичкем сорамады. Гавам мәхшәре дәвам итте: сугыш тегермәне корбаннарга тыгыла-тыгыла тартты, үлем чалгысы уңны-сулны, алны-артны, асны-өсне аермыйча селтәнде дә селтәнде.

— Йа хода! Ялварам синнән: туктат! Үземдә булган соңгы нәрсәмне ал — сине яратуымны. Ләкин туктат!..

Бу юлы аның сүзе ишетелде, ялвару сүзе барып җитте: сугыш аның соңгы юанычын — яратуын тартып алды, полковник Кулунчаковны, аның Арсениен.

Ходай тәгаләгә шулай кирәк булган, күрәсең: алар ниндидер кодрәт белән шул мәхшәрдә бер-берсенә тап булдылар. Чиксез газапта тилмергән адәм балаларын ярату хисен Мария бөтен барлыгы белән Арсениенә бирде һәм бөтен тулылыгында үзенә дә алды. Бу аның сагындырып килгән, канында шуңа кадәр яшеренеп яткан һәм чишмә

[1] Православиедә мәрхүмнең өчесеннән соң тугызын үткәрәләр (Автор).

сыман тыелгысыз төстә ургып чыккан беренче сөюе иде.

Һәм соңгысы да икән.

Беренчесе өчен ул үлем белән тартышкан тормышка, бөек рухка рәхмәтле иде. Соңгысы өчен дә анда яшәүгә карата нәфрәт уянмады, ул күкләргә ләгънәт яудырмады. Аның кайгысы һәм бәласе аңа күктән иңмәде ич. Ул үзен генә гаепләде, үзен генә каргады, чөнки ул үзен-үзе кояш астындагы сөю хисенә бирмәгән, ә бәлки үлемгә хезмәт иткән полковникка тапшырган булып чыкты. Хәрби киемдәге Понтий Пилатка...

Ул моны Кулунчаковның сигез солдатны үлемгә хөкем иткәнлеген белгәч һәм иренең үле гәүдәсен күргәч кенә аңлады. Аларның соңыннан ишетүенчә, большевик булганлыгы Мариягә барыбер иде. Алар аның өчен беренче чиратта к е ш е һәм, солдатларның сөйләүләренә караганда, яхшы кешеләр булганнар. Начарлар өчен полковник, ихтимал, үз-үзен атмас иде. Димәк, алар Арсенийның аны — Марияне яратуыннан да көчлерәк булганнар; димәк, Арсенийның нәфрәте мәхәббәтне дә җиңгән!

Ә Мария мондый хыянәткә бара алмады. Ул аны җансыз калган килеш тә яратты һәм шул яратуыннан башка яшәү юклыгын аңлады. «Алайса, ярый, шулай булсын,—диде ул Кулунчаковның башы очында соңгы сүзен әйтеп,— син сөюдән соң үлдең, ә мин үлемнән соң да сөярмен».

Ул полковникның үле гәүдәсен ерак юлга алып чыгарлык табут ясауларын үтенде. Һәм кара табутны революция ялкынында янган Россия аша Арсениенең туган җиренә кайтарып җиткерде. Полковникның туган җиренә, ә үзенең үләчәк җиренә. Ул алдан ук шундый карарга килде. Яисә ахырдан. Аермасы юк инде...

...Күмүчеләр таралды. Поп белән бер чанага утырып, Марфа Петровна да кайтып китте. Калын кар баскан зираттагы яңа кабер һәм гадәти үк булмаган бу кабердән артып калган зур кызгылт ком, таш, балчык өеме янында Мария белән Наймуш карт, аның чанага җигелгән сары аты гына басып калды. Чанага измәгә буялган агач тагарак, измә ясар өчен учакта кар эретеп корымланган потлы чиләк, тагарак эчендәге дүрт көрәк, ике лом, балта һәм ике мастерок төялгән. Кабер читендә артып калган цементы белән киндер капчык, ике-өч дистә кирпеч ята. Карт аларны төямәде: мәеттән артканны кире алып кайтмыйлар, диде. Һәрхәлдә, шәригатьчә шулай. Монда, әлбәттә, урыс зираты, аларча ничектер, карт моны белми, ахыр килеп, үзенчә эшләде. Хуҗалыкка бик хәҗәт нәрсәләр дә кана, шулай да калдырырга кирәк дип санады. Бәла-каза эстәү ише килеп чыкмагае. Кирпечләрнең кемдер чанага ташлаганнарын да бушатты, пөхтәләп, кабер калкулыгы тирәли тезде. Аннары кайтырга җыенды: ат башына киертеп бәйләгән солы капчыгын чишеп алды, аркалыкны күтәрде дә эзәренә кыстырылган тире бияләйләрен кагып киде.

— Кузгалыйк булмаса, дученка,— диде ул.

Мария әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә илтифат итмәде. Кулын кушырган көйгә кар киртләче белән кабер калкулыгы арасында ачылган былтыргы көрән һәм сары яфраклар, зират чүп-чары түшәлгән урынга баскан да боек, уйсыз-нисез карашын еракка — түбәндә яткан елга аръягына, буш киңлекләргә текәгән. Кайчагында гына, тирән итеп тын алганда, кыйгач уң кашын сикертеп куя. Җирдән себергән кар менә-менә аны үзенә ияртеп, әллә кайларга алып китәр кебек. Ыргымыргым искән җил аның башына япкан һәм аркасына төшеп торган кызыл хачлы ак япмасын җилфердәтә, куян туны астыннан чыгып торган көрән күлмәге итәген шапылдатып балтырына сылый. Җил тынган бер мәлдә ул әллә суык үткәнгә, әллә уйларыннан арынып-мы, иңбашын җыерды, тирән итеп сулыш алды, сулкылдады. Аның күңеле

төбеннән авыр көрсенү авазы бәреп чыкты. Наймуш карт үз гомерендә байтак кешене җирләде, кемнеңдер вакытсыз яки бик вакытлы (картаеп, кеше кулына калмыйча, имгәк булып гомер сөрмичә, исәннәрне җәфаламыйча, тыныч кына үлүне ул шулай санар яшькә җиткән иде инде) үлеменнән соң мондый көрсенүнең ни белдерүе аңа сер түгел. Мондый көрсенү — нәрсәнеңдер үзгәрүенә өмет баглауның тәмам сүрелүе, үлемнең чын булуын бар ачысы, хәсрәте белән бөтенләйгә кабул итү, инде соңгы тапкыр хушлашу билгесе ул. Шуннан соң кешедә яшәүне дәвам иттерергә кирәклеге турындагы уй яңара, ул үзен «үлгән артыннан үлеп булмый» дигән юанычка тапшыра. Кеше яңадан өнгә әйләнеп кайта һәм тора-бара шулай тирән итеп төшләрендә генә көрсенә башлый инде.

Бу юлы Мариянең көрсенүе картны алдады. Кырыс өнне җәяүле буран тәгәрәтеп алып китте, шуннан соңгы вакыйга яман, буталчык, аңлаешсыз төш сурәтендә Наймушны ахыргы көннәренә чаклы изалап, саташтырып, миңгерәтеп йөртте.

Соңга табарак бу вакыйга төсен җуя, ерагаеп томанлана башлады, ә кичереше хәтер сукмакларында югала төште-төшүен. Авыр тәэсире дә таралды, басылды. Аның хакында уйларга яки кешеләргә сөйләргә туры килгәндә картның күз алдында иң алдан чана башына сөяп куелган урыс иконасы, аңа төшерелгән кырыс та, моңсу да карашлы хатын-кыз сурәте пәйда була иде. Хәтер әнә шул сурәттән арына алмыйча йөдәтте. Аны хәтердән балта түтәсе белән мичкә төбен сугып төшергәнише итеп кенә чыгарып ташларлык түгел иде инде. Мариянең йөзе белән шул сурәт чырае аның аңында бергә кушылып терелә торган булды. Мөселман диненең канга сеңгән кануннары, ата-бабалар йоласына буйсыну, гореф-гадәт алдындагы бурыч, тормыш итү ырымнарына тугрылык хисе башка диндәгеләр йөз баглап чукынган яисә баш иеп дога кылган нәрсәләргә, уйда чагылсалар да, күзгә күренсәләр дә, өч тапкыр ян-якка төкергәләп, әгузе бисмилла әйтергә куша. Югыйсә, Алла гөнаһ һәм тәмуг утында көйрәтәм дип яный. Ә Наймуш чана башындагы ул иконага кырын карарга ирексездән дә, ялгышып та базмады, шулай итсә, Мариянең битенә төкерү, үзенең җанын пычрату булыр шикелле иде.

— Син мине шушында җирләрсең, бабайка,— диде Мария.

— Шту син, дученка, авызыңнан җил алсын! Үзеңчә чукын да — кайтып китик. Бакчы, җәяүле буран котыра. Салкын тимәгәе. Исәннәргә саулык кирәк.

— Саулык исәннәргә кирәк,— диде Мария картның сүзен үзенчә җөпләп.

— Әйе, синең белән миңа. Бигрәк тә сиңа. Синең әле чәчәк чагың, яшисе дә яшисе.

— Инде үләсе. Хәзер, шушында,— диде хатын. Ул зират каеннары һәм наратларның шаулавына, ыңгырашуларына сагаеп колак салды.

Наймуш карт кеткелдәп көлеп җибәрде: янәсе, аның сүзен шаяртуга алуы.

Мария чана янына килде дә карлы саламга тезләнде, иконага йөзен баглап, тиз-тиз өч мәртәбә чукынып алды.

Җил көчәя барды, атның койрыгын, ялын җилфердәтте, яңа кабергә учлап-учлап кар китереп сипте, көрттән көрткә сары каен яфраклары куды.

Ә күк йөзе аяз диярлек. Бары тик юка дымык пәрдәсе белән генә өретелгән, аның аша кояш эрегән кургаштай елкылдап күренә.

Мария, карны шыгырдатып, чана башына таба китте һәм иконаны алып, күкрәгенә кысты. Иконадагы сурәтне кояш чагылышы каплады, ул бер генә мәлгә тоныгаеп юкка чыкты да, Мария кузгалган саен, әле өлешчә, әле тулаем ачылгалады.

— Мине шушында җирләрсең, бабайка. Арсений янына,— диде Мария мәрмәрдәй ак һәм түгәрәк ияге белән кабергә ишарәләп.

— Помилуй, дученка! Ходай кичермәс сүз сөйлисең!..

— Беләм. Ходай кичермәс. Күрәм, син изге күңелле кеше, син кичерерсең.

— Кайтыйк, дученка. Вакыт. Әйдә, утыр,— дип, Наймуш карт аның иңбашына кагылды.— Тәмам өшегәнсең, хәсрәт аңыңны томалаган. Әйдә,— диде ул хатынны үзенәрәк тартып.

Мария аркасы белән картның күкрәгенә елышты да, кинәт тартылып, аңа күтәрелеп карады. Битенә алсулык йөгерде, якты күзендә рәнҗеш һәм газап чаткысы чагылды. Ул куян мамыгыннан бәйләнгән бияләйләрен алмаш-тилмәш салды, алар аның аяк астына төште. Наймуш карт аларны күтәрергә иелгән җиреннән хатынның тавышын ишетте:

— Иконаны баш очыма куярсын, бабайка. Югыйсә, табутсыз гөнаһ. Ярый, Богоматерь ярлыкар һәм саклар әле.

Аның тавышы шул кадәр дә ачык, чиста, нык иде ки, Наймушның бияләйләргә үрелгән кулы ярты юлда тукталып калды. Ул, хәле китеп, җиргә чүкте. Акылына зыян килгән мәллә моның, дип уйлады ул хатынга күтәрелеп карарга базмыйча. Алай дисәң, һич тә охшамаган. Әнә ничек катгый, риясыз әйтә бит. Әче җил ыргымнары арасында ул Мариянең тирән, өзек-өзек сулаганын ишетте һәм күз кырые белән аның ялангач кулын тун изүенә тыкканын шәйләде. «Туңа, күрәсең. Кулын җылыта. Яхшы, җылыт, балакай, җылыт»,— дип уйлады ул һәм, күңеленә куаныч, җиңеллек йөгергәнен тоеп, тураеп басты.

— Мин анда, чана башында, акча калдырдым. Алдагы хезмәтеңә күрә азрактыр, ләкин сәдака гына да түгел,— диде Мария.

Карт елмаеп, мөмкин кадәр ягымлырак булырга тырышып:

— Әйдәле, дученка, утыр, утыр. Өстеңә толып ябармын. Яңа түгел, мәгәр ышанычлы. Тиз җылынырсың,— диде, күбрәк сөйләве белән аның игътибрын җәлеп итәсе килде.

— Әйе, әйе, тиз,— диде хатын һәм вак кына калтыранган, салкыннан күшеккән, кызарып чыккан кулы белән изүеннән кара ефәк бауга тагылган нindидер сары тимер суырып чыгарды.

Наймуш тәмам тынычланды, төлке бүреген батырыбрак киде. Хәзер ул Марияне ашыктырмаска булды. «Игә килде бугай, бахыр,— дип уйлады ул,— бакчы, сәгатен карый».

Тимер кисәге хатынның күшеккән бармакларына буйсынмады. Аңа күкрәгенә кыскан иконадан арынырга туры килде. Икона аның затлы күннән тегелгән итек башына шуып төште дә сурәтле ягы белән туфрак түмгәгенә капланды. Шуннан соң Мария кабаланып, озын бармак очлары белән тимер кисәгенә ябышты, ак тырнакларын аның ярыгына каптырды.

— Ходай хакына кичерә күр, бабайка,— диде Мария каны качкан иренен калтыратып,— мин дә һичкемне каргамыйм.

— Онытт, дученка. Була торган хәл анысы. Җан ачысы телгә шайтан төкертә инде ул шулай. Теге сүзләреңне син үзең түгел, шайтан әйттерде аны.

Ниһаять, тимер кисәгенең капкачы ачылды. Хатын аны уң кулының бармак очларында торган килеш иелде дә, сулына бер уч кар йомарлап алды. Турайгач, аны авызына капты һәм, башын күтәреп, тимер кисәген капылт тел өстенә каплады.

— Яхшы...— диде ул иренен ялап.— Шулай яхшырак... Миңа карама...

Яшь хатынның нишләгәне, ниһаять, картның зиһененә барып җитте. Шулай да аның күңелендә моның чын түгеллегенә соңгы мыскал өмете бар иде әле. Хәлсез сыгылып төшкән һәм кар киртләченә

аркасын терәп утырган хатын тагын эндәшер, аяк очында яткан бияләйләренә үрелер, аның юату сүзләрен тыңлап, шуның берсе белән картның җыерчыклы битен кычыттырып һәм тундырып тәгәрәгән саран күз яшьләрен сөртеп алыр, агымлы итеп: «Кайтыйк инде, бабайка».— дияр кебек тоелды. Наймуш, шушы өмет чаткысына өстәмә тотнак, ышаныч табарга теләгәндәй, кояшка карады. Анда, кызыл кояш диңгезендә, җилгә каршы ялгыз козгын очып бара иде.

— Әй, балакай! Ата-анаңның бер газизе булгансыңдыр инде син, ә? — диде карт калтыранган һәм карлыккан тавыш белән.

Ул җирән йонлы калын бияләйләрен киндердән суккан кызыл чуклы эзәренә кыстырды да, Марияне турылап сузып салгач, чанадан көрәк алды һәм гомерендә беренче тапкыр яңа күмелгән каберне ачарга тотынды.

— Бисмиллаһи рахман иррахим...

Кул, аяк, бил мускулларын киереп, каерылып-каерылып авыр туфрак ыргытты ул. Күз яшен салкын җил киптерде, ә чигәсенә һәм борынына вак тир бәреп чыкты, чал сакал-мыегына сарган бәсне кайнар сулышы эретеп, бозга әйләндерде. Ул каберенең елгага караган ягыннан казып керде. Чөнки мужиклар кирпечләрне каршы яктан кабер чокырының читенә терәтеп өйделәр, ә ул казып төшкән якта ара шактый иде. Көпшәк җирне яртылаштан күбрәк, үз буе диярлек казып ыргыткач, Наймуш өскә менде, чанадагы тагарактан лом, мастерок алып, тагын чокырга төште, әле катып өлгермәгән измәне зарарламаска тырышып, стенага сузылып керердәй тишек уйды...

Аннары Марияне төшереп салды, кирпечләрне яңабаштан яхшылап тезде. Каберне әүвәлгечә күмгәч һәм эш коралларын җыйнагач, ул атының яңак асты чокырын кашып торды.

— Без яктыда әле, малкай,— дип сөйләнде ул.— Тегендә караңгы. Монда салкын, ә анда җылы. Аларга барыбер инде, тик безнең дә үләсебез бар әле... Алар алданрак китеп барды, безгә соңрак туры килер, билгеле... Хәер, нәкъ вакытында өлгерербез, малкай, нәкъ вакытында!..

Дилбегәсен тотып, ул үрәчә читенә елышып утырды һәм атны бая кайтып киткән атлар, чаналар, кешеләрдән калган, инде кар күмеп бетерә язган сукмакка — зират үре каплаган урыс авылы ягына борды.

Карт каеннарның ак шәрә ботакларында бүген генә әйләнеп кайткан кара каргалар бөрешеп утыра иде. Кошлар кинәт тузгып күтәрелделәр дә, кыйгачлап әйләнеп килгәч, чиркәү гөмбәзләренә кундылар.

— Сизәсеңме, малкай: яз килде,— диде Наймуш карт.— Яңа яз.

## X

...Җитмеш елның аргы ягыннан Солтан Наймушин белән Степан Масленниковка полковник Кулунчаков карап тора иде.

— Карале, Степан! — дип кабатлады Солтан.

Мәетнең карашыннан ышыкланырлык бернинди калкан юк, шулай ук аңа җитәргә комачауларлык һичнинди киртә дә юк иде. Ул караш компас угыдай тайпылышсыз иде, чөнки ул үлеләр дөньясы белән тереләр дөньясы арасында ачылды. Ә ул ара, мәгълүм ки, якты дөньяга караганда киңрәк, тирәнрәк: тормышны гына түгел, кеше язмышларын да сыйдыра.

Тәрәгә сөяп куелган полковник Кулунчаковның күзе ачылган иде!

«Карале, Степан!» — дип кычкырганчы, Солтан мәет чыраеның тимгел-тимгел куе кызыл таплар белән каплануын күрде. Йә оялган, йә нәфрәтләнгән, йә ярсыган диярсең. Гүя аларның мыскыллы мөгамәлә-

сен, җор төстә, кимсетеп, хурлап сөйләшүләрен күтәрә, кабул итә алмаган! Кызыл тимгелләр җәелде, таралды, аның бөтен чыраен тутырды. Ачуы, ярсуы чамадан тыш көчле эчке тетрәүгә әйләнеп, мәетнең чыраен бугандагы кебек зәңгәрләтте, баклажан төсенә кертте.

Шул чакта аның керфекләре кыймылдады, күзе ачыла башлады! Ул да түгел, ияге салынып төште.

Солтан үзен сәерсендергән чит, үткер карашны шушы мәлдә тойды да инде.

Солтан Наймушин ул зәңгәр карашның үз җаны аша да узганын кичерде. Шул рәвешчә, мәһабәт койрыклары белән планеталарга орынып диярлек, галәм дәрвишләре — кометалар очып уза. Ул, полковникның карашын әләктереп алып, кире кайтарырга теләгәндәй, күккә карады. Күк йөзе зәп-зәңгәр иде. Ничек яратылса, шул төсендә. Ә кешеләрнең ул күккә карашлары төрлечә: кем яшәү күзе белән, кем үлем күзе белән карый...

Мәет минут эчендә каралып чыкты. Солтан моны вөҗдан газабы кичереп диярлек, моның нинди куркыныч, җан өшеткеч күренеш икәнен җаны белән тоеп кына түгел, аңы белән дә аңлап күзәтте.

— Нигә эчмисең, полковник? — диде Степан Масленников кабер тынлыгын чигендереп.— А, беләм: син кан эчеп туйгансың... Аның чырае нигә каралганын беләсеңме, яшьти?

Солтан иңбашын җыерды, бер кәлимә сүз катасы килмәде.

— Безнең һава килешмәде. Болар табут һавасында гына бозылмый. Юл куйсалар, мин моның ишеләр яткан һәммә табутларны тузгытып ташлар идем.

— Кабер актару егет эше түгел.

— Кемдер кара эш эшләргә тиеш.

— Нигә?

— Җир каралмасын өчен.

Степан мәетнең учына кыстырылган стаканны алды, селтәнеп, табутның кургаш капкачына орды. Солтан зелпе куагы астыннан пырылдап кошлар күтәрелгәнне ишетте. Степан, янга чыгып, агач тәрене алга этәрде, мәет табутына йөзтүбән капланды. Күкрәгендәге тәреләре тонык кына зыңлап алды. Полковникның кара итекләре генә тырпаеп калды.

— Аудиенция тәмам,— диде Степан.

Ул, мәетнең баш ягына басып, аны үз урынына тартып яткырды. Нидер уйлап торгач, кулын тыгып, тәреләрен йолкып чыгарды һәм, күлмәген киеп, аларны үз түшенә такты.

— Честь имею! — диде ул үкчәсен үкчәгә бәргәндәй итеп.—Булыш, яшьти.

Табутның капкачларын яптылар. Кара-каршы басып күтәрделәр. Солтан склепка таба атламакчы иде, Степан туктатты.

— А, юк,— диде ул.— Мин аны ераккарак сөрәм. Инде минем хөкемне татысын... Елгага аны, елгага! Мәңгелек сәфәргә!

Һәм алар, тиз тиңентен кереп, табутны суга салдылар. Степан аны яланаягы белән эчкәре этеп җибәрде. Табут елга агымына буйсынып агып китте. Аңа күләгәсе иярде.

Солтан ярга чыккач:

— Ә дулкын кагып чыгарса? — диде.

— Аны һәркем бу ярдан да, теге ярдан да тибеп, ары озатачак,— диде Степан.

Солтан ком алып, аны учтан учка агызды. «Бу ярдан да, теге ярдан да,— дип уйлады ул.— Яшәгән дә инде кеше — ни тегендә, ни монда тукталыр урыны юк. Ни җирдә, ни күктә. Галәмдәге «черная дыра» кебек: бар да, юк та...» Ком бөртекләре аның учыннан коелып бетте, таш араларында югалды.

Су коендылар. Киенделәр, ярдагы әйберләрне көймәгә төяделәр.

Степан көймә моторын кабызды. Утырышып, инеш тамагына кереп киткәндә, Солтан артка борылып карады. Кара табут көймә дулкыннарында чайкала иде.

Бу юлы Солтан үзләрен озатып калган карашны тоймады.

**Икенче кисәк**

## Кояшка таба

### 1

*Күктә йолдызлар, җирдә кешеләр язмышы, елгалар, елга төпләрендә ком бөртекләре ага да ага, ага да ага. Болардан да астарак тагын бер елга ага икән әле. Димәк, алар икәү: бер елга — Кояш астында, икенче елга — Җир астында. Таш катламнары арасында ачылган тар ярыктан кысып чыгарган салкын чишмәсе аша Җир астындагы елга Кояш астындагы елгага әйтте:*

*«Әй син, Кояш астындагы Сылу елга, мине ишет,— диде.— Мин синең дөньяда барлыгыңны бик күптәннән белә идем. Дөнья йөзенә баккан беренче чишмәңнән башлап, Зур суга тоташкан тын култыгыңа кадәр мин синең янәшәңдә агам була инде. Җиде көн, җиде төн буена синең һәр борылышыңны диярлек озата барам, син Зур суга кушылгач та мин бер көн буена синең юлдашың әле. Аннары безнең юлларыбыз аерыла: син Зур елга атлы анаң кочагына елышасың, ә мин, сине кайдадыр эзләп табармын, очратырмын, сүземне әйтермен һәм, ниһаять, үз кочагыма алырмын дигән өметкә ышанып, атам — Караңгылык патшалыгындагы озын-озак сәфәремне дәвам итәм. Шулай агам да агам, агам да агам инде. Арып-талчыгып, Зур диңгездәге соңгы тукталышыма барып җиткәч тә мин сине эзлим, и Сылу елга! Тик таба алмыйм. Фәкать яктылык патшалыгына томан булып, болытлар булып таралган ак сулышыңны гына тоям инде. Шунда синең зәңгәр күзле чишмәләреңне, чәчең булып кыштырдаган зифа камышларыңны, балыклар иркенләп уйнашкан тын чоңгылларыңны, сыгылмалы борылышларыңны, тау күкрәкләре арасыннан җиде көн, җиде төн аккан сылу буеңны сагынуыма түзә алмыйча, мин үргый-үргый бер елап алам. Сагышымның ачысы Зур диңгезгә тозлы күз яшем булып тарала да төпкә тона. Ә мин үзем зәңгәр дулкыннарга әвереләм дә, ярдан ярга бәрелә-сугыла, сине эзлим, сине эзлим. Утрауларның җылы кыяларын, су төбендәге салкын тауларның түбәләрен кагам, Зур диңгезнең тар бугазын үтеп, Чиксез дәрьяларга барып чыгам. Дәртем айкала да чайкала, ә дәрманым басылганнан-басыла, сүрелгәннән-сүрелә. Син һичкайда юксың, юксың инде. Сине кайчандыр, кайдадыр табарыма өметем тәмам өзелгәч, «Аһ!» дигән тыннары белән Яктылык патшасы мине үзенә күтәрә инде. Ә бу чакта синең томанга әверелгән ак сулышыңны көчле җилләр һәм кара болытлар ерак-еракларга куып киткән була инде. Шуннан соң көмеш түбәтәйле тауларга карыйкарый, җем-җем иткән нурлы йолдызларга бага-бага, сине ияртеп киткән кара болытларның кайсы тарафларга юнәлгәнен җитез җилләрдән сораша-сораша, очар кошларның Җир белән Кояш арасындагы хәтәр юлларын буйлый-буйлый, мин яңадан атам — Караңгылык патшасы биләмәләренә әйләнеп кайтам. Шунда мин тагын синең тау итәкләренә орынып типкән йөрәгең тавышын ишетәм: йолдызлар чумып-чумып уйный торган күзләреңне уйлыйм, ташлар булып ташларны елаткан чыңлы җырыңны тыңлыйм; суларыңны эчкән сандугачлардан көнлим инде. Шунда мин синең зәңгәрсу йөзеңә, көмеш*

*тәнеңә кира кутырлар булып ябышучы җир майлары агызган, малтуар тиресләре кушкан, чуп-чар түккән кешеләргә нәфрәтләнәм.*

*Ә син, Кояш астындагы Сылу елга, хәзер синең Олы борылышыңа минем йөрәгемнән салкын чишмә булып бәреп чыккан сүземне тыңла! Сине юксынуым, кызгануым ахыр чиккә җитте инде. Караңгы ярларыма сыя алмаган хисләремнең барысын да йөрәгемә туплап, мин бу иртәне гайрәтле күкрәгемне киерермен дә, караңгы күгем булып яткан тау-ташларны тетрәтә-тетрәтә сиңа таба сукмагымны салырмын. Юллар ачылыр, ә син көт мине. Көт син мине. Әй син, Кояш астындагы Сылу елга, ялгызың гына акма, миңа кил. Минем дә синеке шикелле җәйлы ярларым, тын чоңгылларым бар. Минем синдә булмаган иркен мәгарәләрем, шаулы шарламаларым, караңгы күгемнән асылынып торган таш сөңге очларында ялкынлы зөбәрҗәтләрем, чоңгылларым төпләренә җыелган уч-уч алтын комнарым бар. Боларның барысы да, барысы да ошбу таңнан синекеләр булсын инде».*

*Кояш астындагы елга Җир астындагы елганың таш катламнары арасында ачылган тар ярыктан бәреп чыккан чишмәсе аша болай җавап кайтарды:*

*«Әй син, Җир астындагы Дәртле елга, инде мине ишет! Миңа да хәзер синең дөньяда барлыгың билгеле инде. Җиде көн, җиде төн аккан, шуңа өстәп, анам — Зур елгага кушылгач та бер көн буена дәвам иткән бөтен буем белән мин дә бетмәс-төкәнмәс вакытлардан бирле гел түбәнгә — сиңа якынрак булган җирләргә таба тартылам. Икебезнең арадагы калын балчык, каты таш катламнарын, йолдызлардан да күбрәк сандагы ком бөртекләренә әвереләдереп, мин әллә кайларга таратам. Мин түбәнтен төшәм дә төшәм, ә ярларым биегәйгәннән-биегәя бара. Минем шулай киңәйгәннән-киңәясем, тирәнәйгәннән-тирәнәясем һәм үземә Якты дөнья астындагы бар суларны сыйдырасым килә. Акты суым, үтте вакыт, ә мине өр-яңадан ярларымның читләренә кайтардылар: минем билемә язгы ташуларым да җиңалмаслык буа дигән таш бер пута салдылар. Ярларымнан аштырдылар, күпме җирне суым белән бастырдылар: хәзер минем иркен, яшел үзәннәрем ләм баскан су төпләренә әверелде; җырчы кошлар оя корган әрәмәләрем тәмам корып бетте; бал кортлары татлы сулар җыйган чуар чәчәкләр әллә кайчан сулды инде; кыр казлары язын-көзен канат кага, ә торналар бии торган тигезлекләр тук бакалар өе инде; күпме авыл нигезләрен, күпме зират каберләрен вак комнарга әверелдереп, чиксез дөнья кочагына тараттым, җәйдем. Уртабызда — мин төшә алмаслык, ә син менә алмаслык ара. Минем өметем, синең теләгең икебезнең дә сулары юа алмаслык кара инде».*

*Җир астындагы елга Кояш астындагы елгага әйтте:*

*«Әй син, Кояш астындагы Сылу елга, миңа ышан,— диде.— Бу дөньяда яктылыктан караңгылыкка, караңгылыктан яктылыкка акмый торган сулар, ишетелми торган сүзләр юк инде. Бу дөньяда араларны якынайткан, караларны юкка чыгарган М ә х ә б б ә т бар...»*

*Кояш астындагы елга Җир астындагы елганың таш катламнары арасында ачылган тар ярык аша бәреп чыккан салкын чишмәсе аркылы янә мондый җавабын бирде:*

*«Әй син, Җир астындагы Дәртле елга, минем белән килеш инде,— диде.— Бу дөньяда араларны тагын да ерагайткан, караларны тагын да каралткан Н ә ф р ә т тә бар. Синең дә ярларың җәйлыдыр, чишмәләрең җырлыдыр, борылышларың текәдер, чоңгылларың тындыр. Мин синең үземдә булмаган мәгарәләрең иркенлегенә, шарламаларың шавына, зөбәрҗәтләреңнең асыллыгына, чоңгылларың төпләрендәге алтын комнарыңның сары яктылыгына мөкиббәнмен. Икәү бергә араларны тизрәк үтү, һәммә караларны чистарак юу җиңелрәк тә булыр иде. Әмма бу дөнья мине тикмәгә генә Кояш*

*астындагы Сылу елга итеп яратмагандыр лабаса. Сиңа китсәм, Кояш асты нишләр инде? Чишмәләрем кибәр, ярларым коргаксып җимерелер, ишелер, камышларым саргаешып корыр, балыкларым сусар, кошларым тынар, киекләрем качар, комнарым тузан булып очар инде. Ә иң мөһиме: язгы-җәйге айлы кичләрдә парлашып килеп камышларымнан да назлырак пышылдашкан яшьләр, җәйге челләләрдә балыкларымнан да елгыррак йөзгән балалар, сагынышкан-аерылышкан чакларында сандугачларымнан да моңлырак җырлаган, Якты дөньяга килгән бала-чагаларын суымда коендырган, ата-аналары соңгы сулыш алыр алдыннан аларның иреннәренә каурый белән чишмәләремнең салкын тамчыларын тидергән ир-ат, хатын-кыз нишләр? Сиңа китсәм, боларның һәммәсенең миңа нәфрәте иксез-чиксез булыр иде. Язмышлардан узмыш юктыр; шулай икән, мин — Кояш астындагы Сылу елга, ә син Җир астындагы Дәртле елга килеш үз ярларыбызда гына агыйк инде».*

## II

Масленниковларның умарталы алма бакчасы. Шуның артындагы яңа мунча янына килеп туктагач, Солтан Наймушин артка — кояш нурларында җемелдәп яткан инешкә таба борылып:

— Без т е г е н д ә нәрсәдер оныттык,— диде.

Степан моторны күтәртеп куйган, такта басмага чыгып, көймәне чылбырлап бәйләргә җыена иде. Ул, көймә төбенә караш ташлап:

— Бау белән ломны онытканбыз... Төкер сәнә! Тимер-томыр беткәнме? — диде.

— Каберне томаларга онытканбыз, Степан.

— Шулай икән шул,— диде Степан башын кашып.— Ярый, көн бетмәгән. Өлгерербез. Хәзер черем итеп алырга кирәк.

— Нинди йокы. Бабайлар белән умарталыкка барасым бар минем. Шуңа кадәр томалап меникме әллә?

— Кем күрә соң аны? Анда эт тә йөрми. Чәчү вакыты.

— Яхшы түгел. Болай да арттырып ташладык... Өстә тормасын. Йә төшкә керер...

— Бәйләнчек чебен белән бер икәнсең! — дип көлде Степан.— Утыр әйдә!

Руль төбенә утырып, ул көймә моторын суга төшереп кабызды. Көймә янтаеп борылды да, борынын чөеп, алга ыргылды.

Инеш култыгына барып җитә алмадылар: мотор ике-өч тапкыр төчкеренде дә сүнде. Көймә су иркендә килеш акрын гына ага башлады. Ул кузгаткан дулкыннар яр буендагы кыякларга, талларга какты. Каршыдагы биек ярлы ерганак тамагыннан ялгыз челән күтәрелеп, салмак кына зур су тарафына очты.

— Килеп җиттек! — диде Степан сүгенеп.

— Ватылдыкмыни?

— Бензины беткән лә! Ишкәк тә юк... Инде менә мотор калакларын киптереп утыр...

Степан гадәтенчә ах-вах килде, кабаланды, чын-чынлап пошынды, юан ботларын чапкалады.

— Барып җитә яздык инде,— диде Солтан.

— Җитә яздык та бит... кайтасы бар ич әле! — диде Степан һәм сандыктан канистр алып селеккәләде.— Тамчысы да калмаган ичмасам!

— Алайса син авылдан бензин алып кил, ә мин т е г е н д ә бара торыйм.

— Ник авылга? Асфальт юл якынрак. Берәр шофер бирер әле. Башта, әйдә, каберне томалап киләбез.

Ян-яктан уч белән ишә-ишә ярга чыктылар. Көймәне ләмгә тартып менгерделәр, кеше-кара күзеннән яшереп, өстенә ике-өч тал чыбыгы сындырып салдылар.

Зиратка турылай суктырып киттеләр. Туфрак кипкән инде, аяк асты коры. Кыр читенә өеп куелган торф таулары арасындагы эрәмәдән өч кыр үрдәге күтәрелде дә, киң әйләнеш ясап кайткач, кире кунды. Тургайлар сайрый, кайдадыр урман күгәрчене гөрелди иде. Солтан ялтырап яткан түгәрәк күл читендәге былтыргы камыш арасында бака чиләне шәйләп, бераз шуңа карап торды. Кош аны әллә күрде, әллә юк — сәламләгән кебек, озын муенын салмак кына ян-якка чайкады.

Киртләч яр буенча ары киттеләр. Сул якта, яктырып, елга күзгесе ачылды.

Степанның итеге лаштыр-лоштыр килә. Ул нидер әйтте, Солтан ишетмәде.

— Нәрсә дидең? — дип сорады ул.

— Теге хатынны әйтәм әле.

— Кайсы?

— Кабердәгене инде! Сөякләр иясе... Полковник Кулунчаковны күмгәч, кабере өстендә агу эчкән.

Һавадан зират исе килә иде инде. Соры комда кабырчыклардан купкан перламутр бөртекләре җемелдәшә.

— Ник дәшмисең? — дип сорады Степан.

— Килеп җиттек.

Борылышны узуга, зиһенне томалардай тамашага тап булдылар. Бая алар агызып җибәргән табут, буе белән каралып, склеп турысында ята иде!

Исләре-акыллары китте: туктап, юлдашлар бер-берсенә караштылар. Шикләнгән шикелле, табутны читтән урап узгач, Степан тубыктан суга кереп басты.

— Ә су ага! — дип кычкырды ул.

— Акмый нишләсен тагын?

— Аска таба ага, кирегә түгел!

Солтан, чит кеше юк микән дип, ялт-йолт тирә-юньне күзәтә иде, кычкырып көлеп җибәрде.

— Нигә ыржаясың?! — диде Степан судан чыгып.— Агып киткәнен үз күзебез белән карап калдык ич!

— Үзе йөзеп кайткандыр. Паспорты юк, пропискасы кабердә. Кая барсын ул?

— Әһә, йөзеп... Көймәсе бар, ишкәген каян алды икән соң? — дип, Степан табутны этеп карады. Ул баш ягы белән комда нык ята иде. Алар онытып калдырган бау — капкач өстендә, юеш.

Степан сүс бауны кулына алды, яңа күргәндәй, әйләндергәләп карады.

— Сөйрәп китергәннәр... Кем? Әллә шул арада бурлаклар яллап өлгергәнме? — диде ул һәм табутка тибеп алды.— Яхшы чакта апартаментына олактырырга кирәк моны, яшьти. Бакча башыңа к... леп туктарга күп сорамас бу үҗәт!

— Кунакка дәшәрсең. Мунча керерсез. Арканны чабындырыр.

Степан бауны ачу белән ташка орды.

— Кемдер сөйрәп китергән ич инде аны?!

Кемнедер куып җитәргә ашкынган сыман, ул ярга ташланды, ләкин ул турыдан менә алмады, аяк астыннан ком-таш ишелеп, һәр талпынышы саен кирегә шуды. Солтан ярдәме белән өскә мәнгәч, ул аңа кулын сузды, үрмәләргә булышты.

Һичкем юк иде. Чиркәү янын урадылар, үр кашына күтәрелделәр. Солтан хәтта агач ябалдашларына да күз атты.

— Шайтан эше бу! — диде Степан.

Чиркәү эчен карап чыккач, авыш нарат янына әйләнеп кайттылар. Степан үзен курку биләгәнен тойды. Ә Солтан ояла иде.

— Дөрестән дә, безне кемдер күзәтеп торган булса? — дип сорады Солтан.

«Ә күзәтеп тормаса, оят булмас идеме? — дип уйлады ул.— Мин үз-үземне күзәтмәдеммени? Үземнән дә яхшырак итеп, мине кем күзәтсен?»

Ул йөрәгенең сулкылдап тибә башлаганын тойды. Иреннәре кипте. Су читенә йөгереп килеп, ул хайваннар шикелле аяк-кулына таянды да болганчык су эчте. Кояшта каралып яткан табут аны куркыта һәм жирәндерә иде инде. Табутны склепка кертеп томаламыйча, ул моннан беркая да китә алмаганын аңлады. Табут аның үткәнен һәм киләчәген агулаячак, баш очындагы кояшны гына түгел, бәлки төнге йолдызларны да куләгәләп торачак иде. Баскан җирен баткаклык итәр, ә сулыйсы һаваны боз хәленә китерер. Ул шушыннан башка һәр нәрсәне онытты, хәрәкәтсез калды, карашы анда-монда төште, тик берни күрмәде, бер тавыш та ишетмәде. Дөнья кечерәйде, табут зурайганнан-зурайды шикелле. Вакыт туктады.

Кинәт ул бүген бер тапкыр да сәгатькә карамаганын исенә төшерде. Кул сәгатен ике кат такты бит инде: иртән киенгәндә һәм бая су коенгач. Ә вакытның кирәге чыкмаган,димәк. Яшәмәгән кебек. Яшәмәгәннәргә вакыт нигә кирәк?

«Яшәмәгәннәргә? — дип уйлады Солтан Наймушин, бу уен чит кешедән ишеткән сыман.— Мин бүген яшәмиммени? Күрәм бит: су ага, нарат авыш, учак сүнгән, табут кара...»

Ул сәгатенә карарга тагын онытты. Аңа кинәт бу табут эчендә үзе томаланып яткандыр һәм мең елдан соң яңа гына якты дөньяга чыгып баскандыр кебек тоелды. Бабасы Кадрәкне, дәү бабасы Чанышны чакырып кычкырасы килде. Алар, бәлки, умарталыкка килеп җиткәннәрдер инде, оныкларын көтәләрдер... «Әни!» — дип кычкырудан да мәгънә юк. Атасы тагын да ераграк — әйләнеп кайтмый торган җирдә... Камәрия дә килмәде. Әле дә ярый килмәде. Ул куркыр иде. «Һәм минем бу хурлыкта калуымны кичерә алмас иде. Миңа аның тагын бер тапкыр к и ч е р ү е һич тә кирәк түгел инде!

...Кабергә тагын бер тапкыр керүе аннан табутны алып чыгуга караганда күпкә авыррак булды. Әйтерсең лә монда алар түгел, бәлки бүтән, аларга бөтенләй билгесез кешеләр, ә алар читтән күзәтүчеләр генә. Ул гынамы соң: Солтанга үзенең шул ч и т т ә н к ү з ә т ү л ә р е н дә кемдер карап тора кебек тоелды.

— Йолкып ат әле шул «тавык тәпиләрен»! — дип кычкырды ул Степанга. Тимер тәреләрнең ара-тирә зыңлап алулары Солтанның ачуын китерде.

— Торсыннар,— диде Степан тыныч кына.— Ашарга сорамыйлар ич.

Табутны, кабердән чыгаргандагы шикелле үк, бау белән урап, аяк башыннан тишеккә күтәрделәр, элекке урынына урнаштырдылар. Тирләп беттеләр, сулулары капты. Аларны башлары турысыннан склеп гөмбәзе баса, ә җаннарына кургашындай авыр тынлык иңә иде. Монда, кабер эчендә, бер генә тере җан калган кебек: Алла анасының бөек Казан исеме белән өретелгән иконасындагы сурәте. Солтан маңгаендагы салкын тирне сөрткәндә беләге астыннан аның карашы белән очрашты.

— Йә,— диде Степан.— утырышыйк.

— Монда калырга җыенмыйсыңдыр ич? Тизрәк таярга кирәк!

— Юлга чыгар алдыннан диюем. Ә юл озын. Безнең яшисебез бар әле.

Степан табутка утырды.

— Бигайбә, полковник,— диде ул учы белән капкачка шапылдаткалап,— үпкәләп калма. Без синдә кунакта булдык, син — бездә. Күрдеңме: дөньяда без бар. Без монда, җир астында да бар. Шулай булгач, тынычланып ятам димә, агайне.

Ул басты. Кирпеч ватыгы алып, тишеккә каршы яктагы стенага тырнап яза башлады.

«Здесь были Степан и Султан»,— дип укыды Солтан.

— Көнен куйыйммы?— дип сорады Степан.

— Монда көн дә, вакыт та юк. Монда мәңгелек кенә бар.

— Ярый, алайса болай...

Икенче сүз итеп, Степан яңа сүзләр тырнады:

«XX век от Р. Х.»

— Эрхасы ни?

— От рождества Христова...— дигәч, Степан, хушлашкан шикелле, карашы белән кабер эчен айкап чыкты.— Вакыт. Бер нәрсә дә онытмыйбызмы?

— Лом.

— Әйе, полковникка калдырырга ярамас. Казып чыкмасын тагын,— дип көлде Степан һәм ломны тышка ыргытты.

— Бетте бугай,— диде Солтан.

— Ә үзебез? Үзебезне онытып калдырмыйк тагын!

Башта әкрен генә, тора-бара бер-берсенең иңбашларына суккалап, этешә-төртешә, тыела алмыйча көләргә тотындылар.

— Үзебезне онытып?! Кабердә! Ну, уйлап та чыгарасың, корт чаккыры!

Аларның көлешүе кабергә генә сыймады, су ташкыны шикелле, тышка бәреп чыкты. Кояш яктырткан авызын ачып, склеп, ә аның белән бергә ташландык зират үзе сөяк-санаклары белән шаркылдап көләдер сыман иде. Көлү тавышын басарга, зиратны тынычландырырга теләгәндәй, узып баручы «Метеор» кузгаткан озын, киң дулкыннар ярга кагарга кереште.

Көлү тавышы зур ташны тотып торган ком бөртекләренең кайсысындыр урыныннан кузгатты һәм ул, үз артыннан башка ком бөртекләрен дә ияртеп, түбәнгә шуа башлады. Комбайн бункерыннан аккан ашлык кебек, тыгыз, йөгерек агым хасил булды. Таш асты бушаганнан-бушады. Ул, таянычын югалтып, урыныннан купты, янтая, мәтәлә башлады, өстән үткән агач тамырын үз авырлыгы белән шартлатып өзде. Наратның кәүсәсе тартылып, ыңгырашып куйды.

## III

*Ата сандугачның җим табарга киткән чагы иде. Ана сандугач йомыркаларын басып утырды. Ул көтмәгәндә үз оясының калтыравын тоеп алды, куркудан йөрәге купты. Җир белән бергә зелпе куагының бер өлеше һәм оя авыша башлады. Сандугачның бөтен тәне белән югарыга омтыласы килде, ләкин ул канатларын ачмады. Җирне турыларга, тотып калырга теләгәндәй, оясына төшәлгән үлән сабакларын томшыгы белән кысты, ләкин урыныннан купмады. Югыйсә йомыркаларының тәгәрисен, коелышасын сизенде. Ул аларны канатлары белән ояга кысты, куркуыннан ата сандугачны чакырып аваз салырга да онытты.*

*Аннары ояның бушлыкка очканын тойды. Ләкин ул шундук убыла башлаган зур ташка төшеп, бер генә мизгелгә тотрыклыланды, әмма тагын хәрәкәткә килде һәм янга, инде кире якка шуды. Соңгы мәлдә сандугач ояны ташларга, нарат агачы ябалдашлары арасыннан ертык булып күренгән, тик хәвефсез тоелган зәңгәр күккә ашкынмакчы булган иде. Өлгермәде. Әйләнә-тирәне ком кыштырдавы, таш*

*чыкырдавы, агач, үлән тамырлары өзелгән тавышлар, тузан урады. Ул ата сандугачның, томшыгына кыстырган сары күбәләкне ташлап, ярдәмгә ашыгу, шөбһә, коткару, ләкин чарасыз калу белән тулып торган сызгыруын гына ишетеп калды. Ана сандугачның кабарынган йоннары, канат каурыйлары арасына туфрак, ком коелды. Аннары күз алдын таштай авыр кара караңгылык басты.*

Дуслар склеп тишегән күләгә каплавын күрделәр, ә нарат агачының ауган чакта инде хәрәкәтсез калган таш өстенә авуын һәм аны кабер стенасына кысып, каплап куюын күз алдына китерә алмадылар. Эчкә ком, туфрак, вак ташлар коелды, тузан тулды. Кинәттән караңгылык, тынлык иңде.

— Нәрсә бу?— дип кычкырды Степан.

Солтан:

— Син кайда?— дип аваз салды. Әкрен генә әйтсә дә, тавышы яңгырап чыкты.

— Монда. Ә син?

— Килеп життек. Теге деньяда!

— С новосельем!

Степан үкереп диярлек төчкереп җибәрде.

— Озак яшә!— диде Солтан һәм, ниндидер йомшак нәрсәнең битенә кагылып узуыннан сискәнеп, артка тайпылды, табутка утырды.— Монда нидер оча,— диде ул пырылдаган авазга сагаеп.

— Фәрештәдер,— диде Степан. Ул арлы-бирле йөренде, аягы астында идәндәге сөякләр шылтырады. Шул сөякләр өстеннән мүкәләп узганнан соң, тишекне кармалап тапты да, ташны этеп карады, көче җитмәде.— Булыш әле,— диде ул ыңгырашып.

Солтан дусты янына чүкте, башы белән кытыршы стенага терәлгән килеш, ике куллап ташны кузгатырга тырышты.

Ләкин таш, ябыштырылган диярсең, селкенеп тә карамады. Берберсенә әйтмәсәләр дә, моны сизгәч, аларга эсселе-суыклы булып китте. Хәлдән таеп, алар ничек туры килсә, шулай кирпечләргә утырдылар. Степан кулын тишек тирәли йөртеп чыкты. Урыны-урыны белән тышкы җылылык бәрелеп тора иде. «Ярый әле, һава керерлек икән»,— дип уйлады ул.

Ә кош очты да очты әле.

— Эх, лом булса!— диде Степан.

— Чыккач алырсың.

— Чыккач!— дип кычкырды Степан һәм ярсып урыныннан торды, тагын ташка ташланды.— Чыккач!.. Чыккач...— дия-дия, ул йодрыгы белән стенага төйде.

— Җитәр, Степа! Ишетәсеңме?!

Степан стенага терәлеп утырды. Аның калтыранган, суелып канаган, тирләгән бармаклары ниндидер җылымса, түгәрәк ташларга орынды. Ул аларның берсен борынына якынайтып, иснәп карады — нәрсә бу?

— Шырпы кабыз әле,— диде ул һәм бармак очларындагы түгәрәк «ташның» кош йомыркасы икәнлеген аңлады. Ул аны сак кына — әйтерсең утлы күмер!— учына салды.

Солтан шырпы кабызды. Күзе төшкән беренче нәрсә икона булды. Икона да түгел, бәлки аңа кунган соргылт-көрән кош, аның дымсу кара күзе. Кош уттан өрекмәде, кузгалмады. Солтан аның сандугач икәнен таныды. Кабердә сандугач күрү аны шулкадәр дулкынландырды ки, ул иконага төшерелгән хатын һәм бала сурәтен дә, идәндәге баш сөягенең күз тишекләренә чигенгән караңгылыкны да, ут яктысында алтынланып күренгән табутны да көзгедә чагылган яисә төшенә кергән кебек итеп кенә күрде.

— Бытбылдык йомыркасы ашаганың бармы?— диде Степан.

— Нигә бытбылдыкныкы әле, тавыкныкы түгел?

— Тавыкныкы кетәклектә булганга. Хәзергә минем учымда кош йомыркасы.

— Урынына куй. Исең сеңмәсен,— диде Солтан тыныч кына.— Кошлар кеше кагылган йомыркаларны ташлыйлар.

Ул, янып бетеп бара торган шырпыны әйләндереп, күмерле башыннан тотты. Ут сүрелде дә сүнде. Шундый караңгы, хәтта күзне авырттыра шикелле. Тән дә юк, җан да юк. Эрегәнсеңдер сыман. Ни тере, ни үле.

Ут сүнгәч, кош тагын пырылдап оча башлады. Аның әллә стенага, әллә табутка бәрелгәне ишетелде.

Солтан бүтән шырпы алып кабызды. Сандугач тагын шунда — иконага килеп кунды, әйтерсең андагы сурәттән яклау сорый иде.

— Исең сеңмәсен дисең инде... Менә бераз эчең шиңсен әле, карарбыз,— диде Степан.

— Нәрсә, нәрсә?

— Син ничектер, ә минем яшисем килә әле. Яшәгәч, ашыйсы да килер...

— Сандугач йомыркасынмы?!

— Кирәк булса, үзен дә. Гап-гади нәрсә ул. Гадәттән тыш хәлләрдә исән калу дип атала.

— Сандугач ашапмы?

— Суга нишләрбез менә — анысын белмим әле.

Солтан шаккатты. Янып беткән шырпы бармагын пешерде. Кабаланып, шырпы кабын тагын ачты.

— Ә син бушка шырпы ягуыңны бетер. Бер төнгә кызлар кочагына кермәгәнсең. Боеприпас урынына гына тотасы.

— Караңгыда утырыйкмыни?

— Монда озак утыра алмассың, парин. Полковниктан хуш исләр килә дә башлады инде...

— Каберләрнең керү ишеге генә бар. Күрәсең ич, чыгу юлы юк.

— Табарга туры килер, парин.

Урыннарыннан тордылар. Кош тагын куркынып очынды.

*Сандугач үз оясына килеп кунды. Ул оясын теләсә кайда һәм караңгылыкта да таба алыр иде. Канатларының каурыйлары һәм очлары, түшендәге, корсагындагы йоннары белән ул йомыркаларын барлады; кабарынып һәм кузгалгалап, аларга кунарга өлгергән тузан элпәсен сөртте, ком бөртекләрен какты, йомыркалар җылы иде әле. Ул моны сулык-сулык типкән йөрәге, кайнар каны белән тойды. Ян-якка каерылган канатларын кыса төште, йомыркаларын бер-берсенә якын җыйнап, бөтен тәне белән ояга җайлап ятты. Оя һәм йомыркаларының исән-имин икәнлеген сизгәч, аның шул хакта тышта калган бәгырь дустына хәбәр итәсе килде. Ләкин ниндидер шом аның күкрәген кыса, һавадагы коры тузан аңкавын кыра. Аның йөрәк тибеше һәм сулышы күңеле төбендә талгып калган моң белән тәңгәл түгел иде. Ә сайрыйсы килә, бик килә. Сайрар шатлыгы бар. Җанын сөендергән, канын җылыткан, күз нурын яктырткан шатлыгы бар: оясы, йомыркалары исән-сау. Ул аларның эчке җылысын, үзе генә белгән терелеген тоя, анда тиешле вакытта борнйысы җан ияләрен сизә, алар белән үз телендә сөйләшә. Шуның өстенә җан дустын юксыну, аның өчен пошыну, курку йөрәген парә-парә телгәли. Бер сайрап җибәрсә, дусты әллә кайлардан — ерак-ераклардан, уталмаслык киртәләр аша янына килеп җитәр кебек.*

*Ләкин сандугач аваз салмады. Кинәт кочып алган караңгылык сагайтты аны. Ул янәшәдәге ике җан иясенең тирән, тынычсыз сулышларына, сак хәрәкәтләренә ияреп, һавадагы тузан бөртекләренең тәртипсез очынуын, үзенең канатларына, томшыгына утыруын тойды.*

*Җир убылган чакта, оясы түбән иңгән, көнне төн басканы, якты дөнья-ның рәхәт яки хәтәр авазлары кинәт тынган, юкка чыккан мизгелдә ул курыккан, шуңа күрә бәләкәй гәүдәсе дер-дер килә иде.*

*Ул үзе дә белми торган, ләкин өзелмәскә тиешле* д ә в а м н ы ң *туктап калу ихтималын кичерде. Аңысы нәкъ ул дөньяга килгән нокта-га әйләнеп кайтканнан соң булды.*

*Сызылып таң атканда кайтып төшкәч, ул үзенең туган җирен та-нымады, аның юкка чыкканлыгын күрде. Беренче тапкыр күзен ачкан һәм анасының сайравын тыңлаган чакта аның тирәсендәге һәммә нәрсә ниндидер тынычлык, сафлык белән өретелгән иде. Ул хуш исләр бөр-кеп торган карлыган куагы төбендә борнап чыккан, күзен дә шунда ач-кан, анасы сайравын да шунда ишеткән иде. Аннары, тәненә йомшак йоннар чыгып, канаты ныгыгач һәм беренче тапкыр тирән күккә чум-гач, туган җиренең гөлбакча икәнлеген күрде. Шул гөлбакчада ул җим ауларга өйрәнде. Алар бишәү үстеләр. Карлыганның яшел алкалары башта кызарды, инде алар ата-аналарыннан башка да* я ш и а л а *башлагач, каралды. Ә зуррак агачлары яшел шарлар белән тулганнан-тула бардылар, алсуландылар, яңгыр вакытларында, томанлы иртә-ләрдә татлы ис бөркеделәр. Сандугачлар көтүгә җыелып, ерак юлга чыгар алдыннан әлеге җимешләр дә акрынлап юкка чыкты: кешеләр аларны бергә җыйдылар һәм каядыр алып киттеләр... Бакча моңаеп, бушап калды. Яфраклар корыланды, катыланды, саргайды...*

*Очып китәсе төнне сандугач йолдызларны күзәтте, бу урынның кайда икәнлеген күңеленә, күз нурына беркетеп куйды...*

*Ни аяныч, ерак сәфәреннән әйләнеп кайткач, ул боларның берсен дә тапмады. Әнкелтем исле карлыганнар кырылган, кызыл түшле ал-малар үскән җир тап-такыр. Инеш буена койма корганнар, ак түбәле озын лапас ясаганнар, аның каршысына баганалар утыртып, араталар кадаклаганнар, ә аның эченә аклы-каралы сыерлар япканнар. Якында гына зәңгәр өй. Ә югарырак, элек алмалар алланып пешкән урында чо-кырлар казылган, тигез итеп ташлар өелгән, агач, тимер ташып куел-ган. Анда колакка ятышсыз тавышлы машиналар дөберди, кешеләр кайнаша иде...*

*Сандугач эссе көнне әлеге киселгән алмагачлар, карлыган куакла-ры тутырылган тирән ерганакта үткәрде, ә кояш баегач, кыр ягыннан яңгырап килгән назлы чакыруга каршы очып китте һәм ялгыз бер агач төбендә үзенең булачак пары белән очрашты...*

*Алар оя корырга өлгермәделәр. Кояшны ай, ай кояшны берничә тапкыр алыштыргач, баш очыннан тимер кош очарга керешге. Ул ка-бат-кабат күтәрелде, кабат-кабат кунды. Ә берсендә аның артыннан болыттай сузылып калган ачы исле агым нәкъ алар сайлап алган урын-га туры килде. Сандугачларның тыны кысылды, канатлары хәлсезлән-де. Көч-хәл белән күтәрелеп, алар зур авыл өстеннән киң су буена очып килделәр һәм буш иске зиратка оя корырга яраклы зелпе куагына кундылар.*

*Яр буе көндезләрен якты, җылы, ә төннәрен тыныч, ышанычлы иде. Җим мул, сайрарга һичнәрсә комачауламый, көндезләрен кояш ас-тында эленеп торган тилгәннән һәм төннәрен сиздерми-нитми генә җиргә тия язып шуышып үтә торган мәче башлы ябалактан гайре дошманнары юк. Ә ояларының бөтенлеге, йомыркаларының иминлеге өчен дошманнардан ничек сакланырга кирәклеген алар яхшы үзләш-тергәннәр иде инде...*

## IV

— Ул галәмәт зур,— диде Чаныш колхоз рәисенә, аны машина-трактор паркында эзләп тапкач һәм тракторның ник кирәге чыкканын аңлаткач.

— Галәмәт зур? Кило ярымлапмы?— дип сорады председатель.— Әллә бер пот тартамы?

— Аны күтәрерлек түгел.

— Тимер дә сөйрәп чыгара алмады дисеңме әле?

Чаныш кабатлап тормады.

— Автоүлчәүдә үлчәрлектер ич?— дип көлде председатель.

Аның бөтен килеш-килбәте балык турында картка ихтирам йөзеннән генә, аның мавыгуыннан ләззәт табып сөйләшүен, моңа өстәп, язгы эшләрнең җайлы баруын, фәкать шуңа күрә генә үзенә тоткарланырга кирәк калса, әз-мәз шаяртырга рөхсәт итүен белдерә иде.

Алар тирәсенә кешеләр җыелышты. Тәмәке кабыздылар, атны сөйгәләделәр, тик боларның сөйләшүләренә артык исләре китмәде. Ихтимал, дип фараз кылды Чаныш, алар тракторны бөтенләй башка эшкә сорый, кире какмасыннар өчен генә адәм ышанмаслык балык уйлап чыгарган дип исәплиләр булса кирәк. Алар Чанышка сүз катып карадылар, ләкин ул председатель белән генә сөйләшүен белде.

— Автоүлчәүдә үлчәрлек түгел аны,— диде Чаныш.

— Чыдатмасмыни, Чаныш ага?

— Чыдатуын чыдатыр. Сезнең үлчәвегез амбарга кергәнне киметеп, чыкканны арттырып үлчәүгә дә чыдый... Балык чыдамас.

Председатель тамак кырып куйды.

— Ник алай?— диде ул.— Синең өч тиенлек балыгыңны ни арттыр, ни кимет инде аны.

— Өч тиенлек кеше булсаң, бәлки шулайдыр,— диде Чаныш читкә карап.— Ә ул балык дөнья хәтле...

Кешеләр Чанышның тапкыр җавабын хуплап көлделәр. Председатель яшел «Нива»сының ишеген ачты. Бу машинаны Чаныш нигәдер ошатмый, кыска итәгеннән юан ботлары ачылып йөргән җор хатын кебек шөкәтсез бер нәрсә итеп кабул итә.

— Трактор бирербез, тик иртәгә. Бүген кырга таралдылар инде. Нәрсә соң анда — дулкын берәр бүрәнә кагып чыгардымы соң? Шуны сөйрәтеп алып кайтыргамы? Әллә утын кайгысы төштеме? Утынга иртә бит әле, Чаныш ага,— дип, председатель рульгә утырды, тик хөрмәтле карттан яхшысынмады ахрысы, тагын эндәште:

— Ә бакча сукаларга дисәң, сөйләшеп тә тормыйм. Колхоз бәрәңгесен утыртмый торып, шәхси хуҗалыкларга якын да бару юк.

— Юк, аңламадың, кем... Әйтәм ич, подвалдан балыкны сөйрәтеп чыгарасы иде. Аннары суга җибәрәсе,— диде Чаныш, баягы сүзләрен кабатлап.

— Азынды да соң бу картлар!— диде кызыл битле, кисмәктәй юан бер ир. Ул ягулык, май склады мөдире Петр иде.— Балык тотарга дип, трактор тиклем трактор сорыйлар. Прәме акылдан язганнар!

— Минем, олан, акылдан язар яшем узган инде,— диде Чаныш.— Белеп кал! Картлар акылдан язмый. Алар үләләр генә.

Озын таш бинаның тәрәзәләрендә ут уйнаклады. Әчтә кемдер тимер ябыштыра — бу Чанышка мәгълүм. Хәзер исә зәңгәр ут аңа биек бетон бинадан чыга алмый азапланган яшен булып тоелды. Шул рәвешчә үк умарталык базында балыкның җаны чәбәләнә торгандыр, дип уйлады ул. Күңеленә пошаман төште. Ул кармаланып, каеш дилбегәне кулына алды, ышанмаганнары өчен бу кешеләргә үпкәләп китеп барырга да риза иде инде. Бәлки балыкның зурлыгына ул үзе ышандыра алмагандыр?

Механизаторлар арасында майланып беткән матрос формасы кигән Ринат атлы бер егет тә бар иде. Ул:

— Туктале, Чаныш бабай!— диде дә атны авызлыгыннан тотып алды.— Минем трактор әзер, Самат Сираевич,— диде ул председательгә.— Кырга иртәгә генә чыгам әле. Ә бүген умарталыкка барып килмимме соң?

Карап та тормастан, председатель аңа кул селтәде: теләсәң нишлә, янәсе. Һәм китеп тә барды.

Егет аның артыннан:

— Есть!— дип калды. Ә Чанышка:— Киттек, командир,— диде.

Чаныш аның ни атлы, кем улы, кем оныгы икәнлеген сорашмады. Сораса атасын чамалар, бабасын белер, бабасының атасы хакында байтак сөйли алыр иде. Ул яшь кенә бер егет, егерме яше яңа тулгандыр, шәт. Очраган кешеләр кем, исемнәре нинди, ничә яшьтә — бу нәрсә Чанышны кызыксындырмый инде. Яхшы кешеләр икән, ул аларны үзе белән тигез күрә — шул гына. Начар кешеләрне бар дип тә белми. Соңгы вакытта ул кешеләрнең начарлыгы, кылган гамәлләренең яманлыгы хакында да байтак ишеткәләде. Никтер андыйлар үрчеде әле. Ишәйделәр. Хәзер күп кеше тук. Тук кеше бернидән дә курыкмый шул. Чаныш андыйларның кибеткә бер генә көн ипи кайтмаса да, Совет властен, хөкүмәт җитәкчеләрен яманларга тотынасын белә. Ә менә яхшы яшәргә, яхшы уйларга тырышкан кешеләр әллә нишләп сирәгәйде, усаллардан куркып тынды. Барысы да үз-үзләрен яхшы, акыллы күрсәтергә өйрәнде. Һичкем үзенең начар яшәгәнен ачып салмый, кеше күзеннән яшерә. Шуңа күрә Чаныш үзенә яхшы кешеләр очраса гына үзен яхшы дип саный. Ә начар кешегә туры килгәндә, берәр булдыксызы пешергән ипине кызганган шикелле, тормышның үзен кызгана иде...

— Яхшы балык ул,— диде Чаныш егеткә елмаеп һәм ышаныч нурлары белән тулган йөзе, хәтта йөрәге белән сөенеп.— Кузгалыйк, булмаса, олан.

Мондагы кешеләр дә егетне хуплап:

— Бар, бар. Кайткач сөйләрсең,— диделәр.

Егеткә сөйләп торуның кирәге чыкмады. Умарталыкка кешеләр үзләре килеп җитте. Бик күп кеше. Бу кадәр халыкны Чаныш Сабан туе мәйданында гына күрә торган иде.

Болай булды.

Балыкны тракторында сөйрәтеп чыгарырга риза булган егеткә: «Бар, бар. Кайткач сөйләрсең»,— диделәр бит әле? Менә шуннан соң хәлләр башланды да инде.

Егет үзенең дүрт көпчәкле, җирән, котсыз зур тракторын мастерской бинасы эченнән кабызып алып чыкты да, утырган җиреннән сузылып, Чанышка:

— Монда үрмәлә, бабай! Тизрәк барып җитәрбез! Атың калып торсын,— дип кычкырды.

Чаныш әйтте:

— Берүк кабалана күрмә, олан. Ашыккан җитмәс, боерган җитәр. Мин үз җаем белән барып җитәрмен,— диде.

Җирне дер селкетеп һәм бер сөям хәтле иңдереп, трактор аны узып китте. Юл буш иде. Тирә-юнь Чаныш тирәли тагын шулай ук тын гына әйләнә. Уң яктан карасаң, сәгать теле уңаена, сул яктан — каршыга таба. Телеграмм баганалары һәм чыбыклары шауламый, тып-тын.

Юлның чирегe чамасын узганда аны арттан арбалы мотоцикл узып китте. Аңа икәү — баягы хәбәргә ышанмаган кешеләр утырышкан. Алар картка кул болгадылар, елмайдылар, нидер кычкырдылар. Сүзләрен аерырлык түгел иде. Чаныш аларның умарталыкка ашыкканнарын аңлады. Карасана, эчләренә ут йөгергән, кызыксыну баскан. Ярый, тиздән шаккатырлар, дип уйлады Чаныш.

Бераздан аны велосипедлы ике малай куып җитте. Ни ара ишеткәннәр, шайтан балалары. Алардан яшерерсең, бар.

Чаныш юлның яртысын үткәндә, мотоцикл кире килә иде инде. Кешесе аңа баш бармагын тырпайтып узды да авылга таба җилдерде. Зур балык турында хәбәр салыргадыр инде.

Авыл юлы очлангач, Чаныш атны умарталык юлына төшерде. Бер ара тигезлектәге люцерна басуы буйлап барды. Язгы ташулар уйган текә ярлы тирән ерганак аша салынган агач күпер дә артта калды. Кояш инде югарыга үрмәләгән, шактый кыздыра. Тургайлар концерт бирә. Ара-тирә кара каргалар очып үткәли. Оран салып, куаклыктан саесканнар күтәрелде. Баягы мотоцикл шытырдавы ишетелде, бу юлы аңа өч кеше утырган иде инде. Аннары Чанышны дистәгә якын хатын-кызны утырткан йөк машинасы узып китте. Ул аларның сыер савучылар икәнен таныды. Нидер кычкырдылар. Чаныш тагын аера алмады. Мәгәр аларның балык карарга барулары шиксез иде.

Үр кашына җитәрәк, әз-әзләп кенә елга яктылыгы ачыла барды, ә өскә тәмам калыккач, умарталыкның агачлар белән ышыкланган иңкүлеге җәелеп китте. Үзләре күренмәсәләр дә, Чаныш бал кортлары хәрәкәтен сизде. Су җиләслеге, төрле үлән, җылы җир исе килә иде.

Ул атны тыебрак төште дә йорт ышыгына китереп туктатты. Җирән трактор арты белән баз юллыгына каршы урнашкан иде инде. Һәммәсе подвалны уратып алган. Кычкырыша, көлешәләр.

Ни хикмәт, каян җил ташлаган диген,— Чанышны Зөбәрҗәт атлы (хатын-кызмыни!) озын буйлы, какча гәүдәле участок милиционеры каршы алды.

— Ну тамаша!— диде ул кашынача батырып кигән фуражкасының ялтыравык козырегы астыннан төймә күзен Чанышка чәнчеп.— Бу хан заманы балыгын каян эләктердең син, Чаныш бабай? Тозакка шәп тә каптыргансың соң, минсиңайтим! Тик андый балыкны тоту тыела бит, белгән идеңме?

— Җук. Беләсем дә килми,— диде Чаныш, иңенә аркан төргәген салып.— Каптырмадым мин аны.

— Шулай да акт язарга туры килер.

— Кычытмаган җиреңне кашыпмы?

— Кычытыр, кычытыр. Ничек кашыйсын да белербез. Хәзер монда балык заводы директоры килә. Бу судагы балыкларга ул хуҗа.

— Су ага, балыклар йөзә. Алар үзләренә-үзләре хуҗа,— диде Чаныш.— Син җил куып йөрмә, агайне.

Чаныш туп-туры аңа каршы китте. Милиционер читкә янтаеп калды. Кадрәк белән тракторчы егет туфрак ябышып каткан, күгәрек, бездәй чыбыклары чәнчеп торган, ат башы кадәрле тимер ыргаклы корыч тросны балыкка таба сузып маташалар иде.

— Аркан гына да ярар,— диде Чаныш.— Җан иясе бу, машина түгел.

— Хужырак! Синең бу балыгың су асты көймәсе белән бер, бабай. Балыгыңның койрыгына менә шушы якорьне салсам, әһ тә итмәс!— дип, егет трос ыргагын селеккәләде.

— Якореңне үз борыныңа сал, олан,— диде Чаныш. Һәм аңа аркан төргәген ыргытты. Егет аны һавада ләтчә елгырлыгы белән эләктереп алды.— Син аны, олан, йомшак кына тарттырырга тырыш.

Үр кашында кешеләр утырткан яңа машина пәйда булды. Сикерешеп төштеләр дә аска таба йөгерештеләр. Иңкүлекне тоташ шау күмде.

— Боже мой!— дигән чырылдау ишетеп, Чаныш тавыш иясен эзләп тапты. Яшь кенә бер хатын-кыз икән.— Сногсшибательная рыбка. Невероятно!

Син татар кызының «боже»се кем икән соң инде?— дип уйлады Чаныш. Соңгы вакытта ул аллалары белән бергә ана телләрен дә оныта баручы яшьләрне байтак күрде. Аналарын сайлап алмыйлар, ә аллаларын сайлыйлар, ә?

Сыер савучы хатыннарның берсе — тирләгән таза муенлы һәм дәү күкрәклесе имән бармагы белән Чанышның күкрәгенә төртте:

— Карт шайтан!— диде ул, янындагы иптәш хатыннарына озын керфекле кара күзен кысып.— Кайчагында мондый балык эләктерер-

лек кармагыңны безнең тарафка да салгаласаң соң... Нинди балык белән булашып ята, ә? Әпититеңне әйтер идем... Бал ашап кына яткач соң!..— дип, ул Чанышка яны белән төртеп алды, тик карт аягын аерып баскан иде, кузгалмады, җиргә төкерде дә аның яныннан читкәрәк тайпылды.

Тракторчы егет аркан очын балык койрыгы астына тыкты, икенче яктан аны шлемын салмаган мотоциклчы егет тартып алды. Аны Чаныш, баягыча ук төенләп, үзе бәйләде.

— Балыкның бер чиметеме миңа, яме, бабай?— диде тракторчы егет.— Ухага.

— Мин сиңа чиметермен!— диде аңа милиционер.— Сезгә ирек куйсаң... Кырпы балыгын тотарга ярамый — халык байлыгы санала ул. Законда язылган!

— Шул-шул, халыкныкы!— диде мотоциклчы.— Монда бер Сабан туен сыйларга җитә. Калганнарга да артып кала әле.

Чаныш:

— Халыкныкы түгел ул,— дип кырт кисте.

Халык арасыннан берәү:

— Чаныш агай, син халыкны кыерсытма инде! Гадел генә итеп бүл дә бир.

— Нәрсә аны сорап торган буласыз тагын?— дип өскортты бер хатын.— Мужик башыгыз белән хурланмыйча соранасыз.

— Исемлек төзик, җәмәгать!

— Һәркем гариза язсын. Хатын, әйдә, син башла. Өйдә исәп-хисапка син баш бит. Һәр нәрсәгә кысылам дигәндә сиңа җиткәннәр юк.

— Шулаймыни? Алайса үзең кысыласың килгәндә миңа гариза тотып килерсең инде, яме, җанкай?!

Халык шаркылдап көлеп җибәрде. Чаныш атның сискәнеп киткәнен күреп өлгерде. Балыкның да сырт өстендәге канаты киерелеп килде.

— Милти Зөбәрҗәт хак әйтә, иптәшләр,— диде юан бер ир, йонлач күкрәген кашып.— Балык — халыкныкы. Бүлешергә кирәк — беттекитте!

— Тумаган колынга йөгән кидермәгез әле, җәмәгать,— диде Чаныш.— Бу балык — халыкныкы түгел. Мин әйттем.

Тракторчы егет елмаеп:

— Бер дә яхшы түгел инде, бабай,— диде.

— Халыкны санга сукмыйсыңмыни, Чаныш ага?

— Мин бүген балыкны гына санга сугам. Аны гына. Бигайбә.

Кадрәк бау таккан чиләк белән подвалдан су чумырып, балыкка сибә иде. Бер чиләк суны селтәнеп, хатыннарга сирпеде. Тегеләр бердәм чырулап җибәрде.

Ә халык җыелганнан җыела барды.

Егет тракторына күтәрелде, ул-будан кисәтеп кычкыртты, газ бирде. Трактор, куәтле гөрелдәп, гайрәт белән тулды. Чаныш аны корбанына ташланырга әзер җирән үрмәкүчкә охшатты.

Шулвакыт картның каршысында ни ара килеп чыккан башка бер милиционер басып тора иде инде. Чаныш аның погонында ике бәләкәй йолдыз шәйләде. Бусы участок милиционерын бармак изәп чакырды да аны үз урынына бастырып куйды, аннары балыкны төрле яктан чалт та чолт фотога төшерә башлады.

Тракторчы егет газны киметте, кызыксынып, җиргә сикереп төште.

Лейтенант кесәсеннән җыйнак рулетка чыгарды. Участок милиционеры белән бергә алар подвалның озынлыгын, балыкның буен, койрыгыннан корыган имәнгә хәтле, аннары подвал авызы читеннән елгага кадәрге араны үлчәп чыктылар. Лейтенант һәр санны кызыл тышлы кечкенә дәфтәренә теркәп барды. Шуннан соң ул умарталык-

тагы халык арасында т ә р т и п урнаштырырга кирәште. Үз ниятенә ирешә алмаганына төшенгәч, читкәрәк китеп басарга боерды. Ул моны иминлек өчен дип аңлатты. Кешеләр иминлеге өченме, әллә балык иминлеге өченме — монысын аңлатмады.

Якын-тирә агачларны малай-шалай «иярләп» бетергән.

Чаныш Кадрәк янына килеп басты. Алар бер-берсенең балык язмышы өчен борчылуларын сизгер тойдылар.

— Балыкны бирмим мин аларга, улым,— диде Чаныш.

Сүзен лейтенант ишеткән икән.

— Сезгә генә күбрәк булыр, ихтимал,— диде ул.

— Вак-төяк белән булышмыйм мин, энем.

— Синеңчә, бу — вак-төякмени? Ә эресе нинди була?

— Эресе... белмим. Ә бусысын суга җибәрергә кирәк.

Лейтенант аңламаганга салышты:

— Кая-кая?— дип сорады.

— Урманга түгел инде,— диде Чаныш ачуланып.

— Елгага дисеңмени?

— Ие. Тизрәк кирәк.

— Ник?

Чаныш аның юри сөйләшүен аңлагач һәм ни дип җавап кайтарырга белмәгәч:

— Су саекмасын өчен,— диде.— Күрмисеңмени: балык базга кереп калгач, су күпме кимегән. Балыксыз елга саега ул. Балыксыз калсалар, диңгезләр дә саегыр...

— Алайса ник тоттыгыз соң сез бу балыкны?

— Ул үзе йөзеп кергән.

— Юлын каян тапкан икән соң?

— Үзеннән сора инде, олан. Бәлки милиция дигәч, теле ачылыр.

— Мин служебада. Телеңне тыярга киңәш итәм, бабай.

— Мин дә сакта. Балыкны саклыйм. Киңәшем дә бар: әйдә, бергә җибәрик балыкны суга?

Ул арада балыкның буен бүтән берәү — зур борынлы, калын мыеклы, олы гәүдәле, шакмаклы пинжәк кигән ир-ат үлчи башлады. Лейтенант Чанышка сул кулын селтәп, шуның янына китте. Теге кеше, милиционердан аермалы буларак, күзе белән генә эш итте, ләкин үлчәмен бик төгәл төстә — учын учка караткан кулары белән билгеләп барды. Ул әледән-әле колак артына кыстырган карандашы белән учындагы кәгазь кисәгенә ниндидер тамгалар салгалады. Йөзендә мәшәкать сурәте, үзе уйчан, хәтта борчулы иде. Карашын вакыт-вакыт күккә төби дә, нидер исәпләп, ирен чите белән мыек очын чәйнәштерә. Уендагы нияте белән балыкның буе туры килеп бетми иде ахрысы: ул балык буеннан тагын үтте, бу юлы учлары арасын киметә төште, шулай да урта бер җирдә элеккеге үлчәменә туры калды. Чаныш аның, койрыкка җиткәч, карандашын канәгать төстә күкрәк кесәсенә, ә кәгазен эчке кесәсенә тыгып куйганын, чуар галстугын төзәткәч, читкәрәк, үр кашыннан әле һаман монда таба төшкәләгән кешеләрне күзәтергә уңайлы булган ачыграк урынга барып басуын күзәтеп торды. Аның тәкатьсез төстә, алай да вәкарь сакларга тырышып, кемнедер көткәнлеге йөзенә чыккан иде. Соңыннан Чаныш аның район үзәгендәге балык заводы башлыгы икәнен белде.

Ә халык килә дә килә, гүләү көчәйгәннән-көчәя барды. Шуңа карамастан, алдагы кешеләр бер кавым арттагылар басымына чыдады, лейтенант билгеләгән күзгә күренмәс иминлек сызыгыннан узмады. Умарталык колхозчыларның гомуми җыелышы вакытындагы авыл клубыдай кысанайды.

Халыкка бер умарта оясы уңайсызлаган икән, аны читкәрәк күтәреп куймакчы булдылар. Кортлар, әлбәттә, үз тынычлыкларын саклый белә: алар үзләрен борчыган кешеләргә дәррәү ябырылды. Халык ча-

паланырга, кычкырышырга кереште. Котырынган кортлар ир-атның күлмәк изүенә, хатын-кызның итәк астына томырылды. Ә бер төркеме бүгенге гомер күрелмәгән вакыйга уңаеннан ни ара кызып алырга өлгергән, тирләп-пешкән әлеге дә баягы, май склады мөдире юан Петрга каныкты: бал кортлары аракы исен бер дә яратмый бит. Әрәмәлеккә кергән кәҗә тәкәсен тигәнәк саргандай, бал кортлары Петрны күз ачып йомганчы сырып та алдылар. Ул гаярьләнеп каршы торып маташты, хатыны гомерлеккә дип ныгытып таккан төймәләре белән бергә, бал кортларын да учлап-учлап күлмәгеннән кубара башлады. Кортлардан алай гына котыла алмагач, юкә агачыннан кабык кубаргандай итеп, киемнәрен салып атты. Бераздан, трусиктан гына калган килеш, ул бөтерчектәй әйләнә иде инде. Тавышы башта сузынкы, калын чыкты, аннары тоташ чинауга күчте. Хәлдән таеп аугач, аны җирдә тәгәрәтергә керештеләр, әмма соң чиккәчә үртәлгән бал кортлары көрәшне ахырынача — җиңү яки үлем дип төгәлләргә җыенганнар иде, ахрысы. Петрны алан буенча аркылыга-буйга тәгәрәтә бирделәр. Инде коткарырга соңгы ышаныч беткәч, кызарынган ирне дистәләгән кул күтәреп алды да бер селтәнү белән баз суына — балык янына ыргытты. Ул су өстендә калкавычтай тирбәлеп торды, атасы-анасы белән сүгенде дә, баш очындагы кортлардан котылырга теләп, суга чумды. Моның нәтиҗәсе күңелсез төгәлләнүе ихтималын искәреп өлгергән өч ир-ат ул чумган урынга сикерде. Аны эзләп чума-чума суны бөтенләй болгатып бетерделәр, ләкин Петрны тапмадылар. Петрны бал кортлары да эзләде, дошманының юкка чыгуына ышангач кына күч аланга таралды. Ирләрнең берсе балык кырыеннан кысылып, базның эченә үк кереп киткән икән: ул аннан Петрның юкка чыгуын, аны тәгаен балык йотканлыгын, аның шунда, балык эчендә кычкырып ятуын хәбәр итте. Ул ир кире чумып баз кырыена чыкты. Ике кулында да кәрәзле рамнар, берсенең кәрәзе почмагыннан кыеп алынган. Баз янындагы егет әүвәл аның рамнарын, аннары үзен тартып алды.

Аңардан:

— Бу рамнарны ник алып чыктың, буш ич алар?— дип сорадылар.

— Үзем гуаһ торам, җәмагать: Чаныш абзый бу балыкны кәрәзле балга каптырган. Әнә ничек ашаган!— диде кәрәзгә күрсәтеп.— Ә бал кемнеке? Колхозныкы! Ә колхоз кемнеке? Безнеке! Моннан нәрсә килеп чыга инде ягъни мәсәлән? Колхоз балына каптырылган балык та безнеке — менә ни килеп чыга!— дип сөйләнә-сөйләнә, әлеге ир агач төбенә үк менеп басты. Сүзен, кылыч айкагандай гайрәтле селтәнеп, болай бетерде:

— Ә Чаныш абзый балыкны үзенеке генә итмәкче була. Барып чыкмас! Тавышка куям: кем дә кем балыкны халыкка өләшергә ди — кул күтәрегез!

Кул күтәрүче булмады. Халык:

— Петр кайда?

— Петр кайда?— дип шаулашты.

Әлеге ир, шунда — агач төбенә баскан килеш, юеш кепкасын салды да:

— Әйтәм ич, балык йоткан. Урыны җәннәттә булсын,— диде дә башын иде.

— Гуҗ да нәмәстәкәй икән бу балык, ә?

— Соң, балыкмыни, бу, җәмагать! Соң, карагыз, күзле бүкән булмасагыз: акула бит! Аку-ла!

Судан чыкканнарның берсе:

— Җәтрәк пычак бирегез, җәмагать!— дип оран салды.

— Ни пычагыма сиңа ул пычак?

— Балыкның корсагын ярам! Петр агайны коткарырга кирәк!

— Юкка маташмагыз! Барыбер сиңа балыктан коткарган өчен дигән медаль такмаслар.

— Напрасно! Ату күкрәктә төймәдән гайре берни юк... Ярый, медаль бирмәсәләр — бирмәсләр. һич булмаса, берәр тапкыр президиумга сайларсыз. Иту файда. Мин чумыйм әле. Чыкмасам, бәхил булыгыз!

Тик аңа кабат суга чумарга туры килмәде. Петр «пылт» итеп үзе калкып чыкты. Балык астыннан калыкты да, шешенгән бармаклары белән кабалана-кабалана подвал ярына ябышты, югары үрмәләде, әмма менгән саен шуды да төште, шуды да төште. Аны өзлексез очкылык тота иде. Тракторчы егет арканны чиште дә, элмәк ясап, әледән-әле аның муенына төбәп ыргытты. Элмәк аның саен Петрның су үсемлекләре ябышып беткән шома пеләш башыннан шуып ычкына торды. Ул балыкның тәңкәләренә ябышырга кирәклегенә төшенде булса кирәк, бармак битләрен тәңкә читләренә кисә-кисә, ниһаять өскә менеп җитте, балыкның койрыгына хәл алырга сөялде. Күрәсең, аны коткаруга балык та үз өлешен кертергә уйлады: койрыгы белән җиңелчә генә селтәнеп, Петрны туп урынына югарыга чөеп ыргытты. Ахыры хәерле очланды тагын: Петр су тулы агач кисмәккә барып төште. Очкылык тотуы бетте, ул карлыккан тавыш белән җырлап җибәрде. Тик шундук туктап, җиргә сикереп төште. Хатын-кызлар, тавык йоны йолыккан кебек, аның тәненә кадалып калган бал корты укларын чүпләргә кереште.

Петр, кулларын йодрыклап бутый-бутый:

— У-у, канечкечләр!— дип кычкырынды.

Әллә бал кортларын, әллә хатын-кызны тирги — Чаныш аңламады. Яңаклары шешеп кабарынган, калын күз кабаклары күзенә ишелеп төшкән. Петрга дөнья яктысын күрсәтер өчен, бер ир аның күз кабакларын шырпы белән терәтеп куйды. Петр киемнәренә ябышты, тик ни күлмәгенә, ни чалбарына сыймады. Өстенә арыш капчыгы яптылар.

Халык гүләвен елганың аскы ягыннан килеп чыккан вертолет гөрелтесе басып китте. Ул яшел төстә, кызыл йолдызлы, иләмсез зур, күрер күзгә үк көчле иде. Елга буенча аның күләгәсе шуып үтте.

Шул ук вакытта үр кашына кара «Волга» килеп туктады. Аның кешеләре ашыкмый гына чыктылар, бер кавым умарталыкка карап тордылар да дәрәҗә саклап кына түбән юнәлделәр. Лейтенант белән участок милиционеры бал кортлары тузгыткан халыкны яңадан балык белән ике арадагы күренмәс иминлек сызыгы артына тезделәр. Моннан Чаныш яңа кешеләрнең башлыклар икәненә төшенде.

Алар подвал читенә төшеп бастылар.

— М-да,— диде аларның иң дәрәҗәлесе.

— Әллә акула инде?— диде икенчесе.

— Балык, действительно, балык!

— Патша балыгы бу,— диде балык заводы директоры.

— Патша балыгы дисең инде. Яхшы балык... Күпме тартыр икән?— диде башлыкларның өлкәне.

Директор эчке кесәсеннән кәгазь кисәген чыгарды да карашын өстән аска, аннары астан өскә йөгертеп алгач:

— Мин монда чамалап караган идем, Даниил Афтандилович. Болай ... барысына да җитәрлек шикелле,— диде.

— Барысына да дисеңме? Барысына да ярамас.

— Искә алырмын. Әлбәттә, искә алырмын,— дип, директор кәгазь кисәгенә текәлеп, читкәрәк китте.

Тракторчы егет Ринат арканны яңадан тракторына бәйләгән иде инде. Ул Чаныштан:

— Тарттырыргамы?— дип сорады.

— Вакыт инде, олан. Югыйсә кибүе бар. Бакчы, кояш ничек кыздыра.

— Кояш — кояш инде ул. Монда кайберәүләрнең күзе бик нык кызды бугай инде.

— Син аларга карама. Хәерле сәгатьтә — тарттыр әйдә!

Ул арада вертолет үрдән читтәрәк — тигез люцерна басуына төшеп кунды. Чаныш үр кашында барысы да бер төсле пөхтә, күе зәңгәр костюм кигән кешеләрне абайлады. Алар өчәү иде. Аларга һичкем илтифат итмәде. Күрәсең, теләмәгәндә күзгә-башка ташланмаска өйрәнгән болар.

— Объект урынын квадратка билгеләп куй,— дип боерды Беренчесе Икенчесенә.

Тегесе, янына элгән планшетын ачып:

— Объект эзләү координатына туры килә,— диде.

— Ә сез кешеләрнең күрсәтмәләрен әзерләгез,— диде Беренче Өченчегә.

Планшетын ябып куйгач, Икенче күн сумкасыннан озын объективлы фотоаппарат чыгарды да суында кояш чагылган подвалга төбәде.

— Әмма бу — балык...— диде ул гаҗәпләнеп һәм аптырап.

— Балык?! Объект түгелмени?

— Бәлки без эзләгән объекттыр. Ләкин бу — балык. Зу-ур балык!

— Озынлыгы?

Икенче уйлап-нитеп тә тормастан, ачык, ышанычлы тавыш белән:

— Әгәр ул блиндажның... ягъни подвалның түр стенасына кадәр кереп төртелгән булса,— җиде дә илле,— диде.

— Тоннаж? Ягъни авырлыгы?

— Койрыгының рәвешенә караганда, бу балык осетрлар семьялыгыннан — кырпы балыгы. Тәненең ноль дә җитмеш биш тыгызлыгын озынлыгы белән чагыштырмада алсак, биш йөз, алты йөз тирәсендә. Хәер, ялгышуым да ихтимал, без моны үтмәдек.

— Рапортны тулы дип саныйм.

— Шаһитлардан сорау алыргамы?— дип сорады Өченчесе.

— Отставить! — диде Беренче һәм: — Машина янына! — дип боерды.

Чаныш аларның үр кашыннан юкка чыкканын күреп калды.

Соңрак гөрелдәп күтәрелгән вертолеттан Беренче рация буенча каядыр:

— Объект табылды,— дип тапшырды.— Рәвеше һәм үлчәме водолаз-ремонтчы Сидоров хәбәр иткәнгә туры килә. Су асты көймәсе дигән версияне кире кагам. Шәхсән үзем алган мәгълүматлардан чыгып, хәбәр итәм: М-130 баржасы астында шлюз аша үткән билгесез объект чынлыкта осетрлар семьялыгына кергән кырпы балыгы булып чыкты. Әйе, белуга. Боря, Евгений, Леонид, Усман, Григорий, Анатолий. Эзләүне дәвам итәргә күрсәтмә булырмы? Прием!

Бераздан Беренче наушникны колагыннан алды.

— Нәрсә?— дип сорады Өченче.

— Отбой, егетләр!— диде Беренче һәм тирән итеп сулады да сигарет кабызды, арган кыяфәттә утыргычына җайлап утырды.— Хәзер минем нәрсә теләгәнемне беләсезме, егетләр?

— Исәннәрнең теләге — яшәү. Калганы килә дә китә,— диде Икенче.

— Ә кофе юк,— диде Өченче.

— Ә мин менә нәрсә телим, егетләр: барлык су асты көймәләренең балыкларга әйләнеп бетүен. Әлеге подвалдагы шикеллеләргә. Ә барлык снарядлар, пуляларның ияксез балыкларга әверелеп бетүен. Мин аларны суалчан җимле кармакларга каптырып идем дә җепкә тезәр идем. Менә булыр иде яшәү дисәң дә яшәү! Ул ияксез балыкларның нинди тәмле икәнен беләсезме сез, егетләр? Кырпыларың бер якта торсын...

## V

— Степа, синең «кабер караңгылыгы» дигәнне ишеткәнең бармы?

— Әйткәнем дә бар. Тагын «кабер тынлыгы» диләр әле... Нигә искә төшердең?

— Болай гына...

— Болай гына түгел. Кемдер кабердә булган да, чыккач, ни күргәнен, ни ишеткәнен сөйләгән дисеңме?

— Шулай. Ә кабердән чыккан кешеләр бар бит ул.

— Кабердә калганнары күбрәк, туган,— диде Солтан аны үртисе килеп.

Алар инде кычкырып сөйләшми, көлми иде. Тавышларын склеп яңгырашына көйләделәр. Әйтерсең лә авыл клубыннан кайтышлый кызлар озатып куйганнар да өйләренә кереп ятар алдыннан капка төбендәге эскәмиягә килеп утырганнар һәм айсыз төндә тын гына аны-моны сөйләшәләр. Йолдызлы күк урынына — склепның кирпеч гөмбәзе, эскәмия урынына — кара табут. Менә-менә кузгалырлар, әз-мәз көч салсалар, көчәнсәләр, ташны кузгатып юл ачарлар һәм, берни булмагандай, тыныч кына кайтып китәрләр сыман. Куучы, ашыктыручы юк. Сөйләшеп бетерсеннәр инде, бер тартып җибәрсеннәр. Кая ашыгырга?

Степан кесәсеннән кармаланып сигарет кабы алды. Солтанның кулын капшап табып, бер сигаретны аңа бирде. Ут кабызганда Солтан каш астыннан иконага карап алды һәм сандугачның оясында утырганын күрде.

— Шушылай утырабызмы инде?

— Ашыктырма әле. Т е г е н д ә дә йөгереп туйган. Гомергә бер ашыкмый торган җиргә эләктек. Кумыйлар.

— Тиздән куарлар.

— Кем?

— Полковник. Дөресрәге, мәет исе. Үзең әйттең ич.

— Әйе, яшьти. «Тизәккә орынма — сасысы чыгар»,— дигәнне онытканбыз.

— Хәтәрләге дә бар: «Мне возмездие и аз воздам».

— Ишеткән бар. Тик моның ни икәнен безгә мәктәптә өйрәтмәделәр ич, Солтан.

— Аның каравы хәзер сабагын алабыз. «Белмимнең башы авыртмый»,— дип кенә булмый ул. Полковниктан үч алуыңа канәгатьме инде?

— Нигә мин генә?— дип сорады Степан ризасыз тавыш белән.— «Без» диген!

— Яхшы... Без полковникны хөкем итмәкче идек. Ә ул бездән үч ала! Безнең белән бергә, әнә, табигатьтән — сандугачтан... Чыкмасак, ул безнең белән кала. Ә бер заманны монда керерләр дә күрерләр: безне, оясында кипкән сандугачны...

— Син шуңа исәп тотасыңмыни әле? Юк инде, яшьти. Кешесенә туры килмәдең. Моның ишене генә кичергән!..

— Мин башкага исәп тотам. Кемдер табутны тотып китергән бит?.. Кешеләр ияртеп килер әле. Килмәсә, башкалар эзли башлар. Әнә түгел ич без. Коймаңне табарлар, учак урынын күрерләр. Чамаларлар!

Степан сигарет төпчеген табут капкачына басып сүндерде. Сигарет кабын штормовка кесәсенә тыкканда кулы пәкегә юлыкты.

— Оһо! Исән булсак, яшибез әле!— дип кычкырды ул.— Менә хәзер кабыз шырпыңны, кызганма!

Солтан шырпы сызды. Степан табылдыгын күрсәтте. Ачылмалының пәке.

— Граф Монте Кристо безнең белән чагыштырганда пүчтәк ул!— Степан кепкасын салып, склепның таш идәненә бәрде, штормовкасын табутка җилпеп салды һәм, шырпы сүнгәнче, күлмәк җиңнәрен сызганып өлгерде.— Монте Кристо «таш капчыгын» кашык сабы белән тишеп чыкканмы әле? Ә без... Без болай итәбез, парин... Шырпыңны кабызмый тор, яме?

Солтан анының пәкесен шыртлатып ачканын, ком, кирпеч ватыкларын кыштырдата-кыштырдата, читкә юнәлгәнен ишетте, тик нишләгәнен белә алмады. Дусты мыш-мыш килде, нәрсәдер чатнады, шартлаган аваз ишетелде.

— Кабыз! — дип боерды Степан.— Да будет свет!

Солтан тагын шырпы сызды. Анның янына Степан килеп басты да утка чыра очы тыкты. Кабер җанланды, стенада тоньк күләгәләр биешә башлады.

Степан чыраны икона тактасыннан телеп алган икән. Хәзер ул йөзтүбән, баш сөягенә авышып ята иде. Солтан аны тупсасыннан каерылган ишеккә охшатты. Анның киң, яныр күмерләнгәндәй кара тактасы арттан ике аркылы борыс белән беркетелгән. Калҗаймасын диптер инде. Әйе, йөзтүбән ята. Әйтерсең лә, Божья Матерь, кочагындагы яшь баланы дөньядагы һәммә хәвефтән саклап, кешеләр кылырга ихтимал булган барлык хәтәр гамәлдән аралап, шул ук вакытта үзенә карата кылынган мәсхәрәләүдән оялып, хурланып, булган эшне кире кайтарып алалмаслыгын җаны-тәне белән аңлап, кешеләргә аркан борылып яткан иде. Ә идәндәге баш сөяген үз хәленең фәкать үлемгә генә тиң икәнен белгертеп кочкан сыман.

Әкрен кыштырдау ишетеп, Солтан карашын янга күчерде, сандугачны, анның елтыравык күзен күрде. Ул посарга, яшеренергә теләгәндәй, оясына елышкан. Чит карашны өнәми, өрексә дә, оясын ташларга җыенмый, аны йөрәк җылысы белән генә түгел, тәне белән дә сакларга әзер иде, күрәсең.

Чыраны Солтанга биреп, Степан пәке белән кирпеч араларындагы каткан измәне кырырга, сыдырырга тотынды.

— Иконаны юкка телдең,— диде Солтан.

— Барыбер коргаксып кына ята. Ярдәме тисен,— дип, ул пәкесен кепка белән төреп тотты.

— Нигә алай итәсең?

— Сөял чыгудан куркып түгел. Ялгыш киселеп китмәсен дим.

— Баш беткәндә чәч кайгысы төштеме?

— Һи, баш! Бу стенаны теш белән кимереп булса да чыгабыз аны.

— Лом белән күпме вакыт тиштек әле?

— Бер сәгать тирәсе. Пәке белән бер тәүлеккә җыелыр, шәт. Әзмәз җир казып менәсе.

— Ә ник елга ягын тишмибез?

— Анда таш бит, әкәш![1] Динамит белән дә алдырырлык түгел!.. Ике сменалап эшләрбез. Аренда шушы була инде ул! Түләве ни тора: хезмәт хакы түгел, баш хакы, ә?! — дип көлде Степан.— Менә шушы тугыз кирпечне уйсак, җитәр, сыярбыз. Ике каттан — унсигез кирпеч. Тугызы миңа, тугызы сиңа...

— Керештек алайса,— дип килеште Солтан.

— Кашынма! Башта җитәрлек итеп чыра теләргә кирәк әле.

Солтан тигез генә, тәтенләмичә диярлек янган чырага карады. Күңеленнән Степанның тапкырлыгы белән килеште, әлбәттә. Ләкин кемнәрдер изге санаган, алдына тезләнеп ярлыкаулар сораган иконаны чыра итеп телү ниндидер җан иясен терелә тунау, каезлау, тураклау белән бер шикелләрәк тоелды аңа.

Дусты иконаны телә иде инде. Тактаның җепселләре туры иде ахрысы — җиңел, тигез ярыла. Аркылы чөйләп кагылган агачлар турысында Степан пәкенең очын эшкә җигә, ул урында чыраны каерып телә. Чыра телемнәре зыңлап аерыла да таш идәнгә ава. Коры зың, чиста зың, моңлы зың. Ничәмә-ничә гасырлар буена дөньяның ыгы-зыгысын, кайгы-шатлыгын, көрешү-хушлашуларны, ярлыкау-каһәрләүләрне, ярату-нәфрәтләрен, туу-үлүләрне сүзсез баккан Божья Матерьның

---

[1] Аңгыра (диалекталь сүз).

күңел кыллары телгә килә дә, Степанның резин итеге янына өелә баралар шикелле...

«А-а! Нинди көчлеләр без!» — дип уйлады Солтан үз-үзен мыскыл итәсе, хурлыйсы килеп. Ә Степанга:

— Куркыныч кешеләр без!— диде.— Иконаны чырага телдек, сумала белән казан гына җитми.

— Алары нәрсәгә тагын?

— Оятыбыз белән вөҗданыбызны салып кайнатырга.

— Икона телгәнемне өнәмисеңмени?— диде Степан Масленников каш астыннан сөзеп карап һәм җиңе белән маңгай тирен сөртеп. Ул тирләгән, аның тузан кунган битендә тир эзләре, борын яфракларында кызгылт кунык, чәче чуалган, тузгыган.— Алайса калыйк шушында. Оятыбыз белән вөҗданыбызны учлап.— Ул стена каршына барып басты да билгеләгән кирпечләре арасында пәкесен йөртә башлады.— Ә син авыл уртасындагы ташландык мәчетегезне бел. Хәрабә! Адәм көлкесе!— диде мышный-мышный.— Ә икона — ул җанны коткарыр өчен. Менә, коткарсын хәзер безнең җаннарыбызны!

Ничек каршы төшәсең? Дөресе шул, каһәр! Кайчандыр урамда киеп йөри торган галуш, чабата табаны да тимәгән, фәкать күн читек һәм тула оек яки ак йон оекбаш җылысын гына тойган мәчет идәне хәзер нәҗесләнгән... Мәчет — искелек калдыгы, бетте-китте! Үз хөкемен алган, тормыштан сызып ташланган. Һичнинди исемлектә тормый. Ничек сүтеп ташланмаган, бульдозерлар җимермәгән әле. Авыл уртасында тора, байгыш. Пошынучы, уфтанучы юк. Карт-корыны искә-өскә алган кеше юк. Каршысында гөлт иткән культура йорты, китапханә, колхозның ике катлы идарә бинасы, кибет, ерак түгел мәктәп. Культура заманы, гыйлемле кешеләр чоры. Артка әйләнеп карарга вакыт юк. Киләчәк ашыктыра. Яшисене яшәп каласылары килә. Бар җирдә киләчәк буыннар хакына тырышырга өндәгән язулар. Кибеттән аракы алып чыгып, эчәр өчен урын юк икән — ташландык мәчет. Бер очтан йомышыңны да үтисең. Җайлы! Җир өстендә нәрсә бар, ни булачак — һәммәсе кешеләрнеке. Тимә, миңа! Минеке! Күк йөзенә багу бетте, җир асты да куркытмый. Алланы күргән кеше юк. Барлык аллаларны колхоз председательләре, фирка секретарьлары алыштырып бетерде. Кибетләрдә ризык, күңелләрдә ышаныч кына бетте.

Әнә икона. Сурәтнең яртысы юк инде. Су парга әйләнә, ташлар ком булып уала, кеше туа да үлә. Яки киресенчә: пар су була, комнар таш була, кешедән кеше туа...

Ә ни кала?

Кемнәрнеңдер рухын яктырткан икона хәзер кабер эчен яктырта!.. Каберләр болай яктыртылса, дөнья караңгыланмасмы соң?

Идәндәге сурәт чалкан ята иде инде. Божья Матерь сыңар күзен югарыга — кирпеч гөмбәз аша күк гөмбәзенең үзәгенә төбәгән кебек иде.

Шулвакыт кыяр-кыймас кына, курка-курка гына сандугач аваз салды. Тавышы чиста һәм төгәл. Бу саф авазны тамчылап учка җыеп булыр иде шикелле.

Һәм сандугач, беренче эре тамчылардан соң мул итеп ява башлаган яңгыр сыман, бер тын белән сайрарга керешге! Кабер киңәеп киткән, куе болытлар ертыгыннан бәреп чыккан кояш нуры белән тулган шикелле булды.

Солтанның йөрәге сулкылдап куйды, сулышы кысылды, тамак төбенә төер укмашты. Кулы белән бергә, кулындагы чыра калтыранды, сандугачның куләгәсе дә дерелдәп тора башлады.

Гаҗәпкә калып һәм аптырап, Степан эшеннән бүленде.

— Оҗмах ич бу, яшьти!— дип пышылдады ул.— Ә син мине, Алла белән сүз куешып, тамугка олактырмакчы идең!.. Хур кызлары да килеп чыкмагае әле!

— Хур кызлары белән бәйләнсәң, алимент түләүдән башың чыкмас,— диде Солтан.

Сөйләшәсе, сүз катасы да килми иде. Ләкин алар икәү. Кабер — аларның уртак богаулары, әлегә исә, бер-берсенең күңелләрен күтәрергә тырышудан гайре, ул богауны ачардай ачкычлары юк.

— Алимент — алимент инде ул! Ни әйтсәң дә, баласызлык налогы түгел,— дип, Степан аның өйләнмәгән булуына төрттереп куйды.

Әйе, хак сүз — өйләнмәгән. Кабер тозагына капкан бу сандугач шикелле, җырлап чакырыр пары юк. Кайдадыр югарыда — якты дөньяда Камәрия йөри-йөрүен. Ә җаны шушы кабер кебек караңгыдыр. Аны ялгызлыкка, караңгылыкка язмыш ташы томалап куйды. Юк бугай, ул таш — Солтан үзедер. Камәриянең тормышын шушыңынчы ялгыз, караңгы иткән кеше ул бит инде — Солтан Наймушин. Камәрия , аңа, ә ул Камәриягә сандугач була алмадылар. Кояшы, ае, йолдызлары, болытлары булган, яшеннәр яшьнәгән, яңгырлар, карлар яуган якты дөньяда яшәсәләр дә, әлегә бер-берсенә җырлар җырулары юк... Ә моннан чыккач?

Ул уйлап бетермәде, иңенә Степанның кулы ятты.

— Синең чират.

«Әйе, минем чират. Сандугачны моннан коткарырга кирәк. Әллә үземнеме? Юк, Камәрияне»,— дип уйлады ул.

Сандугач тынды. Аның сукыр яңгыр явып үткәне кебек кенә тоелган сайравы егетләрнең күңелләре тирәнлегенә иңеп таралды, сүрелде.

Солтан кирпечләр арасындагы каты измәне кырырга кереште. Гүя ул кирпечләрне араламый, ә стенага төшкән үз күләгәсен телгәли иде. Бөтен барлыгы, ялгызлыгы белән аның күз алдына Камәрия килеп баскан кебек булды. Солтан аның үзе өчен кем булганы һәм кем булуы ихтималы турында уйлавыннан туктамыйча, көчәнә-көчәнә пәке очын йөртте дә йөртте.

Инде янып бетә язган чырадан Степан яңа ут элде, табутка җайлап утырып, папирос кабызды.

Теләсә нинди эшне тизләтеп, акрынайтып яки бөтенләй туктатып була. Гадәтиен дәвам иттереп, яңасын башлап, туйдырганын ташлап, кирәкмәгәненнән ваз кичеп була. Фәкать бер генә эшне тизләтү, акрынайту яки туктату мөмкин түгел, ахрысы — әйберләрнең комга әйләнүен. Ком к о м булып кына ага. Хәтта вакытның үтүен дә ком агышы белән саныйлар. Сәгатьләр билгеле микъдардагы ком бөртекләренең Кояш әйләнешендә күпме коелуына карап ясалган. Ком бөртеге — һәм Кояш...

Солтан склептан чыгу вакытын аяк астына коелган ком бөртекләре белән саный башлады. Камәрия белән аның арасын якынайтыр өчен күпме ком бөртеге кирәк булыр иде икән?

Әлегә исә артта — чыра яктысы, алда — стена, ике арада — Солтан үзе, ә каршысында Камәрия түгел, бәлки үзенең тонык күләгәсе...

Кирпеч арасында кыштыр-кыштыр йөргән пәке очы кинәт туктап калды. Солтанның күңеле яктырып китте.

— Карале, Степан. Ә ул килгән бит!— диде ул.

— Кем?

— Камәрия.

— Каян белдең әле? Телефон юк бит.

— Килгән, күреп-карап торган. Табутны да ул кире сөйрәп китергән. Көтә ул безне, көтә.

— Ә ник көтә? Кеше чакырсын ул көтеп утырганчы. Начар, яшьти.

— Яхшы, Степан, яхшы. Ул минем чыкканны көтә. Үз янына чыкканны. Кешеләр янына түгел. Көткән җиргә чыкмый калып буламы соң?!

## VI

Дәү балыкны подвалдан сөйрәтеп чыгарып, олы суга җибәрергә вакыт җиткән иде инде. Кешеләрнең үзенә һәм Кадрәккә булышачагына шикләнмәде Чаныш. Ләкин халыкның балыкны коткарырга бер тамчы да омтылып карамавы киң аланны, ирекле елганы, аяз күк йөзен ниндидер сагыш белән тутырып тора кебек иде. Чаныш үзен, улын һәм балыкны яңадан япа-ялгыз калган итеп тойды. Баштагы тантаналы шатлыгының хәзер тирән бер үкенү белән алмашынуы Чанышны тышаулаган сыман итте. Ул бер мизгелгә йокыга талгандай булды һәм, балык алдындагы үтәлмәгән бурычы йөрәген чәнчетер дәрәҗәдә исенә төшеп, тракторга таба китте. Кургашын солдаттай төз гәүдәле милиция лейтенанты трактор каршысына чыгып баскан да, учларын үзенә каратып күтәргән куллары белән аны алга әйдәп маташа икән инде. Тракторчы егет газ бирде, торбадан бәреп чыккан каракучкыл төтен бөтерелә-бөтерелә һавага атылды.

Чаныш үзен һичкем тыңламаганын, ишетмәгәнен белсә дә, тракторчы егеткә:

— Олан, бер үк сак кылана күр. Яхшылыгыңны кызганма, зинһар, — дип пышылдады.

Ул үзен-үзе дә ишетмәде. Аркан тартылып турайды, дерелдәде, авырлыкка чыдаргамы-юкмы дигәндәй, үзенә ябышкан сыек ләмне коя-коя әйләнгәләде, койрык астына уралган төен тыгызланды, тартылган саен балык тәненә бата барды. Балык авышлык буенча югарыга таба сөйрәлә башлады. Койрыгының элпәсе киерелде, турайды. Чаныш үз буыннарының да аркандай киерелүен, шул көчнең үзен җиргә таба тартуын, моңа һәр тамырының карышуын, умырткасының авыртуын тойды. Аның, шулай итеп, балыкның тәне авыртуын үзенә күчерәсе, трактор балыкны җәрәхәтли күрмәсен дип, Аллага ялварасы килде.

Чыннан да, подвал ишегенең яңаклары шыгырдады, балык сыртына һәм суга туфрак кисәкләре коелышты. Балык, саңак калакларын җәеп, ишек яңакларына терәлгән, күрәсең. Ул үзенең соңгы тукталышыннан ничек тә кузгалмаска тырыша, гомере бәһасенә булса да, соңгы сулышы алдыннан картлык тынычлыгын бозмауларын тели иде, ахрысы. Чаныш бу хакта баштук уйламаганына үз-үзен күңеленнән ничек битәрләргә белми торды. Балыкка кояш нурлары үтәли яктырткан чиста су тирәнлекләренә чуму насыйп булмастыр инде; үзле балчыклы текә ярлар астында вакыт һәм су шомарткан йомры ташларга сыенып иркәләнү эләкмәстер; ә томанлы язгы иртәдә дусы белән сай җирдә очрашкач, үз нәселен калдыру чакыруына буйсынган килеш, корсагының татлы наз белән уылдыктан бушануын тоймас; дусты сипкән ак сөткә уралып, тәкатьсезлектән сукыраймас; ниһаять, һәммә эш узгач, ару-талчыгу, алҗудан соң бүрәнә хәлендә калмас һәм елга төбенә ял итәргә төшеп ятмас инде...

Балыкны сөйрәткән саен, баздагы су кими барды. Аның киерелеп җәелгән сырт канаты җир белән тигезләшкән иде инде. Казның каерылган канаты сыман сөйрәлгән, баш-башлары белән подвалның юеш, кызыл балчыгын тырный-тырный өстерәлгән аскы канатлары да күренде. Чаныш үз йөрәгенең дөп-дөп кагуын тойды, күзаллары караңгыланып китте, күкрәген күтәрә алмастай сагыш басты. Аның ябык, сары йөзе тыштан тыныч күренә-күренүен. Ә эчтән? Әнә ул, иренен чак кына ача төшеп, еш-еш сулый, күз астындагы вак җыерчыклы юка тиресе дерелди. Моннан Кадрәк атасының зур газап кичерүен сизде.

Балыкның энҗе кебек елтырап торган күзләре күренде. Чаныш ягында уң күзе, анда кояш нурлары тәре сыман чагыла иде. Подвал чокырының түмгәкле бер урыны ул күзне кояштан каплады. Шунда төпсез, тирән, гаҗәпләнеп ачылган хәрәкәтчән күздә Чаныш үзенең

бәләкәй чагылышын шәйләде. Сурәте ялтыравыклы чыршы уенчыкларындагы кебек бозылып күренә: аяклары озын, гәүдәсе артка каерылып тора. Балыкны әкрен генә сөйриләр. Чанышның балык күзендәге чагылышы да әкрен генә әйләнә. Арбада авылга кайтып килгән чакта аның тирәли, шул рәвешчә, телеграм баганалары, басулар, агачлар, офык һәм болытлар әйләнгән иде бит.

Балык, әйтерсең лә, Чанышны таныды, аңа текәлде. Аның күзендәге үз чагылышының нокта гына булып күренгәнен шәйләде карт. Чанышның үз күзләрендә дә балык чагыладыр әле. Шул рәвешчә кара-каршы торган көзгеләр бер-берсендә чиксез санда чагылып күренә. Аларның бер-берсенә карашында бу дөньяның әллә нинди серләре яшеренеп ята кебек иде. Аның белән балык, икесе бергә, мәңгегә шушында калырлар, ахрысы — Чанышны кинәт кенә шундый уй биләп алды. Чаныш та, балык та әлегә тереләр, тик м о н д а, аланда түгелләр шикелле иде. Чаныш яхшы хәтерли: шундый тойгы сугышта булгалый. Ягъни синең күз алдында үтәли яраланган кешене ава дигәндә тотып аласың, ә бу вакытта, әле исән булса да, аның инде котылгысыз рәвештә ү л е п барганын күрәсең...

Трактор шайтан көче белән балыкны сөйри бирде. Чанышның балык күзендәге чагылышы юкка чыкты: анда тагын тәре сыман нур белән аркылы-торкылы кискәләнгән кояш сурәте чагылды. Балыкның күзе сарык күзе сыман тоныкланды, үле фосфор нуры белән тулды.

Милиция лейтенанты трактор каршында ике кулын да югары күтәрде. Трактор туктады. Балык үзенең бөтен буена ләмдә сузылып ята иде инде. Яшәү билгеләре чыгармаса да, аның киерелгән канатларында һәм койрыгында җимергеч көч барлыгы сизелеп тора. Аны кешеләр шундук уратып та алды: тәңкәләрен тотып-тотып карадылар, сыртына шапылдатып суккаладылар, авызы ачыла башлавын абайлап, артка чигенделәр. Балыкның ирене велосипед шинысыдай тыгыз, кайсы исән, кайсы сынык тешләре тырпаешкан. Саңак капкачлары, сыек ләмне көрәктәй көрәп, ян-якка ачылып китте, әләмнәрдәй тезелешкән алсу саңаклары күренде. Шул рәвешчә, балык һава сулады да аны мәгарәдән ишетелгәндәй мәгърур мөгерәү белән кире кысып чыгарды. Халык, ул тавыштан шикләнеп, аның койрыгы яныннан тагын да читкәрәк чигенде.

Чаныш, кулын Кадрәкнең арык иңбашына салып:

— Ышанмаган булдың. Менә, чыгардык ич, — диде. — Хәзер суга тәгәрәтәбез дә — вәссәлам, хушлашабыз.

— Мин хушлаштым инде, — диде Кадрәк басынкы тавыш белән. — Әнә кара: халык та хушлаша.

Кадрәк халык ягына ымлады.

Чаныш кешеләрнең нишләгәнен башта аңышмыйчарак торды. Алар арасында нindидер сәер т ә р т и п барлыкка килде. Тавышлар басылды. Кешеләр, ч и р а т к а тезелешеп, балык яныннан уза башладылар, әйтерсең лә м ә е т белән хушлашалар иде! Бер ир эшләпәсен салып узды. Аннан күрмәкче, бүтәннәре дә башларыннан салдылар.

Чаныш белән Кадрәк балыкның башы ягында басып торалар иде. Теге, өстенә арыш капчыгы япкан Петр, кайгылы чырай белән Чанышның кулын кысып узды. Арадан тагын берничә ир-ат шулай итте. Чаныш, үзен балык белән котлыйлар дип белеп, кулын сузып торды. Юк икән лә, кулын бөтенләй башка ният белән кысалар икән!

— Балыкны суга җибәрергә булышмыйсызмыни? — дип сорады Чаныш бер өлкәнрәк ирдән.

Җавап ишетелмәде.

Алар янына балык заводы директоры килеп басты.

— Эше бетте, кодагый, — диде ул беркемгә дә мөрәҗәгать итмичә. Тракторчыга борылып: — Арканны чиш, — диде, — рәхмәт.

— Ник чишеп торырга? Койрык качмас. Сез башын карагыз. Сезгә башы, миңа койрыгы. Башыннан да баш тартмас идем анысы. Күзләрен генә кара — светофор итеп куярлык.

— Безгә башы кирәк. Ул беренче номер белән китә, — диде директор, каш астыннан олы түрәгә ымлап. — Мондый балыкның бар хикмәте башында. Анда — ми.

Чаныш аркан очын чишәргә иелде. Тик, чыклы үләндә чыланган ат тышавы сыман, төен кулдан тая, ул бик нык тыгызланган иде.

Кемдер аның беләгенә кагылды. Ул артка күтәрелеп карады. Бая «Волга»дан төшкән кешеләрнең берсе икән.

— Азапланмагыз, — диде ул.

— Азапланма дип... кем...

Ләкин аның сүзен беркем игътибарга алмады.

— Яхшы, яхшы, — диде теге кеше, әре-әре атлап, балыкның башы ягына китте.

Директор олы түрә янына барып басты.

— Керемгә ала башларгамы, Даниил Афтандилович? — диде ул аңа.

— Башлагыз, — диде тегесе, имән бармагы белән балыкның сырт канаты элпәсенә төрткәләп. — Ярый. Без кузгалабыз. Эш беткәч, хәбәр итәрсез.

— Шикләнмәгез, Даниил Афтандилович.

— Ышанам, ышанам.

Әллә үзенең шикләнмәвенә ышанамы, әллә директоргамы — белмәссең, дип уйлады Чаныш. Ярым-йорты ым белән аңлашалар. Бер-береңнең ымына этләр шикелле колак шаңкайтеп сагая торган нинди замана соң бу?

Чаныш үз күңелендә нindидер шом салкынлыгын тоя башлады. Ул шом, таудан тәгәрәгән кар түмгәге сыман, зурайганнан-зурая барды. Бу кешеләрнең тел төбендә ни ятуы аның аңына ирешмәде әле. Шунысы анык: Кадрәк белән алар кайдадыр хата җибәрделәр. Чаныш монысына икеләнмәде. Алга килгәннән качып калып булмый, аны җиңәргә генә мөмкин. Һәм ул балык янында калган кешеләрдән:

— Сез нишләргә җыенасыз? — дип сорады.

Сорамый булдыра алмады. Аның койрыкка иелгән җиреннән тураеп, барысы да Даниил Афтандилович дип эндәшкән әлеге кеше каршысына барып басудан гайре чарасы калмады.

— Сез башлаган эшне без йомгакларга мәҗбүр, бабай... — диде Даниил Афтандилович, һәм, юлдашларының берсенә иелеп, нидер сорады. Чанышның исемен белеште бугай. Дөрестән дә, ул үзенә җәлеп итәрдәй матур елмаю белән: — Менә шул, Чаныш агай, — диде. — Ботканы үзегез пешергәнсез, нигә борчыласыз? Әллә ухамы? — дип ул көлеп куйды.

— Нинди ботка... нинди уха ди ул? Җибәрергә кирәк, иптәш!

— Әйе, ул хаклы, — диде Даниил Афтандилович балык заводы директорына. — Балыкны ул тоткан, бер кисәгенә лаек. Ничек уйлыйсыз, директор?

— Аңладым, аңладым. Рәхмәтеннән калмабыз, — диде директор һәм Чанышка борылып: — Бер кисәген бирербез, бирербез, — диде.

— К и с ә к? Мин сиңа эт мәллә?

— Кызык кеше икән син, бабай. Тулаем кирәкмени? Бөтенләй?

— Тулаем булмыйча ни!..

— Тамагыңа торыр бит, тончыгырсың!

— Ник торсын икән? Мин аны ашарга җыенмыйм. Ә менә балык тончыгыр. Күпме һава йотты. Аны суга җибәрергә кирәк. Адашканны к е ш е генә түгел, э т т ә әйди.

Сүзсез калдылар. Олы түрә читкә борылды. Тынычландырырга теләптер инде. Чаныш янына Кадрәк килеп басты. Тик ул да эндәшмәде. Барысы да ачык иде инде.

— Пычак бир, — диде Чаныш улына.

Кадрәк атасының яман эш кылмасын белә иде. Кесәсеннән ябылмалы пәке чыгарып сузды. Чаныш аны ашыкмый гына ачты. Балык заводы директорының йөзе үзгәрде, ул кабаланып милиционерларга карады. Лейтенант Даниил Афтандилович белән Чаныш арасына басты. «Но-но, бабай», — диде. Чаныш балык койрыгы янына килде, пәкесен өскә каратып, төен төбеннән арканны кисеп ташлады.

— Булыш, улым, — диде ул Кадрәккә.

Ике карт балыкны көчәнә-көчәнә суга тәгәрәтергә тырышып карадылар. Тик балык кымшанмады да. Чаныш җигүле килеш үлән утлаган атына әйләнеп карады. Ул аның бу юлы да ярдәмгә ярамаганын аңлады. Балыкны арканлап атка тагарга була, тик атны салкын суга куып кертмәссең бит инде? Ат этә белми шул, ул тарта гына. Шуның өстенә бу турыда яр текә, су тирән иде.

— Күңелегез булдымы инде? Йә, җитәр, — диде аларга директор. Ул бу картларның ниятенә төшенде, шуңа күрә, үҗәтләр дип, аларга ачуы кабарды.

Чанышның көчәнүдән сулышы капты.

— Кеше ләбаса без!..— дип гыжылдады ул.

Өметләнеп, район башлыгына карады. Хәзер үтсә аның сүзе генә үтәр кебек иде, ул гына аңласа, ярдәм итсә инде.

Юк, Чаныш үзе һичкемнең ярдәменә мохтаҗ түгел, аңа башлыкның аңлавы гына кирәк. Балык ярдәмгә мохтаҗ, ашыгыч ярдәмгә. Аны судан сөйрәтеп чыгарганга тугыз-ун минут тирәсе узды инде, хәзер ул тончыга, тагын берничә минуттан соң аңа бернинди ярдәмнең кирәге калмаячак. Балыкның суга сусавы кебек үк, Чаныш исәннәрнең исәннәргә карата мәрхәмәтле булуына, аеруча бер-берсенең хәленә керә белүгә сусап яшәде. Үз-үзеңне генә белеп тәкәбберләнүдән, масаюдан да яманрак нәрсә юк. Яхшылык каршында тәкәббәрлегеңне тыя, сүрелдерә алу —бар ярату һәм гомер итү шул түгелме соң инде? Ә үзеңдәге яхшы ниятләрне сүндерү үлемгә тиңдер ул.

Чаныш, әлбәттә, менә хәзер бу хакта уйламады. Ул мондый уйлар белән яшәде генә. Үзе үткән озын гомер юлының буеннан-буена ул берәүләрнең яхшылык кына кылырга омтылып торуын, ә икенчеләрнең шул беренчеләргә каршы торырга атлыгуын һәм яманлык кылуын күреп, белеп яшәде.

Козгынга ияреп, үләксә ашарга өйрәнсәләр, күгәрченнәрнең дә куркыныч булуын белә иде ул...

Чанышның чартлатып җиргә төкерәсе килде. Тик теле кипкән, аңкавы коп-коры иде. Нәфрәтләнгән җанын ачып салырга мөмкинлек бирердәй төкереге дә калмаган икән инде.

— Кайда торганыңны онытма син, бабай! — диде башлыкларның берсе.— Үзеңне кулда тота бел әле, пожалуйста. Халык алдында икәнеңне бел. Син бит акыл иясе. Малай-шалаймыни, ә?

А-а! «Кайда торганыңны онытма!» — дигән мондый сүзләрне Чанышның күпме ишеткәне бар! Хаклык дәгъвалый башласа, аны шулай туктаталар иде. Ул мондый сүзләрне яратучыларның үзләренә ярашмаган, җайсыз дип саналган кешеләрне җирдә тормыш яхшылыгы хакына сайлап алган хаклы урыннарыннан сөбереп ыргытыр өчен әйтүләрен әйбәт белә иде. С е б е р к е л е к е ш е н е кем уйлап чыгарган да, бүтәннәрне аның алдында кем гаепле иткән соң әле? Нигә кайберәүләр башкаларга каршы себерке куллана, ә икенчеләр нигә ч ү п санала? Кулына себерке эләктереп алган кеше япа-ялгызы гына калса, ә чүп дип саналган кешеләр тәмам бетсә? Себеркене селтәрләр дә селтәрләр, ә тирә-юнь буп-буш... Һаман шул селтәнү, һаман шул

«Кайда торганыңны онытма». Синең аңыңдагы, күңелеңдәге ачык хакыйкатьне бастырып торучы у т е р г е ч әшәке с ү з.

— Шушында торам мин, улым, синең белән янәшә, — диде Чаныш. — Мин монда син якты дөньяга килмәгән чактан бирле инде. Тик мин синең барлыкка киләчәгеңне белеп тордым. Монда синең белән янәшә булыр өчен торам да. Ник дигәндә, мин биредә синең үзеңне генә калдырырга ярамаганны беләм. Исән-сау булганда, мин шушында торырмын, улым. Бел: мин моннан үлгәч тә китмим әле. Шушында калам.

— Телеңә салынма инде, бабай! Синең алда килделе-киттеле генә кешеләр түгел, — диде милиционер кырыс итеп.

— Килделе-киттеле шул, килделе-киттеле. Киләләр дә китәләр...

Чаныш менә шулай диде. Ул бар зурлыгы, бар ныклыгы белән басып тора: бер кулын кесәсенә, икенчесен изүенә — нык итеп йөрәге каккан урынга тыккан. Хәер, аяк астында тайгак ләм ятканын да исеннән чыгармады, ләкин ул ләм астындагы үлән тамырларының мул, туклыклы җир суы белән тулганын да бик яхшы белә иде.

Алар китте. Аланнан барысы да китеп бетте. Үр кашында машиналар да юк иде инде. Берсе генә калды. Аның хуҗалары — шофер белән телсез бер ир-ат. Алар шунда, машина янында. Балык заводы директоры кул изәгәч, машиналарын кузгаттылар. Машина Чанышка пычрак боз кантары булып күренде.

Кара, Чаныш бөтенләй онытып җибәргән: җирән тракторы белән аның хуҗасы да шушында икән ич әле.

Алардан кала, яр буенда Чаныш белән аның улы Кадрәк тә бар. Һәм, әлбәттә, балык — аларның көмеш тәнле зур балыклары. Тагын ат бар, сыерчык бар, бал кортлары бар.

Ниһаять, машина түбән төшеп җитте.

— Ничек бүлгәлибез? — дип сорады алардан директор.

— Шул инде — балта белән чабып, — диде шофер.

— Бармы соң?

— Ник булмасын ди?!

— Товарлыгын бозабыз бит, егетләр. Ике куллы пычкыгыз юкмы соң?

— Каян килсен инде! — диде шофер. — Хан заманында яшәмибез ич. Яхшырак корал бар — «Дружба». Кичәдән бирле кабинада йөри. Кичә диләнкегә утынга барганыек.

Шофер, ухылдый-ухылдый, кабинадан моторлы пычкы тартып алды.

Чаныш калтырап китте. Бөтен тәненнән кайнар курку дулкыны йөгереп узды, җанында к а й н а р төер барлыкка килде.

— Кайда торганыгызны беләсезме сез, егетләр?! — диде ул.

Аның кычкырасы килде. Тик тамагы һаман коры, коргаксыган мичкә шикелле иде. Тавышы җанының ярыкларыннан коелып кына төште дә аяк астына сибелде, җиргә сеңде, юкка чыкты.

— Без монда, бабай, синең яныңда, — диде директор аның баягы сүзләрен мыскыллы кабатлап. — Балыкны күрәләтә ташлап китә алмыйбыз бит инде, ә? Әрәм була ич, кара каргаларга гына азык була.

— Монда түгел сез, балакайлар, монда түгел, — диде Чаныш, кояшка карап. Ул балыкның суга җибәрсәң дә үләчәген аңлый иде инде. Ул әлегә т е р е, ләкин ү л е м е дә шушы иде инде. Хәзер су аңа яшәү тирәнлеге түгел, фәкать кабер булырга гына ярый иде.

— Монда түгел? — дип кайтарып сорады директор, бирегә килгәннән бирле беренче тапкыр сигарет кабызып. — Кайда соң?

— Чокырда сез. Еланлы чокырда. Минем коткарасым килә... — дип, Чаныш бугазындагы кайнар төергә тыгылып калды.

— Коткарасың килә? Кемне?

— Сезне, оланнар, сезне.

— Безне? — дип гаҗәпсенде директор. — Нәрсәдән?

— Еланнардан... Балыкны җибәрик. Үз елгасында үлсен. Ул үз суында үлсә, еланнар сезнең җаныгызны ташлап качар.

— Гаҗәп кеше син, бабай, — диде директор тыныч кына.

Ул эчке кесәсеннән үтә күренмәле тартмага салынган төсле карандашлар чыгарды, кызыл фломастер сайлап алды. Сул кулындагы кәгазь кисәгенә карый-карый, балыкны төрлечә зурлыктагы кисәкләргә бүлеп, саннар сугып чыкты.

— Эләккән эре балыкны кире җибәргәннәрен кайда һәм кайчан күргәнең бар синең шушы гомереңә чаклы яшәп? — дип сөйләнде ул. — Алтын булса, бер хәер әле...

Кадрәк атасыннан:

— Ник аңламый алар сине? — дип сорады.

— Үз-үзләрен аңламаганга күрә.

— Моннан соң нәрсәгә генә ышанырга кала инде, әти?

— Кешеләргә һәм дә аларның үлеменә. Үлем кешеләрнең кем икәнлеген яхшы күрсәтә.

Чанышның сүзләре пычкы гөрелтесенә күмелеп калды. Шофер әйләнеп торган пычкы тасмасын теләсә нәрсәгә батырырга әзер хәлдә тураеп баскан иде инде.

— Кайдан башларга? — дип кычкырды ул көр тавыш белән.

— Башыннан! — диде директор. — Бу шайтанны алдан паралич ларга кирәк. Коерыгы белән имгәтүе бар, каһәр!

— Койрыгын кисеп бирегез дә, мин тайыйм, — диде тракторчы егет, Чаныш карт ягына карамаска тырышып. — Карап торуы куркыныч.

Телсез ир аның иңбашына сөякчел кулы белән кагып алды да үзенчә нидер әйтеп куйды. «Җебемә, туган!» — дию булды бугай.

— Оланнар! — дип ыңгырашты Чаныш, әле сүнмәгән, тик инде пыскып кына торган соңгы өмете белән. — Әйт әле аларга, Кадрәк... берәр сүз катып кара. Татарча, урысча әйтеп бак. Аналары телендә әйт...

Пычкы гөрелтесен уздырырга тырышып, Кадрәк аның колагына:

— Нәрсә дисең? — дип кычкырды. — Мин синең ни әйткәнеңне ишетмим!

Чаныш кабатламады. Башын күтәрде дә әллә кайчан оныткан Алласына мөрәҗәгать итеп, күңеленнән: «Нигә Син кешеләргә үзең дә күтәрә алмаслык җәрәхәт саласың?» — дип сорады. «Чөнки Син юктырсың, менә нигә», — диде ул үз-үзенә җавап биреп.

Ул күккә карады. Күк йөзе кул гына түгел, ә караш та җитмәслек биек, күңел иңләп бетерә алмастай киң, җан ышанмастай буш иде. Җирдәге эшләргә битараф карап дөньяны яктырткан кояш та, бу аланнан биеккә һәм ераккарак качарга теләгәндәй, күтәрелүен генә белде. Чаныш шул кояш астында, үзенә чит булып әверелгән кешеләрдән өстен хәлдә торды да, барысын да ташлап, әкрен генә читкә, корыган имән төбендә ниндидер язгы гөлнең шәмәхә чәчәге күренгән тарафка китеп барды. Ахыргы мәлдә ул үзенең күләгәсен урталай бүлеп, балыкка якынайган пычкы тасмасы күләгәсен абайлап өлгерде.

Һәм кинәт тирә-якка кырпы балыгының көчле мөгрәве таралды. Мөгрәү кинәт тынды, тирән бер сулыш булып сүнде, сүрелде. Ат моны бөтен тәне белән сагаеп тыңлады да, ышкылып беткән сары тешләрен ыржайтып, күптән булмаганча кешнәп җибәрде. Агач башларын кайнар җил бөгеп китте. Бал кортлары ояларына ашыкты, умарта ярыгы төбенә укмашты. Кошлар сайраудан туктады. Тынлык урнашты. Җирдән кояшка кадәрге араны мотор гөрелтесе генә тутырып тора иде.

Кадрәк карашын күләгә шикелле тын гына барган Чаныштан аерды да балыкның зур күзенә карады. Ул анда кулын сузып чәчәк-

кә иелгән, ләкин кулын ярты юлда туктатып, йөрәге турысына күтәргән, аннары кинәт җиргә ауган атасының чагылышын күрде.

Гаделсезлекне күралмаган Чаныш Наймушин җан бирмәде, ә аны күкрәгеннән көч белән кысып чыгарды. Ул җиңел үлем белән, җан газабы кичермичә үлде. Чөнки аның тормышны яратуы үзеннән таләп ителгән вакытта үләргә әзер торуы белән бер төенгә бәйләп куелган иде. Хәзер ул фәкать шул төенне генә чишеп җибәрде шикелле.

Соңгы мәлдә ул «элеф, би, ти, си...» дип, әллә пышылдады, әллә хәтерләде. Үлем килгәндә сүзләр ясый торган хәрефләр генә кала, күрәсең.

— Карама, балык, — диде Кадрәк һәм атасының соңгы чәчәкне исәргә өлгермәгәнен күрсәтмәс өчен балыкның күзен сөялле учы белән каплады.

## VII

Рациядән боерык биреп, елга буендагы үзәнлекне түгәрәкләтеп ураган солдатларны җиргә яткырдылар, ләкин уяулыкны бермә-бер арттырырга куштылар. Һәм салкын-битараф йөзле, күп еллык тәҗрибәсе бөтен кыяфәтеннән күренеп торган чал майор кулын изәде дә, уставта каралмаганча, әмма ышанычлы тавыш белән:

— С богом! — диде.

Лейтенант-оператор, морадына ирешү шатлыгын яшерергә кирәк тапмыйча, алдындагы кызыл төймәгә бармагы белән басты.

Сусаклагычның майор өстәлендәге критик схемасы буенча билгеләнгән өске өлешендә җир астына куәтле шартлаткыч салынган иде. Ул урында су өсте башта вак дулкыннар белән тулды. Агым бер генә мизгелгә туктады. Су чак кына иңгәндәй булды. Җир катламнары буенча тыгыз тирбәлешләр йөгереп узды. Алар, таралганнан-тарала барып, үлән һәм агач тамырларын өзде, чишмәләрнең күзен томалады, йомран, әрлән, суер өннәрен җимереп, аларны балалары белән бергә томалап калдырды, кош ояларыннан йомыркаларны коеп төшерде, ташландык урыс зиратындагы кеше сөякләрен кузгатты.

Шартлаткыч салып, өстән нык цемент измәсе белән томалап куелган өч шурф тирәнлегендә җир гөрселдәп куйды. Җир астындагы елганы күп тонналы буа белән каплар өчен, төгәл исәпләнгән, каракаршы юнәлдерелгән ике шартлау үткәрелде.

Болары белән бер үк вакытта барлыкка килгән бүтән шартлау ике елганың аслы-өсле аккан турысында катламнарны югары күтәреп ыргытырга һәм түбәндәрәк буылып калган җир асты елгасын өскә бәреп чыгарыр өчен юл ачарга тиеш иде. Исәпләүләр буенча, ул вакытта сусаклагычның суы артып, электр станциясенә куелган өстәмә турбиналарны, ниһаять, эшләтә башларга, ә мелиораторларга сугарулы басуларга юнәлтер өчен яңа ресурс бирергә мөмкин булачак иде.

Әгәр алдагы төнне таш катламнары арасындагы тар ярыктан бәреп чыккан салкын чишмәнең юлы тагын да киңәеп, ул турыдагы сусаклагыч суының аска ага башлаганын исәпкә алмасаң, бар эш алдан күз алдында тотканча төгәл башкарылды...

Көн уртасы — төш вакыты иде инде. Өченче, ягъни югарыга таба юнәлтеп үткәрелгән шартлату турысындагы су күпереп, ташып, ургып чыкты. Югарыга җир асты сулышы ыргылып менде. Кояш нурларында яңа куптарылган таш кантарлары һәм плитәләре ялтырап алды. Алар, батарга теләмәгән шикелле, айкалды-болганды да әйләнә-әйләнә төпкә тонды.

Бер метрдан биегрәк гайрәтле дулкын хасил булып, ул ярга ташланды, үсемлекләрне һәм таллыкларны җиргә сыгып китерде, ә кайбер урыннарда тәбәнәк ярлардан ашып, ерганак һәм чокырларны күмеп ташлады. Язгы ташкыннан калган төрле чүп-чарны күтәреп алып, чокыр-чакырга җыелган нефть күлдәвекләрен ияртеп, су кырларга һәм болыннарга җәелде...

## VIII

Алар бер-берсен әллә ничә тапкыр алыштырдылар инде. Пәке очы тупыйкланды, үтмәсләнде. Степан аны кирпеч ватыгына ышкып кайрарга кереште.

— Артык мавыкма, — диде Солтан. — барыбер тупаслана. Монда пәке генә түгел, булат хәнҗәр дә төтмәс.

Склепта һава җитмәс булды. Алар тирләделәр, пештеләр. Сусау басты.

Солтан кул сәгатенә карады. Җир астында бикләнеп калуларына өч сәгать икән инде. Ә нибар эшләре — ике кирпеч уеп алдылар. Беренчесен куптаргач, эш җайланарак төшәр, калганнарын бәргәләп тә суккалап каерырлар шикелле иде. Кая ул! Чартлап ябышканнар. Һәркайсын пәке белән генә уеп алудан гайре чара юклыгына ышандылар.

— Өч сәгатькә — ике кирпеч. Унсигезгә... егерме алты сәгать кирәк! — дип санады Солтан һәм: — Егерме алты! — дип кабатлады. — Степан, ишетәсеңме? Бер тәүлек дип маташасың тагын... Менә сиңа бер тәүлек!

Степан җавап урынына сүгенеп куйды.

— Таш юешләтерлек тә төкерек калмаган! — диде пәкесен чарлаган кирпечкә төкерергә тырышып.

Егерме алты сәгать... Алай гына булыр микән әле? Стенаның икенче кат кирпечен ую тагын да җайсызрак, озаграк булмагае. Егерме алты сәгать — әле бу төгәл эш вакыты гына. Хәл аласы бар ич әле, йокы да басачак. Менә бит! Сусыз-нисез, ризык заты күрмичә, кабер эчендә күпме интегергә туры килер икән.

Үз уйларын Степанга да әйтте. Ә ул торды да чалбар каешын чиште.

— Таш чылатырлык кына сыеклык бар икән әле, — диде ул. — Тамак чылатырлыгы гына юк.

— Нишлисең?

— Исең китмәсен сәнә! Олы йомышка да кысталмагаек әле. Бусы аның пәке кайрарга ярый ичмаса.

«Кабахәтләр! Менә нинди дәрәҗәгә барып җиттек, ә?! Үз каберләрендә булса, бер хәер. Чит-ят кешеләрнекенә, дөресрәге, мәетләрнекенә кереп бит...» — дип уйлады Солтан.

Ә авыл уртасындагы ташландык мәчеткә сугылып чыкканда бер дә болай уйламыйлар иде бит. Сукырлар! Саңгыраулар!

Татар зиратына мәет күтәреп барышлый җеназаны шул мәчет каршына җиргә куеп торып, дога укыналар иде. Солтан моны бала чагыннан яхшы хәтерли. Татарлар хәзер дә үз гореф-гадәтләренә тугрылыклыдыр әле? Күктән йолдызлар коелып бетмәгәне кебек, гореф-гадәтләр дә юкка чыкмагандыр.

Хәер, күк йөзендә йолдыз белән йолдыз бәрелешмәсә, җирдәге гореф-гадәтләренең бергә кушылып, бер-берсен ямьсезләвенә, юк итүенә мисаллар җитәрлек. Менә аларның авыллары. Элек ул зур, бай иде. Тора-бара тарала башлады. Халык нефтькә, яңа төзелешләргә китте, шәһәрләргә барып төпләнде. Су күтәрелгәч, аларга Благодатное дигән рус авылын күчереп утырттылар. Нигезләре төптә калды, зират-

ларының да байтак өлешен су агызды. Татар малайлары ярым-йорты урысча, рус малайлары ватып-сындырып татарча аңлаштылар. Солтанга җиңелрәк, очучы аталары артыннан ияреп, әллә ничә шәһәрдә яшәде. Авылга кайтып тора башлагач, ул иң элек шушы Степан белән дуслашкан иде.

Ике авыл кешеләре электән үк аралашып, шагыйрь әйтмешли, «тел, лөгать вә әхлак алмашып» яшәгәннәр. Ә бергә кушылгач, яхшы яклар белән начар яклар да керешеп, хәлләр үзгәрә башлаган. Аның бит, шайтан алгыры, начары яхшысыннан тизрәк йогучан. Шул ук мәет җирләүне ал. Поминкада аракы эчүгә татарлар да ияләшкән.

Бала-чаганың бергә әүмәкләшеп, сугышып, дуслашып үскәнен, бер мәктәптә укыганнарын Солтан яхшы хәтерли. Ике милләт егет-кызларның тора-бара сөешә, өйләнешә башлаганын да белеп үсте. Уртак туй мәҗлесләре китте. Табынның бер ягында — татар кода-кодагыйлары, каршы якта — урыс кум-кумовьялары. Бер як «Утыр әле яннарыма» дигән җырны башлый:

> Утыр әле, яннарыма,
> Ял булсын җаннарыма-а-а!..

Каршы яктан «Шумел камыш»ны сузалар:

> Шумел камыш, деревья гну-у-улись...

Җырны ярсу биюләр алыштыра. Бер тараф «Әпипә»гә әйттерә, икенчесе «Барыня»га баса. Хикмәт инде бер..

Бер заманны авылның көнчыгыш ягына өч чакрым ераклыктагы чувашларны да күчереп утырттылар. Бу үзәкләштерү дип аталды. Ә хикмәт башкада. Ничәдер нефть скважинасын бораулаганда нефтьчеләр, план куып, технология кагыйдәсен бозганнар: колонкалар артындагы бушлык цементланмыйча калган. Шуның аркасында чуваш авылы тирәсендәге барча чишмәдән керосин тәме килә башлаган. Кеше түгел, мал-туар да эчмәслек. Солтан аларның суны юынырга да, эчәргә дә бабалары авылыннан машина белән ташыганын яхшы хәтерли әле. Дүрт-биш ел шулай азап чиккәч, туган-үскән нигезләрен ташлап, чувашлар күченергә дучар ителде. Бер үк колхоз кешеләре бит. Илле-алтмыш йорттан торган чуваш урамы да чит монастырьга үз гореф-гадәтләре белән килеп керде...

Газеталарда бу авылны халыкларның дуслык үрнәге дип яздылар. Һәм, әлбәттә, моңа мисаллар да җитәрлек иде. Елга буенча круизда йөргән чит ил туристлары да күренгәләде. Фотога алсыннар дип, йөртүчеләре аларны зиннәтле өйләр янына китерә, бизәкле тәрәзә йөзлекләре, затлы капкалар каршына бастыра. Тегеләр — чарт та чорт инде. Әмма ташландык мәчет «фотогеничный»рак, күрәсең, шуңа балга ташланган чебен кук ябырылалар иде...

Икесенә алмаш-тилмәш бер папирос тарта-тарта (Степанның җиде «Беломор»ы, Солтанның унике «Космос»ы калган иде) хәл алганда ике кабердәш шушылар хакында сөйләшеп утырдылар.

— Хәтерлисеңме, безгә, юеш борынлы бала-чагага, коммунизм турында инша яздыралар иде? — дип сорады Солтан.

Степан акланган шикелле итеп:

— Мин үзем «өч»ледән узмадым, — диде.

— «Мелочь» миңа бишле куйган иде.

— Кем әле ул «Мелочь»?

— Син укытучыларыңны онытма инде, туган.

— Акырудан бүтән нишләде соң ул алай онытмаслык? Бар нотыгы: «Укы, укымасаң, ат көтүе көтәрсең!» — диюдән узмады. Хәзер бик рәхәтләнеп көтәр идең дә бит... атлары кайда?

— Безнең атлар ерак китте. Чит илләргә. Турист булып түгел... Бельгиягә, Франциягә, Италиягә... Аларга — деликатес, ә безгә — валюта. Суеп ашаганнардыр. Валютасы да шунда калды. Безнең атлар

алардан сатып алынган нефть суыручы батырма электр насослары булып кайтты да, нефтьне суырып, тагын аларга озатты. Ил өчен баш салдылар. Аннары — КамАЗ станокларына әйләнделәр, башкага...

— Эх, паря!.. Ул КамАЗларның Әфганстанда ничек янганнарын күреп сызландым мин.

— Теге... халыктан сыер җыеп алганны хәтерлисеңме? Бер очтан колхозның утыз биш атын да алып киттеләр. Халык елап артларыннан чапты... хәтерлисеңме?

— Эх, паря!...

Чыраның төбенәчә янып сүнүен искәрми калдылар. Ут сүнде. Тагын төпсез караңгылык басты. Кабер чиксез кечерәйде кебек. Солтан кысанлыкны авыр кичерә иде: сулышы кысылды, тәне, шартларга җитешеп, ирекә омтылды, җанына шом иңде. Караңгылыкны кара төшергеч кәгазе урынына бөгәрләп ыргытасы килде. Ниндидер авырлык аны шушы кабер белән бергә сытар, изәр, туфрак, ком, таш белән бергә кушып туглар сыман тоелды. Ялгызлык хисе урап алды. Шушы кичереш аның әлегә тере икәнен, әмма үлемсез булмавын, вакыты җиткәч, котылгысыз төстә үләргә туры киләчәген һәм шушындый караңгы кабердә япа-ялгыз калачагын, ә а н д а, өстә, үзен оныттачакларын, кешеләрнең исә яши бирәчәкләрен шәфкатьсез төстә искәртте. Ул, үз үлеменнән соң да күктә яктырачак кояшны соңгы тапкыр күреп калырга теләгән төсле, калтыраган бармаклары белән кабаланып шырпы сызды. Яктырып китте.

Иптәше яңа чыраны шырпы утына төртте. Идәндә, стеналарда, түшәмдә күләгәләр җанланды. Кабер киңәеп китте. Солтан, сандугачка елмаеп күз кыскач, чират анык булмаса да, кирпеч ярыгын үҗәтләнеп кырырга кереште.

— Сәгать ничә? — дип сорады ул.

— Унике тулып килә.

— Бүген шимбә бит әле?

— Шимбә.

— Якшәмбедә генә чыгабыз икән.

— Миңа барыбер. Чыгыйк кына... Әллә калыйкмы? Кешеләргә эш кими торыр, — дип көлде Степан.

— Тәлинкәне әйләндерик әле, Степан. Кабердә яшәү турында сөйләшергә кирәк. Матур үткәннәр, гүзәл киләчәк турында.

— «Тел ачкычы» булса иде ул! Бер яртысыз нинди хыял уянсын?

— Ал, эч.

— Сатучысын тапсак та, кесә буш шул.

— Иптәш полковниктан сора. Әҗәткә ярты йомды бит ул. Куенында кочаклап ята.

— Ну пар-ря!.. Карале, ә? Онытылган!

Чыраны Солтанга биреп, Степан табут капкачын ачты, калай япманы күтәрде, бераз актарынгач, аракы шешәсен суырып чыгарды. Мәет исен тоеп, чырайларын сыттылар.

— Как у Христа за пазухой! — диде Степан, табут капкачларын дөбердәтеп япты. Утырыштылар. Степан пәке белән шешә бөкесен ачарга җыенды.

Кинәт табут астан өскә сикереп, аннары чайкалып куйды. Әйтерсең лә андагы мәет чыгаруларын сорап дулый иде! Икесе дә сикерешеп тордылар. Сандугач пырылдап күтәрелде һәм кабер эчендә бәрелә-сугыла очына башлады. Егетләр ниндидер тонык гүелдәү ишеттеләр, аякларына сизелеп, җир астыннан дулкын йөгереп узды. Тузан күтәрелде, кирпеч ватыклары, идәндәге склет сөякләре кыштырдады, теленгән чыралар зыңлады, ялкын калтыранды. Чатнау ишетеп, кабердәшләр янга борылып карадылар, күз алларында алар пәке белән кырып кергән эз буенча бармак сыярлык ярык ачылып китте.

Шулай ук кинәт бөтенесе тынып та калды.

— Нәрсә бу?— дип сорады Солтан.

Тезе астына суккан сыман, Степан Масленников тезләнде, кулын сузып, югары карады, аннары икона калдыгына текәлде, сыны бөгелеп төште. Ул, йодрыгы белән таш идәнне төя-төя:

— Прости меня, господи!— дип пышылдады.— Прости, что руку замарал о подонка,— дип дәвам итте ул, тавышын торган саен күтәрә барып.— Прости, что над душой своей насильничал. Прости, что это не я, а сволочь какая!.. Прости, что не верую в тебя, потому как ты терпел подобных полковников на земле... Прости, что не умею прощения у тебя просить как следует, так как никто меня не учил этому... Прости!..

Шаярта дип уйлап, Степан көләргә әзерләнгән иде инде. Әмма иптәшенең пычрак битен чылатып тәгәрәгән эре күз яшьләрен күреп, исе-акылы китте.

Степан калыкты, борынын тартып куйды, карамыйча гына шешәнең муеныннан каптырып алгач, бөтен гәүдәсен калтыратып җибәргән гайрәт белән аны стенага томырды.

Куркуыннан нишләргә белмәгән сандугач оясына сеңде.

Кабергә аракы исе таралды.

— Әллә җир тетрәде инде?— диде Солтан.

— Хәзер анысы да булгалый. Күпме нефтьне суырттылар. Ә майсыз калгач, җир нишләсен? Коргаксый. Коргаксыгач мичкә дә тарала... Ә бусы — хәрбиләр эше аның. Җир астындагы елганы өскә күтәрмәкчеләр, дип сөйләгәннәр иде...

Солтан стенага сөялеп утырды. Йокысы килә иде. Нигә черем итеп алмаска? Ул басты да кулындагы чыраны җайлап ярыкка кыстырды, бу юлы сузылыбрак ятты.

Шул чакны авыр тынлыкта ишетелер-ишетелмәс кенә кош сайравы ишетелде. Сандугач! Тыштагысы! А н д а г ы с ы — Якты дөньядагысы! Кояш астындагысы... Ул аваз, әйтерсең лә, кош сайравы да түгел, ә дөм-караңгы төндә әллә кайларда ялтыраган учак уты гына.

Сискәндереп, т е г е н д ә г е кошка м о н д а г ы с ы кушылды. Ярты йөзендәге сыңар күзен зур ачып, иконадагы сурәт тә үлеләр дөньясына җан иңдергән яшәү авазларын тыңлап тора иде шикелле.

V

Авырайган күз кабакларының йомылуын Солтан сизми дә калды. Аны сузып салган аяклары өстендәге ниндидер тавышсыз хәрәкәт уятты. Һичнинди өн-тавыш ишетелмәвенә сагайды. Хәер, монда үле тынлыктан, күзгә төртсәң күренмәслек караңгылыктан гайре һични булмаска т и е ш тә инде. Ул пәке кырган тавыш юклыгын искәрде. Степан кайда соң? Янәшәсендә ята икән. Аягын бөкләп, тезенә башын салган, иренен чәпелдәтә-чәпелдәтә йоклый.

Солтан кулына таянып торырга теләгән иде дә, учы астында ниндидер тыгыз, чиркандыргыч салкын нәрсә тойды. Караш ташласа, катып калды: елан! Ботларына аркылы ятып бүтәне шуыша. Аны шулар уяткан икән! Эченә шомлы салкын йөгерде, авызында күгәрек тәм барлыкка килде.

Ул корт чаккандай сикереп торды, стенага терәлде: аяк астында туктап калган еланга басудан курыкты.

— Степан!— дип кычкырды ул.— Тор!

Степан уянды, башын күтәрә төшеп, күзен угалады.

— Тор!— дип кабатлады Солтан.— Еланнар!

— Нигә чәбәләнәсең?

— Еланнар дим бит!

Степан ул төртеп күрсәткән якка карады. Ләкин иренен чалшайтып һәм тешләрен бер яктан күрсәтеп, теләмичә дигәндәй елмайды гына.

— Ә-ә, кире кайтканнар, хәшәрәтләр,— диде ул.— Баягы тузбашлар.

Солтан тынычлана алмый торды. Еланга таянган уч төбенә кызган тимер тигәндәй тоелды. Сандугач исенә төште. Аның үз урынында икәнен күргәч, буыннары йомшап китте. Үзләре уеп кергән тишек ярыкларыннан әчкә шуышкан яңа еланнарны абайлап, ул кулына кирпеч алды.

— Нишлибез?— дип кычкырды ул карлыккан тавыш белән.— Сытарга кирәк!

— Азапланма,— диде Степан һәм бөтен чыраен киереп, иснәп алды.— Сиңа тими алар.

— Ашарлар ич!

— Безнеме? Ха-ха! Тамакларына торырбыз.

— Сандугачны. Йомыркаларын...

— Анысы ихтимал.

Аяк астындагы еланны тотып, Степан югары күтәрде. Елан бау кисәге шикелле сыгылып төште, әмма шундук киерелеп турайды, Степанның беләгенә уралырга маташа башлады. Степан аны тишек белән таш арасындагы ярыкка башы белән тыкты да эткәләп төшереп җибәрде. Ә анда, ярыкның төрле ягыннан башка тузбашлар сузылып керә башлады. Кабердә алар дистә чамасы икән инде: идәндә дә шуышалар, склет сөякләре арасында да, икона өстеннән дә... Табутка гына менә алмаганнар.

— Ярыкны томаларга кирәк,— дип киңәш бирде Степан.

Кирпеч ватыкларын ярык тирәли тезделәр, штормовка белән свитерны да кыстырдылар.

— Калганнарын үзең кара инде,— диде Степан.— Үңәчләреннән тот та артларына тибеп очыр. Шүрләмә, чакмаслар.

— Ә син?

— Дәвам итәм.

Солтан яңа чырага ут элеп тотты һәм, елан тоткан саен бер үк ташны ачып, аларны тышка чыгарып бетерде. Кайберләре сөякләр арасына, табут астына шуышты, аларны кузгатып ауларга кыймады.

Сандугач аның арлы-бирле йөренүенә күнекте, борчылмады.

— Нигә монда тулган алар?— дип сорады Солтан.

— Үзем дә уйлыйм. Минемчә, аларны җир гөрселдәве куркыткан. Җир тетрәү дип белгәннәрдер. Җир тетрәү бер генә тапкыр булмый бит, кабатлана. Алар өчен таш кабер иң шәп урын инде.

Ярты сәгать эшләгәч, Солтан тагын ял итәргә утырды. Күптәннән җырламаган бер җыр исенә төшеп, тын гына, вакыт үтсен өчен генә көйли башлады. Океан корабына төяп еракка-еракка озатылган кораб, һәлакәткә очрагач, океанны йөзеп чыгарга азапланган, ахырда батып калган атлар турында иде бу җыр.

Ә Степан кирпеч араларын кырды да кырды. Бу аваз аларның күкрәкләрен, тешләрен, сөякләрен тутырган кебек иде инде. Степанның чәче юеш маңгаена ябышкан. Ул илһамланып, онытылып эшләүче скульпторны хәтерләтте.

— Яхшы җыр,— диде ул.

Солтанның күз алдындагы атлар юкка чыкмады. Алар, океан суы төбендә калырга теләмәгән сыман, аның хәтеренә калкып чыктылар, гүя күңел тәрәзәсе аша күренәләр иде. Ул, әлеге тәрәзәгә капланып, әллә кайларда калган балачак күренешләрен исенә төшерде. Әнә салам яки такта түбәле тәбәнәк, фәкыйрь авыл өйләре. Әнә колхозның саманнан салынган ат абзары, аның янындагы бәләкәй, кыйшык кәнүшни йорты, тезеп куелган арбалар. Әнә көне буена кешеләр кебек үк эшләп алҗыган атларның тыенкы пошкырулары ишетелә. Әнә күктә йолдызлар кабынды, тулган ай калыкты...

Һәм Солтан, әле генә җырлаган җыруын дәвам иткән шикелле, әкрен генә сөйли башлады.

## IX

...Ул елны иген уңды. Күптән булмаганча, халыкка ашлыкны хезмәт көненә бирәр килодан бүлделәр. Мондый юмартлыкны оныткаччар иде инде. Өстәвенә, кая карама — болыннарда, басуларда, шәхси хуҗалыкларның ындыр артларында — салам богыллары, печән чүмәләләре. Яшә, шатлан, туйганчы аша, балалар үстер, малтуар асра. Халык арасында, акчаны да унар сумнан түлиселәр икән, дигән сүз чыкты. (Иске акча белән, әлбәттә.)

Ләкин бусы язмаган икән. Колхоз идарәсе утырышында төн уртасына кадәр, карлыгып беткәнче, тәмәке төтененә исергәнче утырдылар. Бигрәк тә уполномоченный Демид Лисин җан-тиргә батып тырышты.

— Югарыда дөрес аңламаслар. Елның уңай килүеннән файдаланып, дәүләткә бурычыгызны кайтару җаен карагыз. Ә бурычыгызның ярты миллион икәнен онытмагыз...

Идарә әгъзасы Шәмгун, өндәү билгесен хәтерләтүче агач аяк киеп йөри торган карт кеше, кая гына бармасын, үзе белән кесә тутырып сорау алып чыга иде. Бүтәннәр черт-черт көнбагыш яра, тәмәке пыскыта, ә ул сорау арты сорау яудыра.

— Моның хәдәрле әҗәтне чәчеп үстерсәң дә җыеп булмый лабаса, җәмәгать! Әйтик, минем нибар дәүләтем Мәйсәрә җиңгәгез инде, иеме? Ул канәгать калган саен, миңа әҗәт кенә өстәлә барамыни?.. Ниемә ыржаясыз?.. Шуның ише, дәүләт баеган саен, колхозның ыштан төбенә җыеламы?

Бу сорауны, кызган тимер чыбыктан кармак бөккән шикелле, Шәмгун карт күптән әзерләп куйган иде инде. Җае чыкты. Шул кармакка Мәйсәрәсен җим урынына каптырып, уполномоченныйның чуртан балыгыныкы сыман очлы танавына ыргытты.

— Политик яктан чатан сораулар белән Совет дәүләтен алга җибәреп булмый бит, Шәмгун агай! — дип, партоешма секретаре Михай Кукушкин аның кармагын турыларга теләде.

— Булмагачыннан соң Колчак мине ниемә дип чатан калдырган?

— Чатан сорау белән чатан аякның ни катнашы бар монда?

— Шуларның икесен бергә кушсаң, шул биш йөз мең тәңкә бурыч килеп чыга да инде. Минә нинди катнашы бар. Минем патшага да аның хәдәрле әҗәтем җукые, энем.

— Кем әле аны синең бурычың ди? Син колхоз бурычын тикшермә, Мәйсәрә апага булган әҗәтеңне генә бел,— дип, парторг сүзне шаяртуга борырга тырышты.

— Анысын мин үзем карармын инде, Михай энем. Ә ярты мильонны мич башында гына хәл итеп булмастыр, шәт.

Бәхәснең чыга алмаслык тирәнгә кереп китүе ихтималын искәреп, идарә рәисе Нәҗип Мияссәров карандашы белән төбе яшелләнеп мүкләнгән графинны каккалады:

— Көн тәртибендә башка мәсьәлә, иптәшләр!.. Тыңлыйбыз сезне, Демид Прокопьевич...

— Шулай тыңлап кына утырсак, тиздән мильянер ук булмабызмы соң, җәмәгать? Ыштансыз мильянерлар!..

— Менә, менә! Ыштансыз калмас өчен мин һәр хезмәт көненә ноль бөтен уннан биш сум түләү максатка ярашлы булыр дигән тәкъдим кертәм,— дип дәвам итте уполномоченный.

Ел ахырына, яңа тәкъдимнәр керә торгач, ноль бөтен уннан биш сум дигәнең ноль бөтен уннан өч сумга калды. Утыз ике тиен урынына (һаман шул иске акча белән инде бу), шулай, «сум» дигәннәр. «Сум» дигәч, күбрәк күренә, янәсе...

Уполномоченный Лисинга да «өлеш» чыккан: аңа «Ноль бөтен»

дигән кушамат такканнар. Аның турында сүз чыкканда баш бармак белән урта бармактан түгәрәк ясап кына күрсәтә башлаганнар.

Колхозның ул елгы бар ашлыгын диярлек дәүләткә тапшырып бетергәннәр. Шулай итеп, ашлык сату йөкләмәсен арттырып үтәгәннәр. Өстәмә план алганнар. Үтәгәннәр. Кышка кергәндә колхоз амбарлары каравылчысы «кыскартылган». Моны хезмәт хакын янга калдыру дип санаганнар. Чөнки келәтләр буш, каравыллар нәрсә калмаган. Склад мөдиренә берданкасы белән яшелләнеп күгәргән ике патронны тапшырган чагында, кимсетелгән горурлыгын яшерергә тырышып, каравылчы Шәмгун карт, ә кушаматы белән әйткәндә Шәмәй, күкрәген каккан:

— Аллаһе тәгалә шаһит, үзем дә китмәкче ием. Күселәрнең ул ачлыктан чинаганына ничек түзмәк кирәк?

Колхоз амбарлары авылдан читтә, инеш аръягындагы ат абзарлары һәм техника мастерское янында тора иде. Ач күселәр башта комбайннарга кыска вакытлы яулар ясап, бункердагыдыр, шнек, барабаннардагыдыр үргән бөртекләрне ашап җан асраганнар. Механизаторлар аларның соңгы тәгәрмәчләренә кадәр ялап алынгандай чистаруына шаккаткан. Кемгә рәхмәт укырга белмичә, башларын кашыганнар. Шикләре тимурчыларга һәм, спутник, космос чоры башланып китү уңаена җайлаштырып, марсианнарга төшкән. Бик яхшы: комбайннарның, чәчкечләрнең серле чистаруы да колхоз акчасын янга калдыру дип исәпләнгән.

Авылга өченче көчеш властьлар кушуыннан тыш кына башланды. Каравылчы Шәмәй картның соңгы әзләре буенча иснәнеп, колхоз амбарларының мәңгелек хуҗалары булган күселәр үзләрен мөһаҗирлек язмышына дучар иттеләр — авылга күчтеләр.

Алар атлар абзарына баштан ук кызыкмадылар. Күселәр кысыр өметкә бирелми. Атларның күптәннән солы, арпа күргәне юк. Яннары кимерелеп, төпләре яланып беткән улаклар абзар артына ук чыгарып өелгән. Атларга солы, арпа, көрпә бирелә торган кышкы зәмһәрир суыкларына кадәр ерак иде әле.

Шәмгун картның каравыл объектына йөри торган үз сукмагы бар. Ул сукмак, картның сыңар аяк табанын туздырмау вә тамак ялгаган ризык көчен юкка сарыф итмәү максатыннан, зират аша турылай салынган һәм инешкә аркылы ауган каен аша үтә иде. Күселәрнең дә ач чагы, хәлләре мөшкел, шуңа күрә мөһаҗирләрнең беренче эшелоны Шәмәй карт таптаган шул сукмакны сайлады. Шулай итеп, күселәрнең беренче һөҗүме Шәмгун картның шәхси хуҗалыгына юнәлде. Күп еллык эшендә тәҗрибә туплаган карт үз келәтендә йөз пот ашлык сыешлы ларның аңлаешсыз төстә кими баруын бик тиз абайлады һәм күзәтүләрен авылдашлары белән уртаклашты. Ирләр, көзге кояшның кичке нурларына хозурланып, бүрәнәдә утыралар иде, бу хәбәрне күмәк рәвештә башларын кашып каршыладылар. Шәмәй карт исә агач аягының резин табанын кашыды. Мондый гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда башына коткаргыч уй килмәсә, ул гаҗизлектән һәрвакыт шулай итә иде.

Бәхәсләшә торгач, Шәмгун картның йөз пот сыешлы ларына марсианнар иярләшкәндер, дигән фикергә килделәр. Ләкин аларга теш җиңел үтмәс, аларны коры кул белән генә алдырып булмастыр. Марсианнарны барлык пролетарийлар дөньясы, кирәк калса, бөтен галәм алдында фаш итү юлларын эзләргә керештеләр. Көн тәртибендәге беренче мәсьәлә итеп, аларны ни белән ауларга дигән сорау тикшерелде. Күсе агуына яки, башкалар да күреп сабак алсын өчен, күсе капкынына тукталдылар. Ләкин крестьяннар җанында һәрчак уяу торган бер шик өскә калкып чыкты. Марсианнар андыймондый гына җан иярләре түгелдер, алар белән белер-белмәс каршылыкка керсәң, галәмара хәлне катлауландырып җибәрү ихтималы

бар бит әле. Тавышка куеп, араларыннан берсенең битараф калуын ачыклаганнан соң, караңгы төшүгә һәм салкынайтып җибәрүгә карамастан, киңәшмәне дәвам итәргә карар кылдылар.
Төрле фикер тәкъдим ителде. Берсе Министрлар Советы рәисе Никита Сергеевич Хрущевка язарга кирәк дигән уен уртага куйды. Ул — баш, крестьян мәшәкатьләре һәм борчуларыннан хәбәрдар булырга тиеш. Бүтәне каршы төште: зур кешенең башын җыен чүп-чар белән тутыру килешмәс, эшләре болай да буа буарлыктыр. Өченчесе космонавт Юрий Гагаринга телеграмма сугарга, бәлки телефоннан ук шалтыратырга киңәш итте. Ник дигәндә, галәмдә Җир шары тирәли әйләнгән кешегә өстән яхшырак күренергә тиеш. Марсианнарны, мөгаен, ул беләдер. Дүртенчесе тагын да тирәнрәк сөрде: Берләшкән Милләтләр Оешмасын ярдәмгә чакырмаска микән, җәмәгать? Халыкара хәлнең кискенләшкән чагы, җыелышып тикшерсеннәр, югыйсә соң булмагае. Чөнки Шәмгун картның лары төпсез түгел ләбаса! Аның төбенә төшеп җиткәч, марсианнарның башка келәтләргә дә ябырылуы бар. Монда эппәр әйткәч, күрше авылларга, бүтән районнарга, өлкәләргә, чит илләргә дә таралулары, бөтен галәм киңлеген басып алулары ихтимал ул гуҗларның! Итәк-җиңне тиз көндә җыярга, коралланырга, баскыннарны себереп түгәргә һәм үз өннәрендә тар-мар итәргә кирәк. Кушкаен авылы кешеләре бу өлкәдә башлап йөрергә, бөтен илгә чакыру салырга һәм Җир шарындагы барлык илләргә үрнәк күрсәтергә бурычлы. Гәҗитләрдә милләтнең теле, рухы, киләчәге куркыныч астында дип язалар, татарның йөзе ак, җаны пакь икәнен тагын бер тапкыр күрсеннәр...
Иң соңыннан туксан тугыз яшьтәге чуваш карчыгы — сөяк утыртучы һәм күрәзәче Юхмача әби, Шәмгун картның йөз пот сыешлы ларын өшкертү йә булмаса имләтү уңайрак дип киңәш иткән иде. Аның киңәшен җитди дип тапмадылар. Тик шайтанның ни уйлаганын кем белә! Алдагы тәкъдимнәр чарасыз калган сурәттә, Юхмача әби ысулын сынап карарга килештеләр.
Озак һәм кайнар бәхәстән соң әлегә район түрәләре, аларның да иң зурысы белән чикләнергә дигән карарга киленде. Аннары күз күрер тагын, диделәр.
Йомышчылар сайланды. Башлык итеп Шәмгун карт билгеләнде. Шуның белән очлап таралыштылар.
Юлга таң күзеннән чыктылар. Башта кабул итү бүлмәсендә көтәргә туры килде. Авыл кешесенә сабырлыкны умырып биргән бит ул. Үгезне мөгезеннән алу килеп чыкмавын яхшы фал һәм кичектергесез сәбәпкә санап, Шәмгунне кизү урынына калдырып тордылар да якындагы ашханәдә «тел ачкычы» салып килделәр.

Төш узгач, баш түрәнең чыпчык чүпләп бетермәслек ашыгыч эшләрендә бер ара табылды. Алай бик җәелеп кабул итмәде итүен. Бөтен ил буенча Алып батыр адымнары белән дәүләткә терлекчелек азык-төлеген моңарчы күрелмәгәнчә тизлектә әзерләү һәм тапшыру буенча Рязань өлкәсе үрнәге җәелгән чак. Ә бу — якты киләчәкне тайпылышсыз төстә тагын да якынайту дигән сүз. Киләчәкнең каршыга җәһәтрәк һәм өлгеррәк килүе ихтималыннан шикләнәләр иде. Рязаньлыларны ничек тә уздырырга, кем әйтмешли, аларның борыннарына чиртергә кирәк.
Крестьяннар баш түрәнең кабул итәргә теләмәвен шактый дәвамлы бәхәс нәтиҗәсендә тар-мар китергәннән соң, аларны, ниһаять, аяк терәп омтылган бүлмәгә керттеләр.
Мәсьәләне кабыргасы белән уртага чыгарып салдылар. Йомышчыларның тирәнтен гаҗәпсенүенә каршы, башлык вакыйгага үтә кызыксыну белән карады. Әңгәмә киңәйгәннән-киңәя, кызганнан-кыза барган саен, бүлмәдә яңадан-яңа йөзләр пәйда булды. Аннары

районның баш хуҗасы — ярты күкрәге җәйге болындай чуар орден-медаль тасмалары белән тулган иптәш Абдуллаҗанов аппаратның барлык әгъзаларын чакыртып китерде. Шәмгун картның амбарыннан ашлык югалу мәсьәләсе аларны аеруча кызыксындыра булып чыкты. Ничә хезмәт көненә тигән күпме ашлык, яңа уңышка кадәр җитәме — барысын да сораштырып, алларындагы ачык дәфтәрләренә язып терки бардылар.

— Артыгы белән, алла теләсә!— дип җавап бирде Шәмгун карт көр тавыш белән.

«Артыгы белән» дигәнгә күмәк рәвештә шатландылар, «алла теләсә» дигәнен ишетмәмешкә салыштылар. Шуннан соң шәхси хуҗалыклардагы мал-туар санын сорадылар, көрлеген, крестьянга аларны асрау авырга килмиме икәнен белештеләр.

— Үз күлмәгең үзеңә якын инде анысы,— дип, Шәмгун карт янә өлгерлек күрсәтте. Ләкин үзенчә бик мөһим булган төзәтмә кертүне дә кирәк санады:— Алай да, наным, җанны бер сорау кимерә: ул шәхси мал-туар дигәнне җәһәннәмгә олактырсаң да таман. Җелекне суыра инде менәтерә! Мәйсәрә җиңгәгезне бер зәхмәт... ничек әле, аты коргыры, ы-ы-ы... радикулит интектерә бит әле. Минем агач аяк та кәҗүнни түгел. Ит-сөтне кибеттән генә сатып ала торган булса, иңнән таш төшәр иде дә бит кана. Күпме мәшәкатьнең муены аска килер иде. Тик акчага тиенгән җук. Учка кергәненә шалкан да сатып алалмыйсың. Шикәрне дә җан башына шакмаклап кына бирәләр.— Шушында Шәмәй халыкара эшләрдә дә шактый тирән йөзгәнен күрсәтмәкче булды.— Тугандаш Куба ни карый? Ни өчен шикәрне әчмүхалап кына җибәрәләр? Теләктәшлекләрен нигә бөтен буе белән чыгарып салмыйлар? Айова штатлы АКШ борын төпләрендә генә ләбаса. Бүтәннәр өлгергәнче, шуларның аналарын өшкереп булмыймыни? Кул гына сузарлык ич, борыннарына чиртсеннәр шуларның безгә шикәр җибәреп кенә булса да! Камышлары корып беткән мәллә? Сазлыкларда су сипмичә үсә бит ул, аңа корылык нипачум. Ул камыш безнең Сөләй тавы итәген ураган сазлыкларда ерып чыккысыз. Килсеннәр дә чапсыннар, без каршы түгел. Безнең авыл халкына гына җитәрлек шикәр эшкәртерлектер әле. Юкса без бит аның җаен-путен белмибез.

Куба һәм шикәр кысанлыгы турында башлыклар кыска гына аңлатма бирде:

— Кочинос култыгы, Плая-Хирон, АКШ ялчыларының контрреволюциясе. Шикәрне әлегә Кубаның үзенә әҗәткә биреп торырга туры килә...

— Хәлләренә керми булмый анысы. Култык астында Хирон торганда, җиңел түгелдер. Тик бит безнең ашказаннарында да хирон!— диде Шәмгун карт.

Кемнәрдер авызын каплап, тыенкы гына көлешеп алдылар. Ә менә Шәмгун карт теле белән халыкның ит, сөт, май кебек көндәлек товарларны кибеттән сатып алу кирәклеге турында дөрес фикер йөртүе өчен йомышчыларны мактадылар. (Каләмнәрен һәм карандашларын күмәк кыштырдатып, монысын да кәгазьләренә теркәп куйдылар). Ә моның өчен нишләргә кирәк соң?

Йомышчылар бер авыздан:

— Акча кирәк!— дип җавап бирделәр.

— Дөрес, акча. Аны каян алырга? Яле, яле, башыгызны эшләтеп карагыз, иптәшләр.

Делегация вәкилләре, күзләрен кысып, башларын күпме генә кашысалар да, анык фикергә килә алмады. Шәмгун исә, гадәтенчә, агач аягының резин табанын кашыды, тик акча мәсьәләсе бик томанлы иде. Үкчәдән баш миенә кадәрге ара шактый шул.

Сүз куешкан шикелле башта бер-берсенә карашып алганнан соң,

башлыклар ярдәмгә килде. Бер-берсенә карашкан вакытта алар нindidер киңәш кордылар бугай, монысы йомышчыларга караңгы калды. Ә башлыклар болай уйлаштылар: боларга үз фикерләрен әйтергәме соң, әллә уңайлырак вакыт һәм үзгәрешләрне кабаланмыйча көтеп, махсус күрсәтмәләрдән башка берни дә кылмый торыргамы? Төп хуҗа җаваплылыкны үз өстенә алырга булды. Ул елмаеп җибәрде һәм кадерле бу елмаюын йөзеннән ахырынача югалтмады.

— Әгәренки...— дип, халыкчан сүздән башлады ул һәм, бүленеп, Шәмгун карт янына күчеп утырды.

Шәмәйнең күршесендә чуваш Порфирий утыра иде. Ул ашыгып үз урынын бирде дә, йөзен читкә борып һәм авызын, йөткерер өчен томалагандай атлы булып, көрәк кадәрле учы белән каплады. Әмма йөткерүе аны коткарып кала алмады, киресенчә, ашханәгә ни өчен барып килгәнлеген фаш итте.

— Әгәренки,— дип дәвам итте башлык Шәмгуннең иңбашына кулын куеп,— әгәренки менә сез, иптәш Шәмәй...

— Шәмгун мин,— дип төзәтте аны карт.

— Әйе, иптәш колхозчы... әгәренки... Менә сез шәхси мал-туар асравы җиңел түгел дидегез. Әгәренки сатсагыз, ә тагын да яхшырагы — дәүләткә тапшырсагыз? Шуннан сез шәхсән ни отарсыз икән?

Бу юлы Шәмәй картка озак баш ватарга туры килмәде. Ул абзарында терлек-туар булмаса ни килеп чыгасын яхшы белә иде: котылгысыз ачлык, ә гадиерәк әйткәндә,— үлем. Үз гомерендә тарихи бөгелешләрне күп кичергән кеше. Берзаманны хәтта мәхрүм ителгәннәр — лишенецлар сафында да торды. Хәзер ул хәйләләргә булды. Кабыргасы белән куйган икән, баш түрә үз соравына үзе үк җавап та бирсен. Шулай да ул:

— Мал-туарсыз абзар мәет чыккан йорт шикеллерәк инде ул,— диде.— Дөяне энәгә ничек алмашасың ди?

— Дөрес,— дип килеште әңгәмәдәше,— дөяне энәгә алмашыр өчен башыңа тай типкән булу кирәк. Ләкин без бит сезгә альтернатив нәрсә тәкъдим итмәкчебез. Чөнки без — альтуристлар...— Йомышчыларның һәммәсе берьюлы башларын кашый башлаганны күреп, ул үз сүзләренә ачыклык кертте:— Ягъни мәсәлән, сезгә тәкъдим ителә торган нәрсә шул: сез дәүләткә шәхси терлекләрегезне — әлбәттә, мөгезле эре терлекләрегезне тапшырасыз, ә дәүләт, тиенгә китереп, сезгә акчасын түли. Менә сезгә, иптәш колхозчылар, акча!— Ул уң кулы белән сул кулының чәнти бармагын бөгеп куйды.— Бу булды бер. Сатып алынган терлекләрне дәүләт азык-төлек рәвешендә кибетләргә чыгара. Бусы — ике. Ә сезгә нишлисе кала? Кибеткә барасы да, сатып аласы кала. Акчагыз бар бит инде! Өченчедән, сезнең келәтләрегездә, ачыклаганча, үзегездән артып калырлык бөртекле ашлык саклана. Әгәренки абзарыгызда мал-туар калмаса, аның артыгы нигә хәҗәт?

Чуваш Порфирий дәдәй телгә килде. Ул фронтта хезмәт иткән һәм сүзенә диңгез төшенчеләре кыстырырга ярата иде.

— Шәмгун абзыйның йөз пот ашлык сыешлы ларының трюмын абордажга алганнар... Сез, Мөбарәкҗан Габдуллаҗанович, хәлне утильнатирно түгел, ә азимут чигендә аңлатсагыз икән. Шәмгун абзыйның келәтенә кем торпеда җибәргән? Аның кок-каютасына «энзе» тутырып куелмаган лабаса! Дөрес курс түгел бу! Колхоз каптеркасының гади вахтовые гына бит ул. Җитмәсә, агымдагы моментта тулы штильдә чайкала — ярга списать ителгән. Чөнки колхоз амбарларын ялтыратканчы ялап чыктылар. Хәзер колхоз камбузында таракан ярышы гына оештырасы калды.

«Тел ачкычы» салып килгән Порфирий керткән ачыклык белән башлыклар тулысынча килеште. Ләкин һәркайсы үзалдына, эчтән генә килеште. Яшереп торган информациянең киң катлау массаларга

таралу куркынычы бар иде. Аеруча менә бу бик халыкчан әйтелгән «таракан ярышы» дигән нәрсә отып алырга бик җайлы. Порфирий күзгә бәреп әйткән нәрсә, ягъни колхоз амбарларының бушап калганлыгы фаш ителсә, «таракан ярышы»н шушы учреждениедә ясамагайлары. Килеп чыккан хәлдән исән-аман чыгу юлын табарга кирәк. Башлыклар тагын бер-берсенә карашып алдылар. Илһамлы утырышларның тәмәке төтенендә иҗат ителгән һәм илне тиз арада ит, май белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән фикерләрне тиешле вакытына кадәр кабинетларда кагылгысыз төстә саклап торырга кирәк булган, ахрысы. Крестьяннар аңының киләчәк офыгында ачылган гомуми муллык белән туры килмәве ачыкланды.

Баш түрә Абдуллаҗанов үз урынына көчеп утырды. Ул иптәшләрчә һәм эчкерсез шартларда үткән сөйләшүнең мондый аңлашылмаган төстә очлануыннан канәгать түгел иде. Ләкин, нык ихтыяр көче күрсәтеп, ул йөзендәге елмаюны саклап кала алды. Көр тавыш белән:

— Шәмгун абзыйның кок-каютасын марсианнар абордажга алмаган. Күселәр ул. Без колхоз камбузларын шул күселәр чистартмасын дип бушатып торган идек тә инде!— диде.

Делегация телдән язды.

— Ишкәнсез икән ишәк чумарын!— диде Шәмгун карт.

Йөткерергә онытып, Порфирий зур итеп авызын ачкан иде, куе тәмәке төтенен шуннан бәреп чыккан аракы исе бөтереп җибәрде. Күселәр? Ничек инде ул! Фәкать шул гынамы? Ә марсианнар кайда? Монда уйларга да уйларга кирәк әле, гадиләштерергә түгел. Ләкин башлыкларның зур абруен искә алып, килешмичә дә ярамас.

Аларның сүзен кайтып тикшерергә һәм, әгәренки чынбарлыкка туры килмәсә, ике арадагы элемтәне дәвам итәргә булып кул бирештеләр дә ишеккә юнәлделәр. Арттан Мөбарәк Габдуллаҗановичның сынаулы карашын тоеп, иң ахырдан Шәмгун карт чатанлап китте. Йөрәге лепердәп куйды. «Тикмәгә түгел бу»,— дип уйлады ул һәм ялгышмады. Башлыкның:

— Шәмгун иптәш, сез калып торыгыз әле!— дигәне ишетелде.

Картның бөтен тәне буенча кайнар дулкын йөгереп узды. «Каптым! Тоткарлыйлар... Шуннан кулга да алалар инде... Иштем ишәк чумарын!»— дип уйлады ул ишектән чыгып киткән иптәшләрен туктатырга базмыйча. Хушлашып кычкырасы, Мәйсәрәсенә соңгы сәламен җиткерәсе килгән иде дә, тыелып калды. Бөтен йомышчыларны гаепләрләр дә групповой чәпәп куярлар... Аны сагыш басты. Циркуль тирәли әйләнгән карандаш шикелле, агач аягы тирәли борылды, ишек төбендәге урындыкка утырды. «Нәрсә аркасында бит, ә?! Әйтүе хурлык — күселәр аркасында! Марсианнар аркасында булса, бер хәер иде...».

Башлык ишеккә күтәрелеп карады, һәм шул мизгелдә үк анда матур, юан, зур күкрәкле секретарь хатын пәйда булды. Ул Шәмгун картка ни өчендер нык амбар йозагы булып күренде.

— Чәй керт әле,— диде аңа башлык.

Үзе артыннан тәмле исләр калдырып, хатын читкә янтайды.

— Якынрак утыр,— диде башлык.

«Котылдым ахрысы, аллага шөкер»,— дип уйлады Шәмгун карт һәм тәрәзә буена күчеп утырды. Җылыткыч батареясыннан аркасына җылы бөркелде.

Юка стаканнарга салып, матур хатын чәй кертте. «Самавыры гел кайнар ахрысы моның,— дип уйлады Шәмгун.— Бу кыстатып тормыйдыр». Өченче тапкыр — бу юлы өстәл янына күченергә туры килде.

Иренен бөрештереп, шүрелдәтеп эчеп куйгач, башлык:

— Сыерыңны яратасыңмы?— дип сорады.

— Как же,— дип мыгырдады карт.— Бер җан булып берекән инде.
— Ә дәүләтне?
Шәмгун карт сагайды. Әллә кайчангы — инде онытыла башлаган, ләкин, искә төшкәнгә салкын тирләр бәрдереп чыгарган утызынчы еллар вакыйгалары күңелендә җанланды. «Минем совет властена мөнәсәбәтемне чамалый инде бу»,— дигән уй кабынып алды. Колхозга ул беренчеләрдән булып кергән иде. Дәүләт милкенең мыскалына да тигәне юк. Кайберәүләр башак урлап та җидешәр ел утырып чыкты. Заемнарга вакытында язылды, налогларын тиенен тиенгә түләп бара. Коткы сүз таратып йөрми. Әллә теге колхоз бурычы турындагы сүзләрен җиткергәннәрме?
— Ә дәүләтне яратмыйсыңмы?
— Кемнекен?
— Тегеләрнекен түгел ич инде. Үзебезнекен.
— Ну... монда минем сыер комачауламый инде. Монда ике яклы, тиң ярату. Соңгы сулышка хәдәрле.
— Яхшы. Әгәренки шуларны бергә кушсаң?
— Мисалга... кайсыларны? Сыерныкынмы, минекенме, дәүләтнекенме?
— Синең сыерыңны һәм дәүләтне яратуыңны.
— Минем карчыгым да бар ич әле — Мәйсәрә җиңгәң!
— Безне ул кызыксындырмый.
— Аллага шөкер.
— Ул синең күпме тартыр икән?
— Аңа җитәме соң?— диде Шәмгун карт ишеккә кырын карап.— Үзең беләсең, район ризыгы бүтән инде ул.
Башлык тыела алмыйча, шырык-шырык көлеп җибәрде.
— Мин сыерыңны әйтәм,— диде ул.
— Мөгезләре булса, чама белән... Минем сыер мүкләк бит ул,— диде Шәмгун карт сыерының авырлыгын хәрби сер шикелле яшерергә омтылып.
— Буазмы соң?
Шәмгун карт монысын яшерергә кирәк санады. Сыерның буазлыгы — крестьянның стратегиясе бит инде ул. Татарда моны: «Алдан кычкырган күкенең башы авырта», диләр.
— Димәк, авырлыгы ярыйсы һәм буаз... Беләсеңме, Шәмгун иптәш: безгә бер күрсәтмә килеп төште бит әле,— дип, башлык кәгазьләр актарып алды, тик эзләгәнен тапмады.— Ярар, каядыр кыстырылган инде... Ә күрсәтмә бик файдалы.
— Сыергамы?
— Юк, колхозчыга.
— Күрсәтмәнең безгә нинди кирәк?— дип хыялланды карт.— Ул, мисал өчен, безнең сыерларга файдалы булсын иде. Сыерларга әйбәт икән, кешеләргә начар түгел инде ул, Мөбарәк кордаш.
— Менә, менә! Нәкъ эзенә бастың! Ул күрсәтмә нәкъ синеңчә инде: сыерларга да начар түгел, кешеләргә дә яхшы... Менә син хәзерләүләр конторасына сыерыңны китереп тапшырдың ди...
— Мисал өчен,— дип, Шәмгун карт учына йөткергәләде.
— Тапшырасың да кулыңа квитанция аласың. Ә сыерың абзарыңда көрәя тора. Ә гади генә әйткәндә, әгәренки синең сыерың, әйтик, ике центнерга тарта икән, хәзерләүләр конторы моны тапшырган итеп язып куя. Сиңа квитанция, аңа өстәп, шул ике центнерны тапшырган өчен акча. Сыерыңны өч центнер итеп симерткәч, тагын бер документ, тагын акча. Аңынчы, күр дә тор, ул бозаулап та өлгерә. Бозауны да шулай иттерәсең. Файдалымы?
Шәмгун карт агач аягының табанын кашып алды.
— Ярый, безгә файдалы да ди. Ә сыерга?

— Ә син ничек уйлыйсың соң? Сыерың да исән-имин, сөт-маена үзең дә тук. Бозау да китерә. Ә синең кесәң тулы акча. Ну, вакыты җиткәч, әлбәттә, хушлашырга туры килер.

— Мин дә шулай уйлап куйдым әле, хушлашу язмасын дип... Ә, мисал өчен, минем сыер үлеп куйса?! Тьфу-тьфу.

— Менә монысы һич ярамый инде! Син дәүләткә бурычлы бит! Шәмгун карт утырган урынында кыбырсып куйды.

— Ул да миңа әҗәтле кала түгелме соң? Бусы инде минем дәүләтне, аның мине яратуы ише генә түгел!

— Ничек?

— Гап-гади. Мисал өчен, барысы да бар: документ бар, акча бар, мүкләк сыер минем абзарда... Дәүләтнең ите генә юк. Бигрәк тә минем сыерым карынындагы бозавы белән бергә вакытсыз дөнья куйса... Алла сакласын!..

— Юк шул, син уйлаганча гына гап-гади түгел ул,— дип каршы төште башлык.— Син сыерыңны тиешле көрлеккә җиткергәнче, дәүләт кибеткә үз итен чыгара тора. Рәхим ит, сатып ал. Акчаң кулыңда.

— Ә мин үз сыерымны үзем суеп та ашый алган булыр идем ич!

— Аласың, әлбәттә, аласың. Тик монда партия һәм дәүләт стратегиясе өчен яну турында сүз бара. Син сыерыңны суеп ашыйсың, ә башкалар, селәгәйләрен агызып, синең авызыңа карап торсынмы? Менә шуны истә тотып, бөтен ил Рязань өлкәсе үрнәгенә иярде дә инде. Ә алар, дәүләткә ит сату планын планда каралганнан өч ярым тапкырга арттырып үтибез, диделәр. Үтәрләр дә! Ничек шуңа ирешәләр соң, ничек?

Монысын Шәмгун карт белми иде әле...

Ул, тагын чәй эчәсе килеп, чак кына: «Сиңәйтәм, Мәйсәрә, чәең кайнадымы әле?» — дип кычкырмады. Хуш исле юан хатын да китеп барган икән инде.

— Ирешербез, Шәмгун иптәш. Безгә ирешмичә һич ярамый. Егерме елдан соң коммунизм төзеп җиткерәсебез бар... Менә мин үзем әле яңа гына егерме икенче съезддан кайтып төштем. Беләсең килсә, бик рухланып кайттым. Хәзер юл ачык инде, туп-туры... Әйе, ирешергә кирәк. Кулга-кул тотынып.

— Шулай,— дип килеште Шәмгун карт.

Озак утырганнар икән. Киенеп урамга чыксалар, бар дөнья ап-ак кар, аларның күтәрелеп, киңәеп киткән күңелләре кебек якты. Кайтырга соңга калдырганы өчен гафу үтенеп, башлык Шәмгун картны үзләрендә куныш чыгарга кыстады. Бүгенге сөйләшүдән соң кире кагуны ошатмас дип, Шәмгун карт Мөбарәк кордашының тәкъдименә шундук күнде.

Район үзәгенең беренче этәчләре аваз салганчы утырдылар. Һәрвакыттагыча кандала исе килеп торган зәһәр коньяк эчтеләр. Кайтып керү белән хуҗа хатынының ит салып пешерелгән тары өйрәсен ашап, чәй эчкәннәр иде инде. Хәзер исә район хуҗасының Мәскәү каласыннан алып кайткан коньягы артыннан лимон капкаладылар. Шәмгун карт майлы селедканы бигрәк тә яратты.

Инде йокларга вакыт җитте дигәндә Шәмгун карт башлыкка берсекөнгә үк мүкләк сыерын хәзәрләүләр конторасына җитәкләп килеп, аны тапшырганына квитанция алып китәргә вәгъдә итте.

Йомышчылар район ашханәсеннән чыккан минутларда авылга күселәрнең икенче эшелоны бәреп керде. Күсе сизгерлеге кушканча, алар киң фронт белән җәелеп һөҗүм иттеләр дә бөтен авылга таралдылар. Һөҗүмнең башлангыч сызыгы инешкә аркылы яткан карт каен кәүсәсе буенча чыккач оешты. Иң соңгы колония, аръергард булып, төн урталары җиткәндә кузгалды.

Бу вакытта йомышчылар шоссейдан авыл юлына төшеп, түбән очка

якынлашып киләләр иде. Ап-ак кар яктырткан төнге авыл өстенә аларның күмәк җырлаулары таралды:

Дөньяда илләр күп, җирләр күп,
Тик безнең ил генә, бер генә.
Дөньяда матур ил, якты ил —
Тик безнең ил генә, ил генә-ә-әй...

Йомышчы крестьяннарның һәркайсы аркасына өч капкын асып, кесәсенә күсе агуы тыгып кайта иде. Аларны көтә-көтә көтек булган хатыннары, бала-чага һәм кызыксыну баскан ир-ат каршы алды. Йомышчылар якынайган саен, алар ягыннан аңлаешсыз, сагаерга мәҗбүр иткән чың тавышы ишетелә башлады. Каршы алучыларның берсе, утыз сигезенче елда «халык дошманы» дип кулга алынып, унтугыз елдан соң гына кайтып егылган хисапчы Вакыйф Фәйзуллин үз шигенә ышанырга белмәстән:

— Әллә богаулаганнар инде?!— дип әйтеп салды.

Гомуми шау-шуны хатын-кызларның елашуы басып китте. Чың авазының сәбәбе ачыклангач кына тына төштеләр. Барысы да аңлатма таләп итте. Әмма йомышчылар мәгънәле төстә телләрен аркылы тешләделәр, чөнки кайтышлый серне чишмәскә ант әчкәннәр иде. Моны, кайчандыр биргән хәрби антларын искә төшерергә мәҗбүр итеп, Порфирий Айдашев өйрәтте. Күселәр хакында авызны ачып ләм-мим сүз катасы түгел, дип кисәтте ул.

— Амба, туганнар! Авызларны кингстон итеп бикләргә. Телләрегезне ватерлиниядән түбән төшерәсе түгел. Ник дигәндә, күселәр — һәртөрле тишек-тошыкка сизгер җанварлар. Сизеп алсалар, кильваторны калдырмаслар. Эзлә аларны аннары. Шулай булгач, Шәмәй абзыйның келәтен кессон итәбез дә миналар белән урап алабыз,— дип, Порфирий капкыннарын чыңлатып, агу салган кесәләрен каккалап күрсәтте.

Һәрвакыттагыча, крестьян тактикасы бу юлы да соңга калды. Бүгенге эшне иртәгегә калдырмаска, Шәмгун картның йортын өр-яңа капкыннар белән уратып алдылар. Җим урынына төрле ризык куелды. Мәсәлән, Мәйсәрә карчыкның ире кайтырына пешереп куйган камыр ашыннан каз боты, шул ук казның бүтәкәсе, уразада авыз ачарга дип саклаган «Слива» конфетларының өч данәсе, иртәгә ипи салырга дип мич башына әчетергә куйган камыры, ярты кадак атланмае һәм башкалар. Өстәвенә җимнәрне мул итеп агуладылар да. Элеккеге каравылчының ярлы хуҗалыгындагы һәр аулак урынга капкын куеп чыктылар. Кимерүчеләрнең чиктән тыш сак һәм зиһенле булуларын истә тотып, әллә нинди почмаклар эзләп табылды. Үзе әйтмешли, «операцияне» башлап йөргән Порфирий соңыннан кыскача йомгак ясады:

— Хәзер капкыннарны мина тральщиклары да табалмый!

Шуннан соң өйләренә йокларга таралыштылар.

Порфирий хаклы булып чыкты: капкыннар шул кадәр җентекләп яшерелгән иде ки, аларны хәтта күселәр үзләре дә табалмаган.

Иртән, әле ай батмас һәм кояш чыкмас борын, яңадан җыелыштылар. Көннең аязганы кебек үк, йомышчыларның махмыры да җилгә очкан иде инде. Ау санар өчен счетын тотып, колхоз хисапчысы Вакыйф Фәйзуллин да килеп җитте.

Ә табыш сәер иде.

Капкыннар гаҗәеп яхшы каптырган. Тик берсенә-бер күсе эләкмәгән. Аларның берсе, кичә таралышу белән, карт-карчыкның челтәрле караваты астында шартлап ябылган. Шәмгун картка хөрмәт йөзеннән һәм кайтса, аның йокысын хәшәрәтләрдән сакларга омтылып, Порфирий район үзәгендә шәхсән үзе сатып алган тимер капкыннарның иң зурысын — бүрегә исәпләнгәнен сагайтып куйган иде. Анысы, Мәйсәрә карчык үзенең авыр гәүдәсе белән карават челтәрен иңдереп, урынҗиргә түнүгә, үзендәге бар гайрәте белән матрац аркылы карчыкның

шактый мул артын каптырып ала язган. Ул коты алынып сикереп торган да, эчке күлмәгенең яртысын бүре капкыны авызында калдырып, күршеләре Чанышларга каравыл кычкырып килеп кергән.

Мәйсәрә карчыкның сөйләме белән рухланган Порфирий Шәмәйләр өенә йөгереп керде дә, тимер кисәү белән коралланып, караватастына иелде һәм, йөзтүбән яктан Шәмгун картны күз алдына китереп, исен-акылын җуя язды.

Келәттән ачыргаланып мәче мияулавы ишетелде. Бактың исә, икенче капкынга хуҗаларның Мыраубикәләре капкан икән. Өченче һәм дүртенче капкыннар иң уңышлысы булып чыкты: Шәмгун картның мөгезсез эре терлеге булган мүкләк сыерның койрыгын һәм бер имчәген эләктергәннәр. (Оеган койрык белән имчәк өченче көнне үк корыды, шуннан соң Шәмгун картның сыерны хәзерләүләр конторына илтеп, квитанция белән акчага алмаштырудан гайре чарасы калмады...) Сөмсере коелган Порфирийның һәм йомышчыларның кәефен унберенче капкын күтәрсә генә инде. Анда ниндидер җанварның кимерелеп, агарып беткән баш сөяген табып алдылар. Күселәр үзләренең саксыз кыланган кардәшләрен ашаган, дип уйлаганнар иде. Ышанычларын ныгыту өчен урындагы җидееллык мәктәпнең зоология укытучысын чакыртып китерделәр. Яшь укытучы кыз, мәктәп линейкасы белән тиешле үлчәүләр үткәргәннән соң, үзенең нәтиҗәсен игълан итте: капкынга эләгеп калгач, күселәр тереләтә ашаган нәрсәкәй — сасы көзән.

Кыскасы, һәммәсе дә ябылуга карамастан, бер генә капкынга да күселәр эләкмәгән булып чыкты.

Ул арада авылга яман хәбәр таралып өлгерде: байтак келәтләрдә онлы капчыклар тишелгән, ашлык салынган лар кимерелгән! Бу хакта районга хәбәр салдылар. Уполномоченный Ноль бөтен килеп җитте. Ул көтелмәгән бәладән котылу чарасын бер генә нәрсәдә күрде: артык икмәкне тиз көндә расписка белән колхозның орлык фондына тапшырырга кирәк. Күселәр шуннан соң үзләреннән-үзләре авылны ташлап качачак, имеш...

Вакыйф Фәйзуллин, счетын култык астына кыстырып, хәйран боек кыяфәттә колхоз идарәсенә таба китте. Аның бүген, сөяк төймәләрне тарта-тарта, капкынга эләккән күселәрне бик тә саныйсы килгән иде.

Яңа яз килде. Кариб кризисы[1] артта калды. Моңа кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән сугыш куркынычы сүнде, сүрелде. Аның каруы Кушкаен авылында бер кризис булып алды.

Алда язгы чәчү тора иде. Ә колхозның чәчүлек орлыклары җитәрлек түгел. Хәлдән ничек тә чыгарга кирәк бит инде. Былтыргы ашлык бүлү исемлекләрен шүрлектән өстәлгә алып салдылар. Хезмәт көненә кемгә күпме ашлык тигәненә карап, кешеләрдән бурычка чәчүлек орлык җыйдылар. Күселәрнең көзге һөҗүме онытылды. Яңасы хәтәррәк иде.

Солтанның бабалары Кадрәккә өч йөз алтмыш биш кило, Чанышка чак кына артыграк тигән иде. Әбиләренеке дә үзләренә генә җитәрлек. Менә шул: Наймушныкылар хәләл ашлыкларының сигез потын кире илтеп бирделәр.

Ә Порфирий Айдашев бирергә теләмәде. Уполномоченный аны:

— Син — коммунист. Югыйсә партбилетыңны өстәлгә чыгарып саласың,— дип өркетте.

— Үзем коммунист та бит. Бу яктан минем офык чиста. Ләкин минем җиде юнгам да бар бит әле. Алар әлегә минем фарватерда түгел...

— Бәхет хакына лабаса, Порфирий Айдашев!

---

[1] 1962 елда АКШ империализмының Куба революциясенә каршы агрессив хәрәкәтләре китереп чыгарган халыкара кризис.

— Кем бәхете хакына?
— Киләчәк буын...
— Нинди буын көтеп тора безне анда, ә?!— дип, Порфирий кулын маңгаена куеп, якындагы офыкка караш ташлады.— Тумас борын җанга торпеда җибәреп яталар. Буын түгел алар.
— Кем соң?
— Флибустьерлар — менә кем! Гадиләштереп әйткәндә — пиратлар. Абордажга аласы иде аларны...
— Син алай сөйләшүеңне ташла, Порфирий! Хатын-кыз алдында оят түгелме сиңа?
— Ни өчен?
— Ни өчен дип ятасың тагын! Нәрсәгә котыртасың син аларны? Аборт та бандаж! Политик позицияң какшаган синең, Айдашев. Күзгә туры карап әйт әле: син аборт яклымы, әллә бандаж яклымы?
— Минем җиде юнгам, синеңчә, бәхетсез аборт корбаннарымыни?
Порфирий үзенең арттырыбрак җибәргәнен аңлады. Ул шаккатты. «Нинди кеше, ә?— дип уйлады ул Ноль бөтен хакында.— Абордажны аборт белән бандаждан юри генә аермаган булып маташамы, әллә мине берәр политик статья астына китереп тыгу өчен тырышамы? Теләсә, тыгуы да бар. Шаһитларын да табачак. Киләчәк буыннарга, димәк, коммунизм фактына ышанмауда тотарлар да гаепләрләр...»
Шуннан риза булды. Тиздән аның җиде «юнга»сы җиде пот арыш һәм бадай күтәреп чыкты. Һәркайсына берәр поттан инде.
Порфирий яңадан офыкны күзеннән кичерде. Болытлар арасында аңа үзләренә тиешлене — шул ук җиде пот ашлыкны алып калыр өчен ыжгырып килгән киләчәк буыннарның тук йөзләре күренеп киткәндәй булды. Ләкин алар Порфирийга бурычка алып торучылар кыяфәтендә чагылмады. Чөнки аңа киләчәкнең үткәннәрдән бурычка алалмаганы яхшы билгеле иде. Бүгенгеләр генә бер-берсенә әҗәткә керә. «Киләчәккә бурыч — шул ук Ноль бөтен инде ул,— дип уйлады Порфирий.— Андый бурычны кире кайтаралмыйсың инде.»
Порфирий кешегә күрсәтмичә генә елап алды. Күз яшьләре юк иде.
Уполномоченный хәлне халыкка:
— Вакытлы чара,— дип аңлатты.— Ашлыгыгызны бурычка гына алып торабыз. Яңа уңыштан кайтарып бирербез. Әгәр дә ел уңышлы килсә инде, әлбәттә.

Авыл кешесе үз тормышын бер вакытлы чарадан чираттагысына, бер вәгъдәдән икенчесенә җайлап, араштырып яшәргә күнеккән инде ул. Газетлар, радио ике дистә елдан соң коммунизм килеп җитәчәген вәгъдә иткән заманнар. Акча бетәсе, имеш!
— Бетсен,— диде Солтанның дәү бабасы Чаныш.— Ул болай да юк.
Авыл кызыл комачка яңа сүзләр язылган лозунглар белән чуарланып бетте. Алар Рязань өлкәсе тәҗрибәсен якты маякка тиңләде. Бу эштә Шәмгун карт байтак кайнашты. Мүкләк сыерын хәзерләүләр конторасына илтеп тапшыргач, рәсемен газеталарда бастылар. Кышын Мәскәүгә алдынгылар киңәшмәсенә үк җибәрделәр. Ул аннан йөзлегенә Кремль сурәте төшерелгән бидон тотып кайтты. Кәҗәсен дә бик рухланып илтеп бирмәкче иде, хатыны Мәйсәрә:

— Кәҗәң белән бергә мине дә илтеп кара, бергә сатып алсалар, һич сүзем җук,— дигәч кенә сүрелде.
Башлап йөргәне һәм үрнәк күрсәткәне өчен Шәмгун картны яңадан колхоз амбарлары каравылчысы итеп куйдылар. Әлегә сакларлык нәрсә булмаса да, ул бик канәгать калды. Ике күгәрек патроны белән берданканы төн саен кулына тотып эшкә йөрүенә чиксез горурлана иде ул.
Сыер акчасын учына кыскан хәлдә, Мәскәүдән алып кайткан ак бидонын тотып, ул көн саен кибет тарафына чыгып китә торган булды.

Мүкләгенең ни сөте, ни ите авыл кибетенә әйләнеп кайтмаганга гына эче поша иде пошуын.

Акча реформасы чыккан иде инде. Сыеры өчен аңа хәзерләүләр конторасының кассиры дүрт йөз дә илле сум акча санап бирде.

— Менә бит, җәмәгать!— дип килеп керде ул идарәгә шуннан кайтышлый.— Каяле, читават, чутыңны ал да төймәләрен тарттыр әле! Гармун шикелле уйнап торсын.

Хисапчы Вакыйф Фәйзуллин, тыңлап, счетының тузанын сөртте.

— Элгәреге җылда минем мүкләгем дүрт мең дә биш йөз тәңкәлек иде бит, ийеме?

— Ийе.

— Быелгысы җылны дүрт йөз дә иллегә калды бит инде, ийеме?

— Ийе.

— Тагын бер рифурмыдан суң күпме була?

— Кырык биш сум.

— Ийе. Ә тагын бер рифурмыдан суң күпме?

— Дүрт сум да илле тиен.

— Ә тагын бер рифурмы ясасалар?!

— Кырык биш тиен.

— Ә тагын берсеннән суң?!

— Дүрт тиен ярым.

— Менәтерә, җәмәгать! Биш рифурмы гына калган!

— Нәрсәгә?

— Суң, биш рифурмыдан суң сыерның бәясе гупчым бетә икән ләбаса! Бушлай гына тия башлый! Барасың базарга, дүрт тиен ярымыңны чыгарып саласың да, сыер җитәкләп кайтасың. Якты киләчәк шулдыр инде ул, ийеме?

Шәмгун картка җавап кайтармадылар. Актив белән бәхәскә керүнең хәерлегә бетмәү ихтималын аңлыйлар иде.

Шул көннән соң Шәмгун карт яңа акча реформалары көтеп яши башлады.

Ә иртәләрен, сызылып таңнар атканда уянып күзен ачкач, аның җаны сискәнеп-сискәнеп китә, маңгаена салкын тир бәреп чыга иде. Шәмгун уйланды да уйланды. Ул мүкләк сыерын сагына, бик сагына иде! Түзмичә, буш абзарга юнәлә дә, аклы-каралы кәҗәсенең сакалын кашып керә, һәм шуннан җаны кайнавы басылгандай була.

Берзаманны, аяз һәм җылы сентябрь кичендә, инде күз бәйләнә башлагач, атлар абзары янына колхозның бөркәүле җиңел машинасы килеп туктады. Аннан колхоз рәисе Нәҗип Мияссәров белән күрше кәрәшен авылыннан партоешма секретаре итеп куелган Михаил Кукушкин һәм уполномоченный Ноль бөтен төштеләр. Кадрәк аларны көтә иде инде. Көтәргә кушылган иде. Бәлки, килмәсләр әле, дигән өмете сүрелде. Әнә, килделәр. Йомышлары аңа билгеле. Бу хакта каты кисәтеп куелган. Атларны төнгелеккә шуңа күрә чыгармады да.

Кадрәк аларның якынаюын кәнүшни йортының тузанлы һәм чебен таплап бетергән бердәнбер тәрәзәсеннән карап торды.

— Килде теге газраилләр, олан,— диде ул.

Солтан йөгәнендәге җиз тәңкәләрне мич көле белән чистартып утыра иде. Фонарь утында ялтыраган тәңкәләр торган саен матураялар. Монда яхшы. Камытлардан, ияр киезләреннән ат тире исе килеп тора.

Ул чагында Солтанга алты тулган гына иде. Шул елны атасын Куба очучыларын өйрәтергә җибәрделәр. Әнисе дә китте. Аны авылга — бабалары, әбиләре янына кайтарып тордылар. Атлар яратканга күп вакытын ул ат карауччы Кадрәк бабасы янында үткәрә.

Кадрәк икенче фонарьга ут элде: бөтен авылда бары тик ат абзары белән кәнүшни йортында гына электр юк иде. Атларга бар нәрсә иң ахырда тәти шул. Абзар мәйданын ындыр табагындагы баганадан төшкән ут кына яктырта.

— Әйдә, олан,— диде ул Солтанга.— Озатып калырсың.

— Мин куркам,— диде Солтан. Шулай да бабасына иярде. Кешеләрнең ник килгәнен ул да белә. Бабасы әйтте.

Такта өйалды бусагасына чыгып баскач, Кадрәк анык башың сыйпады:

— Курыкма,— диде.— Курыккан кеше берни күрми ул. Ә син яхшылап карап кал.

Тигезләп тезелгән колхоз арбалары арасындагы бушлыкны ерып атлаучы җитәкчеләр аларга якынлашты.

Ул елны яңа тәртип кертелде. Уполномоченный тәкъдиме белән, ат җигүчеләргә атларын әүвәлгечә үз ишегалларында түгел, эштән кайтышлый ук ат абзары каршында тугарырга кушылды. Колхозның бу авылдагы ике бригадасында кырык биш җигү аты санала. Колыннар бер дистә чамасы. Егерме биш кырыкмыш тай бар. Җыенысы сиксән ике баш. Тагын ике нәсел айгыры. Хәзер ат абзары мәйданында кырык биш арба куна. Башта тыңламаучылар да булды. Хезмәт көннәрен кисәргә тотынгач, буйсынмый чаралары калмады. Элек чаналарны, арбаларны, дирбияләрне һәркем үзе карый, төзәтә, җайлыйсын җайлый, майлыйсын майлый иде. Яңа тәртип кергәч, бу мәшәкатьләр ат караучы Кадрәк белән Һидиятуллага калды. Малай-шалай ат алып менү, ат төшерү рәхәтеннән мәхрүм ителде. Иртәләрен таңкаләрендә кояш нурлары уйнаган йөгәнне җилкәгә асып ат алмага барулар, ә кичләрен атланып кире китерүләр, юл уңаенда аларны сызгыргалап эчерүләр, буа суында коендырулар, шул очтан атлар белән бергә су керүләр нинди күңелле иде! Ат йөрәге кагуын ишетмәгән авыл баласы үз йөрәге тибешен сизәмени инде ул?!

— Аерып куйдыгызмы?— дип сорады рәис.

— Куйдык.

— Һидиятулла кайда соң?

— Килеп җитәр.

— Карагыз аны, Наймушин.— диде уполномоченный.— Төп-төгәл утыз биш баш булсын.— Аннары ул колхоз рәисенә борылды:— Исемлек!

— Миндә, миндә.— дип, Нәҗип Мияссәров күкрәк кесәсен капшады.

Алар янына, ындыр табагы ягыннан агач аягында титаклап, Шәмгун карт килеп басты. Ул самосад төпчеген дөрләп кабынырдай итеп, соңгы тапкыр суырды да такыр җиргә ташлады.

— Йоклап булмый мәллә, Шәмгун абзый?— дип елмайды Михай.

— Әх, булмый шул, булмый!...

— Каравылчының йокыдан башка ни кайгысы бар инде тагын? — дип кысылды колхоз рәисе, ләкин күз чите белән генә уполномоченныйга караш ташларга да онытмады. Ошатырмы, янәсе?

— Бар шул, Нәҗип энекәш, кайгым бар Җилкәне кырдылар әле минем. Шул йокларга ирек бирми.

— Холку?! — дип сорады уполномоченный русча.

Ул, рус кешесе булса да, татарча аңлый, ә чувашча теттереп сөйләшә үк белә иде. Аның полиглот дигән даны бар, шуңа күрә эшендә дә яхшы бәяләнә. Ә, гомумән, болай гадәткә кергән иде: татар уполномоченныйларын удмурт авылларына җибәрәләр, удмуртларны — руcларга, русларны — чувашларга, чувашларны — татарларга. Шулай итеп, һәркайда район вәкилләре белән колхозчылар, совхоз эшчеләре русча гына сөйләшә.

— Холку?!— дип сорады уполномоченный кабатлап.

Колхоз рәисе Нәҗип Мияссәров Шәмгун картның артына төшәргә тырышып:

— Әкият сөйләмәсәнә, Шәмгун абзый!— диде.— Синең аркаңны кем кырсын ди? Ат түгел ич син, понимаешь! Йә, кем кырды?

— Ат булмасам да кырдылар шул менәтерә. Порфирийның өлкән малае Мишка кырды. Бурлы аңа беркетелгән.

— Бурлының җилкәсен кырдырган ич инде ул алайса! Монда синең ни катнашың бар?— дип гаҗәпләнде Михай Кукушкин.

— Булмаенча! Бурлы минеке ләбаса. Аның җилкә калкымын кырганнар — ә минеке авырта!

— Ничек синеке?!— дип, Нәҗип Мияссәров колхоз милкенә кул сузу ниятенә каршы төште.— Колхозныкы ич ул!

— Анысы хак,— дип килеште карт.— Бурлы колхозныкы. Ни хәл итәсең инде — язмыш... Ә менәтерә Бурлының әнкәсенең әнкәсе — Нэп кушаматлы Кара туры минеке иде.

Парторг Михай капрон эшләпәсен салып, пеләш башын кашып алды.

— Мамонтлар күптән үлеп бетте, Шәмгун абзый,— диде ул алтын тешләрен күрсәтеп.

— Бер дә мамонт түгел иде ул, бахыр. Чын солдат! Сугышка китте ул. Нимес Мәскәүгә ыргылган иң хәтәр вакытта. Минем Кара турым шунда шәһит киткәндер дә.

— Хәбәрен алган идеңме әллә?— дип көлде парторг.

— Алмадым алуын. Тик минем хәбәрсез югала торган атлардан түгел иде ул. Ә плен төшүе турында сүз дә җук.

— Сиптерә дә соң!— диде уполномоченный Шәмгун карт белән бәхәсләшүне эчтән генә яратса да.

— Ишетәсеңме, Кадрәк. Мин сиптерәм булып чага!.. Син үзең сиптерәсең, уполномуч иптәш! Минем мүкләк сыер кайда соң? Ә?— дип, уполномоченныйның авызын каплагач, Шәмгун карт парторгка борылды.— Менәтерә ул хәбәрсез-нисез югалды...

Парторг Михай борчыла калды, тик моны сиздермәде. Җаваплы чара алдыннан мөнәсәбәтләрне бозарга теләмәде.

— Бурлы ат, Кара туры, мүкләк сыер... Бәлки, алар синең төшләреңә дә керә торгандыр әле? Бәлки, сине шул йоклатмыйдыр? Онытырга вакыт инде, Шәмгун абзый.

— Шулай шул, төшкә керәләр Михай наным. Ник дигәндә, алар минем җаным белән бер иде ләбаса. Ә җансыз килеш ничек яшәмәк кирәк?

— Сине шәхси милекчелек хисе күмеп киткән икән инде, Шәмгун агай,— дип председатель Нәҗип Мияссәров читкә борылды.— Ә үзең инициатор дигән дан йөртәсең. Гәҗит саен чабата-чабата рәсемнәреңне бастырган булабыз тагын, понимаешь. Имеш, аның җилкәсен кырганнар! Ялган капчыгы икәнсең син...— дип ул җиргә төкерде һәм, эшкә керешергә вакыт җиткәнен искәртеп, кепкасын батырып киде.

— Әй, оланнар,— дип ыңгыраштьы Шәмгун карт. Ул, ни әйтергә белмичә, агач аягында таптанып алды. Аның җан халәтен белгерткән шикелле, әллә кайлардагы каешлары шыгырдап куйды.— Менәтерә сезнең җилкәгезне кырасы иде ул! Ыңгырчак киезе белән дә түгел, ә арба чөе белән. Кырыр идең дә кана, тик сезнең җилкәгез җук шул, җилкәгез!.. Шоп-шома бит сез, шоп-шома... Кешегә җилкәсез яшәмы соң? Башкача якты дөньяны ничек тотып тормак кирәк? Ә? Сора әле шулардан, Кадрәк, сора әле...

Солтан ул кичне күп нәрсә күрде.

Йолдызлар бая ул көл белән ышкып ялтыраткан йөгән тәңкәләре

шикелле елкылдып тора, ә ай Тимерңең кашкасын хәтерләтә иде. Абзар ягыннан арыган-талчыккан атларның әледән-әле пошкырып куюы ишетелә. Алар төнгелеккә чыгаруны көтәләрдер һәм бераз соңарруга аптырыйлар булса кирәк. Гадәттә, эш атлары да, колыннар, тайлар да җәй-көз көннәрендә бергә тотыла. Аларны кышын гына эчкә — араталарга аерып кертәләр. Төнгелеккә чыгарганчы, алар абзарның буеннан-буена сузылган тышкы арата артында. Салам түбә кыегына терәтеп салынган әвеслекнең жирдалары гына калган, ачык. Саламын язын атларга ашатып бетергәннәр. Яңа салам түшәп ябылмаган әле. Атлар арасына, буй-буй булып, жирда күләгәләре төшкән. Араталар артында бүген утыз җиде генә ат. Утыз бише — иткә озатыласы. Тагын икесе — Кадрәк белән Һидиятулланыкы. Атлар кайтып беткәч, Солтан аларны үзе карап, санап килде. Унөче — картайганрак җигү атлары, калганнары — кырыкмыш тайлар. Ә башкаларын бүген араннарга яптылар. Хәзер әнә аларның кайберләре ватык пыялалы тәрәзәләрдән карап тора. Нәсел айгырларыннан Маймыл тае белән Орлик кына аерым агач сарайда. Аларны машина йөри алмаслык пычракларда, кара көзләрдә, язгы юл өзекләрендә, бураннарда, күп булып кар яуган көннәрдә колхоз рәисенә җигеп бирәләр. Аларның абзарлары чиста, җылы, коры — нәсел айгырлары ич, председательнең үзен йөртәләр.

Арттан — түбәсенә кызыл балчык изеп, салам ябылган тәбәнәк тимерчелек ягыннан Һидиятулла килеп чыкты. Кушаматы кызык аның: Һидиятулла Борын. Аның борынын бервакытны авыл кызларын күзләргә килгән һәм шунда егетләр белән сугышкан механизаторлыкка укучы егетләрнең берсе тешләп өзгән. Һидиятуллага Казаннан яңа борын куеп кайтарганнар. Арт ягыннан ит кисеп алганнар да, ипи камыры шикелле түгәрәкләп, борынына ялгаганнар. Шуннан бирле ул әледән-әле борынын капшый. Бармакларына гына ышанмыйча, иренен бүлтәйтә дә, күзен кылыйлатып, борын очына текәлә. Җитмәсә, борынына карап, ул һава торышын алдан әйтеп бирә ала: коры көннәрдә борыны ак була, ә яңгыр алдыннан кызара.

— Җә, аллага тапшырдыкмы?— диде Һидиятулла.

Уполномоченный Ноль бөтен, кул сәгатенә карап:

— Вакыт,— диде.

Кадрәк Солтанга:

— Йөгән белән камчыны апчык әле, олан,— диде.

Солтан аңа таңкәле авыр йөгәнне чыгарып бирде, чуклы каеш чыбыркыны сузды.

Шулвакыт көтмәгәндә күпер ягыннан кычкырып, кайнарланып сөйләшкән авазлар яңгырады. Солтан ай яктырткан буа суында каралып күренгән агач күпердә шәүләләр абайлады. Күперне үткәч, алар урман каравылчысы Фәттахларның бәрәңге бакчасы читәне белән инеш арасындагы юлга төштеләр. Анда читән шыгырдаттылар. Фәттахларның Алабай этләре буыла-буыла өрергә тотынды. Аңа күпер очының башка этләре дә кушылды.

Йөгәнен иңбашына салган килеш, кулына керосин фонаре тотып, Кадрәк ат абзарына таба китте. Барысы да аңа иярделәр.

Солтан бусагага утырды. Зурлар тәртәләре белән кара-каршы куелган арбалар арасыннан Чулпан йолдызына таба киттеләр. Кадрәк белән Һидиятулла жирдалар астыннан арата эченә узды. Башта үз атларын йөгәнләп чыгалар инде.

Колхоз рәисе, партком Михай капка араталарын дөбердәтә-дөбердәтә тимер атламалардан җиргә суырып төшергәндә, кәнүшни өе артыннан бер төркем кешеләр килеп чыкты. Солтан куркып китте, аягына басып, ишек яңагына сыенды. Егетләр икән. Туры клубтан килгәннәр. Ул гармунчы Илгизәрне танып алды: баяны култык астында. Флоттан быелтыр кайткан, ә тельняшкасын ташламаган. Пин-

жәк эченнән клубка гына киеп йөри. Анда да бәйрәм көннәрендә яисә сөйгән кызы Тайфә белән очрашасы көннәрдә генә кия.

Егетләр күп иде. Араларында олырак мәктәп укучылары да бар. Кайберәүләре күсәк тоткан — читән казыклары. Бая Фәттахлар читәне әнә ник шыгырдаган икән. Шуннан коралланганнар.

Солтан баскычтан алар янына төште. Илгизәр аннан:

— Монда кемнәр бар, брат?— дип сорады.

Солтан санап чыкты. Илгизәр, пинжәген салып, Солтанга япты да, баянын баскыч читенә куйгач:

— Тотсыннар капчыкларын!— дип кычкырды.— Палундра, егетләр! Атларны бирмибез. Делай, как я!

Тельняшкасының җиңнәрен сызгана-сызгана, ул арбалар арасыннан алга йөгерде. Бүтәннәре дә аннан калышмады. Тынлыкта мышнаулары һәм түфлиләренең дөпелдәве генә ишетелә. Абзар мәйданы читенә җиткәч, Илгизәр иң кырыйдагы арба тәртәсенә ябышты да алга этеп китте.

— Урап ал, егетләр, урап!— дип кычкырды ул һәм карлыккан тавыш белән:— Ур-ра-а!— дип сузып җибәрде.

Яссы даймон һәм озынча кытай кесә фонарьлары кабынды. Егетләр аларның нурларын арата капка төбендәге кешеләргә төбәделәр. Егетләрнең күбесе, Илгизәр кебек үк, арбаларга ябышкан: кайсысы сөйри, кайсысы этә. Ат абзары түбәсеннән күгәрченнәр тузгып күтәрелде. Солтан ындыр табагындагы амбарлар, келәтләр ягында да кош канатлары шапылдаганын ишетте. Егетләр атлар чыгасы юлны арбалар белән киртәләде. Ул да булмады, арттан һәм ян-яктан ике «Белорусь» тракторы, ике йөк машинасы килеп туктады. Фара утлары ат абзары мәйданын яп-якты итте. Йолдызлы күк, курыккан шикелле, югары сикерде. Йолдызлар качып бетте. Югарыдагы ай белән түбәндәге Чулпан йолдызы гына урынында калды.

Автомашиналардан, тракторлардан кешеләр сикерешеп төште. Егетләр генә түгел. Солтан хәтта тәкъва карт Сәлимҗан бабайны да таныды. Почта йөртүче Пәрхигә хәтле бар. Болар гынамы — тумыштан сукыр гармунчы Нур да шунда. Фара утларының юан көлтәләре кесә фонарьларының пычактай айкалган нурларын тоныгайтып калдырды. Җирдән тузан болыты күтәрелде. Абзар алды биек буадан аркып аккан язгы ташу шикелле шаулый иде инде. Ара-тирә колакны ярырдай ярсу, уттай кайнар сүзләр ишетелгәли.

— Атларга кагыласы түгел!

— Атларның ни гаепләре бар?

Чәрелдек тавышлы бер апа да сөрән салды:

— Лутчы сыерымны алыгыз, ат җанкайлар җанын кыймагыз...

— Оятыгыз кайда?!

— Сугышка да уптым илаһи алып китмәделәр...

— Ахырзаман җиткән мәллә ул хәдәрле?!

— Җәмәга-а-ать!

Арада диңгез бүресе Порфирий тавышы барысыныкына караганда да ачыграк ишетелә иде.

Аратаның ачык капкасыннан атлар томырылып чыккач, Солтан баянны күтәрде дә караңгы ишек авызына чигенде. Атлар аңа барысын да таптап, изеп үтәр дә канатланып, очып китәр шикелле тоелды. Арбалар баррикадасына җиткәч, иң алдагылары үрә басып, һаваны алгы аяклары белән дөмбәсли-дөмбәсли янга янтайдылар. Аларның кешнәүләре бар тавышны басты. Араннардагы колыннар, кырыкмыш тайлар да аваз салды. Аларның кешнәве яңгыравык, өзек-өзек һәм хихылдап көлгәнгә охшый иде. Уң кул якта чатнап пыяла ватылды. Маймыл таеның бүтән атлардан тыелгысыз гайрәте белән аерылып торган мәгърур кешнәве Солтанның аркасын чемердәтеп

җибәрде. Ул Маймыл таеның аран тәрәзәсен бәреп ватканын аңлады. Солтан инде берни күрми, ишетми кебек, күз алдындагы бу хәлнең куркыныч бер нәрсә икәнен генә аңлый. Кайчагында клубта кино караганда шулай була: тавыш кинәт бетә, ә ак пәрдәдәге снарядлар шартлавы, кешеләр үлүе, йортлар җимерелү дәвам итә. Андый чакта олы кешеләр, стенадагы тишектән сибелеп чыккан һәм калтырап торган утка карап, бер генә сүз кычкыралар: «Сапо-о-жник!» Солтанның да хәзер шулай дип кычкырасы килде. Тик тавышын кемгә юнәлтергә икәнен белмәгәнгә генә тыелып калды. Атларның яллары тузгый, койрыклары айкала, янга сикергән, тибешкән чакта тоякларындагы дагалары ялтырый. Атлар барысы бергә менә-менә ялкын булып кабынып китәрләр дә яллары ялкынга әверелер кебек.

Солтан карашы белән бабасы Кадрәкне эзләде. Ул күренмәде. Барысыннан да югарырак — гармунчы Илгизәр: арбага менеп баскан. Егетләрне абзар капкасы каршысын уратып алган арбалары бер генә атны да бөҗрадан үткәрерлек түгел. Юл бикле. Тимергә атланган килеш атларны алданрак ерып чыгарга өлгергән Кадрәк Солтан янына чаптырып килде, күрәсең, нидер кычкырды. Аннан атыннан шуып төште дә фонарен өреп сүндерде, аны эчкә кертеп чыккач, ишекне бикләде.

— Өйгә кайт,— диде ул һәм яңадан Тимергә атланды.

Атлар арасыннан уполномоченный белән колхоз рәисе, парторг та килеп чыктылар. Ничек тапталмыйлардыр. Хәер, Солтан атларның басып торган зур кешеләргә генә түгел, алга егылып төшкән малайларга да басмаганын яхшы белә.

Уполномоченный Ноль бөтен, яшел фуражкасын учына йомарлап, югары күтәрде дә:

— Ти-иха-а!— дип кычкырды. Әмма шундук буылып ютәлләргә тотынды: тамагы тыгылды, күрәсең.

Аның каршысына председатель чыгып басты.

— Туганнар!— диде ул.

Тик аны да тыңларга теләмәделәр.

— Җәмәгать, җәмәгать,— дип сөйләнә-сөйләнә Илгизәр күршесендәге арбага Шәмәй карт үрмәләп менәргә тырышты, аны да күрмәделәр.

Фәкать ләм-мим эндәшмичә, Илгизәр арбасына менеп баскан сукыр Нурны гына күрделәр, аны тыңларга әзерләнделәр, сүзсез тын калдылар. Мәйдан тынычлана төште. Атлар гына буылып пошкыра, өздереп кешни һәм ярсып тибенә иде. Нур йөзен шул тавышларга каршы куйды һәм калын кара чәчен озын бармаклары белән артка тараштырып:

— Карагыз әле, егетләр!— диде.— Бүген сезне мин булып мин дә ачык күрәм. Барыгызны да күрәм. Сорыйсым гына килә: намусыбыз бармы безнең, юкмы, ә? Әгәренки булса, атларны алып киткәчтеннән суң ары табан нишләрбез инде, ә?

Аны уполномоченный бүлдерде:

— Төш аннан!— дип кычкырды ул.— Төрмәгә эләгәсең килдеме әллә?— Ул арбага менәргә талпынган иде дә, каршысына егетләр бастты, юл бирмәделәр. Халык тагын берара тавышланып, гүелдәп алды.

— Мин болай да төрмәдә инде,— дип дәвам итте Нур.— Караңгылык төрмәсендә. Ие... Кем син — күрмим, шулай да таныйм: уполномоченный Ноль бөтен. Әйт әле, иптәш уполномоченный: атларны апкитәсезме?

— Моны мин кушмадым. Ил сорый. Колхоз идарәсенең карары бар. Бездән генә түгел, бөтен районнан җыялар. Задание — мең баш ат. Иртәнге унга һәммәсе пристань янына җыелган булырга, беренче партиясе баржага төялгән булырга тиеш.

— Беләбез: бездән утыз биш ат, районнан мең ат. Ә ат җигүдән мәхрүм калган мең ир-егетне санадыгызмы соң? Аларны да шул баржага төяп апкитегез!— диде Нур.

Уполномоченный җавабын уйлаган арада председатель телгә килде:

— Атларга алмашка безгә тиздән трактор кайтарталар, җәмәгать!

Сүзгә Шәмгун карт кушылды:

— Ихтимал, кайтартырлар да. Кызыл кар яугач... Минем мүкләк сыерымның сөтен кибеттә сатарга кайтарган шикелле. Мин, карт җүләр, яңа бидоннар алып кайткан булам тагын!..

Дәррәү көлү яңгырады.

— Рәхәтлеккә чыдый алмаганнан түгел ләбаса, туганнар!— дип өзгәләнде председатель.— Яшермим, мин сезнең алда кыяматкә тикләем винават калам. Үтмәс пычак белән салып суегыз, әмма дә ләкин илгә ит кирәк. Рязань өлкәсе бөтен илгә өлгерлек үрнәге күрсәтте. Әнә күпме малларын дәүләткә тапшырып бетерделәр. Артка калмыйк, политик өлгергәнлек үрнәгенә иярик... Ие, илгә ит кирәк, валюта кирәк. Әмма дә ләкин... Да!

— Минем сүзем бетте,— диде Нур һәм Илгизәргә баш кагып:— Калганын син әйтеп бетер, яшьти,— дигәннән соң аягын шудырып кына алга атлады. Аңа астан кул суздылар, күтәреп төшерделәр.

— Әйтеп кал,— диде Михаил Кукушкин Илгизәргә.— Тик бел: үзең утырган ботакны үзең чаптың син, малай. Позор: комсомол секретаре була торып, шушындый мәйханә оештыргансың.

— Аны сез чаптыгыз, Михай дәдәй,— диде Илгизәр. Аннары халыкка баш иде.— Гафу итегез, иптәшләр. Без атлар артыннан авылдан китәбез... Бөтенләйгә китәбез. Әйткән сүз — аткан ук, егетләр!— дип кычкырды ул.

— Әйткән сүз — аткан ук!— дип кабатлады егетләр.

Халыкны аралап, атларга каршы киткән егетләрнең ниятен һичкем аңышмый калды. Алар ниндидер сүз куешкан, монысы ачык. Ләкин нинди сүз икәнен белмәгәч, ни кылсыннар соң?

Ә егетләр, ягымлы эндәшә-эндәшә, атларны муен асларыннан кашый-кашый, сыртларына йомшак кына суккалый-суккалый, тузгыган ялларын тарый-тарый тынычландырдылар да, кошлар шикелле җиңел генә талпынышып, аларга менеп атландылар. Солтан, ник икәнен белештермәстән, ат өстенә төз, матур итеп атланган җайдакларны санап чыкты. Алар унбиш иде. Кайберләре ат ялларына ак кулъяулыклар бәйләп өлгерде. Сөйгән кызларының бүләкләредер инде.

Алар арасында Шәмгун карт та титаклап йөренде. Ул үзенең бурлы алашасын эзләп тапты да, муенынннан каккалап, шикәр шакмагы каптырды.

— Хуш инде, җанкай, хуш,— диде ул аның танавыннан сөя-сөя.

Илгизәр:

— Юл бирегез!— дип боерды. Ул да атта иде.

Арбаларга җан кердемени: көпчәкләр дәррәү кузгалды, күчәрләр шыгырдады, тәҗе чылбырлары зыңлады. Җайдакларның кайсысы алга чыкты, икенчеләре атларның әле йөгән кимәгәннәре һәм җайдак атландырмаганнары артына төште. Арата каршысын уратып алган арбалар арасыннан атлар елгадай агып чыга башлады.

— Фарватерны тәки ачтылар,— диде Порфирий.

Илгизәр Солтан янына юыртып килде.

— Гармунны бир әле, энекәш,— диде ул.

Солтан аңа башта пинжәген, аннары баянын бирде.

— Сау бул, энекәш. Онытма, яме?— диде Илгизәр, һәм пинжәген кигәч, баянының каптырмаларын ычкындырганнан соң, ике яктагы

каешларын иңбашына салды да, күрекне елатырдай сузып торып җибәргәч, җыр башлады:

Олы юлга чыккан чакта
Күтәрелде тузаннар.
Я кайтырбыз, я кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар!..

Хат ташучы Пәрхи:

— Хат языгыз ыштубы!— дип кычкырып калды.

Аларның ни уйлаганын җыелган халык шунда гына төшенде. Кайсыдыр:

— Сугышка китәләрмени!— диде.

Шулай җырлый-җырлый, атка атланган егетләр караңгылыкка кереп киттеләр дә Ногыртлы юлына төштеләр. Һидиятулла иң алдан, Кадрәк иң ахырдан барды. Атлар башта юырттылар, аннары буталышып, кушаяклап чабуга күчтеләр.

Аларны ат абзары янындагы халык сүзсез калып, ә хәвеф көткәндәй йокламаган авыл өйләре тәрәзәләрен балкытып озатты. Күктәге эре йолдызлар әүвәлгечә тере җемелдәшә иде инде. Солтан Чулпан йолдызының офыкка тияр-тимәс түбәнәйгәнен, кызаруын искәрде.

Колхоз рәисе кешеләрдән яшермичә, уңайсызланмыйча елый иде.

— Гомерем буена винават... Гомерем буена винават,— дип кабатлады ул.

Шул китүдән авыл егетләре кайтмады. Атсызлыкка дучар ителгән авыл әлеге җайдак-егетләрсез дә калды. Бераз вакыттан соң аларның ата-аналарына, сөйгән яки күңелләре төшеп өлгергән кызларына сәлам хатлары килә башлады. Алар бөтенесе дә Себердәге Усть-Илим дигән җирдә су электростанциясе төзелешендә эшли булып чыкты. Кайберләренә җавап төсендә кызлар үзләре дә шул тарафка чыгып киттеләр.

Солтан ул төнне, арыса да, Чаныш бабасы белән сөйләшеп ятты. Булдыра алганынча, күргәннәрен сөйләде.

— Син нигә килмәдең соң? — дип сорады ул бабасыннан. — Атлар белән саубуллашыр иең.

— Дөньяда картлар күрергә теләмәгән нәрсәләр дә була, улым,— диде аңа Чаныш бабасы.— Син күргән дә бик җитеп торыр. Тик күргәннәреңне онытма, яме?

— Ә атларны алып киттеләр ич инде, бабай.

— Киттеләр,— диде Чаныш бабасы авыр сулап.— Тик алар гел булмаса да бер кайтырлыр әле.

— Кая? Авылгамы?

— Анысы юк инде. Ә минә хәтереңә әйләнеп кайтырлар. Шул чагында син аларны кире куа күрмә, яме?

Солтан ул вакытта:

— Ярар, бабай,— дисә дә, соңыннан барысын да оныткан иде...

Хәзер исә ул: «Искә төшерер өчен шушы кабергә капланып калу кирәк булды микәнни?»— дип уйлады. Күрәсең, кешенең кабергә кергәч тә үкенеп исенә төшерер нәрсәләре дә каладыр...

## X

Умарталыктагы ташландык подвалга кереп калган Зур балык бөтен тәненең кайнар авырту белән тулуын, үзенең ярсыз-нисез, караңгы дәрьяга кереп китүен тойды. Аның каны салкын пычкы кыл урталай телгән йөрәгеннән саркып, ләм буенча елгага таба сузылды. Зиһененең

инде мәңге эремәслек калын боз белән томалана барганын сизгән Зур балык үзканының елгага агып төшүен күреп өлгерде.

Инде барысы да беткәнен, үзенең аяк астындагы җир, баш очындагы кояш кебек үк, япа-ялгыз калганын аңлаган Кадрәк сөялле учын балыкның салкын күзеннән аерды. Чаныш тарафына юнәлде. Ни пычкы үкерүен ишетмәде, ни ул тараткан төтен исен сизмәде. Барып җиткәч, Чаныш иснәргә өлгерми калган соңгы миләүшә чәчәген иелеп иснәде. Түбәннән туфрак исе генә күтәрелә иде. Кадрәк үзенең болай иснәвен кемдер күрүдән шикләнеп, арттагы кешеләргә борылып карады. Беркемнең аңарда эше юк иде. Пычкы үкертеп, ул тынган арада бер-берсенә кыска сүзләр кычкыргалап, зур балыкны турыйлар. Ул атасының гәүдәсен сузып яткырды, кулларын тынсыз күкрәгенә кушырып куярга үрелгәндә атасының сары бармаклары арасындагы яшел үлән сабакларын абайлады. Чаныш учына бер чеметем туфрак кыскан иде. Кадрәк:

«Миңа...» — дип уйлады.

Кеше үз кабеgame туфрак салалмый.

Кадрәк атасының туфрак кыскан кулын үзенең уң учына куйды, авырттырмый гына аның салкын бармакларын язды. Җылы туфракны, атасына караганда да катырак кысып, тыгызлап йомарлагач, уң як кесәсенә тыкты.

— Үзем салырмын,— диде ул.

Кулыннан туфрак тузанын каккач, Чанышның күзен йомдырды. Аның күз кабаклары салкынча, ә маңгае җылы иде әле. Кадрәк, чигенеп, корыган иманнең шома кәүсәсенә сөялгәч, умарталыкка карады. Арбасын сөйрәгән килеш Тимер төшеп килә иде. Күзен яшь элпәсе каплаган, күрәсең,— ат ике, өч булып, ә керфек кагып алгач, шәүлә булып кына шәйләнде. Гүя Кадрәк көтүләрдә көткән, эшкә җиккән, каплатыр өчен айгырлар янына алып чыккан, колыннарны төлкенекедәй купшы койрыкларын тырпайтып имгән чакта ипи кыерчыгы белән сыйлаган, суярга озаткан яисә чалыр өчен үләксә базына куган, ә бер чакны көтүләре белән баржага илтеп тапшырган атларның һәммәсе, Тимергә әйләнеп, аның каршысына килә. Кадрәкнең карашы умарталыкка күчте. Алары берсеннән-берсе матур өйләр кебек. Андый йортлар хәзер авылда күп. Күзен сөрткәч һәм бу саран күз яшенең инде тәгаен соңгысы икәненә ышангач, ул агачларга карады. Алар монда күп. Ә авылда сирәк. Умарта оялары шикелле матур өйләрне көчәнмичә салып керергә өйрәнгән авылдашлары агач утыртудан бизде. Иманнары корый башлаган халык белән ил баскан дошман гына агач утыртмый. Ә Кадрәк һич югында тагын бер агач утыртырга өлгерер әле. Соңгысын, атасы каберенә.

«Имән утыртырмын инде,— дигән карарга килде ул.— Ә аңынчы бусын — корганын кисеп аударасы булыр».

— Нишләгән ул?

Кадрәк янына килеп баскан тракторчы егеткә күтәрелеп карамады.

— Вафат булган,— диде.

— Үзем дә күмешермен, Кадрәк бабай.

— Алайса атны бор, Ринат.

Егет, Чанышны әйләнеп үтеп, үрәчә белән кабык арасына кыстырылган дилбегәне тартып алды, ат белән арбаны кайтыр якка борды.

— Күтәреп салырга безнең көч кенә җитмәс,— диде егет һәм балык янында кайнашканнарга карап сызгырды. Аны ишетмәделәр. Фәкать Пәпәй генә күреп алды. Ул, кабаланып, янындагыларга ишарәләде, директор игътибар иткәч, Кадрәкләр тарафына төртеп күрсәтте. Тракторчы егет чакырып кул изәгәннән соң, балык заводы директоры ризасыз гына аларга таба кузгалды, бер-ике мәртәбә борылып, Пәпәйне чакырды, тегесе аңа иярде.

Ә шофер зур балыкның койрык очын кистерә иде инде. Кисеп чыгарганнан соң пычкы моторын сүндерде, тураеп, корсагын бүлтәйтеп, билен язды, җәйпәк кепкасы белән маңгаен сөртте. Шунда гына янында кеше юклыгын шәйләде, як-ягына башын боргалады, аннары аларга карады да балык кисәгенә утырып, папирос кабызды, нидер мыгырдады.

Умарталык тып-тын. Кадрәкнең әллә колагы гөжли идеме, әллә шулай бал кортлары гүлиме икән, ачыклыйсы килмәде.

— Ни булды?— дип сорады директор килеп җитәр-җитмәс.

Кадрәк тә, тракторчы егет дә эндәшмәде. Кадрәк арбадагы сусыл печәнне буйдан-буйга кабартып чыкты, ә Ринат, хезмәт иткәндә күнеккәнчә, Чанышның костюм-чалбарын пөхтәләп төрде, җирдә сузылып яткан каеш белән төйнәде.

Директор:

— Ни булды?— дип кабатлады. Ни булганын мәеткә карап түгел, бәлки Пәпәйнең, йоннан бәйләгән керле баш киемен салып, күкрәк турысында учында йомаргалавыннан гына аңлады. Директор эндәшмәде. Ни әйтсә, нишләсә дә, соң һәм файдасыз. Ул шуңа төшенеп, алданрак китә алмавына үкенде. Булган эшнең җиле аңа да кагыла, ә бу — артык мәшәкать кенә түгел, начар фал да. Кайдадыр аңа да җавап тотарга туры килер — монысы тәгаен билгеле. Акланыр анысы. Моңа гына башы җитәр, сүзе үтәр. Чаныш картның нияте аның турыдан-туры вазифасына капма-каршы булган икән, үкенеч тә, куркыныч та юк. Карт үзенчә сукаладьг, аның беркатлы балалыгын аңларга да мөмкин, ләкин ул да үз мәнфәгатен генә каермады бит. Ни хәл итәсең — шулай килеп чыкты инде. «Барыбыз да бер үләсе».— дип уйлады ул үз-үзен тынычландырырга, юатырга теләүдән бигрәк, акланырга тырышып. Шуңа күрә аның:

— Да-а,— диюдән гайре бүтән чарасы юк иде.

Пычкысын кабинасына куйгач, алар янына шофер да килеп басты. Директор аңа иңбашын җыерып, кулын җәеп күрсәтте: янәмәсе, нәрсә инде бу? Шушы да булдымы эш? Безнең ни катнашыбыз бар?

Бу ишарәне шәйләгән һәм аңлаган Кадрәк: «Шулай инде: кемгә сарык, кемгә тун»,— дип уйлады.

— Балык дип инде ул хәтле...— диде шофер.— Барыбер үләсе иде инде ул.

Пәпәй әле балыкка, әле мәеткә төртеп күрсәтте дә, үз йөрәге турысына кулын куйды, башын чайкап, директорга һәм шоферга ярсу төстә йодрыгын изәде.

Тракторчы егет:

— Салыйкмы инде?— дип сорады.

Кадрәк баш какты. Ул дилбегә тотып торды, калганнар сүзсез, әмма үзләренең кирәге чыгуларына, әле менә болай да итә алуларына канәгать төстә мәетне җирдән күтәрделәр, көч килмәсә дә көчәнгән булып, сулышларын тыеп һәм уфылдап, арбага салдылар. Директор атлый-йөгерә барып, зур балыкның бер кисәген күтәреп китермәкче булды, тик көченнән килмәде.

— Ярый, без киттек,— диде Кадрәк. Ул боларның нишләгәннәрен генә күрмичә, ни уйлаганнарын да белеп торды. Ул сак кына дилбегәне какты һәм йомшак тавыш белән:

— Но-а, малкай,— диде.

Ат башын тәртәнең икенче ягына борды. Кадрәк, үзе күрмәсә дә, аның күзендә Чаныш чагылганына икеләнмәде. Менә ат алгы уң аягын күтәрде, бөтен буена сузылды һәм, камыт баулары, аркалык белән түшлек тартылса да, тәртәләр киерелсә дә, арба урыныннан кузгалмады. Кадрәк ниндидер тоем белән аның тере Чанышны ни гомер җиңел генә тартып йөртүенә карамастан, үле Чаныштан куркуын аңлады. Шуның өстәвенә, арбада Чанышның җансыз гәүдәсе генә түгел, ә бәлки

аның сүнгән зиһенендәге зур балыкны мәңге яшәтәсе килгән матур хыялы да ята иде. Елыйсылары килсә дә, тамагына укмашкан еламаска кирәк дигән каты төергә буылып, Кадрәк тагын:

— Пчо!— дип чөңгерде.

Ат Зур балыкны тарткандагыга караганда да ныграк көчәнде. Биегәндәй, дүрт аягында да таптанды. Эре тояклары астында җир дөпелдәде. Һавада дагалары ялтырады. Ялы кабарып тузгыды. Койрыгы таралып күтәрелде. Кадрәк ике куллап үрәчәгә ябышты. Аннан күрмәкче, арбаны арттан Пәпәй, тракторчы егет этеште. Учларына төкереп алгач, Кадрәккә каршы тәртәгә шофер тотынды. Директор да йөгереп килде, ул, алга чыгып, атны авызлыгыннан сөйрәде. Кадрәк янгарак тайпылды, өне китәрдәй булып, тимер күчәрләрнең көянтәдәй алга бөгелгәнен күрде. Киерелгән тәҗе башлары күчәр чөйләрен суырып чыгарды. Тәҗе чылбырлары, көтүче чыбыркысы сыман бөтерелеп, алга очты, чыңлап җиргә коелды. Көпчәкләрнең тимер кыршаулары купты, тырнаклары чалшая башлады. Алгы көпчәкләр тугымы башларына тиклем туфракка батты.

Тик Чаныш һәм аның сүнгән зиһенендәге Зур балыкны мәңге яшәтәсе килгән матур хыялы салынган арба урыныннан кузгалмады.

Шофер тәртәгә чытырдап ябышкан кулларында күтәрелде дә, арба аша сикереп, Кадрәк ягына килеп төште һәм дилбегәне тартып алды.

— Но-а-а!— дип кычкырды ул карлыккан тавыш белән. Гүя тамагына кадалган сөякне төкереп чыгарырга теләде.— Но-а-а-а!— дип кабатлады ул һәм, теш арасыннан кысып, атасы-анасы белән сүгенгәч, берничә мәртәбә баш очында айкалган дилбегә очын атның сыртына китереп сылады. Тимернең сырт тиресе ярылып китте. Ул урында, реактив самолет артыннан аяз күктә сузылган эз шикелле, майлы җәрәхәт агарып калды. Ат югарыга сикерде. Камыт баулары белән өзәңге шартлап өзелде. Ат киң күкрәге белән җиргә капланды. Дирбиядә буталып, тозакка эләккән карчыга сыман тыпырчынганнан соң, ул аякларын аерып киерелде, башын күтәрергә теләде, ләкин булдыра алмады.

Димәк, ул шундый итеп яшәгән ки, дип уйлады Кадрәк атасы хакында, аның иманын урыныннан аныңча яшәмәгәннәр бер карыш та кузгата алмый.

Нишлисен белмәстән, аңлата алмастан, Кадрәк, аягын киң аерып, тәртә арасына басты. Чак кына артка бирелде дә, тирән сулыш алып, арбаны алга сөйрәде. Аңа көч биргәндәй, Чанышның гәүдәсе селкенеп куйды. Һәм арба тауга каршы җиңел генә кузгалып китте. Арба узганда ат ахыргы тапкыр башын күтәрде.

— Рәхмәт, эти,— дип пышылдады Кадрәк.

Тау сыртына менеп җиткәч, Кадрәк туктады. Тәртәләрне җиргә куеп, кызган маңгаена учын тидерде. Тирләгән кебек иде. Юк икән. Маңгае коры, бер тамчы да тирләмәгән икән. Ул тагын:

— Рәхмәт, эти,— дип кабатлады.

Шуннан соң ул каршысындагы ерак офыкка, күз алдындагы якты суга әйләнеп карады. Һәм күз алдындагы күренештән бер мизгелгә телдән язды, өнсез калды.

*Үзенең болганчык, сасы исле майлар сеңеп беткән, әллә нинди тозлар эремәсе агулаган, шакшы чүп-чар белән тулган суына астан саф сулышлы, салкын чиста су ташкыны актарылып, ургым кушыла башлагач, Кояш астындагы елга Җир астындагы елгага эндәште:*

*«Әй син, Җир астындагы Дәртле елга, сиңа яхшы булгандыр инде,— диде.— Анда, миннән астагы Караңгылык патшалыгында, синең күзең юк иде — бер нәрсә дә күрми яшәдең инде; анда, миннән астагы Караңгылык патшалыгында, синең колагың юк иде — һични ишетми актың да актың. Ә миңа монда, Яктылык патшалыгында бары-*

*сы да күренә, һәммәсе дә ишетелә инде. Хәзер, миңа кушылгач, күр инде: кешеләр минем соңгы горурлыгым, соңгы куанычым, соңгы сердәшем булган Зур балыгымны да терелэй турадылар. Хәзер, миңа кушылгач, ишет инде: кешеләр мәңгелек зиратта мәңгелек йокыга талган мәетләрне синең атаң — Караңгылык патшалыгыннан чыгарып мәсхәрәли башладылар. Ул мәет кемдер — миңа билгесез, анысын синең атаң — Караңгылык патшасы белә торгандыр инде. Ә мин белгән Зур балык минем анам — Яктылык патшасы астында башка йөзми инде. Аның минем йөгерек суымны сафландырып җилфердәгән кызыл саңаклары кипте инде. Минем агымымны дулкынлаткан көчле канатлары яргаланды инде. Тәнемне дулкынлаткан зәңгәр койрыгы шәлперәйде инде. Аның тыгыз тәне бөгелә-сыгыла минем текә борылышларымдагы ярлар буенча үтмәс инде. Яшькелт чоңгылларым төбендә төнге йокыларга сузылып яткан чакта мин аңа тын бишек җырларымны көйләмәм инде. Ул минем чоңгылларым өстенә җәелгән утлы-яшелле, сасы нефть элпәләрен таратмас инде. Аны үземнең кочагымда назлаган чакларда мин сары комлы ярларымнан ташып чыгар дәрәҗәдә тулуларымны юксынырмын инде. Минем юксынуым аның Олы борылыш ярларына ышкыла-ышкыла үзенә тиң иптәш эзләп ярсуланган чагында сагынуы ише генә булмас инде. Нишләтим соң, нинди чаралар табыйм соң инде, и Караңгылык патшалыгының Дәртле елгасы! Аның кичә ыңгыраша-ыңгыраша, ак корсагын ташларга ышкый-ышкый, төптә яткан агач төпләренә тырнала-тырнала йолдызлар шикелле сары уылдыкларын чәчкән вакытта үзенә тиң ата балыкның ак сөтен ничек юксынуын судагы балыклар куркышып күзәтте инде, караңгы ояларыннан керәшәләр моңаеп карады, тугайдагы атлар колакларын шәңкәйтеп тыңлады инде. Ә Зур балыкның өлешенә тияр көмеше якын — минем Олы борылышымны чикләгән биек таш буаның аскы ягында гына иде инде. Нишләсен соң ул: сагынуына һәм ярсуына түзә алмыйча, үтеп булмастай таш дивар төбендә бәргәләнде. Зур балыкның карынынnan ташкындай ургып чыккан үги уылдыкларны минем суым комнар, вак ташлар белән бергә бутый-бутый таш буадагы шарламамнан түбән койды инде. Зур балыкның тиңе, әлеге уылдыкларны тойгач, күргәч, ак томандай куе сөтен сипте. Тик аннан ни мәгънә, адашкан тарау уылдыкларның һәммәсен таш буа астындагы вак-төяк гүҗ балыклар йотты инде. Зур балыкның тиңе үзе сипкән сөттә сукырайды, чарасыз калгач, таш буага башын орды, үлде, ак корсагын шәфәкъ нурларында алсулатып, Зур елгага агып китте, бер утрауның сай суында калып, бу таңда су күселәренә, ала каргаларга ризык булды инде. Хәзер мин чоңгылларымны сукырайткан пычрак майлардан, суларымны тәмсезләгән тозлы гөрләвекләрдән, агымымны хәлсезләгән таш буалардан, ярларымдагы зират каберләрен актарып, мәңгегә йокыга талган мәетләрне мәсхәрәләгән, соңгы горурлыгым, соңгы куанычым, соңгы сердәшем булган Зур балыгымны терелэй тураган кешеләрдән — мине Зур елгаларны, иркен дәрьяларны пычратучы елга иткән һәммә нәрсәдән курыктым, җирәндем, туйдым, биздем, гарык булдым инде.*

*Хәзер мин синнән оялам инде. Чөнки үзләренең сукыр һәм рәхимсез көчләре белән горурланган, үз мөмкинлекләренә мөкиббән булган, тыйнаклык, басынкылыкны танымыйча, бар нәрсәне үзләренә буйсындыру ниятенә бирелгән, шуның аркасында тереклек итүнең гавам тигезсезлегеннән һәм тәртибеннән, шулай ук яшәүнең бөек чуарлыгыннан мәхрүм булу куркынычы астында калган кешеләр сине гаҗәеп мәңгелектән, чиста матурлыктан куып чыгардылар да Кояш астындагы тормышның дөньяга килү, газап чигү һәм үлү белән тулып торган күренеше каршысында калдырдылар. Бетмәс-төкәнмәс сагыш, борчылулар ыгы-зыгысы кичерә-кичерә мин синең назыңны, ялкыныңны, омтылышларыңны тоя идем инде. Миңа син пәйда булдың. Шуннан ни була инде? Синең караңгы тоткынлыгың шакшылык һәм дуамал көч-*

*ләрдән кадерләрәк тоелмыймыни инде? Син шат яктылык белән ваемсыз куанычка атлыккан идең дә, тик минем чал дулкыннарымның моңсу иңрәвен, ярларымның боеклыгын, агачларның газабын, кошларның хәсрәтен, зиратларның сүзсез картаюын очраттың инде. Минем күктәге Олы яктырткыч, зәңгәр күкләр, төнге йолдызлар, яшел үзәннәр һәм күләгәле урләр, җылы яңгырлар һәм ак карлар, исәннәрнең көлүе, үлгәннәрнең тынлыгы белән саубуллашуым өчен гафу ит инде. Мине, үземнең үлемсез газапларымны һәм синең алда соңгы тәүбәмне дә кичер инде. Әй син, Җир астындагы Дәртле елга, ишетсәң — эндәш, күрсәң — кара: миңа биредә кысан, ә сине мәңгелек карыннан, тынычлыктан куып чыгарып, синең чисталыгыңны миндәге шакшылык белән кушкач, миңа биредә — аккан җиремдә һәм агарга ярамаган урынымда тагын да кысанрак инде. Мине караңгы билгесезлеккә, очсыз-кырыйсыз әйләнешеңә ал инде. Хәзердән минем язмышыма саңгырау һәм ишетелмәс булу, сукыр һәм күренмәс булу язган инде».*

*Җир астындагы елга эндәшмәде. Ул буылды, ишелгән ташлар арасында үзенә юл эзләде һәм, таба алмагач, артка ташланды, бердәнбер ачык урыннан югарыга ыргылды.*

*Су арттаннан-артты. Ә сусаклагыч төбендәге җир катламы өстәмә авырлыкны чыдата алмыйча иңде һәм ныклыгын югалтты. Тектоник хәл бозылды. Җир һәм таш катламнары хәрәкәткә килде.Төнлә катламнар арасындагы ярыктан ургып чыккан егәрле чишмә янында кинетик көч соңгы чиккә җитте һәм төрле якка юнәлеп чатнаган ярыклар буенча тарала башлады. Бу турыда суы агып бетеп, юкка чыккан җир асты елгасының түбәсе ишелеп төште һәм аның мәгарәсенә югарыдан су ташкыны томырылды. Сусаклагычның агымы туктап калды, аннары су бер урында әйләнергә кереште.*

*Елганың Зур борылышка кадәрге өлеше алга таба агуын дәвам итте, ә шуннан соңгы өлеше артка таба чигенә башлады. Елга хәзер ике якка ага иде инде! Ике агым кара-каршы кушылган, бәрелешкән урында әйләнмәле зур бөрәнкә хасыйл булды. Җир астыннан бәреп чыккан тыгыз газ ташкыны суны шау китереп кайната иде.*

Атасы Чанышның җансыз гәүдәсе салынган арбаны тау маңгаена тартып меңгергәннән соң каршысындагы ерак офыкка, күз алдындагы якты суга әйләнеп караган Кадрәк менә шушы хәлне күрде һәм бер мизгелгә телдән язды, өнсез калды.

Ул да булмады, гөрселдәгән тонык шартлау тавышы яңгырады. Корыган имәннең туфрактан калкып чыккан тамырларыннан башлап, күккә орынган ябалдашларына чаклы яшен ялтырадымыни: агачның кабыксыз кәүсәсе буеннан-буена кыл урталай чатнап ярылып китте. Агачның төп башыннан ике елан сузылышып чыккан һәм капма-каршы якларга шуышып киткән сыман булды — җир дә ярылды. Җансыз атның башыннан югарырак урап, бер очы имәннең сул ягындагы ак ташлы ярны кисте, икенче очы, умарталык подвалының уртасы аша узып, куаклар арасында югалды. Подвалдагы болганчык су күз ачып йомган арада юкка чыкты. Ләм баскан яр, корыган имәннең ярты-сын, җирән тракторны, зәңгәр автомашинаны ияртеп, аска шуа башлады. Туралган зур балыкның түгәрәк бүлемтекләре бер-берсен уздыра-уздыра түбән тәгәрәштеләр һәм суны чәчрәтеп елгага чумдылар. Аннан соң трактор белән автомобиль, иң ахырдан ат төпкә китте. Имән агачы да ярде, уртасына кадәр суга күмелгәч туктады.

Кадрәк янына Пәпәй, директор, алар артыннан шофер йөгереп менде. Директорның уң яңагы калтырый, шоферның аягы тотмый иде. Ә Пәпәй... ә чуваш Пәпәйнең теле ачылды! Ул, чукына-чукына, «Ләхәүлә вә лә куәтә» дип, мөселман догасы укына башлады. Тракторчы Ринат, кул кушырып баскан килеш, имәннең умарталыкта тырпаеп калган өлеше төбендә дөньяның күз алдында үзгәрүен күзәтте.

Шуып төшкән яр урыны яңа гына туналган сыер түшкәсе сыман кызарып тора иде.

Атның Чаныш салынган арбаны урыныннан кузгата алмау сере Кадрәкнең аңында күк капусыдай ачылып китте кебек. Малларга гына хас сизгерлек һәм зирәклек белән Тимер аяк астындагы җирнең кайдадыр аста ярдан аерыла башлаганын, ә алдында әлегә һичкемгә күренмәгән, фәкать үлән тамырларын гына өзәргә керешкән ярык пәйда булуын тойган, ул ярыкны атлап чыгарга курыккан, күрәсең. Арбаны ат менә ни өчен кузгата алмаган икән! Күпер астында бүре торса, ат аңа аяк басмый бит. Хикмәт шунда икән.

Пәпәй, чукынуыннан туктамыйча һәм кычкырып укынуыннан үзе үк куркып, авылга таба йөгерде.

— Пычкы кызганыч, өр-яңа иде,— диде шофер үз-үзенә.

— Чаныш картның теләге кабул булды. Балык суга китте,— диде балык заводы директоры.

Кадрәк аларны тыңламады. Ул, арбаның түбән тәгәрәвеннән шикленеп, арт көпчәкләр астына таш кыстырмакчы иде дә, кире уйлады: атасы Чанышның исән чагында үзе басып торган урыннан бер карыш та чигенмичә, фәкать алга гына атлап китүче кеше булганын исенә төшерде. Өстәвенә, аларның һәммәсе суның сизелерлек артуын, ә елга уртасында торган саен көчлерәк әйләнә барган агымны һәм әкренләп барлыкка килгән чоңгылны күреп алдылар. Су агымы тукталды. Тукталып кына калмыйча, кирегә таба ага башлады. Кадрәк елганың үлеп баруын һәм бу үлемнең атасы Чаныш үлеменә караганда хәтәррәк икәнен сизде. Сизде генә түгел, бөтен фаҗигасе белән аңлады. Чөнки кешеләрнең якты дөньяга бер килгәне кебек, бер китәргә дә тиешлеге бәхәссез. Ә менә агарга, гел агарга, мәңге агарга, фәкать түбән таба гына агарга һәм аккан җирләренә җитәргә тиеш булган елгалар кипсә кипсеннәр, мәгәр к и р е г ә   а г а р г а тиеш түгелләр. Әгәр дә елгаларның кирегә агуы мөмкин эш икән, моны атасы Чанышның сусыл үлән җәюле арбада яткан җиреннән торып утыруы белән генә тиңләп булыр иде. Нindидер кодрәт белән елгалар кирегә ага башлаган икән инде, димәк, бу дөньяда кешеләр тарафыннан нindидер зур хата эшләнгән дигән сүз.

Кадрәк тәртә арасына керде дә мәет яткан арбаны авыл ягына тартып китте. Күктә — ялгыз тилгән, ә җирдә — ул. Барасы юл ерак түгел. Әмма Кадрәк белән Чаныш арасы ераграк. Тиздән якынаерлар инде. Аралары ике кабер уртасындагы бушлык кадәр генә калыр. Бер-берсенә сузылсалар, куллары җитәрлек кенә. Кешеләрне иң якынайткан ара — каберләре. Алар бер-берсеннән узышып яшиләр. Ә шулай да бер-берсен еракта калдыра алмыйлар: үлемне беркем дә әйләнеп узалмый. Үлем һәркемне тигезли. Бер-береңне кабердә генә куып җитәргә мөмкин.

Дөрес, Чаныш хакында: «Ул булдыра алганнан азрак яшәде»,— дип әйтсәң дә ярый. Эш котылгысыз нәрсәдән озаграк качып йөрүдәмени?! Иң мөһиме, Чаныш исәннәр арасында буталып йөрмәде, ә ахыргача барып җитте: соң үлмәде, ә тиз яшәде. Хикмәт гомернең озынлыгында түгел, ә зиннәтле ташлар кебек кадерле булуында. Чаныш үз гомерен вакыт белән санамады, эшләре белән үлчәде. Шулар белән аның гомере үлгәч тә дәвам итә. Ул, кайберәүләр шикелле, үлмәс борын мәет булмады. Вакыты-вакыты белән аның баш очындагы күк йөзе аяз иде, кайчагында аның кояшын болытлар каплады. Максат гомер озынлыгындамыни? Максат — югарыдагы күкнең, астагы җирнең үзеңнән соң да урыннарында калырлык итеп яшәүдә...

Кадрәкнең болар хакында уйлап кына калмыйча, башкаларга да сөйлисе килә иде. Әмма янында аны тыңлардай җан иясе юк. Хәер, бар — әнә, тилгән. Ул да үзенчә гадел: корбанына поскан урыннан ташланмый, ачыктан-ачык һөҗүм итә. Давыл да шулай: тузгыр ал-

дыннан җиле белән хәбәр сала. Янгын алдыннан төтен күренә. Чагар алдыннан елан сызгыра. Бәндә генә астыртын яный: нияте никадәр яманрак булса, йөзендәге елмаю шулкадәр мулрак, сүзе шулкадәр татлырак. Әнә ич, балыкны тартып алыр алдыннан Чанышны мактадылар, балыкның үзен халык байлыгы дип игълан иттеләр.

Үзеннән алдарак очкан тилгәнгә карап, Кадрәк:

— Шулаймы, тилгән?— дип сорады.

Тилгән туктады, канатларын җәеп, уктай җиргә ташланды. Күтәрелгәндә Кадрәк аның тырнакларында кыр тычканын абайлады.

«Шулай,— дип уйлады Кадрәк,— корбаныңа ташланганчы, син туктадың. Тычкан, хәленнән килсә, качып өлгерә ала иде».

Ә Чаныш үлемнән качып калырга өлгермәде. Дөресрәге, теләмәде.

Электр станциясендәге өлкән диспетчер ток көчәнеше һәм зурлыгының кимүен баш инженерга хәбәр итте. Тегесе, тикшергәч һәм ышангач, моны директорга кереп әйтте.

Пәпәй авыл кешеләрен Олы борылышка әйдәп йөгерде. Халык җәяүләп, автомобильләрдә, атларда, мотоциклларда, велосипедларда тагын умарталыкка ашыкты. Бераздан нефтьчеләр, хәрбиләр, район җитәкчеләре, республика башлыклары агыла башлады. Бөтен чаралар белән елганы кирегә — һәрвакыт аккан юлына төшерергә тырыштылар. Су бөтерелмәсе уртасына вертолетлардан авыр тимер-бетон блоклар ташладылар. Ахыр чиктә берничә авиация бомбасы шартлаттылар. Тик берни кыла алмадылар. Елга Олы борылыш уртасына кадәр генә агып килә дә, шаулы шарламага әверелеп, җир астына томырыла иде. Шарлама чоңгылы киңәйгәннән-киңәйде, җир бушлыкка убылганнан-убыла барды, су кимеде. Юеш ләмнән, чокыр-чакырлардагы судан чагылган кояш нурлары ярдан-ярга салават күпере булып сузылды.

Тау башындагы йомры ташка, тетрәнүдән, ару-талчыгудан бөрешеп утырган Даниил Афтандилович янына, арттан шым гына якынаеп, балык заводы директоры килеп басты.

— Гафу итегез инде, Даниил Афтандилович, балык та шунда китте бит,— диде ул.

Даниил Афтандилович аңа боек караш ташлады да торып басты, теш арасыннан кысып:

— Яхшы балык иде,— диде.

— Әйе, балыгы шәп иде, балыгы!..— дип көрсенде директор.

— Балык микән?— диде Даниил Афтандилович.— Балык микән? Сиңа шундый уй килмиме, Эдуард Сәйфелмөлекович: без тормышта иң мөһим нәрсәләрдән бизгәнбез. Безнең әлифбабыздагы беренче хәрефләр үзенең мәгънәсен югалтты. «А» хәрефеннән ваз кичеп, «я»— ягъни «мин» дигәнгә табындык. Шуңа күрә яр читендә басып торабыз да.

— Мин начар эш эшләмәдем. Ниятем яхшы иде.

— Ә кемнеке начар? Яхшы нияттән килеп чыккан яман эшләр азмыни?!

— Алай икән, безнең үз-үзебезне мөмкин кадәр кыйммәтрәк сатуыбызга юл куймагыз соң, Даниил Афтандилович.

— Аянычка каршы, син хаклы,— диде Даниил Афтандилович карашын еракка, кичке шәфәкъка төбәп.— Әйтә алмыйсыңмы: нигә безгә намуслы кешеләр яманнарга караганда шиклерәк күренә, ә? Без Чаныш картка ышанмадык, ниятенең изгелегеннән шикләндек. Кайчаннан бирле чит батырлыктан йөз чөерергә күнектек икән? Җавабың юкмы?— дип сорады ул бераз көтеп торгач.— Ә җавап бар, Эдуард Сәйфелмөлекович, бар! Без дөньядагы тәртипне үзебезгә кирәгенчә генә аңларга тырышабыз, теләсә кемне — кешеләрдән башлап, аллаларга кадәр — үзебезгә җайлап үзгәртергә телибез. Тик үзебез генә үзгәрмибез... Дөресен генә әйткәндә, бу хакта мин хәзер Чаныш карт белән сөйләшер идем... Карале, директор, кайда әле ул?— дип, яр буен ура-

тып алган һәм үзләреннән алга беркемне дә чыгармаган кораллы солдатлар артындагы сирәк халык арасыннан Чаньшның үз хәтерендә уелып калган кыяфәтен эзләде.— Умарталык өендәдер. Чакырып кил әле. Хәер, чакырма. Үзем барам.

— Үлде ул, Даниил Афтандилович. Аны улы Кадрәк, арбага салып, авылга алып кайтып китте.

Даниил Афтандилович кан качкан иренен ялап, ышанырга теләмичә:

— Ничек инде ул үлде?— дип сорады.

— Егылды да үлде. Бик картайган иде ич инде.

— Ялгышасың,— диде Даниил Афтандилович карлыккан тавыш белән.— Ул карт түгел иде, ул акыллы иде. Ул, минемчә, картлыктан үлмәгән. Ул акылына, рухына таяныч тапмаудан үлгән.

— Матур әйттегез әле, Даниил Афтандилович!

— Ташла сана!.. Хәер, нәкъ үзе. Сүзебез матур, ә эшебез... Кагылдың исә, кәгазь көле шикелле тарала да китә,— диде Даниил Афтандилович.

## XI

Елга, дөресрәге, аның ачык төбе өстендәге һава бөркү иде. Эңгермеңгер иңә башлады. Мондый һавада Камәриянең кан басымы күтәрелә, башы чатнап авырта башлый. Ләм, су үсемлекләре исе борынны ярып керә. Баш өстендә озынборыннар безелди, черки көтүе бөтерелә. Ыгы-зыгы килеп һәм канатларын кыштырдатып, аларны энә караклары аулый. Зәңгәр ситсы күлмәген киеп, Камәрия җылы һәм коры җирдә утыра, елга төбендәге сулы чокырларның шәфәкъ кан төсенә манчылган чагылышларын күзәтә иде. Һәркайда буш моңсулык, билгесезлек, шом хөкем сөрә.

Бер кара кырмысканың яшел чебен үләксәсен җирдәге тишеккә сөйрәп кертергә азаплануын Камәрия җентекләп карап торды. Чебен тишеккә сыймады. Ә кырмыска аны әйләндерә-әйләндерә сөйри, тарта, йолка бирде. Гүя аның көчәнүен чыдата алмыйча, уч төбе кадәрле җир убылып китте. Кырмыска белән чебен, алар артыннан бер чеметем үлән күздән югалды. Тынлыкта ниндидер казыну, чокчыну, кыштырдау авазы ишетелде. Камәрия: «Йомран, ахрысы»,— дип уйлады. Аның алдындагы яшь әрем дә калтырып куйды, әкрен генә иңә башлаган туфракка ияреп, җир астына убылды.

Камәрияне борчылу биләп алды. Тишек авызыннан бәреп чыккан чит-ят ис куркытты аны. Бу ис аның борынына, күкрәгенә тулды, тынын кысты, сулышын буды.

Кыз тезенә калыкты, сузылып түбән карады. Һәм, ни кычкырырга, ни торып йөгерергә белмичә, шул килеш тораташтай катып калды: астан кеше тавышы ишетелә!

Ул бу сәгатьне көтеп алды, тавышларның кемнеке икәнен аңлады. Шуңа күрә тәнен һәм аңын биләп торган киеренкелек бушанды; күңеле түземсезлек хисе белән тулды, йөзендәге кырыс җыерчыклар таралды, күзенә елмаю чаткысы кунды.

Тагын бер кисәк җирнең убыла башлавын күреп, Камәрия мукәләп артка чигенергә кузгалган гына иде, аның битенә тия язып, тишектән нидер атылып чыкты да, нечкә резинга элеп куелган шикелле, өскә-аска тирбәлеп тора башлады. «Кош!»— дип уйлады ул, аның нинди кош икәнлеген ачыкларга тырышып. Ә танығач, шатланып:

— Сандугач!— дип пышылдады.

«Менә син кайда икәнсең, бәгырькәем!— дип уйлады кыз.— Алар белән бергә томаланып калгансың... Ә сине парың ничек моңаеп көтте!»

Кош тыпырчынды, сызгырынды, тишеккә таба талпынды, тагын

югары омтылды. Шул мәлдә аның янәшәсендә тагын бер кош пәйда булды. Анысы да тынычсызланып ыгы-зыгылана, сызгыра, югарыга атыла да түбән томырыла башлады.

Ниндидер курку тойгысы аларны читкә куды, ләкин алар шундук түбәнәйделәр, шул мәлдә бер чите зур булып эчкә убылган чокырның авызына ук кереп киттеләр. Камәрия дә шунда үрелде һәм җир астыннан күтәрелгән кош оясын күрде. Ояда сыек көрән-яшькелт төстәге йомыркалар ята, ә кошлар, аларны хәвефтән сакларга теләгәндәй, ояга куна язып җилпенделәр.

Ояның кеше учында күтәрелүен күргәч, Камәрия тын гына елмаеп куйды. Ә шулай да кыз алдындагы күренеш җанны өшетерлек куркыныч та иде. Аның: «Әни!»— дип кычкырасы килде, ләкин ул авызын учы белән капларга өлгерде. Ул йөрәгенең ярсып тибүен, кагуын гына тойды. Әнә, теге чакта, шушы зиратта күккә ашкан шартлау вакытындагыга охшап, аның күз алдында канлы бармаклар, пычрак беләк, аңа текәлгән кара күзләр, кара сөремгә, туфракка баткан чырай, сүзсез кыймылдаган ирен, ап-ак тешләр хәрәкәтләнде — боларның һәркайсы куркыныч төшне хәтерләтә иде.

«Delirium» [1],— дип уйлады Камәрия. Ул бу сүзнең әллә кайчан — техникумда укыган чаклардан бирле онытылганнан соң исенә төшүенә гаҗәпсенде.

Шул чакта саңгырау дөнья аңа үз исеме белән эндәште:

— Камәрия!..

Теткәләнгән дөньяның меңнәрчә кисәге бер-берсенә ялгана башлады. Тишектән, кулына кош оясы тотып, ул байтактан бирле көткән кешесе аның каршысына чыгып басты.

— Солтан!— диде кыз пышылдап һәм күз яшьләрен керфекләре белән кагып.

— Камәрия...

Үләннәргә ябыша-ябыша, туфракны тырный-тырный чокырдан тагын берәү үрмәләп чыкты да ухылдап җиргә сузылып ятты, гүя ки ул азатлык белән, яңадан туу минуты белән ләззәтләнә иде.

— Нишлисең син монда, Камәрия?— дип сорады Солтан.

Кыз, үзенең биредә ник утыруын аңлаткан шикелле, күкрәгенә кочкан бер бөтен ипине ачып күрсәтте.

— Бер нишләмим. Сине көтәм, Солтан,— диде ул.— Сезне...

— Күптәннәнме?— дип сорады Солтан Камәриянең үзләрен кабергә күмелеп калган мәлдән күзәтүен күз алдына китерергә тырышып. Аңа оят иде.— Күптәннән көтәсеңме?— дип кабатлады ул.

— Мең ел бардыр инде,— диде Камәрия һәм, күз карашы белән чокырга ишарәләп:— Нишләдегез анда?— дип сорады.

Җавап эзләп, Солтан иңбашын җыерып куйды, кулын селеккәләде һәм, кош оясына ымлап:

— Менә ... сандугач оясын алып чыктык,— диде.

Степан, яткан җиреннән авыр кузгалып, аягына калыкты да, Солтаннан кош оясын алып, зелпе куагы төбенә куйды.

Камәрия, кызыл чәчәк төшерелгән бидонга ишарәләп:

— Мин сезгә сөт тә апкилдем. Эчегез,— диде.

Солтан ташка куелган савыт алдына тезләнде һәм йотлыгып эчә башлады. Сөт аның төк баскан иягеннән ачык күкрәгенә, үләннәргә, җиргә акты. Тыны бетеп, эчүдән туктагач, бидонны каршысына тезләнгән Степанга сузды. Тегесе дә туймастай комсызланып эчәргә керешге.

— Ипиең дә безгәме?— дип сорады Солтан.

— Сезгә. Мәгез, мә.

Камәрия, ике кисәк ипи сындырып, аларга тоттырды.

---

[1] Саташу (латинча).

— Безнең монда икәнне кайдан белдең?— дип сорады Солтан.
— Карап тордым.
— Бөтенесенме?
— Бөтенесен.
— Тегене дә күрдеңме?
Нәрсә турында соравын аңлап, Камәрия баш какты.
— Сез агызып җибәргәч, аны мин сөйрәп китердем бит,— диде ул.
— Ә ник без сине күрмәдек соң? Эзләдек сине,— диде Степан.— Кайда идең?
— Ватык кыңгырау артына постым.
— Томаланып калганыбызны белгәнсең, ә коткарырга кеше чакырмагансың,— диде Степан үпкәләп.
Камәрия җавап кайтармады.
— Шул кирәк безгә,— диде Солтан.— Кабер кортлары кемгә хаҗәт?
Степан җиргә тезләнгән җиреннән авыл ягына каерылып карады.
— Исән чакта мин кирәк идем!.. Бакчаларын сөрергә, өйләрен бурашырга, каберләрен казышырга... Онытканнар... Тереләй күмгәннәр...— дип кычкырды ул.
— Хәзер безне тереләй күмсәләр дә таман, Степан. Бу чүп кенә. Ә менә үлгәч казып чыгарсалар нишләрсең?— диде Солтан һәм үз соравыннан үзе куркып китте.
Алар үз-үзләрен казып чыгардылар. Ә алар бу кабердә күмелеп калганчы кем иделәр дә менә хәзер — чыккач кем?
— Сезгә юынырга кирәк, егетләр,— диде Камәрия.
Алар моңа кадәр һаман Камәриягә каршы гына басып торалар, артка — балык тотканнан соң көймәдә килеп туктаган ярга әйләнеп карарга базмаганнар иде әле. Хәзер елга тарафына борылдылар һәм дымык пәрдәгә төренгән җирнең тын гына, әмма яшәү билгесе белгертмичә ятуын күрделәр. Аның үле кочагында тирән һәм пычрак җәрәхәт ярылып ята иде. Шунда гына тонык гүләүгә илтифат иттеләр. Гүя җир ыңгыраша һәм сызлана иде. Аеруча тирән ярыннан чак кына күренеп торган инешнең элеккеге елга агышы юнәлешенә капма-каршы якка агып ятуы сәерсендерде, тетрәндерде, хәтта куркытты да.
— Боже, ни бу!?— дип сорады Степан.
— Елга су астына китте,— диде Камәрия тыныч булырга тырышып.— Чөнки умарталык подвалына галәмәт зур бер балык кереп калган. Ә кешеләр аны тураклап ташлады. Чаныш бабай белән Кадрәк бабай аны суга җибәрергә теләгән иде. Аларны беркем тыңламады. Шуның өчен Чаныш бабай...— дип, Камәрия бүленеп калды, калганын әйтеп бетермәде.— Кадрәк бабай авылга кайтып китте...— Ул зәңгәр яулыгын салып, егетләргә сузды: — Сөртенегез...
Тау битләрен, урләр һәм үзәннәрне кыр, авыл исе белән назлап кына җил исеп куйды. Зират урнашкан үргә кичке шәфәкъ нурлары сузылып яткан, ә түбәндәрәк шәмәхә күләгәләр җиргә хуҗа булган иде инде.
Менә тау кашы артына кояш та батты. Аның соңгы нурлары күк гөмбәзендәге сирәк болытларга күчте. Елга үзәненә эңгер-меңгер төште. Ләм баскан түмгәкләр, чокырлардагы сулар кургашындай ялтырый иде әле. Елга төбенә акчарлаклар көтүе төшеп кунган, алар әледән-әле кычкырып куйгалады.
— Рәхмәт,— диде Солтан Камәриягә яулыгын сузып. Аның канәфер исләре аңкып торган бу яулыкны керле-тузанлы битен сөртеп буйыйсы килмәде.— Инештә юынырбыз. Әйдә, Степан.
Степан сүзсез генә ризалашты. Күкрәгендәге тәреләрне зыңгылдатып, күлмәген салды да җирдәге штормовкасына куйды.

— Син кайта тор,— диде Солтан кызга,— без сине куып җитәрбез. Олы юлга чык, яме?

Яр читеннән аска сикереп төштеләр. Степан лом белән бауны югарыга ыргытты.

— Әле көймәне дә карыйсы бар,— диде ул.

— Инеш саеккан ич инде. Нинди көймә? Атка салып кайтарырбыз әле.

Алар инешкә карап киттеләр. Авыр итекләрен сөйрәп, алдан Степан бара. Аңа Солтан ияргән. Армаган-талчыкмаган да диярсең: адымнары тигез, җиңел. Ул як-якка каранды, борылып, Камәриягә кул изәде: янәсе, бар инде, кайта тор.

Камәрия, егетләрне олы юлда көтәргә булып, яулыгын кысып бәйләде, чәчен кыстырды. Бер сандугачның тыйнак кына сайрый башлавын ишетеп, аяк очларында гына куакка якынайды, ләкин кошның сагаеп тынуын абайлап, кире чигенде. Җирдә тәртипсез яткан киемнәрне агач тамырына элеп куйды. Бармаклары Степан күлмәгендәге тәреләргә орынды. Авызын каплап, бераз уйлап торгач, ул аларны берәм-берәм ычкындырып алды. Әллә киеренкелектән, әллә җаны тынычсызланудан аягы калтырарга керешә. Шуннан соң ул күлмәкләрне тагын җайлап куйды, әмма Солтанның күкрәк кесәсендә шырпы шылтыравын ишетеп, аны да чыгарды. Башта ул тәреләрне кабер тишегеннән генә ыргытмакчы булган иде. Төшереп үк куярга ниятләнеп, тишек читенә утырды һәм, сузылып, эчкә кереп китте.

Склепка килеп кергәч, кабаланып шырпы кабын ачты. Ләкин шырпылар күп түгел икән, биш-алты гына. Шуларның берсен тырнаклары белән чеметеп алгач, ут кабызды. Караңгылык чигенде. Тонык сары яктылыкта ул стена һәм түшәмнән кала һичнәрсә абайламады әле. Шырпы ялкыны бармакларын пешереп сүнә дигәндә генә идәндә яткан чыраны күреп өлгерде, икенче тапкыр сызган шырпысын шуның очына төртте. Чыра уты дөрләп киткәннән соң, Камәрия чүгәләгән җиреннән генә егетләрнең кайда булганлыгын күрде, алар сулаган һаваны сулады. Күңеленә әллә нинди буш моңсулык иңеп керде. Ул тәреләр тоткан учын алга сузып, табут янына килеп басты, һәм аларны капкачка беркетелгән сигез почмаклы бронза тәрегә куйды. Ул табуттан курыкмый, анда нәрсә бар икәнлеген белә иде инде. Сары баш сөягеннән һәм яртысы чыра итеп теленгән иконадагы сурәттән генә шикләнде. Кием-салым калдыкларыннан, баш сөяге астыннан чыгып торган чәч толымыннан ул сөякләрнең хатын-кызныкы икәнен чамалады. Кайчандыр бервакытны ул үзе дә шундый гына булып калачак... Камәрия исән-сау чагында күрергә тиеш булмаганны һәм инде үлгәнче оныта алмаячак нәрсәне күрде. Чөнки ул — хатын-кыз, һәм ана карынынnан якты дөньяга чыкканнан соң шушындый мәңгелек тукталышка кереп туфрак булырга тиеш икәнлекне күрү аның язмышына язылырга тиеш түгел.

Ул кайдандыр «Менә ничек!» дигәнне ишетте сыман. «Менә ничек!» — дип кабатлады кыз үзалдына һәм ислам диненең хатын-кызларга ни өчен зиратка аяк басарга тыйганын аңлады. Үзендә зур газаплар белән дөньяга киләчәк, ә тугач, яшәүне үз тәннәренә кабул итеп елап җибәрәчәк җан иясе өчен карын йөрткән хатын-кыз мәетләр иленә орынырга тиеш түгел икән...

Камәриянең иренена саран гына елмаю чаткысы кунды. Ул үзе хакында үзенең кайчандыр бала тапкан хатын шикеллерәк уйлануына гаҗәпләнде. Ләкин ул барыбер кемдер тапкан, имчәк имезгән, аннан соң газапланып үлгән һәм шушы кабергә күмелгән кешеләрне кызганды.

Сагыш белән тулы склепны карап бетергәч, ул чыгу юлына борылды һәм, әле һаман нидер әзләнүеннән арына алмыйча күзәтә торгач, аяк астына әллә каян гына килеп чыккан ике еланны күреп ал-

ды. Еланнар да аңа текәлгәннәр, тагын бер атласа, чагып алырлар шикелле тоелды. Аңа еланнар түгел, бәлки үлем үзе төбәлгәндер сыман. Камәриянең тыны буылды, учы, кошларның давыл вакытында агач ботагына тырнаклары белән ябышуы кебек, калтырар дәрәҗәдә чыраны кысты. Ул чигенде, үкчәсе астына туры килгән кирпеч ватыгы кыйшаеп китте. Камәрия тигезлеген югалтып егылды, башы белән табут почмагына бәрелде һәм аңын җуйды...

Сандугачлар үз ояларын бөтенләйгә ташлады һәм һәркайсы аерым ботакка кунды. Оялары аста суына башлады, ә йомыркалары таң алды йолдызлары шикелле агарып күренә иде әле. Алар бу оя турысында борнап чыгачак балаларына тапшырасы җырларын бүтән сайрый алмыйлар иде инде. Ояга төрле яктан биш елан шуышып килде. Алар уклары белән йомыркаларны капшап чыктылар, авызлары зур булып ачылды һәм йомыркаларны ач карыннарына суыра башлады. Сандугачлар аларга битараф төстә карап тордылар да, куактан күтәрелеп, ерак урманнар тарафына очып киттеләр.

Элеккеге сусаклагыч турысында учаклар балкышы уйный иде. Солдатлар паекларын җылыта һәм су төбендәге күлдәвекләрдән коры кул белән тотып алган балыкларны пешерә иде.

Майор белән геология эшләре башлыгы сигез кырлы стаканнан аракы эчеп, карта уйнап яттылар. Кирле карталар сусаклагычның кызыл һәм зәңгәр тамгалар белән чуарланган критик сызым картасы өстендә бик җайлы шапылдады. Иртәгә килеп төшәчәк хөкүмәт комиссиясе, бүген аларның кайсысы дурак калганлыгын тикшермичә, һәлакәтнең сәбәпләрен ачыклаячак. Аларның уртак фикеренчә, бу икәүнең погоны һәм карьерасына куркыныч янамаска тиеш. Чөнки алар кушканны гына үтәделәр.

Шарламадан ерак түгел кешеләргә соң сулышына чаклы хезмәт иткән Владимир токымлы, Тимер кушаматлы атның пычрак түшкәсе ята иде. Өч дистәләп ала карга аның өстеннән күтәрелделәр дә, авыр һәм тук тәннәренә яңа көч алып, ташландык зираттагы ояларына кайтып кундылар.

Ә бу вакытта Наймушиннарның дүртпочмаклы җыйнак өендә чуар күлмәкләр кигән ак йөзле җиде карчык өч сажин ярым калынлыгындагы кәфенне хәстәрләп куеп, энә җебен идәнгә тидермичә һәм төенләмичә, иртәгә Чанышка кидереп гүргә иңдерәсе ак бәз каплагычны тегә башлаганнар иде.

Егетләр чистарынып-юынып килделәр. Алар, бер-берсенең кәефен күтәрергә теләгәндәй, юри кычкырып сөйләшсәләр дә, ихлас булмаганнарын, үз сүзләренә үзләре ышанмаганнарын аңлыйлар иде. Киенделәр, каралып торган тишектән читкә китеп, комсызланып, сөт белән ипи ашадылар.

Һәр тарафта саңгырау тынлык хөкем сөрә иде. Чәчәкләр йомылган, яшеллек караңгылык белән кушылган. Тирә-юньдә сүнгән тормыш таралып ята: максатсыз, фикерсез, хәрәкәтсез тормыш. Елга суы белән һичнәрсә агып килми, агып китми, агып кайтмый иде инде. Елга үткәннән, бүгенгедән һәм киләчәктән мәхрүм булды; үзен аска — караңгылык һәм тынлык хөкем сөргән урынга тартып алган көч ихтыярына буйсынды. Ул җирнең тоба карынына шарлама булып ага һәм астан үзенең Кояшны сагынып елавы турында хәбәр сала иде.

Кайтырга вакыт җитте. Егетләр тордылар, әйберләрен җыйнадылар. Ләкин Степан кинәт артка каерлып карады да, лом белән бавын ташлагач, мәче сыман җилкәсен бөкрәйтеп, ярдан түбән сикерде. Тиздән ул көчәнеп югарыга бер яссы таш ыргытты.

— Тегендә куй!— дип кычкырды ул.

Солтан кая икәнлеген аңлады.

Дистә ярымлап таш белән алар теге дөнья тишеген томалап куйдылар һәм билгесез вакытка үзләрен киләчәктә котылгысыз рәвештә көтеп торачак нәрсәдән араладылар. Үзләренең яшертен төстә тойган, күргән гөнаһларын үлем чокырына таш белән бастырып калдырдылар шикелле.

Степан менгәч, ярдан Солтан сикереп төште.

— Ал!— диде ул һәм өскә агач тәрене этеп менгерде.

— Нәрсәгә бу?— дип сорады Степан.

— Үзем беләм...

Югары калыккач, Солтан ауган нарат тамырлары актарып ташлаган урынны лом белән чокчыды да, кроссовкасы белән туфракны таптый-таптый, тәрене шунда бастырып куйды.

Бу юлы һичнәрсәне онытмаганнарын аңлап, кыйшайган тәреләр, авыш кабер ташлары һәм исемсез каберләрдәге бөкре калкулыклар янынннан үз язмышларын югарыга алып менеп киттеләр.

Бөтенләй караңгыланды. Күктә Сириус йолдызы балкыды. Иртән Кояш җиле күтәргәнгә кадәр, олы юллардагы тузан басылды.

*1986-1988.*
*Казан.*

## ШИГЪРИЯТ

# Рәшит Әхмәтҗанов

## Карачкы

ПОЭМА

### Карачкының пәйда булуы

Бүген дә ул
Шәфәкъ утларында
Янып кайта «сүнгән» җиреннән.
Китте инде, бетте, диючеләр
Шаккаталар:
— Тагын терелгән!

— Әнә, кайта! Әнә, кайта!..— диеп,
Бала-чага төртеп күрсәтте.
Ай-һай, җирдә кеше дигән затның
Картайганы юктыр шул хәтле —
Таралырга тора... Бар дөньядан
Шәфкать көтә сыман Карачкы.
Кеше куркытырлык берние юк,
Бу балалар күреп ник качты?

— Таралмагыз,— ди күк ул аларга,—
Курыкмагыз, миндә — җан исән!
Җанымдагын тапшыралмый калып,
Җирегезгә әгәр күмелсәм...

Күмелгәннәр кузгатамы әллә,
Тетрәүләрдән тынмый җирегез...
Юкса, васыять йолдызларга иңәр...
Күңелегезгә салыйм — килегез!

Туган итеп калдырасым килә
Җирнең сезгә һәрбер үләнен.
Җиңелмени миңа карап тору
Җаныгызда иман үлгәнен?!.

Ак болытка хәлен сөйлидерме,—
Күккә багып тора Карачкы.
Агып киткән болыт
Хәтерендәге
Хәсрәт ташкынына юл ачты.

Сөйли... Җылы шәфәкъ кочагында
Аны тыңлап гөлләр тын тора.
Ә сүзләре... барыбер
Кемнәрнедер
Котып җиле сыман туңдыра.

### Карачкының яшь чагына кайтуы

Йокламый Карачкы.
Күз йомса —
Йөрәге ыңрашып уята.
Йөрәге кычкырып уята...
Таң ата.

Көн дә бер кемнәндер кыйнала,
Көн дә бер сөрелә иленнән;
Этапта муенына бау сала,
Билбавын ала да биленнән...

Әнә шул уйларын сөйләргә
Юк аның янында беркеме.
...Сөйли ул — тыңлыйлар шикелле
Баягы балалар төркеме.

«...Уналты яшь тулган ел иде.
Авылым кол иде — акларда.
Атлары кырылган. Яшьләрне
Күзләре күрмәгән якларга
Ияртеп киттеләр. Авыр йөк

Төялде һәркемнең атына.
Үрмәләп урманга качканда,
Аттылар — үлмәдем чак кына.

Аларның иманы тамчы да
Кушыла алмады каныма;
Атадан-бабадан күчкәне
Шунда ук китерде аңыма...

Һәм миннән карачкы ясады
Кан чәчеп сызгырган камчылар.
Үтереп тә үлмәгәч, тегеләр
Куркышып качтылар...

Егерме беренче ел иде.
Ачлыкта — кол идек барчабыз.
Атлар юк — ашадык. Үрмәләп
Кем кая үлемнән качабыз.

Авабыз, авабыз... Ачлыкның
Шыр сөяк кулында — утсибәр.
Икмәккә бару юк кырларга,
Үлекләр җыярга ат җибәр.

Хәтердә ялтырап яталар
Сөякләр сибелгән ул юллар:
Мең еллык тарихын кочаклап,
Ачлыктан үлделәр авыллар.

Карт-коры яшьләргә ялынды:
— Юк карга чукырлык итегез,—
Күз-колак булырбыз авылга,
Китегез, балалар,
Китегез!

Җаннарын коткарган шикелле,
Озатып калдылар. Калдылар.
Яшәсен хәрәкәт! Йөрәктә
Аларның кап-кайнар каны бар.

Кайный кан.
Ник килдең дигәндәй,
Табанны яндыра чүл комы...
Күзләрне керфексез калдырды
Авылдан качуның шаукымы...»

...Таң атып килгәндә, йөрәге
Дөньяны кычкырып уята:
— Ә теге ялварып калучы
Картларга җан алып кем кайта?

Авылга Кояшны тапшыра
Авылның артыгы — Карачкы.
Һәм саный: дененнән, теленнән,
Яшисе көненнән
Кем качты?

## Карачкының шәҗәрәсе

«...Авыл саен бер галим —
Сабагыңны ал, бала.
Мөгаллимнең һәр сүзен
Күңелеңә сал, бала...

Күренмәсне — күрергә,
Табылмасны — табарга,
Югалганны — юлларга
Өйрәтте ул аларга.

Табып бирде тарихны,
Укый-укый ташлардан.
Ул ташларны кемнәрдер
Чокырларга ташлаган...»

Уйлану — аңа яну,
Яңа көн — җан сызлавы.
Иске яраларында
Эри тарих тозлары.

Янгырый күк янавы
Миһербансыз елларның:
— Татар диеп тормамын,
Чалгы булып чабармын,

Тырма булып тырмармын,
Елан булып чорнармын...

Кыйнаганнар, куганнар:
— Җилгә китсеннәр болар,
Бизеп бетсеннәр болар,
Утта янсыннар болар,
Суга батсыннар болар...

Туктаусыз каргаганнар:
— Йорт-җиреңне ягып кит,
Сулар кебек агып кит,
Җиттем дигәч, җимерел,
Куандым диң, куырыл...

Һай, ул бөек таралыш!
Борынгыдан башланды:
Суга батып үлгәнче,
Халык утка ташланды,
Уттан исән калганнар
Далаларга таралды...
Күз алмабыз, күрәсең,
Шул кайгыдан каралды.

Таралган су — тамчы су,
Таралдыгыз, беттегез.
Ятлар назы — камчы ул,—
Тагын нәрсә көттегез?!

Талаучылар, билгеле,
Бар асылны сайлыйлар...
Ярый әле бу жирнең
Урланмаган Ае бар!

Талаучылар суырып
Иманыңны алалар...
Баш куйдыгыз кылычка,
Бирмәс өчен, балалар!

Сорыйк, әйдә, Иделдән:
Сезме илдә җиңелгән!..

Асылынып үлдегез,
Китмәс өчен бу жирдән.

Ил таланып таралса —
Ташларына куй башың...
Бәхетеңне табыша
Урланмаган Кояшың!

Карачкының йөзендә
Канлы еллар тузаны:
— Кайтыр балаларына
Халык күпер сузамы?
Берәр кеше узамы? —
Сагынып карап тора,
Сызланып санап тора,
Йөрәге канап тора...

## Шигърия фал ачты

Чын исемен аның белми авыл,
«Карачкы» да һаман «Карачкы»! —
Ашыкмагыз, нидер табар кебек,
Шигърия үзе фал ачты:

«...Яшь чакта ул Төрек Садыйк булган,
Төрек кызын сөйгән — бусы бер.
Икенчесе: Караком чүлләре...
Мари урманнары...
Һәм Себер!

Гомерләре сак астында узган...
Таң алдыннан тыңла һәр көнне:
Иле белән ире яклый алмый,
Сөю җәлләп елый Әменне[1]...»

Төрек кызы — мондый җәза күргән
Хатын-кызның жирдә соңгысы.
Сөюнең дә туган иле булсын,
Үтерә юкса сагыш сөңгесе...

Ә Карачкы йөзгә житеп килә.
Әменне ул һаман сагына.
Улын эзли... Тукта! Үзе сөйләп
Бирмәс микән, көтик аз гына.

## Карачкының сугыштан кайтуы

Сөякләр сибелгән юллар,
Һай, озын икән алар.
Башыңны жир читләренә
Житкәнче озаталар.

Ачлыктан котылгач, озак
Йөдәтте ирнем кибеп.
Күлләре ямьсез боларның,
Керфексез күзләр кебек.

Чүлләрне уздык. Байларга
Эт булып ялланмадык.
Бетле вагоннар шикелле
Әҗәлгә ялганмадык.

Жыйнады Кызыл Армия
Үзенә солдатларын:
Су түгел, ком эчтек... Кичтек
Гасыр гарасатларын.

Шөкер, дөньяда үләргә
Өйрәндек инде менә!
Өйрәнәсе калды хәзер
Бары яшәргә генә...

---
[1] Төрек кызының исеме.

Карамадым яулар салган
Яралар сызлавына,
Көндәш алып кайттым беркөн
Авылым кызларына.

Туган җиргә йөрәк кайтты,
Авылыма — яшь килен.
Үзем инде бары әнкәм
Өчен генә яшь идем.

Ул чакта ук иңгән иде
Карачкы чалымнары,—
Мәхәббәт матурлагандыр,
Күзгә бик чалынмады.

Сабан сөрергә кайтабыз —
Эш үтерми кешене.

Үлемнәрдән эш коткарып
Кала безнең ишене.

Яуда егылган атларны,
Гүя, ияртеп киләм,
Һәм сыйлыйм туган якларның
Яшел чирәме белән.

Колны гына эш үтерә,
Без коллар түгел хәзер,—
Эш белән без бар дөньяны
Буйсындырырга әзер.

Димәк, тиздән кылычларның
Кирәге калмаячак;
Кеше үзенең дошманын
Эш белән яулаячак...

## Карачкының туган җиргә ант итүе

Каплаган җиремне яшь үлән.
Миңадыр — намазлык җәелгән.
Сугышлар, орышлар беткәнгә
Дога кыл гөнаһсыз җан белән.

Яшәсен кандагы хәрәкәт! —
Яшәтә үлмичә калганны.
Сугышта төшемә керде бер...
Тугач та таныдым баламны.

Чигенде сугышлар. Күңелне
Үстерде кырдагы уңышлар.
Балалар нәкъ безгә охшаган —
Арышны сагына тумыштан.

Ияреп сабанга чыгалар,
Мең шөкер, туфракта — тәпиләр.
Әтиләр-әниләр аларга
Яшерен кайгыны әйтмиләр.

Икмәкле кырлардан бик озак
Игелек күрергә язмаган —

Җир йоткан шикелле, кешеләр
Югала башлады бер заман.

Бик күпләр
Җаннарны бәйләгән
Туганлык җепләрен өзделәр.
Сукырлар җибәргән әмерне
Төп-төгәл үтәде күзләләр.

Кешеләр күзеннән яшереп,
Атыңа-арбаңа төядең:
Кайларга озаттың, замана,
Иң асыл ирләрнең сөяген?

«Салып кит, тагып кит! Алыгыз!
Канунга буйсынмый каныбыз.
Сеңәрбез, иңәрбез! Барыбер
Менә шул туфракта калырбыз!»

Ил-җиргә табынган ирләрнең
Анты бу. Башка сүз дәшмәдек.
Төннәрен атылган йөрәкләр
Яктысын көн итеп яшәдек.

## Карачкының авылдан сөрелүе

Мине дә төнлә алдылар,
Салдылар казаматка.
Әменне дә теркәделәр
Тагылган яманатка.

Имеш, мин нидер яшерәм,
Имеш, мин Төркиядән
Хатлар аламын. Кыскасы,—
Бигрәк мин төрки адәм.

Хат түгел, кош та узалмас
Иде андый чикләрне,—
Әмен шулай гомерлеккә
Чит җирләргә бикләнде...

Ярымнан, газиз баламнан
Аерып алып, болар,—
Идарә карары белән
Карачкы ясадылар.

Каршына бастырып, палач[1]
Иманны талый тагын.
Иманны ала алмагач,
Җанны сораячагын
Аңладым... Башка әмерне
Ишетми калачак ул,

«Асарга!»— дигәннәренә
Тамгасын салачак ул.

Бер атна эчендә мине
Сөрделәр шундый җиргә:
Ирненә тидерергә су
Булмасын үлүчегә!..

Әй, ялвардым үз-үземә,
Инәлдем иманыма:
— Көч-куәт бир! Егылырга
Ярамый монда миңа.

Монда үлеп, үз халкыңа
Хыянәт итмә, йөрәк:
Коллыктан аны тагын бер
Азат итәргә кирәк!

## Әменнең туган илен сагынуы

Яр буенда,
Тал куенында
Кер бәләкли хатыннар.
Шул хатыннар арасында
Төрек кызы Әмен бар.
— Уйнап түгел, уйлар уйлап
Ага,— ди ул,— суыгыз...
Сәфәр чыккан аякларым
Сынсын, әйдә, сугыгыз!

Көтмәгән идем җәзаның
Мондыен мәхәббәттән,—
Сизми дә калдым, ул мине
Тәмугка тәгәрәткән.
Мине илдән урлап киткән
Мәхәббәткә сугыгыз!
Шомлы ага суыгыз...

Шәмнең — кояшым икәнен
Ул чакларда кем белгән?
Бүлмәмдәге янган шәмне
Бармак басып сүндергән
Яр кулына сугыгыз!
Уйларымны ала-ала,
Кая ага суыгыз?..

Яр сөеп тә сөенергә
Әллә өлгермәдемме? —
Хәсрәтләрем — йөрәгемдә,
Алыгыз йөрәгемне!
Йөрәгемә сугыгыз!
Җырларымны дулкын ала,
Моңлы ага суыгыз...

Ай калка мине сихерләп,
Кагылмый ишләремә.
Ашыга сөйгән яр булып
Керергә төшләремә.
Күз нурымны ала-ала
Ага сезнең суыгыз...
Тулган айга сугыгыз!

Башны су төбенә тарта
Әллә нинди авырлык.
Төшсә әгәр — кешесе юк
Аны тартып алырлык.
Су төбенә төшим дигән
Уйларыма сугыгыз!
Ай-һай, тирән суыгыз...

Дөньямның җылысы калган
Әнкәм учакларында,—
Тәмугка китеп барганмын
Егет кочакларында.
Төенчегемне күтәргән
Кулларыма сугыгыз!
Тынычланыр суыгыз...

[1] Биредә герой хаксызга җәзалаучы төрмәчеләрне «палач» дип атый.

## Карачкының яңа Дәүләт төзүе

Салкын төрмә эчендә
Мин үземә бер Дәүләт.
Казнамдагы байлыкны
Барлап торам берәмләп.
Мыскал да юк алтыны,
Алу-сату тыелган;
Тереләрнең барчасы
Иманыма сыенган...

Димәк, баскан җиремнең
Бар Кояшы, бар Ае,—
Тегесеннән бу Дәүләт
Яктырак булмагае.

Гимны — балам тавышы:
Көләме ул, елыймы?..
Яшәмиләр сабыйлар
Уйнап үлем уены.

Богаудагы абыйлар
Яшәмиләр боегып,
Яшисе бар — тик шуңа
Чак торалар тыелып!

...Бусын инде кешеләр
Яшәрлек итәчәкбез,
Таш диварлар ауганчы
Аны киңәйтәчәкбез.

Башкалардан бу Дәүләт
Шул ягы белән үзгә:
Табарлар иде аны,—
Күренми нурсыз күзгә;

Таларлар иде аны —
Сөюне табып кара!

Ерак булса да ара,
Кош булып очып бара,
Кош булып очып кайта
Әменнән сәлам алып...
Каргармын дигән, үлсәң
Таш асларында калып...

Каргамыйм инде, дигән,
Илемнән аерганга,—
Буялып яши торгач,
Кушылдым сезнең канга...

Бәс, шулай кеше җаны
Дөньяны сыйдыралгач,—
Дәүләтемнең чигендә
Сакчымыни син, палач?!

Имештер, син иректә...
Һәм яшисең кем булып!
...Балам берәр почмакта
Сыенгандыр ким булып.

Яклый алмыйм баламны,
Мөмкинлегем булмагач,—
Ипи тоткан кулына
Сукма аның син, палач!

Халык биргән ипидән
Авыз итсен ул бала.
Ачтан үлсә — хөкемдар
Булып сиңа кем кала?!

Кайтарачак ул сиңа
Яши-яши һәммәсен...
Яшен сукмас микән дип,
Үз-үзеңне җәллә син!

## Әменнең авылдан сөрелүе

Көмеш башак, җәүһәр бөртек,
Ука кебек сабагы.
Ахак саплы урак кулда,
Сары алтын — саламы...

Кырлар шулай төшкә керә
Игеннәр өлгергәндә,—
Башакларның җил ягына
Дулкыны йөгергәндә.

Йөгерә дулкын, йөгерә дулкын,
Йота офык балкышы.

Сугыш бара. Сугыша бит
Хәтта җирнең арышы.

Сугышка китә ипи дә —
Шундый чагы дәвернең.
Үсә... Сөте җитми хәзер
Баласына Әменнең.

Күз нурлары күчә алмый
Баласына — сөтендә.
Шуны уйлап каны кибә
Кызу урак өстендә.

Ерагайды авыл белән
Хәзер басу арасы,—
«Мәм-мәм» диеп, каршы килә
Салам чәчле баласы.

Бер уч арыш яшерде ул,
Күкрәге арасына,—
Кайта. Тормыш алып кайта
Өзлеккән баласына.

Тентеде, тапты. Идарә
Тәмугта яндырачак,
Төпсез киледә жаныңның
Ярмасын ярдырачак!

Жиргә бер уч арыш сибеп,
Уңыш алырга була,
Уңыш алырга була да
Исән калырга була.

Бер уч арыш — хәзер аның
Нәселен корытачак,
Кире әйләнеп кайтканчы,
Баласы онытачак...

Кибәк җилгәргән шикелле,
Авылдан җилгәрделәр:
Башта мари урманнарын
«Урырга» җибәрделәр...

Үз илен төенләп таккан
Шикелле беләгенә,
Тагын төенчек алган ул,
Тагын бәләкәй генә.

Китә Әмен. Күз алдында
Кабына сары шәмнәр...
Һуштан язмасын диептер,
Баласын яшергәннәр.

Өч хатын китте авылдан,
Яулыклар — ап-ак күбек...
Киткәннәрнең бөтенесе
Диңгезгә батты кебек.

...Себердә улын сагынып
Ун ел саргайгач кына,
Кайтып егылды бер көнне
Авылның кочагына.

Тик аның улын да күптән
Килеп алганнар иде,
Кайсыдыр төпсез коега
Илтеп салганнар иде.

Кычкырган диләр: «И балам,
Нәни аллам, син кайда?!»
Һәм мәхәббәт сәфәрен[1] ул
Тәмамлаган шул айда.

## Карачкының бала елавын тыңлавы

Алданрак кайтып үлде Әмен,
Җыеп алды аны каберлек...

Көн дә килә.
Монда яшәсә соң! —
Карачкыга барыбер кадер юк.

Уйларында һәр көн Әмен үлә,
Көн дә җирли, гүргә иңдерә...
Өйгә кайтмый.
Кайтса — әллә кайда
Бала елый, бала илерә.

Әллә нигә ак сыерга охшый,
Авыл күгендәге ак болыт.
Сабыена сөт эчерер иде...
Әллә кемнәр тора сак булып.

Килә-китә болыт. Ак сыерның
Һәрбер имчәгеннән кан тама...
Җирдә тагын Әмен үлеп бара,
Сүзе бардыр — йөзен каплама.

Күргән кешеләрнең күзе канар:
Улын сорый һаман... Йә, нишлик?!
Таш капчыкка бикләп куйсалар да,
Табар иде җаны бер ишек
Һәм юатыр иде кереп улын,
Нәни кулларына нан[2] биреп...
Уе туктап калса Карачкының,
Бала елый башлый илереп.

Шул уйлардан котылырга теләп,
Күккә бага, күзли Карачкы,—
Чиксезлектә йөзгән хәрәкәтнең
Бер тамчысын тотып алмакчы.

[1] Гомерен мәгънәсендә.
[2] Икмәк.

Дәшеп куя:
— Очасыңмы, балам? —
Хәбәр җибәр җаның хакында.
Кеше заты син генәме анда,
Безгә көлгән йолдыз артында?

Нинди затлар анда кыргый калган,
Нindиләре асыл, алдынгы?
Һәр терене гашыйк итә алган
Берәр юлдаш таба алдыңмы?

Кайберләрен җир ягына чакыр,
Гамьнәренә җирнең төшендер,—
Бәлки әле алар баш кисүне
Белми торган гаҗәп кешедер.

Тере гамьнәр белән сөйләшергә
Җиргә төшкәч, бездән өйрәнер...
Хәсрәтләрдән үлгән булыр идем,
Җырламасам әгәр көнгә бер.

Шул гамьнәрме Галәмнәргә алып
Менгән сине — җирнең яфрагын?
Сәфәреңдә яралансаң, олан,
Халкың йөрәгенә кайт тагын.

Иң кыйммәте җирдә — җан җылысы,
Җан җылысы җитми. Туңабыз.
Хәятеңне күләгәләр күмсә —
Каның янсын! Барыбер ут кабыз!

Ә мин монда уйлап торам әле
Үз халкымның җаны хакында.
Халкың кебекме син, улым, анда —
Безгә көлгән йолдыз артында?

Ирекләме анда, мәҗбүриме
Гамәлләргә хисап бирүләр?
Нинди була анда җиңелүләр,
Нинди була анда җиңүләр?

Син әсире булып кемнәрнеңдер,
Ниләрнеңдер булып син колы
Очмыйсыңмы анда? — Үтерерләр
Ике метеор сугып берьюлы.

Кайтып күрен, балам...
Һәм Әменнең
Гүрен капшый:
— Киткән иленә.
Илләренә ничек күчкәнлеген
Кояш белән бары ай белә.

Күчеп беткән шулай.
Үлемнәрнең
Мондыйлары була бик сирәк.
Сагышлардан саргаюны беләм,
Саргаеп та үлү бар, димәк.

## Карачкының палач янына килүе

Палачына килеп ишек шакый:
— Тук-тук!
— Кем бар?
— Бу мин — Карачкың! —
Өйгә керә алмыйм. Бала елый...
Җирдә, күктә елый... Ник качтың?!

Таң вакыты. Татлы йокылардан
Кыен булса булыр уяну,—
Күзләреңне күреп чыгыйм әле,
Ач күзеңне, палач, дөнья бу!

Мине инде кабат күрмәмен дип
Уйлагансың булыр, и надан!
Синең белән әле очрашмыйча
Китүләр юк якты дөньядан!

Исендәдер? Туган җиргә качтык —
Өйрәтелгән эттәй эзләдең.
Хуҗагызга тотып бирде безне
Мин күрергә килгән күзләрең.

Ишегеңне япсаң, тәрәзәңнән
Керергә дә бар шул сәбәпләр,—
Этапларда этләр талаганын
Карап барды синең бәбәкләр.

«Тезлән!»— диген, «Күзгә кара!»— диген
Сүзләреңнең ямьйм эзләрен...
Кешеләрне җирдә кол итүдә
Гаепләнә, палач, күзләрең.

Үз йөзеңне күрү бетте сиңа:
Көзгеңә бак — анда мин торам.
Су төбенә кара — муеныма
Таш бәйләнгән килеш утырам.

Тор! Кием дә киенмәскә мөмкин,
Кием нигә сансыз башыңа!
Гафу үтен, барып егыл тизрәк,
Корбаннарың кабере ташына.

Башың — аяк, кулың — таяк булды.
Ә кыйнаучы — барыбер күзләрең!
Җан юк иде синдә — ләззәтләнеп
Җәзаладың, палач, бездәген.

Тоттың. Тоткын иттең.
Мишеньдәге
Нокта булдык — мылтык төзәдең...

Бөтен дөньям белән бәреп керәм,
Сыйдырсыннар хәзер күзләрең!

...Юк, каласым килми кан эчендә,
Яңа гасыр,
Тизрәк ишек ач! —
Шәүләләре йөри... эзәрлекли
Шымчылары белән шул палач!

## Карачкының таң атканда ишеткәннәре

Кайтышлый ул тыңлап кайта
Читтә калганнарны...
Кемнең елый җаны анда,
Кемнең елый каны:

— Һай, мәхәббәт! Аягым бул,
Кайтыр илләремә.
Җилләр илтеп җиткерәчәк,
Юллап җибәр генә...

— Идәнем — җир, ишегем,— җил
Булса булсын иде,
Тик ил булсын, җаным кабат
Шунда тусын иде...

— Ялгызлык таштан да каты —
Үз иясен ашый,
Әкрен генә бу дөньядан
Тегесенә ташый...

— Сырлар салып маңгаема
Еллар куйды язып:

Ил кайгысы картайтмаса,
Узган гомер — язык...

— Илгә кайтасы атымның
Тояклары ярык,
Җиде оҗмах ишегенең
Капкалары ябык...

— Тел тибрәтсәм — сүзләремне
Кисә ачы сагыш.
Мин — ерактан тавыш биргән
Корып беткән камыш...

— Күзләр күмергә әйләнде —
Танымассың күрсәң.
Ил каргышы буган булыр,
Чит җирләрдә үлсәм...

Пышылдый ул:
— Кемнең читтә
Кайнар яше тама? —
Таң атканда йокламагыз,
Кеше канатлана!

## Карачкының авылдашларын каршылавы

Кем каргаган иде — юл бирегез!
Кара йөрәгегез — тетрәсен!
Бездән туган оланнарның рухы —
Бу дөньяның соңгы төрмәсен
Җимерәчәк әле!..
Чыга халык
Канлы гасыр капкаларыннан.
Җаннар көйгән. «Дошман түгел» дигән
Язуларны аркаларыннан
Трахомалы нурсыз күзе белән
Укып кала тарих-фәхишә,—
Кайсы телдә, нинди әлифбада
Язылганын хәтта белмичә.

Чыга халык
Китаплары янган
Манаралар ауган янгыннан.

Ә җир шары — тереләй янганнарның
Көлен ябынган...

Барысын да таныйм.
Киемнәрдә
Миңа таныш таплар,— кан да кан!
Авылдашлар илгә кайтып килә,
Моңлы тавышлары карлыккан:
— Үзем белән дүрт улымны алып
Яуга киттем. Кайтам берүзем.
Югалтулар шактый гына булды:
Дүрт балам... Һәм тагын бер күзем.

Күкрәк тулы орден-медаль белән
Алып кайттык яңа исемнәр:
Яшьләр хәзер «Сукыр Зәки» диләр,
Дөрес инде, нәрсә дисеннәр?..

— Сагындырды туган илем,
Сагындырды көн саен.
Ташлап китүләрем өчен
Үч алгандыр, мөгаен...

— Шушы җирдә,
Әллә берәр «бүре»
Ачтан егылып үлгән дисеңме?!
Мыскыл итеп калдырганнар безгә
«Халык-сарык» дигән исемне.

«Сарык булма — бүре ашамас», дип,
Борынгылар әйтеп калдырган.
Ә без аны искә төшерәбез,
Сөякләрне күмәр алдыннан...

— Күтәрәмгә калдым. Рәхмәт, авыл,
Арык кулларыңа күтәрдең.
Мин бәхетле. Күтәрерләр иде —
Авыллары үлде күпләрнең...

— Өлешемне, бәхетемне эзләп
Кайтып киләм әле ерактан.
Бездән алган әҗәтләрен язган
Кенәгәсен тарих югалткан.
Ашыбыз да, башыбыз да китте...
Бер түләрбез әле, дигегез.
Хәтерләсәң — хәтәр: авыллардан
Нәрсә алып торган идегез?!

Кенәгәгез юк ителгән булса,
Терелтүе аны бик ансат:
Недоимка кәгазьләрен төпләп,
Заемнары белән тышласак —
Менә дигән китап!..

— Ялагайлар көнен кояшладык,
Фәхишләрнең төнен айладык...
Үзебезгә күмер шахталарын,
Кара урманнарны сайладык...

— Яңа карарлардан курка-курка
Картайганнар безнең хатыннар:
Бала имезергә рөхсәт сорап
Йөриләр күк һаман, факырлар.

Ана сөте юньләп күрмәгәнгә,
Ул балалар илдән таралган.
Алга таба бара алмый торган
Гаҗәеп бер токым яралган...

— Исемлекне алдан төзегәннәр:
Кемгә үлем тиде, кемгә дан...
Кем өйрәтер безне — котылырга
Дөньядагы бөтен коллыктан?..

...Идарәдә исәптә дә тормый,
Карачкының башы башмыни!
Китүчеләр Төнен уздыра да,
Кайтучылар Көнен каршылый.

Илдән адашканнар төркемендә
Төн уздыра әллә кайларда.
Бик тә гөнаһлыга булыша күк,
Җиңелрәк үлем сайларга.

Өнди калганнарын:
— Илгә кайтып
Күмелегез иген эшенә.
Эшен күрсәтмәсә — нинди иман
Иңә алсын икән кешегә?!

Илдә җанга бөтен нәрсә җитә,
Гомер генә бары җитмидер.
Җитмәсә дә — җирдән эшле кеше
Ялкаулардан алда китмидер.

Наемщиклар иле булдык инде! —
Йөремәгез читтә тилмереп,
Яшик әле илгә кан биреп без,
Китсә-китик эштә җан биреп!

## Карачкының оран салуы

Җир түзә ул.
Кеше сөягенә
Тиеп яна безнең табаннар.
Җан сораган бөтен шәһитләргә
Бу гасырда җавап табалмам.

Җавап эзләп үлә алмый йөрим.
Читтән кычкыралар: «Асылын!»
Асылларны эзлим — васыятен
Тапшырырга канлы гасырның.

Җанымдагын
Сезгә тапшырмыйча
Китә алмыйм әле дөньядан,—
Тәмугларга керә-керә кеше
Эзләячәк аны яңадан.

Ул васыятьне җую — соңгы хата,
Туктар ул зат кеше булудан.
Болай да бит кем икәнен белми
Йөрүчеләр белән җир тулган.

Шәһитләрнең дәвамнары булып
Яши алсак кына — ил исән.
«Ә» дигәнче тәмуг тартып ала,
Тартып ала — әгәр җиңелсәң.

Сезгә киләм.
Ә сез, балаларым,
Шикләнәсез, миннән качасыз,—
Кешеләрдән әллә бернәрсә дә
Алганыгыз юкмы акчасыз?

Безнең иман — сезгә!
Шуны сизеп,
Иске дошман кат-кат сискәнде:
Йөрәгемне барлый — атылганмы,
Башны барлый — палач кискәнме?

Минем аша
Сезне барлый шулай,
Сезнең җанны капшый, балалар,—
Ничегрәк сулыш алалар да,
Кая таба, имеш, баралар?

Капшатмагыз башны! —
Табигатьтә
Бар матдәләр безнең яклылар.
Йолдыз булып, яфрак, йә җыр булып,
Ут-су булып сезне саклыйлар,
Саклыйлар!

---

Кыскартылып басылды. *Ред.*

## Акъегет

### Тарала бөтнек исе...

Язгы җил дә түгел бу,
көзге җил дә түгел бу.
Нәрсәдер бер өмет итеп,
соңгы җилпенүме бу?..

Һаваларда кош төркеме,
нәрсә көтүемдер бу?..

### Бар иде дә...

Бар иде дә, юк инде...
Бергә салган сукмагыбыз —
тапталган бер юл инде...

Бар иде дә, юк инде...
Хәтфә болын, сөйгән ярым
бәхил генә бул инде...

Бар иде дә, юк инде...
Янды утлар, сүнде утлар,
урыннары көл инде...

Бар иде дә, юк инде...
Йөрәк — учак көлләрендә
үсеп чыккан гөл инде...

### Бер тойгы

Карашымнан өлгеләрнең
пыяласы уела —
күпме күтәргә була?

Чәчәк аткан иде гөлләр,
инде алар коелды...
Кабына... сүнә... йолдызлар,
кабына... сүнә бер тойгы.

---

АКЪЕГЕТ *(Рөстәм Фәйзуллин) — шагыйрь, 1951 елда туган, «Ак болыт шәүләсе» исемле китап авторы. Казанда яши.*

## Яшьлек

Су белән тулды үзәннәр,
моң белән тулды җаным.
Соңгы бозның кисәгендә
яктым өмет учагын.

Яшьлегем акты бозларда,
төтен калды сузылып.
...Соңгы борылышта ялкын
дөрли яулыгың булып...

## Күзгә аңлашу

Кистереп әйттең сүзеңне,
әйтеп бетердең инде.
Бер ише — яфракны өзде,
бер ише — үзәгемне...

## Бар да уза...

Кайгы-хәсрәт,
бәла-каза,
сагыш-моң да уза...

Бар нәрсә дә уза...

Нинди хозур —
бала-чага
уйнап йөри кузна...

Бар нәрсә дә уза...

Каерылып
кара әле:
гомер-шәм дә сыза...

## Үткәнне көтү

Сагынасы әйберләрне
алгы көннәрдән көтеп,
күзләрен ерак төбәгән
бу беркатлы өметем.

## Яшьлек

Халык диңгезе өстеннән
дулкыннар ярып килә —
җилкәндәй җилкә белән...

## Күңел тыкрыгы

Тәрәзәләр ачылуга,
пәрдәләр — җилкән тагын...
Димәк, вакыт бер барларга
күңелем тыкрыкларын...

## Бәхилләшү

Мин бу җәйдә бераз тоткарланам —
туктап калды күңел сәгате...
Көзгә миннән алдан барып җитсәң,
очар кошка сәлам әйт әле...

❁

*Балачакта берәр әйбер турында хыяллансаң, «кызыл кар яугач»,— диләр иде...*

Ничек ышанып көттем мин
ул карларның яуганын...

Туган җиргә кайтып киләм...
Әллә чыннан яуган инде —
алланды күз алларым...

## Олыгаю

Еланып бетмәгән күз-яшь,
сүнеп бетмәгән хисләр.
Сәях җилләр исеп куйса,
күңелләр иләс-миләс.

Тик шулай да караш бүтән
каенга, карамага,
елга-су, болын-урманга,
күктәге ялгыз айга.

Зәңгәр эңгер булып җанга
туган як моңы иңде.
Элек очып йөрдем микән,—
тоя башладым Җирне!..

## Ник дәшмисез?

Бу хакыйкать инде, хакыйкать!
Ник дәшмисез?

Сез бит беләсез,
болай барса дөнья,
болай барса,
калуың да мөмкин милләтсез!..

Ник дәшмисез,
Сез бит беләсез!..

## Утыз яшь тулгач

*Нишләтер мине бу бәндә? —*
*сорау катыш карап торам*
*көзгедәге сурәтемә.*

Үткәннәр — хәтердә,
киләчәк — хыялда.
Мин — урталыкта:
уйлан да, тукта,
уйланырга тукта!..

❁

Сүз сөйләде дип уйладым,
ул орлык чәчкән икән.
Шул орлыктан йөрәкләрдә
илаһи чәчәк үскән.

❁

Гөрләгән сулар туктаган,
җаным аша ага тоташ,
ага Киек каз юлы...
Күп йөгәнләдем йөрәкне,
чыдап булмас бу юлы...

❁

Кагыл син аңа, кагыл,
ләкин кагыл сак кына.
Күрәмсең аның күзләрен —
алар фәкать җан гына...

❁

Йолдызлар күп ди күкләрдә,
көндез күренми генә.
Күңел күген күрмичә,
бу кеше... гамьсез димә.

❁

...Хәтергә килә кинәт...
Дуга эчендә ат башы —
рам эчендәге сурәт...

❁

Йолдыз тора атылырга
суы тонган коега...
Уй да шулай,
форсат көтеп,
җан күгендә оеган...

❁

Агымсулар тып-тын агып,
чүеп куя балыгын...
Белә микән шушы сулар
керфегемдә
бер тамчысы барлыгын!?.

❁

Талгын гына яңгыр ява.
Тарала бөтнек исе...
Бер яңа яра төзәлде,
тик яңарды искесе...

❁

И ашкына да бу күңел!
Беренче вагонга утырдым,
тизрәк кайтырмын кебек...

❁

Колак астына
кулын куеп яткан —
матур төшләр күрә, күрәсең...
Бер гөнаһсыз уйларын да беләм,
ә күңеле менә тирән сер...

❁

Кем ни белән яралы бит...
Күңел бәйдән ычкынган.
Ут булып дөрләп кабындым
бары бер сүз-очкыннан...

## Анатолий Шавкута

# АХШАМ КҮЛӘГӘСЕ

хикәя



Птицынның элекке директоры бәйләнчек һәм эчпошыргыч бер адәм иде. Аның шул яман холкына иярләшкәнчегә кадәр Птицын шактый җәфа чикте, бик күп йокысыз төннәр үткәрде, ашказаны белән интекте. Ниһаять, ияләште.

Кайчак алар икесе — директор һәм аның урынбасары Птицын — коридор буйлап бергә үтәләр, ябык һәм борчулы йөз, караңгы чырай, нәрсәнедер өнәп бетермәгән төксе кыяфәт белән барча хезмәткәрләрне өнсез итәләр иде. Тегеләре исә күзгә-башка чалынмаска тырыша, болардан читкәрәк тайпылу ягын карый. Югыйсә, әгәр күреп алсалар, беттең: акыл өйрәтергә, вәгазь укырга керешәчәкләр. Сез, ягъни мәсәлән, эш кәгазьләрен тутыру тәртибе турындагы соңгы күрсәтмәне беләсезме? Ә, юкмыни?! Ул чакта бер-бер артлы ике хата җибәрүегез бер дә гаҗәп түгел.

Директор һәм аның урынбасары һәрбер күрсәтмәне, һәрбер инструкцияне яттан беләләр һәм үзләренең шул күп белүләре белән җелегеңә төшәләр иде. Синең эш язуыңда инструкциягә туры килмәгән берәр нокта була икән — үзеңә үпкәлә: кәгазеңне укып та тормыйча кире борачаклар, кул куймый йөртәчәкләр, үзәгеңә үтәчәкләр. Бар, бәхәсләшеп кара син алар белән!

Акыллы кеше кулына кергән инструкция, беләсегез килсә, ерып чыккысыз карурман, һичничек алып булмаслык ныгытма, теләсә кемне аяктан егарлык корал ул. Кайбер җүләр һәм исәр башлар инструкция укырга яратмый: имеш, укуы кызык түгел. Һе, укый белеп укысаңмы?! Ничек кенә кызык әле! Птицын, мәсәлән, элекке директорына меңмең рәхмәтле булып калды: Сан Саныч инструкцияләрне уку һәм куллана белү осталыгына, эшләү һәм яшәү осталыгына өйрәтте аны.

Шулай да, ни генә булмасын, бәйләнчек кеше белән эшләү җиңел түгел инде ул. Птицынның да Сан Санычтан тәмам туйган чаклары күп булды. Кайчак шулай кемнедер эшеннән алырга яки эшкә урнаштырырга уйлыйлар. Ә шул мәсьәлә хәл ителгәнчегә кадәр мең төрле ният, мең төрле сүз булачак, бер фикер кырык тапкыр үзгәрәчәк. Алыргамы бу кешене эшкә, әллә юкмы? Калдырыргамы кешене үз урынында, әллә калдырмаскамы? Берьюлы, бер уңайдан гына хәл итеп булыр кебек тоелган мәсьәләне дә атналар-айлар буена сузалар, үзләрен дә тинтерәтеп, башкаларның да башын әйләндереп

бетерәләр. Җитмәсә, Птицынның гадәте шул: эштәге нәрсәләрне эшендә генә калдырып кайта белми, хатынын, туган-тумачасын борчып бетерә, киңәш-табышка аларны да китереп куша. Йокларга ятса — шул хәл ителәсе мәсьәлә аңа йокы бирми. Иртән торса — башына янә шул уй кереп кунаклый һәм Птицын, исәрлеккә чыккан кеше сыман, иртә-таңнан миңгерәп йөри.

Птицын да, директор кебек үк, киемнең төссезен, күзгә-башка ташланып тормаганын кия иде. Мондый киемнең кулай булуы главкада узган техник киңәшмәләрдә аеруча нык сизелә: башкалардан бернәрсә белән дә аерылып тормыйсың, җитәкче иптәшләрнең күзенә чүп булып кермисең. Андый киңәшмәләрдә Птицын каядыр читкә, еракка, билгесез бер ноктага төбәлеп утыра һәм, сүзнең ни турында баруын да аңлап бетермәстән, «Әйе, без тырышырбыз...» дип директоры артыннан кабатлый. Ул беркайчан да үзлегеннән генә уйлый алмый, бернәрсәне дә үзе генә хәл итә алмас кебек иде.

Кайчак аны үзенең гаугалы холкы һәм яман усал тавышы белән дан алган, кемнедер тиргәп һәм каргап ташлауны чүпкә дә санамаган идән җыештыручы хатын күреп ала, институт коридорында туктатып, яңа себерке яки чүпрәк сорап тавыш кубара. Андый әйберләрне сораганда урынбасар янына гариза тотып керү кирәклеген бары тик үз тәрбиясезлеге һәм наданлыгы аркасында гына аңламаган бу хатынга да Птицын «Без тырышырбыз... Тырышачакбыз...» кебек сүзләрне кабатлый, күзләрен яшереп, читкә таю ягын карый.

Кыскасы, Птицынның газиз гомере ялкау көтүче иңенә салынган чыбыркы сыман арттан сөйрәлә, эзсез һәм төссез үтә иде.

Менә шул рәвешле яшәгәндә аның язмышында яңа директор пәйда булды. Аны, Первенцевны, элекке директор белән чагыштырып та булмый иде. Хәрәкәтчән, киң колач белән эш итүчән. Карашы — хәнҗәр, үтәли төбәп карый. Теләсә нинди мәсьәләне кабыргасы белән куя, берьюлы, бер сулыштан, хатасыз һәм төгәл хәл итә. Иң мөһиме — беркемне дә изеп, басып тормый: эшне ничек һәм ни рәвешле башкаруны һәркемнең үз ихтыярына калдыра. Үзләре хәл итеп, үзләре башкарсын. Аңа эшнең нәтиҗәсе кыйбат. Юк, ул үз хезмәткәрләрен бишектә тирбәтергә дә, эшкә соңга калып килүчеләрне тикшереп йөрергә дә җыенмый. Үзләре белеп, үзләре хәл итсеннәр, эшнең нәтиҗәсе генә булсын.

Яңа директор үзенең эшендә дә, хезмәттән тыш вакытында да гаҗәеп серле һәм күтәренке бер тормыш белән яши иде. Аның бар дөньясы соклану катыш гаҗәпләнү белән тулган, сагышлы һәм шатлыклы мизгелләр белән бизәлгән. Кая булса да командировкага барып кайтса, шунда ук киңәшмә сыман бер нәрсә уздырып ала, үзе күреп кайткан яклар, үзе ишетеп белгән яңалыклар турында җанланып сөйли. Аның әнә шул җанлы тәэсирле хикәятен тыңлап утырган Птицын бу мизгелдә кабинеттан очып чыгып киткәндәй була; әйтерсең, ул да директор күреп кайткан урыннарда йөри, дөнья гизә, кояшта янып каралган, дәрте һәм дәрманы ташып торган директоры эзләреннән урап кайта.

Птицын директорның һәр яңа хикәятен йотлыгып, онытылып тыңлый һәм аның артыннан оҗмахка да, тәмугның үзенә дә барып керә алыр сыман иде. Чыннан да, чираты җиткән башка хезмәткәрләр белән бергә, Птицын да юлга еш чыга башлады. Директор аларны, берәмләп һәм дистәләп тә, аерым-аерым һәм төркемләп тә, үзе белән ияртә, күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга алып китә иде. Юлга чыгучылар арасында проектлар остасы Зин Шер — Зиновий Шереметов та, яңа полиматериаллар сынаучы Дерябкин да, затлы туйлар тоткасы — главканың элекке башлыгы, картлыктан йончыган, әмма үзенең купшы һәм вәкарь кыяфәтен югалтмаган Ти-

мофей Аристархович Стрельницкий да, шефның сөяркәсе Наташа Сухинечева да, секретарь кыз Зенон да, төрледән-төрле ассистентларның тулы бер өерләре дә була иде. Алар барысы бергә, бер омтылыш белән дәртләнеп, юлга чыгалар, эш барында таләпчән һәм кыю хезмәткәр була беләләр, ә инде ял иткәндә (җаена һәм вакытына карап) уен-көлке, җыр-бию белән шау-гөр килгән үзешчән сәнгать коллективы булып тоелалар. Кая гына барсалар да, алар өчен яңа бер матурлык табыла. Башкаланың тынгысыз мәшәкатьләреннән, троллейбус һәм машина ыгы-зыгысыннан, шәһәрдәшләренең үзара өзмәс-куймас әйткәләшеп һәм орышып алуларыннан арган мәскәүләр өчен һәр сәяхәттә яңа бер дөнья ачыла. Үз дәрәҗәсен бик белеп кенә сөйләшкән тыныч холыклы ирләре, уңдырышлылык алласының үзе булырдай — мул күкрәкле, сусыл иренле, матур тавышлы, йомшак билле, таза гәүдәле һәм алты потлы хатыннары белән дан алган, саф һәм чиста һавасына карбыз, җиләк-җимеш исләре таралган Полтава якларында да йөрде алар. Аксак Тимер оныкларының данын саклаган роза гөлләре даласында, эссе кояшында яндырган һәм агач күләгәсенең дымсу һавасында изрәткән, базарлары белән шаулап, мәчет һәм мәдрәсәләренең гөмбәзләре белән балкып торган Сәмәркандтә да булдылар, анда өч тапкыр баруың Мәккәнең үзендә хаҗ кылуга тиңләшкән затлы каберлек-төрбәләрне дә күрделәр. Латвиягә — латыш халкының тарихи яңарыш чорлары сулышын җуймаган Цесис шәһәренә барып чыктылар, акшарлары кат-кат коелган иске йортларны карап, урыннарыннан йөзәр ел буена купмаган урам ташларына басып, тар һәм серле чатлар буйлап уздылар. Әлеге иске йортлар, әлеге тар урамнар мәңгелекнең янәшәдә генә булуын, вакытның һәрчак хәрәкәттә икәнлеген искәртә, үз гомереңне шул мәңгелек белән чагыштырып карарга мәҗбүр итә. Һәм синең уйларың каядыр еракка — басу-кырлар, әрәмәлекләр, чәчкәле аланнар ягына китә. Ә анда — уйларың йөргән якта — гап-гади бер агач йорт тора; арткапкадан башланган тар гына сукмак сине күл буена алып төшә. Күл өстендә — көймә, көймәдә — балыкчы... Кояшның соңгы нурлары су өстенә ал сукмак сала, шул сукмактан күтәрелгән яктылык үлән сабакларында, агач яфракларында уйный. Тынлык...

Птицын юлда еш йөрде. Хатынын һәм туганнарын кат-кат гаҗәпләндереп, үзе күргән һәм үзе ишеткән нәрсәләр турында мавыктыргыч хикмәтләр сөйләде. Аның сөйләве әлек һәрчак кызыксыз, ялыктыргыч, күңелсез була иде. Хәзер аны сокланып, онытылып, бирелеп тыңлый башладылар. Аһ, ул күргән, ул йөргән җирләрнең байлыкларын бергә туплап булса икән! Алма-Атаның сусыл һәм татлы алмаларын, Байкал күле балыгын һәм Алтайның иркә гөлләрен! Бохараның мәшһүр манараларын, Днепр буйларының иркен кыяфәтен!... Ә Әстерханның карбызлары?! Күз кочагына кергән Батуминың сулап туймаслык татлы һавасы! Илнең бу гаҗәеп могҗизаларын санап чыгар өчен генә дә калын бер китап кирәк булыр иде. Птицын үз күңелендә туа барган әнә шул китапның илаһи битләрен сокланып та, гаҗәпләнеп тә, илһамланып һәм канатланып та укый иде кебек.

Ул үзе дә нык үзгәрде. Эшендә вакланмый башлады, хезмәткәрләргә юк-бар өчен каныкмады. Һәр мәсьәләне үзенең шефы кебек үк төгәл һәм кичекмәстән хәл итәргә күнекте. Нинди дә булса лабораториянең еллык эш нәтиҗәсенә бәя бирү, әгәр кирәксә, һич икеләнүсез читкә кагу хәзер аның өчен бернәрсә дә тормый иде. Теге яки бу хезмәткәрнең язмышын хәл итү дә ул кадәр үк кыен эш түгел икән: монда инде Птицынга моңарчы һич таныш булмаган әллә нинди бер җайланма хәрәкәткә килә һәм акылның кайсыдыр бер почмагында яшеренеп яткан, ата-бабалар тәҗрибәсеннән килгән.

әмма ничектер онытылып, җуелып торган әзер чишелеш калкып чыга; шул чишелешнең хаклыгына, дөреслегенә, бердәнбер булуына ышанасы гына кала һәм аны тудырган сәбәпләрне эзләп ачыклап торуның кирәге дә булмый.

Птицынның өс-башы да нык үзгәрде. Юк, аның киеме артык ялтыравык та, күз явын алырлык та түгел иде. Әмма килеш-килбәте барыбер башкачарак, бүтәнчәрәк иде инде. Үзенә бик килешеп, иңнәренә тигез ятып торган көрәнсу пәлтә; плащ кигәндә — муенында йомшак ефәк шарф, ачык һәм якты төстәге күлмәк; аякта — күн үкчәле ботинка. Гомумән, ул — заманның эшлекле һәм иреклe бер кешесе. Карашы мәгънәле, яктылык сирпеп тора. Адымнары җиңел, ышанычлы.

Әгәр дә берәр бүлек мөдире эшкә үтүкләнмәгән чалбардан килсә, Птицын аны шунда ук өенә кайтарып җибәрергә мөмкин. «Сезнең бүлектәге хезмәткәрләрнең яртысыннан күбрәге — хатын-кызлар. Өс-башыгызны тәртипкә китермәсәгез, аларның хәтере калуы бар...» Андый чакта әлеге дә баягы бүлек мөдире кире өенә чаба, киемнәрен үтүкләп, ялт иттереп килеп җитә һәм аны бу кыяфәттә күргән хатын-кызлар «аһ» итә иде.

Птицындагы бу үзгәреш аның гаиләсен, өйдәге көнкүрешен дә читләп үтмәде. Элек урын-җир әйберләренә, өйдәге җиһазларга соң чиктә битараф булган Птицын хәзер инде, кем әйтмешли, барысын да астын-өскә әйләндерде. Иске обойларны кубарып, стеналарны чәчәкләп-бизәкләп буятты. Ваннасын, су торбаларын алыштырды, краннарның иң яңасын, тутыкмый торган тимердән эшләнгәннәрен куйды. Иске җиһазларны яңартты, хуҗалык кибетләренә көнаралаш диярлек чапты. Фатирын ремонтлаткан кеше бу эшнең ни бәрабәренә башкарылуын яхшы белә: ун тапкыр алдап, кырык тапкыр төп башына утыртачаклар; акчаңны алдан алып, килми йөреп интектерәчәкләр; дефицит әйберне өчләтә хакка бирәчәкләр, җаныңны мең кат йолып, адәм мәсхәрәсе итәчәкләр. Бу коточкыч мәшәкатьләр тавын Птицын ниндидер бер күтәренкелек белән, бер сулыштан, бер талпынудан яулады. Үзенә бирелгән һәр мөмкинлектән файдаланып акча тапты: лекцияләр укыды, ялкау студентларның диплом эшләренә рецензияләр язды... Шул ук вакытта үз белгечлеге буенча иң соңгы яңалыкларны туплаган картотека төзеде: биш мең карточкадан торган «фән сарае» белән эш итүдә үз ысулын булдырды. Эштә дә һәр көнне ике-өч сәгать вакытын фәнни һәм техник әдәбият укуга багышлады. «Төп хезмәт — уку һәм белем туплау,— дип фикер йөртте ул.— Ә калган эшләр белемеңне куллану дип аталган бер мавыгу гына. Безгә белемле кешеләр кирәк...»

Әлбәттә, кайчакларда, бигрәк тә беренче айларда, аңа болар барысы да ниндидер бер уен гына булып тоела иде. Әйтерсең, шушы сәер һәм серле, мавыгулы һәм могҗизалы дөньяда Птицын үзе түгел, ә бәлки бөтенләй бүтән бер кеше яшәп ята; әйтерсең, Птицынны аның үзеннән бик күпкә аңлырак, акыллырак, бәхетлерәк, көчлерәк һәм сәләтлерәк башка берәү белән алыштырып кына куйганнар.

Чит шәһәргә баргач, шеф ресторанга керергә ярата иде. Юк, анда керүнең максаты эчеп исерү дә, ашап кына чыгу да түгел. Рестораннар да, музей һәм театрлар кебек үк, шәһәрнең чын йөзен чагылдыра — шеф шулай дип исәпли һәм ресторанга йөрүенең сәбәбе дә шул иде. Андый чакларда ул үзенең таныш-белешләрен һәм, һичшиксез, хатын-кызларны дәшә, табын артында һәрвакыт көләч, ягымлы, билгеле бер дәрәҗәдә юмарт та була. Аның табындашлары ашап-эчеп кенә утырмый, чын-чынлап күңел ача, бәйрәм итә, фикер осталыгын һәм тел җорлыгын таләп иткән сүз уенында көч сыныша, үткен сүзләре белән ыспай официантларны шаккатыра. Официантлар да аларны һәрчак ачык йөз белән каршылыйлар,

үзләре дә сизмәстән, бу шау-шулы төркемнең уенына кушылып китәләр, үз хәйләләре, үз уеннары белән уртаклашалар. Еш кына шулай була: кызып барган бәйрәмне кыл уртасында өзеп, әчесенә дә, төчесенә дә бай табынны вакытлыча калдыралар да, шәһәр читендәге подвалларның берсендә урнашкан мәйханәгә китеп баралар; анда, шушы борынгы һөнәрнең серләре турында кыска гына лекция тыңлап, иң татлы шәраблардан авыз итәләр, аларның төсен, исен чагыштыралар, таза имән мичкәләр өстенә утырып, авызы җиз кувшиннардан эчәләр. Ә аннан соң, нниндидер бер билгесез чакыру авазына буйсынып, шәһәрнең икенче башына — музейлар, гыйбадәтханәләр урнашкан якка ашыгалар, нинди дә булса бер соборга кереп, хор тавышын, унбишенче гасыр музыкасын тыңлыйлар, җанның мәҗүсиләрчә табынуын, каядыр күккә ашарга теләп талпынуын, балкуын һәм яктыруын тоялар.

Ә инде иртәгәсен алар җаваплы оешмаларның кырыс коридорында һәм кабинетларында эш мәсьәләләрен хәл итәләр. Тәртип шул: һәрнәрсәне тиз һәм төгәл хәл итәргә, һәр эшне күп сүз сөйләшеп тормыйча, вакланмыйча һәм вакчылланмыйча, бернинди ыгы-зыгысыз башкарып чыгарга! Әйткән сүз — аткан ук!

Шеф джаз музыкасына гашыйк иде. Джаз уен коралларының кеше авазына охшаш аһәңнәре аңа чын ләззәт бирә, җанын иркәли. Әлбәттә, моннан тыш ул рок музыкасының шашынуларын да, блюзның өзгәләнеп сагышлануын да яратып тыңлый. Әмма джазны ул аеруча якын күрә. Джазга үсмер чактан ук тартылуын яки бу музыканың тарихын сөйли башласа, шефның күзләрендә очкыннар кабынып китә.

Птицын да моңарчы джазны беләм дип уйлый иде. Әмма музыкада нинди дә булса фәлсәфә булуын ул башына да китермәде. Ә менә шеф шушы музыкадан фәлсәфә таба, ул гына да түгел, шул фәлсәфә кануннары буенча яши, дөньядагы бик күп нәрсәләрне әлеге кануннарга бәйләп аңлый һәм аңлата.

Джазның иректе фәлсәфәгә корылуы, тар һәм кысан кануннардан азат булуы ошый иде аңа. Монда һәр башкаручы көйне үзе теләгәнчә, үзенчә уйный ала, шашынган хисләр һәм шатлык-сагышлар дәрьясында җилкән киерүне аңа Аллаһы тәгалә үзе язган дип уйлый. Шефны джазның тарихы да, аңа бәйле һәртөрле вакыйгалар да гадәттән тыш кызыксындыра һәм дулкынландыра иде. Җитәкләп йөртүгә мохтаҗ булган, әмма музыканы чын йөрәктән тойган сукыр Джеферсон һәм ду килеп котырынган тынгысыз Сидней Бише, тыныч холыклы, тыйнак, оялчан Джоплин һәм Яңа Орлеан шәһәренең чүплекләрендә аунап үскән тимер яңаклы малай — кол әбисенең һәм кол бабасының бөек оныгы, барлык чорларның иң яхшы җырчысы һәм музыканты даһи Луи Армстронг... Шеф алар турында сәгатьләр буена сөйли ала иде. Бервакыт шулай командировкага баргач, яшьлек хатирәләренә бирелепме, шеф рояльдә уйнап күрсәтте һәм Птицынны чын-чынлап таң калдырды. Юк-юк, Птицын гаҗәпләнеп кенә калмады, аны ниндидер бер көтелмәгән сискәнү, тетрәнү хисе чолгап алды: кайчандыр музыка юлыннан кереп китмәгән шеф үзе өчен бик күп нәрсә югалткан, ә инде музыкада тойган фәлсәфәсен күңел юанычы өчен генә калдырган кебек тоелды аңа... Шефның музыкага кагылышлы фәлсәфәсендәге бер фикер Птицынны аеруча җәлеп итте. Негрларның хезмәт турындагы җырлары хакында сүз башлаган шеф, үзе дә сизмәстән, аларны рус халык җырлары белән чагыштыра башлады, «Эй, ухнем!» кебек берничә җырны көйләп күрсәтте, аннан соң Африка халыкларының иҗтимагый аңы турында фикер йөртергә кереште. Әйтик, аларда — африкалыларда — җәмгыять һәм шәхес төшенчәләре аерылгысыз бәйләнгән, «минем өем» дигән сүз «безнең өй» сүзе белән тәңгәл

яңгырый: бала туса да, кеше үлсә дә, туй үткәрсәләр дә — барысы да уртак шатлык, уртак кайгы белән яши. Гел көтмәгәндә, ләкин бик нигезле итеп, шеф кабаттан үзенә, үз тормышына әйләнеп кайта һәм әле шушы шартларда да жуелып-югалып бетмәгән шәхси «мин»е турында сүз кузгата. Птицын аңлады: җанына-тәненә джаз музыкасы сеңгән, баш-аягы белән интеллигент булган һәм башкалар алдында үз дәрәҗәсен бик белеп сөйләшкән бу кешедә гап-гади авыл малаеның җаны сакланып калган, джаз аның өчен каяндыр ерактан, читтән килгән олы бер мавыгу булып әверелгән. Птицын да үзенә нинди булса да бер мавыгу, шөгыль табарга теләде. Шушы теләкнең каян, кайчан һәм ничек барлыкка килүе турында уйланганда үзе өчен гаҗәеп бер ачыш ясады: аның уйлары, тирә-юньне кабул итүе һәм аңлавы һаман-һаман катлаулана бара, ул үзе дә камиллеккә, матурлыкка күбрәк омтыла, яхшылыкка тартыла икән бит.

Птицын йог системасы белән шөгыльләнергә булды. Беренчедән, умыртка сөяге үзен сиздереп тора, авыртып-авыртып киткәли; аның бер танышы шулай гап-гади йог күнегүләре белән дәваланды. Икенчедән, йог белән бүлмәдә, өйдә генә дә шөгыльләнеп була, ә Птицынга йөгерү, сикерү кебек күнегүләр бик үк хас түгел — ялкаулыгы комачаулый иде. Һәрхәлдә, йог күнегүләре кан йөрешен тизләтә икән — моны шеф үзе шулай аңлатты, Птицын аңа ышана иде.

Күнегүләрнең нәтиҗәсе Птицын үзе көткәннән дә уңышлырак булып чыкты. Ни генә әйтсәк тә, кеше үз организмын бик начар белә икән. Без — дөньяга килүебезнең беренче минутларыннан алып соңгы мизгеленә кадәр һава суларга яралган җан ияләре — дөрес итеп сулый белмибез, тирән сулыш дигән нәрсәнең файдасы турында уйларга да, аңларга да теләмибез. Ул гына да түгел, бу дөньяны бәйрәм итеп кенә кабул итәбез дә, аның тоташ көрәштән торганлыгын онытабыз, үзебезгә янаган һәрнәрсәдән — уңышсызлыклардан, авырулардан, җиңелүләрдән куркып яшибез, үзебезне сәләтсез дип уйлап, килеп туган хәлне үзгәртеп карарга да кыймыйбыз... Ялгышларыбызны һәм хаталарыбызны язмышка кайтарып калдырабыз, якыннарыбызга сылтыйбыз. Без — артык тәкәббер һәм тиз үпкәләүчән адәмнәр —нәфрәт һәм көнчелек хакимлегенә тарган вактан-вак җан ияләре. Дөньядагы хәлләргә күз йомып яшәгән, язмыш тәгәрмәче астына үзе үк барып кергән һәм шуннан котылырлык җай тапмаган кеше соң дәрәҗәдә көлке һәм кызганыч. Андый кеше үзен гаиләгә, хезмәткә бәйле дип уйлый, шушы йөкне үз җилкәсенә үзе үк төяп куйганын, үзенең ирекле икәнен оныта.

Боларның һәммәсен дә Птицынга шефы сөйләде һәм ул аның һәр сүзен, һәр фикерен ышанып тыңлады. Йог күнегүләре турындагы калган белемнәрне китаплардан һәм төрледән-төрле кулъязмалардан алды. Әлеге китапларны укыганда Птицын нинди дер бер сәер дөньяга сәяхәт кылды: әйтерсең, ул моңарчы бөтенләй яшәмәгән, ә бәлки илаһи һәм якты бер тарафка — бәхет тарафына юл чыгу өчен әзерләнеп кенә тереклек иткән. Башта ул иң гади күнегүләргә тотынды, иртән дә, кичен дә даими шөгыльләнде. Өйдә чакта да, командировкада булса да, Птицын бер генә көнне дә әрәмгә үткәрмәде. Тиздән ул катлаулырак күнегүләргә күчте, аякларны бөкләп, умыртка сөяген турайтып утыру, үз организмы белән идарә итәргә тырышу аның өчен нинди дер бер зарури таләп, котылгысыз ихтыяҗ булып әверелде. Әгәр үз хезмәткәрләренең кырын һәм шикле карашларыннан курыкмаса, Птицын бу шөгылен эштә дә дәвам итәр һәм, мөгаен, бер ай буена өзлексез күнегүләрдән соң гәүдәсе өстеннән йөк машинасы узудан да курыкмас иде. Моның өчен бары тик мускулларны соң дәрәҗәдә йомшарта, йоклата белү һәм аңыңны бу фани дөньядан аерып тора алу кирәк. Чыннан да, үзенең

исереклеге аркасында автобус астына барып кергән һәм аның тәгәрмәчләрен үз гәүдәсе аша үткәргән теләсә кайсы агай әлеге тәгәрмәчләрнең коточкыч авырлыгын сизми дә кала, үз тәне күтәрергә тиешле авырлык турында уйларга да, ишетергә дә, белергә дә теләми; аягына кире торып баскан чакта аның күңелендә сүнмәс-сүрелмәс бер өмет — бүгенге бәйрәмне һичшиксез дәвам итү өмете генә була. Авария вакытындагы травма нәтиҗәләрен аның баш миенә нәкъ менә шушы халәте үткәрмичә кала. Бу нисбәттән, рус җиренә хас «йог күнегүләре» бик күптәннән кулланылган дип исәпләргә кирәк. Һәммәбезгә бик яхшы билгеле булганча, әлеге үзенчәлекле күнегүләрнең асылы ике-өч көн буена «ычкынып» торудан һәм айнык кешеләр аңына барып җитәрдәй тышкы тәэсирләрне бөтенләй бар дип тә белмәүдән гыйбарәт.

Птицынның гәүдәсенә егетләр сыйфаты керде, корсагы тартылды, мускуллары ныгыды, җилкәләре тураеп китте. Ул һәр сулышыннан шатлык табып яши, сабыйлар йокысы белән изрәп йоклый, ә күргән төшләре балачакның татлы һәм матур төшләрен хәтерләтә иде. Ул салкын тию һәм грипп кебек нәрсәләрне үз тәненнән куып чыгарырга, чирне-сырхауны бергә-бер торып җиңәргә, үз организмын теләсә кайсы вакытта эшкә җигәргә өйрәнде. Кирәк икән, барлык ихтыярын һәм игътибарын туплап, тәненең туңган өлешен җылыта, теләсә кайсы урындагы авыртуны баса ала иде.

Кыскасы, тормыш юлыннан ул бәхетнең үзе белән җитәкләшеп атлый башлады. Бервакыт алар, шеф белән бергәләп, көньякка командировкага бардылар, шунда фоторәсемгә дә төштеләр. Икесе дә кояшта каралган, икесе дә бәхетле елмая, икесе дә бер-беренә бик тә охшаш. Башларындагы юка җәйге кәпәч тә, изүләре ярым ачык һәм җиңнәре сызганулы «Винстон» күлмәге дә пардан иде. Икесе дә бик яшь күренә — утызлардан әле чак кына узган, ә үзләре — фәннәр кандидаты (шефны инде тиздән фәннәр докторы дияргә була), зур гына гыйльми җитәкчеләр... Ни генә әйтсәң дә, фоторәсем искиткеч шәп чыкты. Бу рәсем аларның хәл-халәтен бик тә ачык чагылдыра иде. Истәлек өчен төшкән әлеге фоторәсемне Птицын үзе дә бик яратты һәм, һич тә озакка сузмыйча, ихлас зәвык белән эшләнгән рамга беркетте, эш өстәле каршындагы стенага элеп куйды. Кызыл агачтан ясалган, сырлы-сырлы аяклары белән балкып торган өстәле янына килеп утырса, Вольтер заманнарыннан калган иске һәм затлы кәнәфигә кереп кунакласа, стенадагы рәсемгә күз төшерә, шефны һәм үзен күреп, елмаеп куя, көньякта йөргән чакларын искә ала, тәнендә — көч, җанында дәрт-дәрман артканын тоя.

Әйе, билләһи, гаҗәеп һәм искиткеч дәрәҗәдә матур иде Птицынның тормышы. Кайгылардан өстен, борчулардан азат булган бу тормыш каядыр ерак-ерак офыкларга төбәлгән иде...

Шефны алардан алдылар да, аның урынына яңа бер директорны — Бурбонны китереп куйдылар. Монда инде Птицынның ниләр кичергәнен, нинди уйлар һәм газапларга тарыганын сөйләп тору кирәк микән?

Бурбон аларга каяндыр югарыдан, министрлыктан күчеп килде. Канәгатьсезлек билгесе чәчрәп торган кыяфәте белән коридордан бер генә үтте — кызыксыну хисенә ияреп чыккан хезмәткәрләр шунда ук үз бүлмәләренә кереп бикләнделәр. Бурбонның (бу кушаматны аңа беренче көнне үк тактылар) бөтен коридорны иңләп барган калын туны да, артык эре, артык һавалы кыяфәте дә әллә ничек сәер, килбәтсез, ияләнелмәгән һәм ияләшеп тә булмас, аңлашылмас бер нәрсә кебек иде. Машинага утырыр алдыннан ул башта шул калын, иләмсез тунын сала, аны арткы утыргычка ташлый, аннан соң гына үзе кереп урнаша. Менә шундый иде аның туны...

Кырыс һәм килбәтсез бу кешенең даны беренче көнне үк бөтен институтка таралды. Бурбон, ниндидер бер гаеп табарга теләгәндәй, гел кәгазьләр арасында актарынды, үз янына кергән хезмәткәрләрне каш җыерып кына тыңлады, һәрбер сүзгә, һәрбер җавапка каныкты, ишек катында бастырып тотты, ярты сүздән бүлдереп, кире борды. Әйтерсең, аның каршында үзе кебек үк кешеләр түгел, ниндидер вак җан ияләре, игътибарга лаек булмаган түбән затлар басып тора иде.

Бу хәлгә Птицын аеруча нык көенде. Җитмәсә, үзенең өнәмәвен һәм дошман күрүен алдан ук белдерергә теләгәндәй, Бурбон аны үз янына чакырырга ашыкмады. Ә бу инде коллективта шефтан соң беренче кул булган кеше өчен бер дә шатланырлык хәл түгел иде...

Птицынның кулыннан эш китте, инде тәмам онытылган, искә дә төшеп карамаган ашказаны кабат борчый башлады, яшисе дә килми, яшәүдән мәгънә дә юк кебек иде.

Бурбон белән беренче тапкыр очрашасы көнне, нәкъ менә аның кабинетына керер алдыннан гына, Птицын элекке шефы турында уйлап утырды. Ниндидер йомыш белән кергән хезмәткәр кыз Вика да, аның уйларын сизгәндәй, шеф турында сүз кузгатты:

— Ә аның чәйгә пешкәнен хәтерлисезме? Безнең бүлмәдә! Хәтерләмисезмени?! Без ул чакта көлә-көлә хәлдән таеп беткән идек...— Виканың күзләре балкып, йөзләре алсуланып китте.— Нигәдер безнең бүлмәгә кергән иде ул. Ә без чәй эчеп утыра идек. Аңа да чәй ясадык. Безнең чәебез суына башлаган иде инде. Ә аңа кайнарын, кайнап торганын агызып бирдек. Бер йотты да, башын чайкап җибәрде, түзәлмыйча, капкан чәен кире өреп чыгарды, туп-туры безнең өскә, кәгазьләр өстенә өрде! Шундый курыктык, эләгәчәк инде безгә хәзер, дип уйлыйбыз. Ә ул көләргә тотынды! Без дә аңа ияреп көлешәбез. Әйтәм бит, көлә торгач, хәлдән таеп беттек. Аннан соң да шактый озак көлешеп, сөйләшеп утырдык әле. Аңа чәйнең яңасын ясадык, ә ул безгә Һиндстанга баруы, анда күргәннәре турында сөйләде...

Птицын үзе Виканы тыңлый, ә үзе сагышлы уйлар эчендә утыра иде. Шефның никадәр гади, гадел һәм акыллы кеше булуын уйлап куйды. Әйтик, менә шушы хатын-кызларның да хәленә кереп, кайгыларын да, шатлыкларын да, нинди борчу-мәшәкатьләр белән яшәүләрен дә үтәли күреп, аңлап һәм белеп тора иде бит ул. Кирәк чакта ярдәм итә, булыша, беркемне дә рәнҗетми. «Хатын-кыз өчен, дускаем, җаныңны ярып бирә белергә кирәк. Алар белән соң дәрәҗәдә ягымлы һәм ихлас бул. Эшең никадәр генә мөһим булмасын, хатын-кызны онытма, үзеңне тулысынча аңа багышлый бел. Әгәр шулай итмәсәң — беттең, җиңелдең дигән сүз: синең тарафтан бер тапкыр фальшь сизгән хатын-кыз бүтән беркайчан да сиңа чын күңелдән ышанмый. Бу таләп рыцарьлардан ук килә. Мәхәббәтне нәкъ менә алар уйлап тапкан. Алар хатын-кызга табынуларын Шәрыкның кануннарына — хатын-кызны ләззәт чыганагы итеп кенә караучы кануннарга каршы куйганнар. Без, һәрхәлдә, рыцарь булырга тиеш...»

Шеф гаҗәеп бер кеше иде. Һәрнәрсәне бер җепкә бәйләп, бер төенгә төйнәп аңлата, тарих күзлегеннән карап, үз хисләре белән җылытып сөйли иде. Аның белән эшләве рәхәт, күпме ишетеп тә туйдырмаган сүзләрен тыңлавы рәхәт иде.

Шеф турында татлы истәлекләргә чумып утырган Птицынны нәкъ менә шул чакта Бурбон янына чакырдылар. Әлеге хәбәрне ашыгудан сулышы кысылган секретарь кыз җиткерде:

— Яңа директор чакыра! Бик кәефсез күренә...

— Сезнең ул директорыгызның кәефе булган чагы да юк! —

дип коры гына җавап кайтарды Птицын. Секретарь кыз үпкәләде:

— Ничек инде «сезнең директорыгыз»? Сезгә ничек булса, безнең өчен дә шул кадәр генә «безнеке» ул, беләсегез килсә!..

Әйе, институтта Бурбонны беренче көннән үк яратмыйлар, күралмыйлар иде. Сәламенә күрә җавабы!

Птицын, ияләшкән гадәт буенча, өс-башын рәтләп сыйпады, җиңел генә атлап, башын югары тотып, директор кабинетына барып керде.

Аның каршында, кулларын як-якка җәеп, өстәл кырыена нык тотынып, авыр, усал карашлы, куе һәм керпе чәчле бер адәм утыра иде.

Птицынның күз алдыннан бер мизгел эчендә шундый күренеш үтеп китте: алар, шеф белән бергә, Алтай якларында йөриләр, елга ярыннан ук башланган калкулыкка күтәрелеп киләләр. Елганың теге ягында, егерме чакрымнар ераклыкта, урман башланып китә. Агач бөдрәләре үзара тоташкан, әмма каен кәүсәләре ап-ачык булып, аерылып, күренеп тора — көн шундый аяз, һава шундый саф. Күзгә кебек тигез су өстендә кечке болытлар йөзә. Офыктан төшкән кызгылт нурлар шул болытлар арасында уйный. Су өстендә зур-зур роза чәчәкләре йөзеп бара кебек. Аста, яр буенда, ярымтүгәрәк ясап тезелгән халык җыр суза. Баян уйный, җыр тавышы еракларга тарала, елга да җәелеп-җәелеп ага. Үлән исе, мәтрүшкә, бөтнек, ромашка исе аңкый. Киңлек, яктылык, хозурлык... Баш әйләнә! Шеф тар гына чалбардан, алсу төстәге җиңелчә күлмәктән. Калкулык башына бик җиңел атлап, җитез күтәрелә. Аннан соң, кинәт кенә туктала да, борылып карый, кулларын авызга куеп, көчле һәм дәртле тавышы белән тирә-юньне яңгырата: «Әһәй-й! А-һа-һай!..» Аннан соң ул тавышның кайтавазы килә. Аһ, ул җәй!..

Яңа директор, Птицынның кесәләрен капшагандай, баштанаяк күз йөртеп чыкты да карлыккан тавыш белән кистереп әйтте:

— Сине бөтен директорларга да яраклаша белә диләр, дөресме?

Птицын кычкырып җибәрүдән чак кына тыелып калды, бу көтелмәгән сүзгә эчтән рәнҗеп җавап кайтарды:

— Сез нәрсә?!. Сез ни сөйлисез?

— Ярар, ярар,— дип кул гына селтәде директор, аннан соң урыныннан кузгалды.— Яраклашмасаң да, барыбер — Ышаныч яулыйсың дигән сүз. Бер аермасы да юк.

Птицын кызарып-бүртенеп чыкты, күңеленнән усал сүзләр эзләде, кистереп җавап кайтармакчы булды. Әмма Бурбон, аны тәмам гаҗәпкә калдырып, дустанә кыяфәттә елмаеп җибәрде, ачылып, якын күреп әйтте:

— Ә мин нәкъ менә шундый кешеләрне яратам, туган. Ышаныч яулый белү үзе үк бик зур сәләт бит ул. Ә син, әйдә, утырып тор әле, утыр!..

Птицын урындыкка иңде. Әмма директорның баягы тупаслыгыннан кузгалган ачу һәм рәнҗү хисе һич тә кимемәде. Җитмәсә, аның әлеге сүзләрендә җанны үртәп, кимсетеп торган нindидер бер хаклык бар иде. Юк, хаклыкның бер кисәге, бер өлеше генә. Әмма барыбер...

— Мин, туганкай, үзем кешеләрне таный беләм,— дип дәвам итте директор.— Ышаныч яулый алган кешеләрнең бәһасен дөрес чамалыйм. Андый кешеләр һәрбер җитәкчегә кирәк, чөнки алар җитәкче кешенең эшен дә, характерын да, фикер сөрешен дә дәвам итә алалар. Ә дәвамың булу рәхәт ул. Аңладыңмы?

Птицын, үзе дә сизмәстән, баш какты.

— Менә шул-шул,— дип шатланып дәвам итте Бурбон.—

Синең кебек кешеләрдән гадәттә нәрсә сорала? Әллә ни күп түгел. Иң мөһиме — яраклашу, ышаныч, ялау, үзеңнән өстәрәк утырган кешегә охшарга тырышу. Сез, магнит тирәсендәге тимер комы кебек, шул бер кешегә тартылырга тиеш.

«Сиңа тагын магнит булу! — дип эчтән генә мәсхәрәле елмайды Птицын. Аңа хәтта кызыграк булып китте.— Синнән соң, атакаем, нәрсәгә өйрәнеп була?!»

— Син ашыкма, тыңлап тор,— диде директор, аның уйларын тоеп.— Артык һаваланма. Бер дә һаваланыр, горурланыр нәрсәң күренми әле синең. Шулай ук, әгәр төптәнрәк уйлап карасаң, синең элекке шефың Первенцев та ярык тагарак өстендә утыра, баш чөеп йөрер бер нәрсәсе дә юк.

— Ничек инде алай? — бу юлы инде Птицын түзмәде, үчекләп һәм әче итеп елмайды.— Министрлык буенча беренчелек кем кулында иде? Ә?..

— Әфтияк! — дип кырт кисте Бурбон.— Майсыз боткадагы китек кашык. Нәрсә соң ул сезнең беренче урыныгыз? Кемнәр арасындагы беренчелек соң ул? Нәкъ үзегез кебек әкәм-төкәмнәр арасында гына беренче бит сез! — директорның тавышына янә кырыслык, тупаслык кайтты.— Беренче шул сез, әмма бердәнбер түгел! Ни кушсалар — шуны майтарасыз, ә үзегез уйлый да, уйлап таба да белмисез. Йә, нәрсә, тәгәрмәчне сез уйлап таптыгызмы әллә? Нинди ачыш ясадыгыз соң әле, кабатланмас ачыш, ә? Шулай... Күбрәк рестораннарга, кибет-кабакларга йөреп, кызлар янына гына чаба беләсез. Кием алыштырасыз, кемнәргәдер охшарга тырышып яшисез...

— Ничек инде алай? — дип агарынып кабатлады Птицын.

— Ә менә шулай... Бер яктан икенче якка чайкаласыз. Кая таба авышырга, кайсы якка барып бәрелергә белмисез. Әле бер якка, әле икенче якка чабышасыз. Әле джаз белән маташасыз, әле йог ысулына тотынасыз. Сезнең кебекләрнең үз фикерләре, үз идеяләре булмый. Була да алмый!

— Ничек инде?!.— Птицын, ни әйтергә белмичә, эчтән көеп, тыштан агарынып каршы төште.— Ничек инде алай?..

— Ә менә шулай,— директор бөтен гәүдәсе белән аска иелде, әллә өстәл тартмасыннан, әллә келәм астыннан кызыл тышлы папка тартып чыгарып, Птицын алдына ташлады.— Мә, укып рәхәтлән! Тоташ полимерлар. Нәрсәгә кирәк булды икән алар безгә, ә? Полиэтилен капчык ясар өченме? Шул-шул менә, кемнәрнедер куып җитмәкче буласыз, чабышасыз, этенәсез-төртенәсез. Беренчелекне яулыйсыз! Кеше табагын ялап тамак туйдырасыз...— менә шушы берничә сүз белән ул Птицынның айлар-еллар буена башкарган, күңел җылысын салган, яратып өлгергән, иң эффектлы, иң заманча, иң җиңел ысуллар тәкъдим иткән эшен — тоташ полимерлар буенча эзләнүләрен сызып ыргытты, изде, таптады.— Институтка яңа идеяләр кирәк! Үзебез тапкан идеяләр! Аңладыңмы! Елга бер, елга ике яңа идея тусын — әмма үзебезнеке булсын! Артыгы кирәкми. Гомумән, дөньяда идеяләр әлләни күп түгел. Алар турында күп лыгырдыйлар гына, шуңа күрә идеяләр дә бихисап булып тоела. Ә чынлыкта исә, идеяләр бармак белән генә санарлык. Аңладыңмы?

Птицын янә искәрмәстән баш какты. Ә үзе эчтән яна, эчтән дулый, эчтән шашына иде: «Карале, нәрсә сөйли бит бу, ә? Үзе кем соң әле ул! Үзенең фәнгә нинди өлеш керткәне, нәрсә майтарганы бар?!»

— Мин сиңа маймыллар турында сөйләдемме әле, юкмы? — директорның бу сүзләрен Птицын каяндыр еракта, томан эченнән генә ишетте һәм айнып киткәндәй булды.

— Маймыллар турында? Нинди маймыллар? Юк, сөйләмәдегез...

— Алайса, сөйләргә кирәк икән,— дип көрсенде директор һәм Птицынга таба иелә төште.— Беләсеңме маймыллар ничек яши? Көн күрүләре бик гади аларның: бер агачтагы бананнарны ашап бетерәләр дә, икенчесенә үрмәлиләр. Анысын талаганнан соң, өченче агачка күченәләр. Өлгергән банан өчен талашалар, тәртешәләр, кычкырышалар, төкерешәләр. Ашап туйганчыга кадәр туктый белмиләр. Бервакыт маймылларга хәбәр килә: янәшәдәге урманда, зур бер аланда ак тәнле кешеләр пәйда булган. Маймыллар инде шул аланга ашыга. Кызык бит: ак тәнлеләрне күреп калырга кирәк. Баралар, кызыгып карап торалар-торалар да, кире үз урманнарына таялар. Банан ашарга.

— Ә алары, ак тәнле дигәннәре кем инде аның? — Птицын кипшенгән иреннәрен ялап куйды. Ул инде төшенеп өлгергән иде: Бурбон маймыл көтүе турында нәкъ менә аның элекке шефы — Первенцевны күздә тотып, мәсхәрә итеп сөйли.

— Ак тәнлеләрме? — директор үзенең бу җавабыннан чынчыннан ләззәт таба һәм моны яшерми дә иде. Кәнәфигә иркенләбрәк утырып, күзләрен кысып елмайды.— Ак тәнлеләре — идея табып яшәүчеләр. Первенцев белән син алар рәтендә түгел.

Бурбон, үз өстенлеген һәм тупаслыгын күрсәтүдән тәм табып, бер мәлгә тын калды. Аннан соң каршысында яткан кәгазьләрнең иң өстәгесен, пөхтә һәм тыйнак сызымнар белән бизәлгәнен үреләп алды:

— Мин монда кайбер нәрсәләргә күз йөртеп чыктым,— диде ул, янә үчекле елмаеп.— Сезнең эшләр... Ачышлар, уйлап табулар... Исеңә төшереп тору кирәк микән?

Птицын тартышып куйды, күзләрен читкә борды. Әйе, булды андый нәрсәләр, булды! Каядыр барырга акча җитми иде. Һәм Птицын нindидер юк кына бер нәрсә сызгалап ташлады. Нәрсә икәнен үзе дә төшенеп җитми иде. Аның ул эшен яңа техника планына керттеләр... Бөтен җирдә дә шулай эшлиләр... Птицынның кемлеген шушы юк-бар кәгазьгә карап кына бәяләү дөресме? Аның, аллага шөкер, саллырак хезмәтләре дә җитәрлек.

Бурбон, чыраен сытып, аска карап, тынып калды. Хәзер инде Птицын аны бөтенләй кызыксындырмый кебек иде. Бу хәл Птицынны хафага, шик-шөбһәгә салды: киләчәктә ни булыр, иртәгә Птицынны ниләр көтә? Хәер, нигә куркып-калтырап утыра соң әле ул? Ике кулына бер эшне ул кайда да табачак. Ә инде Бурбон казып чыгарган кәгазьләр — барысы да законлы эшләр: бернинди комиссия дә, бернинди тикшерү дә борын тыгарлык түгел. Мондый гына нәрсә турында сүз кузгатып та тормаячаклар.

— Менә шулай! — дип кистерде, ниһаять, Бурбон.— Фәнне шушы институтта, үзебездә, бергәләп үстерәчәкбез! Тәҗрибәне читтән эзләп күп чапкансыз, җитәр! Халыкны тәмам азындыргансыз, тезгенне ычкындыргансыз. Монда һәркем үзенә хуҗа булып өлгергән, ни телиләр — шуны кыланалар!..

«Үзеңне җәлләмичә эшлисең-эшлисең, гомереңнең иң матур чакларын эшкә бирәсең, ә менә шушы Бурбон кебек бер... әйттем исә кайттым... синең бөтен хезмәтеңне юкка чыгара... Юк, дөреслек дигән нәрсә юктыр бу дөньяда. Язмыш бәхетне аз-азлап, тамызып кына бирә кешегә. Аннан соң анысын да кире йолкып ала, үзеңне чүплек базына ташлый: йөз шунда рәхәтләнеп, тончык...» — директор кабинетыннан чыкканда әнә шулай фикер йөртте Птицын. Әмма соңыннан, үз бүлмәсенә кереп утыргач, Бурбонның соңгы сүзләре турында иркенләбрәк уйлагач, аның күңелендә өмет һәм ышаныч кебек бер нәрсә пәйда булды. Бигрәк тә «фәнне үзебездә, бергәләп үстерәчәкбез» дигән сүзләргә кат-кат әйләнеп кайтты Птицын. Бергәләп, дип әйтә икән, димәк — бергә-бергә эшләргә, бер

урында эшләргә дигән сүз! Башта бу ышаныч сизелер-сизелмәс булып кына калыкты, тора-бара Птицынның күңелен тулысынча биләп алды. Ни генә булмасын, мондый ышанычның тууы Птицын өчен олы бер хәбәр, аның фикерен кузгаткан, җанын алгысыткан киная иде.

Тиздән аңа Бурбонның өендә, яшәгән квартирасында кунакта булырга туры килде. Юк, монда ул сәнгатьле итеп сырлап-бизәкләп эшләгән, алтын төскә буялган җиһазларны да, Парижкдан яки башка бер чит илдән кайтартылган сирәк һәм затлы әйберләрне дә күрмәде. Сәүдә контрактлары төзелгәндә «рус белгечләренә» бүләк ителә торган вак-төяк сувенирлар да, ярым шәрә килеш бию-че кызлар рәсеме төшерелгән календарьлар да юк иде монда. Өстәл өстендә очраклы рәвештә генә ачып салынган сыман итеп, «Плейбой» һәм «Америка» журналларының яңа саннары да таралып ятмый. Хәтта кухня ягында — гаилә бәхете, гаилә күрке булган суыткычта да махсус заказ белән китерелгән колбаса, кара икра, чит ил шәраблары күренмәде.

Бурбонның өч бүлмәле квартирасы иске кирпеч йортның өченче катына урнашкан иде. Моннан икенче катка, ягъни әлеге кирпеч бинаның дүртенче катына (андагы бүлмәләр Бурбонның эти-әнисе исеменә теркәлгән), калын һәм киң такталы сөзәк баскыч күтәрелә. Алгы бүлмәнең ян-як стеналарына келәмнәр эленгән, идәнгә дә келәм җәелгән. Каршы як стенаны майлы буяу белән төшерелгән зур рәсем били: Кавказ тауларының ап-ак түбәләре күзгә бәрелә, кыя артыннан җирән атка атланган, чем кара канатлы япанча бөркәнгән җайдак чыгып килә... Бүлмәгә кергә, тәнең бер мәлгә эсселе-суыклы булып китә.

Кухня ягында зур, авыр имән өстәл тора. Бер читтәрәк, тәрәзә янында, ит һәм яшелчәләр турау өчен тагын бер имән кискә куелган. Агач утыргычлар... Ялтырап торган зур самавыр... Җиздән коелган люстра... Йокы бүлмәсендәге җиһазлар кедр агачыннан ясалган, ышанычлы, нык: мондый шкафларга көя керми. Эш бүлмәсендәге өстәл — кедр агачыннан, аңа инде озак яшәгәнлек төсе, вакытның серле төсе сеңгән.

Калын такталы агач киштәләргә шыплап-шыплап китаплар өелгән. Махсус әдәбият, белгечлек буенча гына да йөзләрчә китап. Аларның күбесен Птицынның күргәне дә, хәтта ишеткәне дә юк. Бернечә рәттәге китапларның тышлыгы ике телдә язылган. Надан булып күренмәс өчен, Птицын аларга тукталып та тормады.

Икенче каттагы йокы бүлмәсендә ир белән хатынның уртак ятагы ялан кыр кебек киң һәм иркен булып җәелгән. Ә янәшәдә — балалар бүлмәсе. Птицынны иң шаккатырганы менә шушы бүлмә булды. Аның бер ягында, алсу тышлы мендәр һәм юрганнар белән балкып, биш кечкенә караваттора. Ә икенче яктагы берлән-бер караватка зәңгәр тышлы (малайлар төсе) мендәр куелган.

— Бу ни хикмәт? — дип гаҗәпләнде Птицын.— Берьюлы алты бәби алып кайттыгызмы әллә?

— Юк ла,— дип тыныч кына кул селтәде хуҗа.— Безнең нәсел шундый: башта бер-бер артлы гел кызлар гына туа, аннан соң гына — малай. Шуңа күрә мин барысын да алдан ук хәстәрләп куярга уйладым. Хатын үзеннән нәрсә таләп ителгәнне төгәл белеп торсын! Ә, менә ул үзе дә кайтып җитте! Таныш булыгыз!..

Бүлмәгә ашыгып атлаудан битләре алланып чыккан, җәймә итәкле зәңгәр юбка һәм үтә күренмәле ап-ак кофта кигән бер кыз атылып килеп керде. Һәрвакыт гаҗәпләнеп, сокланып һәм елмаеп торган зур, коңгырт күзләре өстендә кыйгач кара кашлар сызылып киткән. Бәрхет кебек ияге, уймак кебек җыйнак сусыл иреннәре нәкъ сабыйларныкы.

— Таныш булыгыз: хатыным Надя!

Птицын бу ханымга карап каушап, югалып калды. Шул каушаган мизгелендә ул, ниндидер ачы үкенү хисе тоеп, үзенең дә, хәтта элекке шефы Первенцевның да мондый хатыны булмавы һәм була да алмавы турында уйлап өлгерде. Әлбәттә, очраклы рәвештә танышкан сөяркәләр табылгандыр табылуын. Алары да аның үз кирәкләре өчен, бер генә көнгә, бер генә сәгатькә яр булганнардыр. Ә менә хатын мәсьәләсендә... Аларның хатыннары, дөньядагы бик күп нәрсәләр турында сүз куерта белсәләр дә, шушы самими кыяфәтле, сабый йөзле ханым янында коточкыч бер җанвар булып тоелырлар, ябык һәм килбәтсез гәүдәләре, тырышып-тырышып та яшерә алмаган маңгай җыерчыклары белән теләсә кемне өркетерләр иде. Әйе, монда — нәни кызчык, сабый, үсмер, аңа карап, телдән сүз китә. Аның шушы кыяфәте, кечкенә аяклары, чак кына калку күкрәге, елмаюы, буй-сыны, сафлыгы һәм садәлеге күз алдыннан югалмый тора, җәфалый, интектерә, ымсындыра.

— Менә бу иптәш,— диде хуҗа, Птицынның аптырап калуын шәйләп,— синең минем хатын булуыңа ышанмый. Имеш, син мине яратмыйсың, тиздән ташлап ук китеп барасың.

— Минме? — дип кычкырып көлде ханым һәм Бурбонның сакал кырып зәңгәрләнгән яңагыннан үбеп алды.— Син бит минем дөньяда иң акыллы кешем! Сине ташлап китү мөмкинмени?!

Бурбон, канәгать елмаеп, хатынының иңеннән кочты.

— Йә, ярый, мин ашыгам, җаным,— диде ханым һәм нәзек беләгендәге сәгатькә борчылып күз ташлады.— Концертка соңга калам. Ә Света, кызыбыз, дачада калды, әни белән!..

Ханым чыгып та йөгерде. Бүлмәдә, татлы ислемай белән бергә, яшьлек исе, яшь һәм саф тән исе бөркелеп калды. Ә Бурбон, яңагын кашып, Птицынга таба борылды:

— Әллә соң кухняга чыгабызмы? Шашлык әзердер бит инде?!

Шашлык әзерләүчеләр — Бурбонның туганнан туган абыйлары — дәшми-тынмый гына үз эшләре белән мәшгуль иде. Боларның керүен күргәч, өстәлгә аракы, ипи һәм яшелчә тезеп куйдылар, каминда кыздырылган шашлыкны әйләндергәли башладылар.

— Барлык авырулардан да шушы нәрсә генә дәвалый,— диде Бурбон, аракы салынган стаканны күтәреп.— Башка төр даруны белмим дә, белергә дә теләмим.

Йог ысулы белән шөгыльләнү дәвамында кызыл кәбестә, алма һәм чөгендер кебек әйберләргә, яшелчә-җимешкә күнеккән, итле ашларны чамалап кына ашаган Птицын бу хәтле ризыкка — табак тулы ит һәм аракыга гына түгел, шушы кадәр аракы эчеп тә агуланмаган, шушы кадәр ит ашап та маемламаган кешенең үзенә, аның организмына, үз көченә нык ышанып яши белүенә дә чын-чынлап гаҗәпләнде.

— Менә,— диде Бурбон, колачын җәеп.— Бу — минем яшәү рәвешем, яшәү асылым. Монда барысы да нык, ышанычлы. Ә сездә...— аның тавышында үчекләү төсмере пәйда булды.— Сезгә, имеш, эш күрсәтү кирәк. Сезнең шулай: тыштан ялтырый, эчтән калтырый. Ә мин, беләсең килсә, сезнең кебекләр кулына калмадым. Мин боларның барысын да үзем таптым, үзем ясадым!

— Үзем ясадым? Ничек инде? — Птицын аңламый калды.— Акча мәсьәләсен әйтәсеңме?

— Юк ла,— дип ачу белән кырт кисте Бурбон.— Барысын да — менә бу каминны да, өстәл-шкафларны да, караватларны да, стенадагы рәсемнәрне дә! Үзем!

Бурбонның кыяфәте тыныч, кодрәтле, үз-үзенә ышанулы иде. Калын йон оекбашлар кигән, майка өстеннән тире камзул ябын-

ган, таза гәүдәле, зур йодрыклы бу кеше хәзер инде Птицынга бер дә көлке тоелмый иде. «Кем белә,— дип уйлап куйды Птицын.— Бәлки, мин үзем бу дөньяның асылын бик үк аңлап бетермимдер?..»

— Ә менә сугыш башланса?..— диде Бурбон, аның уен бүлеп.— Сугыш башланса, син ни хакына үләчәксең?

— Ничек инде «ни хакына»? Соң, әлбәттә, шушы тормышыбыз өчен!..

— Синең тормышыңны әйтер идем...— Бурбон кул гына селтәде.— Синең соң, туганкаем, үз өең дә бит. Синең өең — читтән кергән, чит илдән кайткан вак-төяк белән тутырылган тартма гына бит ул! — Бурбон янә кулларын җәйде.— Менә, өй шундый булырга тиеш! Мин бу йорт өчен, кулыма балта тотып, теләсә кайсы дошманга каршы барачакмын. Бу бусагадан бер генә дошман да исән-сау үтә алмаячак! Мин исән чакта!..

«Ә бит чынлап та балта күтәреп чыгачак! — дип күңеленнән куанды Птицын.— Билләһи, чыгачак!..» Һәм ул, кулына балта тотып ишек катына баскан Бурбонны күз алдына китереп, калтыранып куйды. Аннан соң йокы бүлмәсендә, идәндә яткан аю тиресен искә төшерде:

— Ә теге аюны?.. Анысын инде үзегез үтермәгәнсездер бит?

— Үзем.

— Аудамы? — Птицынның тыны кысылып куйды.

— Нинди ау ди ул,— дип коры гына җавап кайтарды Бурбон.— Мылтыктан соң аюның тиресе каламыни аның?! Гадәти үтерү, пычак белән... Тиресе өчен...

Бурбон сүзсез калды. Птицын исә каяндыр эчтән, тирәннән калыккан уйлары белән гәпләшеп утырды. Әйе, ул тормыш дигән нәрсә турында берни дә белми һәм белергә дә курка икән бит. Ә менә монда, аның янәшәсендә, дөньяны шактый күргән, белгән кешеләр утыра. Алар инде бу дөньяны өйрәнеп, аңлап бетергән. Юк, голландия рәссамнарының иҗатын яки Уссури юлбарысының авырлыгын белү генә түгел икән бу... Хәер, Бурбон аларыннан да бик яхшы хәбәрдар булып, белмәгәнгә генә сабыша кебек...

Өенә кайтып барган Птицын тәмам аптырашта, пошаманда калган, соң дәрәҗәдә уйчан һәм сәер иде. Метрода, кайнап торган халык төркеме арасында ул, әйтерсең, берьялгызы. Поезд, күп булса, ике генә минутка соңга калды, әмма бу Мәскәү метрополитены өчен шактый озак вакыт иде: станциядә халык артык күп җыелган, укмашкан, өелешкән. Ниһаять, мәрмәр стеналар буйлап нурлар йөгерешә башлады. Поезд, башына кояш таккан аждаһа кебек, караңгы тоннельдән атылып чыкты һәм Птицынны утыртып, өенә алып кайтып китте.

Шаулап, гөрелдәп, кайнап арган шәһәр йокларга җыена иде. Гаҗәп шәһәр бу: яхшылыгы да, яманлыгы да үзе белән; ул гел шушы тормышның үзе кебек — матурлык белән начарлык, камиллек белән зәһәрлек, зирәклек белән юләрлек бергә кушылган. Мондагы дөнья һәр мизгеле аша Птицынга кагылып, орынып үтте. Гауга яраткан, ярым акылсыз чирләшкә карчыклар. Диваналар, исерекләр. Йөзләреннән нәфрәт һәм ягымлылык ташып торган, кулларын бутап-бутап сөйләшкән телсезләр. Чыраенда тире авыруыннан зур тимгел калган егет. Бу күңел кайтаргыч шәмәхә-көрән төстәге тимгелне берничек тә яшереп булмый. Ул моны үзе дә бик яхшы белә, әмма битенә пудра яккан, кара эшләпәсен күзенә үк төшереп кигән. Чәчләре җилкәсенә кадәр салынган... Шагыйрь кыяфәте. Бу егетне беркем дә, беркайчан да үпмәячәген аңлап-белеп тору коточкыч. Әлеге дә баягы үзеннән этәреп торган тимгелдән җирәнү киртәсен атлап чыгу мөмкин түгелдер...

Калинин проспектында күзгә чалынган бер ханым бурсык тире-

сеннән тегелгән итекләр, алюмин төстәге ялтыравык комбинезон кигән. Айдан төшкән сыман...

Арка мие зарарланудан гарип калган егет, исәр елмаеп, газапланып-интегеп, аякларын сөйрәп, халык арасыннан атлый. Аның йөзендә катып калган бу сәер елмаюы үзенең мәңгегә гарип калуын аңлаганнан соң пәйда булгандыр кебек. Өстерәлеп, сөйрәлеп, бөтен тәне белән калтыранып атлый...

Шушы кычкырып торган газаплы күренешләрне машина гөрелтесе каплап китә. Электр утлары балкый. Каядыр ашыгучы, кабаланып атлаучы кызлар. Көтүе-көтүе белән дә, аерым-аерым да йөргән бу кызларны һәр тукталышта, һәр урамда очратасың. Башны артка ташлап, кычкырып көлүче егетләр. Дәшми-тынмый гына атлаучы карт-корылар. Боларның һәрберсе янәшәдән уза, янәшәдән...

Төн җитте. Урамга таралган томан агач башларына, өй түбәләренә эленде. Төн пәрдәсен як-якка аерып күренгән машиналар ниндидер иләмсез тау куышыннан килеп чыга кебек.

Эчеп өйрәнмәгән һәм эчкәннән соң ятып йоклый белмәгән Птицын үзенең язу өстәле артында шактый озак утырды. Бер сәбәпсездән күптәнге кәгазьләрен, язу-сызуларын актарды. Аннан соң стенага эленгән, шефы белән иңгә-иң төшкән фоторәсемгә карап торды. Бу рәсемдә алар икесе дә бик кызганыч, елмаюлары әллә ничек ясалма кебек иде. Птицынның башына кинәт кенә мондый уй килде: ул үзе, мәсәлән, имән өстәл ясый алыр, аю белән бергә-бер чыга алыр иде микән? Озак уйлады, әмма бу сорауларга җавап таба алмады.

Кинәт ул Бурбонның ярым караңгы ашханәсен, андагы каминны кузалдына китерде, үз-үзенә нык ышанган шушы кешенең шаркылдап көлүен ишеткәндәй булды. Каминнан саркып чыккан сыек яктылыктан стенага Бурбонның коточкыч зур күләгәсе төшә; әлеге күләгә, Бурбон селкенгән саен, стеналар буйлап шуыша, Птицын өстенә килә сыман иде.

Птицын өстәлдәге кәгазьләрен бер читкә этәрде. Бүлмәдәге утны сүндерде дә, өстәл лампасын кабызды. Аннан соң лампа каршысына басып, исәр кеше сыман, үзенең стенадагы шәүләсенә карап тора башлады. Лампага якынлашкан саен шәүлә зурая, иләмсезрәк була бара иде.

Птицын аякларын аерып басты, күкрәген киереп, бер кулы белән өстәлгә таянды. Кинәт ул үзенең беләкләренә, гәүдәсенә әллә нинди бер көч, аңлашылмый торган, әмма бик-бик таныш тоелган сәер бер көч тула башлавын сизде. Аның стенадагы күләгәсе нәкъ Бурбон күләгәсенә охшап тора иде...

*Нияз АКМАЛ тәрҗемәсе.*

## Николай Година,

руc шагыйре

### Хикәят

Берсе Себер якларында урман кискән,
Икенчесе монда адәм каны эчкән.

Хәзер бергә утыралар, туган сыман,
Хәмер эчеп, уртлап чучка салосыннан.

Уйламассың да бит читтән карап баксаң,
Язмышлары канлы төендәй укмашкан!

Очын табып баксаң җепнең, нәкъ шунда сер:
Берсе бит берсенә тиеш ун ел гомер.

### Шигырьләр

*Алар әле һаман яза...*

*Витторио Серени*

Берсе дан-шөһрәт дип яза,
Кайберәүләр икмәк өчен.
Кайберсе сөю хакына.

Бүген дан икмәктән очсыз,
икмәк тә сөюдән хаҗәт,
ә сөю — иректәге кош.

Әнә шуңа
шагыйрь дигән
сүз языла
кечкенә хәрефләр белән.

### Туган йорт

Яр буенда алтынчы йорт тора.
Әрбәлектә этәч сала оран.
Аш ягында әткәм төтен куа...

...Барысы шулай, элек ничек булган,
Әнкәм генә юк үз урынында.

## Янгын

Шөлди кошы ыңгырашып түкте моңын.
Яр буендагы таш кебек кара көеп,
Ана күзләрен йомдырды сабыеның...
...Каралтыларда уйнады кызыл яулык
Иңләп төнге кинлекләрнең бөтен буен.

## Онытылу

...Ничек тә вакытсыз акылдан шашмаска —
Чиркәнеп бушлыктан, килгән куырылып.
Ялангач, туң җирдә Колыма ята
Онытылып, бер читтә, каберташ булып.

Кемгә һәм кем куйган? Агыла көннәр.
Төш һәм өн эчендә җаваплар эзлисең:
Тимерчыбык челтәр. Эчтә эскәмия.
Утыртылганнарнымы утыртыр өчен?

*Мөдәррис Әгъләмов тәрҗемәләре.*

# Александр Лесин

## Гитлерның соңгы әмере

*(30 апрель 1945 ел)*

Ул бетон астына поскан...
                    Биредә — дымлы,
Казылган кабер эчедәй — ярым караңгы.
Хәмердән кызарынган эсэсчылар
Ишек төбендә һәм өстәле янында саклый аны.
Тәмәке төпчекләрен туры идәнгә атып бәрәләр —
Бөтен бүлмә төтенләнгән,
Алар өчен хәзер —
                    барсы да бер!..
Ул бөтен Европаны диярлек үз кулында тоткан,
Ә хәзер өченче рейх көймәсе комга утырган...

---

Александр ЛЕСИН — безнең Татарстанда туып-үскән шагыйрь. Бөек Ватан сугышы ветераны. Бүгенге көндә Симферопольдә яши. Без тәкъдим итә торган шигыре «Наш современник» журналының 1987 ел, җиденче санында басылган.

Нигә һәм кем китергән бирегә бу аю тиресен?
Хәер, ул үзе шулай боерган иде.
Күзен дә йоммыйча карый тирегә фюрер —
Күзенә әллә ниләр күренә:
гүя аю терелә,
Тешләрен ыржайтып ул аның өстенә килә,
Себер тайгасы булып аны талый,
Аяклары белән җиргә егып салып, аны ботарлый!..
Салкын кулы белән салкын тирен сөртә фюрер.
Эсэсчылар берсе дә кузгалмый урыныннан.
Тиздән менә фюрер
Әмер бирер:
«Гитлерны яндырырга!»— дип.
Бу — соңыннан.
Ә хәзер Ева Браунга әйтер туй балдагы кидерү хакында —
Барысы каршында.
Һәм, ниһаять, фюрерша хаклы рәвештә
Никах тастарын бөркәнер башына.
Көчләп китерелгән рухани, аптырап, йөзен яшереп,
Аларны нинди язмыш көткәнен аңламыйча,
Калтыраган кулы белән «гашыйк»ларның
Калтыранган кулларын куша...
«Гитлерны яндырырга!»— Бу сүзләрдән аның коты оча.
«Гитлерны яндырырга!»— Ул иреннәрен кыса.
Гитлерның кабере булмаячак бер чакта да,
Аның көл ителгән мәетен таратыр җил бар якка да.
Шулай яхшырак.
Читлек кенә булмасын тик.
Юкса, йозаклы читлеккә бикләп аны,
Ул имгәткән илләр буйлап йөртерләр.
Һәм кырык бернең июнендә полклары белән ул бәреп кергән
Рәсәйгә дә китерерләр.
Россияннарның нәфрәт ташкынын фюрер
Үзе күрер.
Бөтен яктан, бөтен юллар буйлап
Читлеккә килер, терелеп, хәтта үлгәннәр: нәниләр,
олылар...
Читлекне ватып алар,
эчендәге хәшәрәтне тартып чыгарып,
Йөзенә төкерә-төкерә, нәләт укырлар!..
...Учак көйри.
Бензин исенә,
Сөремгә чумган ишек алды...
Гитлерны яндыралар! —
Ә Берлин өстендә,
Рейхстаг түбәсендә Кызыл Байрак кабынды.

*Мәхмүт Хөсәен тәрҗемәсе.*

# Магҗан Җомабаев,

казакъ шагыйре

Талантлы казакъ шагыйре Магҗан Җомабаев 1909—1910 елларда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укый. Ул Галимҗан Ибраһимов, Шәехзадә Бабич, Мәҗит Гафури, Сәйфи Кудаш кебек бик күп татар һәм башкорт язучылары белән аралашып яши.

Аның «Чулпан» исемле беренче шигырьләр китабы 1913 елда безнең Казан шәһәрендә басылып чыга. Бу вакытта шагыйрь 19 яшьтә була. Лирик шигырьләр китабы белән бергә Магҗанның зур талант иясе булу даны да киң тарала.

Шагыйрьнең икенче китабы да шулай ук Казанда, 1922 елда чыгарыла. Шуннан соң аның тәрҗемә һәм оригинал хезмәтләре, китап булып, бер-бер артлы Ташкентта, Оренбургта, Мәскәүдә чыга башлый.

Шагыйрьнең оныгы Улжан Мөсәлимова — Җомабаева Магҗан турында, «Казакъ әдәбияты» газетасына биргән истәлегендә түбәндәгеләрне яза: «1920-30 елларда Могҗан Җомабаевның бик якын дусты, авыр чакларда аның белән бергә янып-көеп яшәүче сөйгән яры — Петропавыл кызы Зөләйха була. Магҗан белән Зөләйха 1922 елда өйләнешә. Шул елда, дусларының киңәше белән, Ташкент шәһәренә барып, анда казакъ халкының күренекле җәмәгать эшлеклесе Солтанбәк Кужанов белән очраша. 1924 елда С. Кужанов үзенең шагыйрь дустын Мәскәүдәге югары уку йортына — матур әдәбият институтына озата. 1927 елда Магҗан, укуын тәмамлап, тормыш иптәше Зөләйха белән бергә Казагыстанга кайта.

Магҗан беренче тапкыр 1929 елда, Петропавыл каласында кулга алына һәм 10 елга сөргенгә җибәрелә. Зөләйха аны эзләп Карелиягә бара. Шул очрашуда Магҗан Зөләйха аркылы Максим Горькийга хат язып җибәрә. Ул М. Горький белән яхшы ук таныш була: 1924 елда аның тәрҗемәсендә М. Горькийның хикәяләр җыентыгы басылып чыга.

М. Горький, Магҗанның хатын алу белән, Зөләйханы, үз исеменнән, Мәскәүдәге «Пешков комиссиясы»на җибәрә, кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә кирәклеген әйтә.

Беркадәр вакыт үткәннән соң, Зөләйха Магҗан янына тагын бара. Бу юлы шагыйрь аңа «Пешков комиссиясы»ннан хат алуын, суд билгеләгән мөддәтнең җиде елга калдырылуын белдерә.

Шушы җиде ел эчендә Зөләйха Магҗан янына — Карелиягә ундүрт тапкыр бара.

1936 елда шагыйрь, җиде елын тутырып, туган җире Петропавылга кайта. Кайтып бер генә ел үткәч, аны яңадан кулга алалар. Зөләйха соңгы тапкыр ирен Алма-Ата төрмәсендә күрә...

Магҗан Җомабаевның тугры яры — Зөләйха әле дә исән, Алма-Атада яши. Аңа инде туксан алты яшь.

Шулай итеп, казакъ халкының талантлы шагыйре Магҗан Җомабаев фаҗигале язмыш кичерә. Культ чорындагы авыр шартларда сөргеннәрдә, төрмәләрдә интегеп һәлак була. Ниһаять, алтмыш елдан соң, шагыйрь бөтенләй гаепсез дип табыла, аклана.

Журналның бу санында аның иң беренче китапларыннан алып 1927 елларда ук минем тарафымнан тәрҗемә ителгән шигырьләреннән бер өлеше бирелә.

*НУРИ АРСЛАНОВ.*

## Җил

Җил бик шаян бер бала,
Җан сөйгәне сардала,[1]
Бер туктамый йөгерә.
Иреннәре елмая,
Сер әйткәндәй кылана,
Я ерткычтай үкерә.

Җилне беркем куалмый,
Тау да юлын буалмый,
Җил шаркылдый, сикерә.
Җил ашыга, җил чаба,
Берәү йөзен капласа,—
Ача, биткә төкерә.

[1] Сардала — сары дала.

Тынгысыз җил бик иркә,
Уяна да бик иртә,
Уйнаклап йөгереп китә.
Төш күреп яткан чакта
Күл битен шадралата,
Аны әүвәрә итә.

Карт урманны уятып,
Әллә ни дип юатып,
Елмаеп-көлеп үтә.
Күр бәхетле җил туен,—
Әйтергә серен-уен
Карлыган күзгә җитә.

Тын алалмый ашыгып,
Йотлыгып та, баш орып:
«Сиңа — сылу, бәгырьгә
Килдем очып, гашыйкмын!
Бер үбәргә ашыктым,
Кара миңа, фәкыйрьгә!»

Ди дә, үбеп күзеннән,
Чәче, алма йөзеннән,
Коча асыл иркәсен...
Бәхетле җил, назлы җан!
Ва дәрига,[2] йә мәүлям,
Ник мине җил итмәдең?!

## Нәкъ шул сәгатьтә

Күрдем дә килдем,
Кулымны бирдем:
«Сөям сине, сылу кыз.
Йөрәгем — очкын,
Сөюләрем — чын,
Гуаһ булсын күп йолдыз».

Дип татлы телдән,
Кочаклап билдән,
Шашып үбә башладым.
Якынладың син,
Тартылмадың син,
Кит, димәдең, качмадың.

«Сөям!» дип үзең,
Мөлдерәп күзең,
Тидердең син биткә-бит.
Мондый язмыштан
Яздым мин һуштан,
БәгъРем, мине гафу ит!..

Бәйгегә комар,
Торамы толпар
Бер урында чаң йотып?
Җил идем, очтым,
Күпләрне кочтым,—
Киттем сине онытып.

Бүген син килеп,
Кулыңны биреп,
Кайгы белән карыйсың:
«Ышандым, яран,
Сөюең ялган,
Алдадың!» дип агълыйсың...

«Алдамадым мин,
Арбамадым мин,
Ышан сүзгә, сылу кыз,—
Нәкъ шул сәгатьтә
Сөйдем, әлбәттә!
Гуаһ моңа күп йолдыз».

## Төш

Яктылыкны — айны-көнне күрмимен,
Ярым үлек, тулы гомер сөрмимен...
Ирекрәге шат яшәгән халыкның
Нишләгәнен, ни дигәнен белмимен.

Хур иттем мин гайрәтне дә, көчне дә.
Кулдан килсен төрмәдә ни эш кенә?
Йокларга дип йомамын күзләремне,
Бер чара юк, юанычым төш кенә.

[2] Ва дәрига! — и кызганыч!

## Булса гөлсез

Булса гөлсез —
Былбыл өнсез,
Өнсез былбыл — соры кош.

Өнсез гомер —
Сүнгән күмер,
Утсыз йөрәк — буш куыш.

## Җир йөзен басса туфан

Җир йөзен басса туфан,
Таулардан ашса туфан,
Кайнатып дулкыннарын
Күбекләр чәчсә туфан!
Юса туфан җир өстен,
Япса томан күк йөзен!
Җанлы-җансыз күмелеп,
Калсам җирдә бер үзем!
Җирдә өннәр тынсалар,
Җан иясе югалса,

Балкыр иде дөньялар,
Кояш булып мин янсам!
Ут — телем белән җирне
Бер ялап алсам иде,—
Яктыртып кара төнне
Бер үзем калсам иде!
Янгынымнан бу фәна[1]
Көл булса яна-яна,
Гаҗәп кеше өр-яңа
Ясар идем дөньяга!

## Аксак Тимер сүзләре

— Җиһан диләр, нәрсә ул? —
Тик бер уч төбе генә.
Димәк, булырга тиеш
Җирдә хуҗа бер генә!
Тәңре — күкнең тәңресе,
Мәгъруур күген биләсен.

Җир тәңресе Тимер — мин,
Җиремә тәңре тимәсен.
Күк хуҗасы тәңренең
Нәселе юк, заты юк.
Җир тәңресе Тимернең
Нәселе төрек, заты ут!

## Күбәләк

Утка оча күбәләк,
Алга-артка карамый:
Белми мескен, ул утны
Һәлакәткә санамый.

Ут тирәли әйләнеп
Йөрер дә ул бер кунар:
Кызыкканы байгошны
Көйдерер дә — җан тынар...

Дустым, син дә омтылсаң,
Уйламый какма канат,
«Һәр балкыган алтын» дип,
Чапма ялкынга карап.

Җилгә ачсак канатны,
Күбәләктәй көярбез,
«Алтынга!» дип барганда,
Көлдән кәфен киярбез.

[1] Фәна — вакытлы дөнья.

## Мирпулат Мирзаев,

узбәк шагыйре

### «Үзбәкләр эше»

(ӨЗЕК)

Гел чиста торсаң да, намуслы булсаң да
Кайсы бер давылда тупыллар яна.
Көндәлек гонаһлар фаш булып торганда,
Зур җинаятьләр дә ачылды яңа.

Чын халык намустан салганда дивар,
Кабахәт төркемгә бер яклау булып,
«Үзбәкләр эше бу»— бар мәмләкәткә
Таралды бер аваз дөньялар тулып.

Бу халык тир түгеп эшкә чыкканда,
Бер таңнан элгәшеп, бер таңга тикле —
Имештер, тирәлек шулай булганга
Хезмәттә бил бөккән үзбәк гаепле.

Имештер, аларда бөтен каралык,
«Ак алтын» таулары күтәрсә дә күп,
Имештер, мамык күк бетте таралып
Ил эше — халыкта яманлык күреп.

Әле дә яхшы дим, исә җылы җил —
Әле дә яхшы дим, әле дә яхшы!
Ленинның эше һәм Ленинның сүзе
Дивардай калыкты аларга каршы.

Күңеләңне турайт, и михнәтле халкым,
Имансыз затлардан йөзеңне чөер!
Дөньяга бак та бер, житәр, бас, уян,
Үзеңә лаеклы — күкрәгең киер!

### Нәваи васыяте

Исемем үрнәккә алынмак тиеш,
Шанымны күкләргә күтәреп — биек?
Ул — миңа һәйкәлләр калыкмак тиеш,—
Йокламак тиешләр каберемә килеп?!

Түгелгән каным да көл булган сизеп —
Ник шуңа олылау, ник миңа зиннәт?
Сезгә соң васыятем йөрер ил гизеп:
— Сөеп яшәгез, и Туган тел кыйммәт.

*Мөдәррис Әгъләмов тәрҗемәләре.*

# Хамид Галимҗан,

үзбәк шагыйре

*Хамид Галимҗан — үзбәк халкының танылган шагыйре һәм галиме 1909 елда туган. Ул — Үзбәкстан халык шагыйрәсе Зөлфиянең тормыш иптәше һәм әдәби остазы.*

*Хамид Галимҗан татар әдәбиятын өйрәнеп, укып үскән шагыйрь. Габдулла Тукайны һәм Һади Такташны ул үзенең остазларыннан санаган. Утыз бишне дә тутырмыйча, һәлакәткә очрап, яшьли дөнья куюына карамастан, аның әдәби мирасы күп милләтле совет әдәбиятында күренекле урын алып тора.*

*Бу айда Хамид Галимҗанның тууына 80 ел тулды. Без түбәндә шагыйрьнең әдәби мирасыннан берничә шигырь тәкъдим итәбез.*

❁

*«Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә,*
*Ләкин,*
*Һәрбер йөрәк аны яңарта...*

Һади Такташ

Һәр йөрәкнең тик бер язы була,
Ә мәхәббәт аның кунагы,
Һәр йөрәктә сөю чәчәк ата,
Гөл бакчасы итә ул аны.

Әйе, Ләйлә күргән кара көннәр
Безнең өчен түгел, безгә ят,
Ширин бәхетен буган шук язмышны
Өлеш итмәс безгә бу хәят!

*1936.*

❁

Чәчәкләнгән яшьлек чагымда
Син ачылдың күңелем багында.
Шунда күрдем бәхет язымны,
Йөрәгемә исемең язылды.

Кошлар сайрый хәзер җанымда,
Мин гыйшыктан мас бу чагында,
Сахраларда уза көннәрем
Арасында чәчкә-гөлләрнең.

Кочак-кочак чәчкә тиергәнем
Һәм китереп сиңа биргәнем
Кичәгедәй һаман исемдә.
Сиңа, бәгърем, шигырем, хисем дә!

Шуннан бирле исемең телемдә,
Гүзәл сының йөрәк төбемдә.
Аяз күкле яшел язымда
Чәчәк аттың күңлем багында.

*1937.*

## Думбрага мактау

*Абдулла акынга*

Сүз башлыймын сөйләп яхшы-яманнан:
Күзләремнең нуры булган думбырам,
Синең белән кичеп үттем җиһаннан,
Йөрәгемнең җыры булган думбырам.

Синнән башка мөмкинме юл ярышым,
Син тауларда бергә гизгән кәвешем,
Синең белән киң таралды тавышым,
Йөрәгемнең өне булган думбырам.

Син барында сизелми тук йә ачым,
Синнән башка канат җәйми колачым,
Синең белән мөлаем күз карашым,
Коллыгымда өшеп-туңган думбырам.

Хәлимәкәй-былбыл, уяң гөлбакча,
Сагынганда йөрәгем парча-парча,
Синнән башка — бәгырем канлы калҗа,
Беләгемнең көче булган думбырам.

Әйләнсә дә төсем сары саламга,
Сине чалдым, хур булмадым яманга,
Картайганда җиттем яхшы заманга,
Яуларыма бүре булган думбырам.

Син барында һәр эш килә кулымнан,
Син барында, курыкмыймын үлемнән,
Иркәләндем, бәхет таптым илемнән,
Миңа түрдән урын алган думбырам.

Синең белән сер бирмәдем яуларга,
Синең белән бергә чыктым ауларга,
Алып киттең бөек башкалаларга,
Йөзгә бәхет нуры салган думбырам.

Хөрмәт белән сине кулга алырмын,
Мең яшәреп, чиртеп-чиртеп чалырмын
Һәм яңадан Мәскәүләргә барырмын,
Җәннәтемнең хуры булган думбырам.

*1937.*

## Корал ал кулга

Хәят тулы таң томанында,
Күз җитмәслек тау, урманында,
Зур өлкәнең кайнар канында
Кузгал! дигән бер фәрман булса,
Корал ал кулга!

Күрсен дисәң җиһанны күзем,
Үссен дисәң багымда йөзем,
Өмет белән үстергән кызым
Әйләнмәсен дисәң син колга,—
Корал ал кулга!

Булсын дисәң сиңа дөнья киң,
Калсын дисәң үзеңдә иркең,
Чын кешегә булыйм дисәң тиң,
Булмыйм дисәң әсир дә, кол да,—
Корал ал кулга!

Алыйм дисәң фашистлардан үч,
Ал кулыңа син алмаз кылыч,
Автомат ас, шунда булыр көч!
Калмыйм дисәң көрәштә хурга,—
Корал ал кулга!

Әгәр акса тамырда каның,
Булсын дисәң бер кисәк наның,
Газиз булса намус, вөжданың,
Егет яки чалмы — тик торма,—
Корал ал кулга!

Туган илгә басып кергән яу
Тауларында алалмасын ау,
Син куганда дошманың җәяү
Качсын тузып уңга да сулга,—
Корал ал кулга!

*1941.*

## Газәл

Ни булган ди яңагыңда беразга мин дә миң булсам,
Иреннәреңдәге татлы, хуш исле балга тиң булсам,

Талыңда тирбәлеп, былбыл кебек төннәр буе сайрап,
Үбеп чәчкә-гөлеңне иркәләүче таңгы җил булсам.

Таратып хушлыгыңны бар галәмгә, айнымас булып,
Үземнең сәнгатемә мин үзем хәйран калып торсам.

Синең янда, бу телсез, мас галәмдә ялгызым калып,
Югалтып үз-үземне, тын хыялларга талып торсам.

Әгәр бакчаңда гөл булмак миңа насыйп түгел икән,
Риза гүзәл сараеңа фәкать япма-чатыр булсам.

Пошынмыйм бер дә гайбәттән дә хурлаудан, җаным фида,
Алар алдында түш киереп торырдай бер батыр булсам.

Газап чиксәм дә, кичсәм дә ерак сахра-далаларны,
Җаным фида күрешсәм бер, сиңа үз һәм якын булсам.

*1943.*

*Үзбәкчәдән Нури Арсланов тәрҗемәләре.*

## Мәгъсүм Насыйбуллин

# ДУСЛЫК — ЗУР БАЙЛЫК

Казах һәм татар халкы борын-борыннан ук бер-берсе белән тыгыз аралашып, тел-ләгать, җыр-шигырь алмашып, кыз бирешеп-кыз алышып, яхшы күршеләр булып тату яшәгән. Халыкларыбызның мондый дуслык-туганлыкка омтылышы җырларда, риваять, дастаннарда чагылган. Казах халкы үз балаларын хәреф танырга, белем-гыйлемгә өйрәткән мәрхәмәтле татар мөгаллимнәренең, мәгърифәтчеләренең кайнар эзләрен хәзер дә саклый. Бу урында казах шагыйре Җакан Сыздыков истәлекләренә күз салу урынлы: «Казах язма әдәбиятын тудырган беренче буын язучыларыбыз турыдан-туры татар әдәбияты осталыгында тәрбияләнде, татар мәдрәсәләрендә белем алды, татар матбугатында чыгыш ясады, татар нәшриятларында китапларын бастырды». Казах арасына килгән татар яшьләреннән сәләтле акын-шагыйрьләр дә күп була. Үзара элемтә, иҗади аралашу аларга әдәби мәргәнлек үрләрен яуларга мөмкинлек бирә. Казахстанда икенче туган илен тапкан уртак шагыйребез Мифтахетдин Акмулла моңа бик ачык мисал. Урта Азиядә, Казахстанда булу, анда яшәүче халыклар белән аралашу, дуслашу Габдулла Тукай, Һади Такташ, Мәҗит Гафури, Хәсән Туфан һ. б. әдипләребезнең иҗатына көчле йогынты ясавы да һәркемгә мәгълүм.

«Яңа татар әдәбиятының кәрван башы Габдулла Тукай иҗат юлын Казахстан җирендә башлап, шагыйрь буларак илгә шушында танылган,— дип яза казах әдибе Т. Әбдерахманов.— Гомеренең соңгы елларында, казах сахрасына тагын да әйләнеп килгән, дала күренешләрен кызыгып сурәтләгән шигырьләр язган. Тукай казах халык иҗатын бик югары бәяләгән, аңа җылы тойгыларын белдергән. Ул казах үләң-җырларының кайнар хисле, матур булуына хәйран калган. Күп кенә казах җырларын яттан белсә кирәк. Шулай итеп, татар шагыйре казах халык рухи хәзинәсенең саф чишмәсеннән иркенләп эчеп, сусынын кандырган, аңардан өлге алган, өйрәнгән. Тик ул ризыгын күп авыз иткән илгә бурычлы булып китмәгән, тере чагында ук шул замандагы бер төркем акыннарыбызга осталык иткән: Солтанмәхмүт Торайгыров, Сәбит Дөнәнтаев, Әкрәм Галимов шикелле сәләт-фикер ияләренең сәнгатьтәге юлы, сүз дә юк, Тукайның игелекле тәэсирендә калыплашканлыгы рас».

Казах халкы Г. Тукайны бүген дә яхшы белә, әсәрләрен яратып укый. Аның әсәрләре еш кына аерым китап булып чыга. И. Нуруллин язган Г. Тукай турындагы повесть та казах укучыларына үз ана телләрендә барып җитте. Казан, Уфа, Оренбург, Җаек, Троицк шәһәрләре исә әле хәзер дә гыйлемгә сусап килгән казах яшьләрен хәтерли. Бу тамырлар тел якынлыгы, күп кенә гореф-гадәт, йолаларның уртаклыгы, яшәгән җирләрнең чиктәшлеге кебек бәрәкәтле туфракка берегеп үсканнәр.

Тарих битләрендә без татар мәгърифәтче галимнәре Шиһап Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйрилар белән янәшәдә казах Чокан Вәлихановны, Ибраһим Алтынсаринны да күрәбез. Чокан Вәлиханов белән Хөсәен Фәезханов арасындагы дуслык, хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре күз алдына үзе бер илаһи дөнья булып килеп баса. Аларның язышкан хатларында туганнарга гына хас җылылык, ихласлык, тирән хөрмәт, олы ихтирам сокландыра.

Архивларда табылган яңа мәгълүматларга караганда, заманында Казанда укыган казах һәм татар яшьләре демократик, революцион оешмаларда бергә эшләгәннәр, жандарм идарәсенә җавап алырга чакыргач, бер-берсен яклап сөйләгәннәр.[1] Революциягә кадәр үк татар театры Урта Азиягә барган чакта, аны казах интеллигенциясе һәм яшьләре кочак җәеп каршы алганнар, булышлык күрсәткәннәр.

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасы, Казан, 1980 ел, 15 июнь.

Казах халкының үсешен, һәр яңа адымын татар халкы куанып каршы алган. Шул заман газета-журналларын укыган кеше, бу хакта бик әһәмиятле мәгълүматларга тап була. «Аң» журналының 1916 елда чыккан 5 нче санын гына алыйк. Шунда басылган «Телләре башка булса да, күңелләре бер» исемле мәкаләсендә Галимҗан Ибраһимов төрки телләр турындагы буталчык буржуаз фикерләргә каршы чыга, казах һәм кыргыз халыкларының милли телен яклый, аның мөстәкыйльлеген раслый. Ул халыкларның әдәбиятларын югары бәяләп: «Бу халыкның рухында бик куәтле самобытность бар. Боларның халык әдәбияты һичбер төрле кабиләнекенә охшамас дәрәҗәсендә бай һәм зурдыр! Безгә әдәби хәзинәбезне баету өчен казах халкы әдәбиятын киң рәвештә өйрәнү тиешледер»,— ди. Шундый нигезле, гадел караштан чыгып, Г. Ибраһимов татар әдәбиятында беренче булып тугандаш халык тормышын яктырткан киң колачлы «Казах кызы» дигән роман яза.

Бу яктагы киң далаларда борынгы заманда ук төрле талантлар чәчәк аткан. Аларның чыганагы Отрар тарихына, ерак гасырлар төпкеленә барып тоташа. Ул чор дөньяга Исхак әл-Отрари, Исмаил әл-Жаухари, Җамал әл-Төркстани, әл-Сыгнаки, әл-Кыпчаки кебек олы фикер ияләрен, Әбү Наср әл-Фараби кебек бөек галим, философ һәм шагыйрь, математик һәм астрономны бирә. Унтугызынчы гасыр исә Чокан Вәлиханов һәм Абай, Җамбул һәм Мохамбет, Ибрай Алтынсарин һәм башка күренекле галимнәрне тудыра. Шулай да казах әдәбиятының чәчәк атуы Бөек Октябрь революциясеннән соң башлана. Ул Сәкен Сәйфуллин, Ильяс Җансүгуров, Баимбәт Майлин, Мохтар Ауэзов кебек күп үзенчәлекле язучыларны иҗат юлына чыгарды. Үзләренең милли әдәбиятларының иң яхшы алымнарын дәвам иттереп, рус һәм башка әдәбиятларның реалистик алымнарын үзләштереп, алар казах совет әдәбиятына нигез ташы салдылар.

Революция һәм гражданнар сугышы чорында туган казах, татар әдәбиятларының беренче әсәрләрендә үк рус, казах, татар хезмәт ияләренең азатлык өчен иңгә-иң торып көрәшүләре чагылдырылды: А. Таһировның «Алатау», «Ташкын дәрья тармакларында», Ш. Усмановның «Памирдан хат», М. Гафуриның «Шагыйрьнең алтын приискасында», Г. Гомәрнең «Тупсадан түргә», «Җаңыл», И. Салаховның «Төн кызы», «Иманнәр тамыр җәйгәндә» әсәрләре һ. б.

Казах халкы белән тыгыз бәйләнештә яшәгән, туганлык мәхәббәте саклаган Нури Арслан, Сәйфи Кудаш, Ибраһим Салахов, Мәхмүт Хөсәеннәр Казахстан һәм аның халкы турында аеруча күп, җылы итеп язалар. Сәйфи Кудаш, мәсәлән, «Хәтердә калган минутлар», «Яшьлек эзләре буйлап» дигән китапларында революциягә кадәр мөгаллимлек иткән чагындагы җанлы хатирәләрне бүгенге тормыш белән тыгыз аралаштырып, яңа Казахстанның җанлы, гүзәл панорамасын тудырды. СССР Халык артисты Габдулла Шамуков исә үзенең истәлекләрендә Казахстанның Җаек шәһәрендә чыга башлаган беренче татар әдәби журналы «Әлгасрел-җәдит» турында, Г. Тукай тормышының шушы шәһәр һәм казах халкы белән бәйләнеше хакында язды.

Безнең якташыбызны — Татарстанның Әгерҗе районында туып, 16 яшькә кадәр шунда үскән Сабир Шәриповны да — казах халкы бик яхшы белә. Казах совет әдәбиятының нигезен салышкан бу язучы һәм революционерга, дипломатка һәм дәүләт эшлеклесенә, Сәкен Сәйфуллинның якын дустына хәзер Алма-Ата шәһәрендә һәйкәл куелган. Аның иҗаты һәм тормыш юлы мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнелә.

Күренекле казах әдипләре үзләренең иң яхшы әсәрләрендә халыкларыбызның дуслыгын, хезмәттәшлеген югары бәяләгәннәр, аны матбугатта даими яктыртып, элементәне ныгытып торганнар. Сәкен Сәйфуллин егерменче елларда ук «Күкчәтау» исемле поэмасында, «Безнең тормыш» дигән романында бу изге темага мәдхия җырлаган, онытылмас образлар тудырган. Ильяс Җансүгуров 1933 елда Казахстандагы социаль каршылыкларны, яңа тормыш өчен барган көрәшне чагылдырган «Иптәшләр» исемле роман язган. Анда казах авылында мөгаллим булып эшләгән татар егете Фазыл Җиянгильдинның якты образы зур урын билəп тора.

«XX гасыр башында кардәш татар әдәбияты әһелләренең яшь казах язма әдәбиятын тудыруга, казах укымышлыларын үстерүгә хезмәт итүе шиксез,— дип язды Казахстанның атаклы шагыйре Җакан Сыздыков.— Татар мәдәниятының шифалы йогынтысында тәрбияләнгән кеше буларак, мин моны зур ышаныч белән әйтәм. Миңа татар әдәбиятын уку гына түгел, аны казах теленә тәрҗемә итү дә насыйп булды. Бу эшем Б. Майлин киңәше буенча Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасыннан башланган иде. Соңрак бирелеп, Г. Тукай иҗатын казах укучыларына җиткерү хезмәтенә керештек. Аның әсәрләрен яңабаштан уку мине шул кадәр биләп алды ки, «шат яратса да җиһанга, ят яраткан раббысы» дигән юллары тетрәтеп, күзебә ирексездән яшь китерде».

Татар һәм казах халыкларының үзара бәйләнеше, аларның үткәне, бүгенгесе С. Торайгыров, Т. Жароков, Г. Җомабаев һәм бик күп башка әдипләрнең әсәрләрендә тасвирланган. «Без, Көнбатыш Казахстанда туган казахлар, барыбыз да татарлар белән

аралашып, җырыбызны уртаклашып үстек,— дип искә ала Җамбулның әдәби секретаре булган шагыйрь Касыйм Тугызаков.— Татар әдәбияты укыдык, татарча сөйләштек. Соңрак татар әсәрләрен, шул исәптән Муса Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосын да тәрҗемә иттем».[1] Казах язучысы, әдәбият белгече Хәмзә Исәнҗанов әйткән сүзләр дә гыйбрәтле: «Казах, татарларның әдәби дуслыгы — ул безнең тормышыбыз. Шул тормышыбызны образлар аша гәүдәләндергәндә, әсәрләребезгә дә ирексездән татарлар килеп керә. Әйтик, «Якты Җаек» исемле трагедиямдә каһарманнарның яртысы татар лабаса» (шунда ук). Моңа казах халык язучысы Сырбай Мәүләновның «Җырлы Казан», атаклы язучы-галим Бөркет Исхаковның «Казах-татар әдәбиятларының элемтәсе» дигән тирән мәгънәле әсәрләрен дә өстәргә кирәк. Чөнки болар бар да халыкларыбызның борын-борыннан килә торган туганлыгына какшамас һәйкәл булып торалар.

1936 елда Казахстанның Мәскәүдәге беренче әдәбият-сәнгать атналыгын күрер өчен Казаннан күп кеше китә. Алар арасында күренекле язучылар М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Ф. Бурнаш, Ә. Ерикәй, М. Максуд, атаклы композитор С. Сәйдәшевләр була. Казахстан мәдәниятенең үсеше татар әдипләрен шатландыра, онытылмас бер истәлек булып кала. Бу хакта Фәтхи Бурнаш «Совет әдәбияты» журналының җиденче санында (1936 ел) күләмле мәкалә язып чыга.

Халыкларның күбесендә «Агач тамыры белән, кеше дуслык белән көчле» дигән мәкаль бар. Әдәбият, сәнгать әһелләренең үзара бәйләнеше һәм иҗади очрашулары да ихлас дуслар табарга, тормышның катлаулы якларын, кеше язмышларын тирәнтен өйрәнергә мөмкинлек бирә. Андый аралашу иҗатчыларны канатландыра, яңадан-яңа көч, илһам өсти. Тәрҗемәче Лирон Хәмидуллин, мәсәлән, Алма-Атада булып кайткач, казах әдәбияты, аның сүз осталары турында дистәләгән мәкалә бастырып чыгарды, хәзер күләмле әсәр язу белән мәшгуль. Казах әдибе Шерхан Мортазаев та Казаннан кайту белән РСФСРның халык рәссамы Бакый Урманчега багышлап күләмле очерк язды, аны «Казах әдәбияты» газетасында бастырып чыгарды. Казах галиме У. Сөбханбердина да казах студентларына Казандагы очрашулары, Кол Гали иҗаты турында лекцияләр укыды, фәнни хезмәтләр язды.

Дуслыкны ныгытуда әдәби тәрҗемә мөһим урын тота. Ә менә казах һәм татар әдәбиятларын тәрҗемә итү ничек тора соң? Г. Тукай, М. Акмулла, М. Гафури, М. Җәлил, һ. Такташ, Ә. Фәйзи, Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Ә. Исхак, Н. Арслан, Ә. Еники, Н. Фәттах, А. Гыйләҗев һәм башка күп әдипләребез Казахстанда икенче туган телен тапты. Казах халкы безнең язучыларыбызның исемнәрен тирән хөрмәт белән искә ала, аларның юбилейларына, татар әдәби бәйрәмнәренә багышлап китаплар, махсус җыентыклар чыгара килә.

Татар әдәбияты да казах дусларыбыз алдында бурычлы булып калмады. Халкыбыз әүвәл-әүвәлдән казах әдәбиятын ана телендә укуы белән горурлана, аны үз итте. Мохтар Ауэзов, Абай Конанбаев, Ибрай Алтынсарин, Сәкен Сәйфуллин, Җамбул, Габит Мөсрепов, Сабит Муканов кебек халык акыннарын, язучыларын татар укучысы мәктәп яшеннән үк белә, әсәрләрен яратып укый. М. Ауэзовның «Абай» һәм «Абай юлы» дигән роман-эпопеялары да безнең укучы күңелендә онытылмас эз калдырды. Бу дилогияне бездә казах халкының көзгесе дип атыйлар. Шуңа күрә Ауэзов, Сәйфуллин романнарының, Абай, Җамбул шигырьләренең татар телендә күп мәртәбәләр дөнья күрүе аңлашыла. Проза жанрында эшләп, үз халкының язмышын һәм эчке дөньясын оста сурәтләгән Б. Майлин, Г. Мостафин, Ә. Әлимҗанов, А. Кекильбаев, С. Моратбәков, А. Сатаев, С. Санбаев, С. Бирдеколов, Ә. Шынбатыров һ. б. казах язучыларының әсәрләрен дә татар китап сөючеләре яратты. Татарстан китап нәшрияты соңгы елларда шулай ук С. Мукановның «Тормыш мәктәбе», Ә. Әлимҗановның «Отрар хатирәсе», С. Моратбәковның «Әрем исе» әсәрләрен һәм казах әдәбиятының иң яхшы хикәя-повестьларыннан төзелгән «Дала җыры», «Ак дөя» исемле җыентыкларын да бастырып чыгарды.

Шәһәрдәге һәм авылдагы мәдәният сарайларында, республиканың газета, журнал битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында татар, рус шигырьләре белән беррәттән еш кына казах акыннары М. Үтәмәсов, И. Алтынсарин, С. Турайгыров, Ж. Мулдагалиев, С. Дунәнтаев, К. Аманжолов, Г. Урманов, Ә. Туктагамбетов, Т. Жароков, А. Тажибаев, С. Сәитов, Д. Абилев, К. Каирбәков, К. Мырзалиев, М. Әлимбаевларның да әсәрләре урын ала. Һәм казах әдәбияты әсәрләре һәр җирдә дә бик теләп, җылы каршылана. Казах халкының үзенә генә хас фольклоры, бүгенге әдәбиятында чагылыш тапкан табигатькә, хатын-кызга, матурлык-нәфислеккә, гомумән, тормышка карата гаҗәеп самими мәхәббәте безнең әдәбият сөючеләрне сокландыра, аларның игътибарын тылсымлы рәвештә үзенә тартып тора.

Казах мәдәнияты белән даими таныштырып, рухи хәзинәбезне баетып торган

---

[1] «Социалистик Татарстан», 1976 ел, 11 июль.

өчен тынгысыз галимнәребездән Миркасыйм Госмановка, Рәфыйк Нәфиковка, Әбрар Кәримуллинга, Нил Юзиевка, Баян Гыйззәткә, музыка белгече Зәйнәп Хәйруллинага, танылган язучыларыбыз Әхмәт Исхак, Нури Арслан, Зәки Нури, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Лирон Хәмидуллин, Тәүфикъ Әйди, Мәхмүт Хөсәен, Самат Шакир, Миргалим Харисовларга һәр ике халыкның рәхмәте зур.

Ике халык, ике әдәбият арасында тамыр җәйгән иҗади аралашу, дуслык мөнәсәбәтләре сәнгатьтә дә күпкырлы чагылыш таба. Октябрь революциясеннән соң сәнгатьнең барлык төрләрендә дә бу мөнәсәбәтләр ныгый, камилләшә. 1918 елда, мәсәлән, Кустанайда казах яшьләре «Кызыл кәрван» исемле һәвәскәр театр төзиләр. Троицкидагы татар театры белән якын аралашып, еш кына казах, татар телләрендә уртак кичәләр оештыралар, спектакльләр куялар.

Казах һәм татар халыкларының ике зур театры арасындагы дуслык мөнәсәбәтләре бүген дә уңышлы дәвам итә. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры берничә тапкыр Казахстанга барып, республика тамашачыларының мәхәббәтен яулап кайтты. М. Ауэзов исемендәге Казах академия драма театрын да Татарстан халкы күптән белә һәм аның чираттагы гастрольләрен көтә. Нигез ташлары 1926 елда салынган бу профессиональ театр чын мәгънәсендә талантлы артистларны, сәнгать осталарын туплаган. Ул Советлар Союзында гына түгел, чит илләрдә дә шөһрәт казанган.

СССРның халык артисты Габдулла Шамуков кунакларның спектаклендә булганнан соң болай дип язган иде: «Моннан алдагы гастрольләр вакытында күп спектакльләрне, шул исәптән, «Ана — җир ана» пьесасын карап искиткеч куанган идем,— ди ул.— Быелгы гастрольләрнең беренче спектакле «Кан һәм тир» дә ифрат зур тәэсир калдырды. Мондый очрашулар онытылмас эз калдыра, рухи яктан баета». Хөрмәтле аксакал әйтеп калдырган сүз дөрес. Кайчан гына килмәсен, казанлылар өчен бу театр белән очрашу зур бәйрәм. Аның һәр спектаклендә сәхнә белән зал арасында сокландыргыч якынлык, тыгыз бәйләнеш, җылы мөнәсәбәт туа. Татарстан радиосы һәм телевидениесе, матбугат спектакльләрдән күренешләр, өзекләр бирә, рецензияләр язып театр коллективының хезмәтен югары бәяли.

Татар һәм казах халыклары арасындагы иҗади дуслык музыка белән җыр сәнгатендә дә күптәннән бирле яши. Композитор Әхмәт Жубанов XIX гасыр уртасында казах җырчысы Җәяү Мусаның Казанга килүен яза. Казан, Уфа, Оренбург мәдрәсәләрендә, мәктәпләрендә укучы алдынгы карашлы яшьләр 1909 елдан башлап оештырган әдәби-музыкаль кичәләрдә казах көйләре дә җырлана. Аларны бергәләшеп казах һәм татар егетләре җырлый.

Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына багышлап Алма-Атада «Казахстанда халык музыкасы» исемле китап чыгарыла. Композитор Латыйф Хәмиди шул китаптагы мәкаләсендә 1930 елда Алма-Атада радиостанция ачылу тарихын яза. Беренче радиотапшыруларда татар артистлары Хәдичә Ваһапова, Рәхилә Әлханова, Халидә Хәбировалар катнашып, татар халык көйләре белән беррәттән казах, уйгур, башкорт көйләрен дә җырлыйлар. 1937 елда Казанда Татар дәүләт филармониясе ачылгач, казах белән татар музыка сәнгатенең аралашуы тагын да ныгый, алмаш концертлар күбәйгәннән-күбәя. Мансур Мозаффаровның «Казах кызына», Заһид Хәбибуллинның «Казах дустыма» (С. Хәким шигыре), «Казах кызы сөйгәнем» (Г. Сәгыйдуллин сүзләре) җырлары халык күңеленә сеңә. Нәҗип Җиһановның «Җәлил» операсындагы казах егете Сатпаевның җыры да казах җиренә, туган илгә тирән мәхәббәт хисе белән сугарылган. Казахстан композиторларының әсәрләрен Татарстанда шулай ук яхшы беләләр, яратып җырлыйлар. Бәхтиҗан Байкадамовның «Куанам», Латыйф Хәмидинең «Казах вальсы», «Былбыл»ы, Ильяс Җакановның «Идел-Җаек», Евгений Брусиловскийның «Кил безнең авылга», Шәмси Калдаяковның Мәхмүт Хөсәен сүзләренә язган «Әниемә» һәм «Кара күзләр, кара кашлар», казах халык көйләреннән «Тургай», «Уналты кыз» — болар барысы да җырчыларыбызның репертуарын бизәп торалар.

«1962 елда ике халык өчен тарихи вакыйга була,— дип искә ала Зәйнәп Хәйруллина,— Казахстанда татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы уздырыла. Шул ук елның декабрендә Казахстан язучылары, сәнгать осталары Казанга килә. Ул көннәр күңелдә хәзергәчә халыклар дуслыгы бәйрәме булып калды. Роза Багланова, Ермәк Серкәбаев, Фуат Мансуров чыгышлары мәдәниятебез тарихына һич онытылмас сәхифә булып теркәлде».

СССРның төзелүенә 60 ел тулу бәйрәмен каршылаганда да яңадан-яңа очрашулар була. Алма-Атада композитор Нәҗип Җиһанов, җырчылар Зилә Сөнгатуллина, Хәйдәр Бигичев һ. б.ларның концертларын музыка сөючеләр кайнар алкышлар белән каршылый.

Татарстан халкы Казахстанның әдәбият-сәнгать осталарын әле бүген дә рәхмәт хисләре белән искә ала, аларның кабат килүләрен көтә. Чыннан да, ерак тарихтан килгән бу бердәмлекне, иҗади дуслыкны хәзерге яңарыш чорында тагын да үстерәсе, ныгытасы иде.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Әхмәт Рәшитов

# БЕЗ КЕМНӘН КИМ?

Аның ата-анасы тапкан, мулла кушкан исеме Мәүлет иде. Диндарлык аңкып тора, диеме, әллә башка берәр сәбәп бар идеме — сугыштан соң ул тиктомалдан гына Павел Иванович булып йөри башлады. Дөрес, якыннары һәм туган-тумачалары өчен ул һаман да Мәүлет иде. Әмма паспортына инде яңа исем язылган һәм, табигый, без дә хаттагы адреска шулай дип куярга мәҗбүр идек. Мәскәүдә яшәүче ул ерак туганыбызга хатларны, гадәттә, миннән яздыралар. Шуңардан файдаланып, мин — кире беткән малай — берзаман конвертка аның элекке, ул үзе яраксызга чыгарган борынгы исемен язып куймыйммы? Югыйсә бу игелекле, саф күңелле, һәрвакыт көләч абыйга бернинди үпкәм дә, кинәм дә юк иде. Ләкин аның ят, яңа исеме күңелнең әллә кайсы җирендә рәнҗү һәм ризасызлык тудырды. Әлбәттә, әлеге хат авылга кире әйләнеп кайтты һәм миңа туганнардан байтак кына шелтә сүзләре ишетергә туры килде.

Балачакның тагын бер хатирәсе искә төшә. Авылыбызның бер егете армиядән татарчасын «онытып» кайтты. Имеш, өйләренә кайтып кергәч:

— Ани, паставь чемодан на саке... — дип әйткән икән. Яшьтәшләренә дә русчалап кына җибәрә, ди, бу. Янәсе, без кемнән ким?! Авыл егетләре шул ук көнне аңа татарчаны сыналган «ысул» ярдәмендә исенә төшергәннәр. Солдат кеше башка алай кыланмас булган.

Ыгы-зыгы тулы көндәлек тормышның бу бәләкәй һәм ярымкөлке хәлләренә, бәлки, игътибар итмәскә дә кирәктер. Азмыни дөньяда сәер кешеләр?! Җаны теләгән, елан ите ашаган, ди халык. Һәркем үзенә-үзе хуҗа; тели икән — Павел Иванович була, тели икән — башка телдә сөйләшә. Гади халык, әлбәттә, бу очракта алдын-артын, ахыр нәтиҗәсен уйлап та җиткермидер. Ләкин шактый зур пост биләгән татар кешесенең, түрә булып алгач, күпмедер вакыттан соң «Федор Александрович» яисә башка шундыйрак исемгә күчүен ничек аңларга?! Хәер, тарихта андый гыйбрәтләр җитәрлек шикелле. Генерал Мансуровлар, князь Юсуповлар, Шереметьевлар һәм башка бик күп чукынган морзалар, әлбәттә, моңа бүтәнчәрәк караган, күбрәк үз мәнфәгатьләрен күздә тоткан. Ә совет чорында, дәһри заманда мондый исем үзгәртүләрнең нинди әһәмияте бар икән соң?! Нәрсә бу — кемнәргәдер яраклашырга тырышумы, үз халкының меңнәрчә еллар дәвамында сыналган исем-атамаларыннан, гадәтйолаларыннан оялу-тартынумы, әллә гап-гади наданлыкмы?! Болайга китсә, Америкада бер, Кытайда икенче, Һиндстанда өченче, Буркино-Фасода дүртенче исем белән йөрергә туры килә түгелме соң?! Еш кына миңа (һәм, әлбәттә, башка татар балаларына да) әткәм-әнкәм кушкан исемне әйткәч, «Ә русчасы ничек була?» — дигән сорау ишетергә туры килә. Андый чакта мин: «Белмим тагын, миңа Һиндстанда да, Грециядә дә, Малайзия һәм Сингапурда да Әхмәт дип дәшәләр иде», — дип җавап бирәм. Әңгәмәдәшләрем бер мәлгә аптырап калалар. Алар минем дә аларныкы кебек үк үзенчәлекле үз исемем булу мөмкинлегенә гаҗәпләнәләр. Югыйсә минем Владимирны Вәли дип, Михаилны Мөхәммәт дип йөрткәнем юк ич. Ә нигә мин, кемнәргәдер ярарга тырышып, руска, японга, финга, эфиопка яки кхмерга әверелергә тиеш?! Болында һәр чәчәк матур. Исемнәр бакчасындагы чәчәкләрнең дә һәркайсы үзенчә матур һәм кабатланмас лабаса?!

Хикмәт исемдә генә булса икән?! Эш нинди телдә сөйләшүгә генә килеп терәлсә икән?! Мин дөньяда күбрәк яшәгән саен берсеннән-берсе гаҗәбрәк хәлләргә юлыгам, яңадан-яңа «ачышлар» ясыйм.

Бервакыт Казанның Яңа бистә зиратында заманында республикабызга җитәкчелек иткән партия һәм совет эшлеклеләренең (милләте буенча татарларның) каберләрен эзләп йөрдем. Үзем дә инде беркатлы! Аларның күбесе анда күмелмәгәннәр икән ич! Мәңгелек тынлыкны Арча кырындагы рус зиратында тапканнар.

Тагын «Кемдә кемнең ни эше бар?» дияргә мөмкин. Үз васыятьләре буенча яки туганнары теләгәнчә җирләнгәннәрдер ич! Ә мин, үҗәт адәм, тагын кирәкле-кирәкмәгән сораулар биреп маташам, табигый кызыксынуым алдында берүзем гаҗиз булып калам. «Теге дөньяга да интернационалист булып китәселәре килде микәнни? Татарның беренче большевигы Хөсәен Ямашев янәшәсендә ятарга ярамый микәнни? Ата-бабаларыбызның каберләре кадерсезрәк, дәрәҗәсезрәк микәнни? Ни өчен соң аларга, һичшиксез зур ихтирамга лаек кешеләргә, хәтта сугыш чорында Казан госпитальләрендә үлгән солдатларның каберләрен юк итеп булса да (бу хакта «Вечерняя Казань» газетасы 1989 ел, 5 сентябрь санында бик ачынып язып чыкты!), мәңгелек ятакны нәкъ менә шушы җирдә әзерләгәннәр?»

Сорауларны күп бирергә мөмкин, кайберләренә җавап та табыла торгандыр. Әмма кемдер бу юлланы инде ихтыяри-мәҗбүри традициягә әверелдергәч, югалып та каласың. Күңелне нәрсәдер тырный башлый, ризасызлык хисе, каршы әйтү теләге туа.

Туа шул, туа — әле ярый, тел яшерә торган заман түгел; бүгенге демократия һәм хәбәрдарлык шартларында әйтәсе килгәнне авыз тутырып әйтәләр. Шәхес культы чорларында яки торгынлык елларында дәшә алмаган өчен дә әйтәләр. Ил-йортыбызны чистарта-тазарта башлагач, чүп-чарларның, тузаннарның, ай-һай, күп җыелган булуы ачыкланды. Вак-төякләр шулай җыела башлагач, көннәрдән беркөнне мөһим проблемага әверелә — чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, бөтенесе бергә өелә. Әйтик, нииндидер бер татар бюрократы үз конторасының вывескасына татарча язуны кирәк санамаган. Ә бу кемнедер рәнҗетә, кемнеңдер милли хисләренә кагыла. Поездга яки самолетка утырасы авыл әбисе татарча игълан көтә, көтеп-көтеп тә ишетмәгәч, бөтенләй югалып кала. «И алла, үз илеңдә дә үзеңчә сөйләшмәсеннәр инде», — дип сукрана. Авызын-борынын югары градуслы нәмәстәкәй белән буяп алган исерекбаш поездда татарча җырлап кунакка кайтучы кызларга: «Тара-бара»гызны туктатыгыз!» — дип җикеренә. Анысына «тәрбиясез» дип кул селтәдең дә ди, әмма җитди кешеләр җитди рәсми документларда «Чүпрәле»не «Дрожжаное»га, «Биектау»ны «Высокая Гора»га әйләндерсә, һәм, татар теле нормаларын санга сукмыйча, ике сүзнең берендә «уборка», «лущить итү», «крс» дип сөйләсә, ничек кенә эчне пошыра әле. Вакыт-вакыт вак кына нәрсәләр белән дә үз тормышыбызны үзебез ямьсезлибез түгелмени, юктан гына да яңа проблемалар китереп чыгарабыз түгелмени? Бүгенге стресслар заманында, юк кына нәрсә өчен дә шырпы кебек кабынырга торган мизгелләрдә эмоцияләрне учка йомарлау, телеңне аркылы тешләп булса да түзү, дәшми калу, ай-һай, кыен эш. Шуңа күрә җитәкче кешегә һичкайчан булмаганча һәр дәгъва һәм таләпкә ирексездән тиешенчә игътибар итәргә, төпле фикер йөртергә, акыллы һәм сабыр булырга туры килә. Яман сүгенеп, йодрык белән өстәл төеп үз туксанынңны туксан дип «исбатлаулар» чоры үтте шул инде. Тәмам каешланып каткан бюрократ та хәзер алдын-артын уйлап сөйләшә, яңа шартларга ярашырга тырыша. Әмма ахмаклыклар әле һаман да дәвам итә. Нидән бу болай? Асыл сәбәпләре нәрсәдә? Кайчан булса да бер адәм рәтле яшәргә өйрәнербезме, ниһаять? Бөтен ил күләмендә димим, үзебезнең татар хәятында гына булса да заманча тәртипләр урнаштыра алырбызмы? Башка милләтләр үз тормышларын үзләренчә көйлиләр, мәсьәләләрне гадәт-йолалары, тарихлары-традицияләре нигезендә хәл итәрләр. Безнең татарның да гасырдан-гасырга күченеп килгән рухи кыйммәтләре, күңел хәзинәләре бар лабаса! Шуларны киләчәккә саклап алып бару, алдагы ерак заманнарда да үз-үзең булып калу турында сүз бара. Бабаларыбыз укыган сабактан яшь, таныш түгел буынның гыйбрәт алырга тиешлеге турында сүз бара. Югыйсә бөек остазыбыз Тукай безгә әнә нинди мәрхәмәтсез хөкем чыгарган:

*Татар халкы, син үләргә мәхкүм инде...*

Бу җан өшеткеч шигъри юлларны укыган саен, мин әллә ничек куырылып киләм. Шулай ук бөтенесе дә өметсезмени?! Инде шул мескен язмышка дучар булырбыз микәнни?! Әнә бит, Гаяз Исхакый да «Ике йөз елдан инкыйраз» дип кисәткән. Ике йөз елдан соң онытылу... юкка чыгу... телдән төшү...

Әдәбиятыбыз олугларына үпкәләргә нигезебез юк безнең — алар халыкны сөйгәнгә, аның бәхетле язмышы өчен җаннарын фида кылганга, аның киләчәге өчен кайгыртканга күрә әнә шулай әрнеп, ачынып әйткәннәр. Гәрчә ул заманнарда милләтебезнең хәле ул кадәр мөшкел булмаса да, кырыс карар чыгарырга җөрьәт иткәннәр.

Ә хәзер? Компьютерлар сан артыннан сан чыгара, фактка өстәп факт китерә...

һәм аларның берсе дә безнең файдага сөйләми... Татар мәгарифе... татар китабы... татар театры... татар... Елдан-ел түбәнгә... елдан-ел инкыйразга таба. Әти белән әни кешеләр өф-өф итеп үстергән бердәнбер сабыйларын фәннәрне урысча гына укыта торган мәртәбәле мәктәпкә илтәләр. Янәсе, без кемнән ким?! Туган телендә бишек җыры ишетмичә үскән егет һәм кыз, әлбәттә, «Каз канаты»н яки «Гөлҗамал»ны үз итә алмый. Юк, ул русның «Дубинушка»сын, украинның «Рушник»ын, грузинның «Сулико»сын да җырламаячак. Аның игътибарын ата-анасыз ниндидер чит авазлар җәлеп итәчәк. Ул гомер буе ерак бабаларының Чыңгыз яулары белән килгән булуы турындагы әкияткә ышанып яшәячәк, чөнки тарих дәреслекләре, тарихи романнар, кинофильмнар, рәсемнәр, симфонияләр — аны уратып алган бар мохит аның миенә гел шул ялганны сеңдергән. Себердә яшәүче милләттәшен ул мәшһүр рәссам Суриковның Ермакка багышланган картинасындагы кысык күзле, чытык чырайлы кыргый адәмнәр белән тиңләштерәчәк. «Татар» сүзе аның колагында гел кушамат булып, сүгенү сүзе булып яңгыраячак.

Тарих каһәре авыр — нахак булса да авыр. Үз халкының саф һәм керсез икәнен һәркемгә исбат итеп йөреп булмый. Синең хакыйкатьне юкка чыгарыр өчен йөзләгән мәкальләр, җырлар, былиналар китерәчәкләр. Гасырлар буена башка халыкларга кимсетеп карарга күнегүчеләр, указ һәм карарларга карап кына, геннарга сеңгән «тарихи багаж»дан тиз генә баш тартмаячак.

Без ерактан киләбез. Фаҗигаләргә юлыга-юлыга, тарихыбызның күпме асыл сәхифәләрен җуя-җуя якты кояш астында яшәү хакыбызны куз яшьләре, кимсенүләр, канлы сугышлар аша расլый-раслый киләбез. Тарих сабагы ачы. Кемнәрдер безнең нәсел-ыруыбызны җир йөзеннән юк итәргә теләгән чакта аның Җикмәргәннәрен саклап калырдай Тугзаклары да булган. Киләчәк өчен дәвам калдырырлык гүзәл һәм батыр кызлары Кара пулат ташларына ут капканда да янмаган. Шәһәрләр һәм кальгалар юкка чыккан — халык югалмаган, тырышып-тырмашып, үҗәтләнеп көн иткән, яңа башкалалар калкыткан, ерак мәмләкәтләргә илчеләр җибәргән, сәүдәгәрләрен Һиндстанга һәм Кытайга, Иранга һәм юнаннар иленә юллаган, күк һәм җирнең әллә нинди серләрен ачардай галимнәр тудырган, мәшһүр шагыйрьләре яшәешне һәм бәхетле тормышны данлаган. Һуннар дип аталганмы алар, сөннәрме, болгарлармы, кыпчакларммы — тарих хөкемдарлары әле һаман бәхәсләшәләр — әмма әллә никадәр цивилизацияләрнең сыйфатларын канына сеңдереп уртак максат өчен берләшкән халык бүген дөньяга татар буларак билгеле. Ул күп санлы халыклардан — җир йөзендә без җиде миллионнан артык. Дөрес, төрле төбәкләргә сибелгәнбез. СССРда без Карпат тауларыннан Тын океангача, чит мәмләкәтләрдә без — Төркиядә, Германиядә, Финляндиядә, Япониядә, Кытайда... Һәм хәтта Америка белән Австралиядә. Ләкин күңел күзләре бүгенге Татарстанга, Бөек Болгар дәүләтенең дәвамчысына — варисына төбәлгән. Тарих уртак, яралар уртак, өметләр уртак. Бәлки бу нәрсә кемнеңдер эчен тырный торгандыр, тик ни кылыйк соң — заманага хакыйкать кирәк.

Дистә еллар буена тарих китаплары Иван Грозныйның яулап алуларын прогрессив күренеш дип атап килделәр. Россия империясе Казан ханлыгын буйсындырудан, ил-йортларын саклаучы татарларны үтерү-суюдан башланды. Сталин идарә иткән елларда әлеге канлы тиранга тел тидерттермәделәр, ул кылган вәхшәтләр яңа термин белән «геноцид» дип аталмады. Ә бит рус чыганаклары да Казанны дошман явыннан саклаучы татарларның искиткеч батырлык күрсәтүләре, халыкның чебен урынына кырылуы, хәтта сабый балаларның кылычтан үткәрелүе, хатын-кызларның мәсхәрә ителүе турында ачыктан-ачык язганнар иде. Канлы тиранны «басурманнар» гына түгел, Новгород һәм Псков кебек рус җирләре дә, «Юрьев көн»еннән мәхрүм ителгән, ачтан һәм ялангачлыктан интегүче миллионлаган христианнар да каргады. Сталин Иван Грозный шәхесендә үзенең рухи туганын таптымы, әллә башка сәбәп бар идеме, бөек тарихчылар Карамзин, Ключевский, Погодин чыгарган хөкемнәрне «спецхран»нарга яшереп, залим патшага фәрештә битлеге кидерелде.

Ерак гасырлар артында калган маньякның куркыныч өрәген, бәлки, бүгенге көннәргә өстерәп чыгарырга кирәкмидер дә, ләкин нишләргә соң: һич кенә дә «интернационалист» булырга теләмәгән хәзерге заман шовинисты әледән-әле «азрак кыйнаган әле ул сезне», дип кисәтеп куя. Нервлары йомшагракларга җитә кала.

Юк, куркаклардан түгел безнең халык. Канлы яулардан соң да, биреләм, дип кулларын күтәрмәгән. Явыз патшаның «тәре походлары»на баш күтәрүләр белән җавап биргән. Ул залимне гади халыктан аера белгән. Хезмәт кешесенә — русмы ул, татармы — бертигез караган; өстен сыйныфларга каршы көрәш дигәндә, рус белән дә, чуваш, мари, удмурт белән дә бер сафка баскан. Иван Болотников, Степан Разин, Емельян Пугачев хәрәкәтләрендә юкка гына катнашканмыни соң ул?!

Безнең халык өчен милләтчелек чире ят. Интернационализмның беренче дәресләрен ул Рус җире өчен Грюнвальд сугышларында, крестьяннарның гасырдан-гасырга кабатланып кабына торган баш күтәрүләрендә, Рус-француз сугышы бәетен язганда үткән.

Без ерактан — гасырлар түреннән киләбез. Ул еракларга, ул үткәннәргә әледән-әле үрелеп карарга кирәк. Чөнки алар — тарихыбызның үрләре, ялланган биеклекләре. Мин шул хакта еш уйланам. Мөгаен, Тукай да, сөйгән халкының гыйбрәтле тарихын шулай күздән кичерә-кичерә йокысыз төннәр үткәргәндер дә:

*Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк!* —

дип ачынып әйткәндер.

Уйланган кешегә уйланыр нәрсәләр бар ул дөньяда. Җаваплары табылмаган сораулар, ай-һай, күп. Ләкин ничек сорамый түзәсең?!

Казан Кремлендә Благовещение дигән собор бар. Аның төзелү тарихы турында экскурсоводлар чәчелеп сөйләргә яратмыйлар. Моннан берничә ел элек Татарстан китап нәшриятында чыккан «Казань в памятниках истории и культуры» дигән китапта да ул хакта ык-мык рәвешендәрәк кенә әйтелә. Ә менә профессор Н. Загоскинның 1895 елда чыккан «Спутник по Казани» исемле хезмәтендә аның Иван Грозный тарафыннан ханлыкны буйсындыру хөрмәтенә махсус салдырылуы турында әйтелә. Бабаларыбызның туган җирләрен саклап түккән каннары өстенә салынган ул. Мин башка халыкларның дини хисләренә тирән хөрмәт белән карыйм. Ләкин христианнарның архитектура ягыннан тагын да кыйммәтлерәк башка гыйбадәтханәләре склад, айныткыч, мастерской биналарына, торак йортларга әверелеп, кадерсезләнеп яткан бер чорда татар халкын кимсетә торган шушы «культура истәлеге»нә алтын гөмбәзләр өстенә алтын тәреләр куелуын гади кеше буларак аңлый алмыйм. Шәһәрнең әллә кай җирләреннән чекерәеп күзгә кереп торган бу күренеш татар кешесендә якты истәлекләр яңарта ала микән соң?!

Казанга кунакка килгән кешеләр тагын бер һәйкәлгә игътибар итәләр. Бу — шәһәрне алган чакта һәлак булган рус сугышчыларына атап салынган корылма. Татарлар аңа күнеккән инде — дөресен генә әйткәндә, Иван Грозный вәхшилекләре өчен ул солдатлар гөнаһлымыни — урыннары җәннәттә булсын! Ә менә:

— Казанны батырларча саклап шәһит киткәннәргә һәйкәл кайда? — дип сорасалар, анысына ничек җавап бирергә?

Борынгы Болгар хәрабәләре янәшәсендә ярымҗимерек тагын бер чиркәү бар. Нигезендә — болгар бабаларыбызның кабер ташлары. Иданенә дә кабер ташлары түшәлгән. Бу вәхшилеккә гаҗәпләнгән туристларга кайсы интернационалисты рәтлерәк җавап бирә алыр икән?! Берзаман без әллә ни игътибар итмәгән шушы вак-төякләр шактый зур гаугага сәбәпче булмасмы?

Әйе, уйлаган кешегә уйланыр нәрсәләр бар ул дөньяда!

Егерменче гасыр башы баррикадаларына татар халкы, башка милләт вәкилләре белән беррәттән, социаль гаделлек даулап кына түгел, үзенең хурланган тарихын, кешелек дәрәҗәсен яклап та басты. Ленин бик хаклы рәвештә «халыклар төрмәсе» дип билгеләгән патша Россиясендә бер-берсенә дусларча, көрәштәшләрчә кул сузган милләтләр арасында әнә шундый һәйкәл сурәтендәге киртәләр дә ара-тирә калкып тора иде шул.

Дөнья тарихын бөтенләй яңа тарафка үзгәртеп җибәргән Бөек Октябрь революциясендә кайсы халыкларның ни дәрәҗәдә катнашкан булуына игътибар иткәнегез бармы сезнең? Ялкынлы еллар шаһит — татарлар ут сызыгының иң алгы сафында иделәр. Бүген җырларда җырланган Татбригада сугышчыларының каһарманлыклары турында җитәрлек беләбезме без? Алар кулыннан азатлык алган буыннар бүген дә рәхмәтлеме безгә?! Әллә Сталинның команда-административ системасы кайбер изге нәрсәләрне онытырды дамы? Заманалар бервакытта да манкортларга мохтаҗлык кичерми. Шаһәдәтнамәләрне төрмә һәм концлагерь архивларыннан, сталинизм корбаннары истәлекләреннән, очраклы кешеләрдә сакланып калган бердәнбер документлардан гына барлап була. Күп нәрсәләр онытылган шул, хәзер дә онытыла тора.

Соңгы елларда миңа илебезне байтак гизәргә туры килде. Бу сәяхәтләрдән мин бай тәэсирләр алып кайттым. Милләттәшләребез кайда гына эшләмәсеннәр, йөзләренә кызыллык китермәгәннәр — һәркайда макталганнар, орден-медальларга лаек булганнар. Миндә алар өчен горурлык хисе туа иде. Ләкин шул ук вакытта һәр очрашу саен күңелгә нинди дер юшкын да утыра килде. Донбасс якларына барыр алдыннан мин егерменче-утызынчы елларда аның культура тормышы ничек оештырылуы белән кызыксындым. Ул вакыттагы Сталино шәһәрендә татарча өлкә газетасы һәм күптиражлы 6 шахта газетасы чыккан. Н. Дәүли, Ш. Маннур, А. Аитов, М. Сөндекле кебек шагыйрьләрнең беренче шигырьләре монда дөнья күргән. Сиксәненче еллар ахырында исә милләттәшләребез ана телендә тамаша-концертлар күрергә, татарча китаплар укырга тилмереп яши.

Ерак Себернең Лангепас каласында адым саен якташларны очратасың. Кибетләрдә, бик үк өелеп тормаса да, җаның теләгән нәрсәне табып була. Тик татарча китап кына сорама!

Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районы авылларында лозунг, стенд, панно һәм башка күргәзмә агитация атрибутларының гел русча гына булуына гаҗәпләнгәч, колхоз җитәкчеләре безгә:

— Райком кушмый, милләтчелектә гаеплиләр, — дип аңлатканнар иде. Әлбәттә, гаеп атта да, тәртәдә дә бардыр. Һәр боерыкны арттырып үтәргә тәмам күнеккән бит ул безнең халык! Русча дигәннәр икән — русча булсын, без кемнән ким, анысын да булдырабыз. Татарча газеталарны туктатканнар — карышып маташмаганнар, татар театрын япканнар — дәшүче булмаган, мәктәпләрне русча укытуга күчергәннәр — ләббәйкә! Түрәләр авызыннан өзелеп төшкән һәр әмерне сәгате-минуты белән тормышка ашырырга әзер ялагайлар, рухына коллык күндәмлеге сеңгән бәндәләр азмыни?! Аңа план кирәк, йөкләмә кирәк, директива һәм карьера кирәк. Сыерларга прәннек ашатырга күрсәтмә килсен — ашата. Әйтсеннәр генә! Тукай томнарын мичкә ягып, дуңгыз абзарын җылытырга да әзер. Боерык кына булсын! Ә халык нәрсә? Күндәм ул. Куркытылган. Мәсләге буталган. Әнә бит, колхоз басуларында ничә еллар буе бер тиенсезгә эшләде — күтәрелеп бәрелмәде. Хәтта паспорт алырга да хакы юк иде — ә ул «азатлык кояшы даһи Сталинга» гимн җырлап яшәде. Юк, «атадан калган хатаны» алай тиз генә куып чыгарып булмый. 400 елга якын патша самодержавиесе итеге астында интеккән, 70 ел буе команда-административ системасының ялган вәгъдәләренә алданып яшәгән, чын демократиянең ни икәнен төшендә дә күрмәгән татар халкы рәсми карашлардан, көчләп тагылган кануннардан ничек җиңел генә баш тартсын икән! Тарихы хурланган, дине мәсхәрәләнгән, гореф-гадәтләре «искелек калдыгы» дип тамгаланган, телен, җырын, моңын әллә нинди «модерн»нар китереп кыскан...

Ләкин без бүген ил тарихындагы якты эзләребезне искә төшерик, халкыбызның горурлыгы булган бөек гамәлләрне уйдан кичерик. Бу безгә үз-үзебезгә ышаныч тудырыр өчен кирәк, бу безгә киләчәк көннәр өчен кирәк.

Без ерактан киләбез. Безне таныганнар. Безнең белән санлашканнар. Бабаларыбыз гомер-гомергә язу белгән. Рун язулы истәлекләре бүгенгәчә сакланган. Ул, ислам дине белән бергә, ислам культурасын кабул иткән. Көчләмичә, үз теләге белән кабул иткән. Моннан 1100 ел элек канына сеңгән бу инану аңа тарихның хәтәр борылышларында үз-үзен саклап калырга ярдәм иткән. Гасырлар буена яшәеше дәвамында ул гадел хезмәткә күнеккән, дошманнардан курыкмаска өйрәнгән, дусны кадерли белгән, буыннар хәтеренә тормыш әлифбасын сеңдерергә ирешкән. Аның вакытлыча тайпылулары, чигенүләре, югалтулары, бөек Тукаебыз икърар иткәнчә, бары «өстеннән кара көчләр басып торганга гына».

Мин табигатем белән оптимист кеше. Киләчәккә якты күз белән карыйм. Юк, бу — халыкның тәрәккыятен теләүдән туган хыял гына түгел. Татар этносының рухи һәм энергетик потенциалына ышанганга шулай.

Чыннан да, без кемнән ким?!

Бөек Ватан сугышы кырларында ярты миллионга якын татар башын салды. Халкыбызның 200 гә якын улы һәм кызы Советлар Союзы Герое исеме алды. Үз генералларын тәрбияләп үстерде. Шул халык тарих сәхнәсеннән югала аламыни?!

Магниткалар чорында бөтен дөньяны шаулаткан Мирсәет Галиуллинның дәвамчылары бүген иген игәләр, терлек карыйлар, нефть чыгаралар, самолет һәм автомашина ясыйлар. Күбесенең күкрәгендә Хезмәт Батыры билгеләре, орден һәм медальләр балкый. Шул халык этнос буларак ничек инде юкка чыксын?!

Совет власте елларында безнең үз академикларыбыз үсеп чыкты. Фәннең кайсы гына тармагын алма, анда үҗәтләнеп гаҗәп ачышлар ясаучы татар галиме булыр. Шул халыкның «өлешенә тигән көмеше» фәкать онытылу була димени?!

Табигать түземлек-сабырлыкны да, зиһенне-тапкырлыкны да, көч-куәтне дә кызганмаган аннан. Уе йөгерек, хыялы ашкын, теләге көчле, гайрәте ташып тора. Шулай дигәндә минем күз алдыннан меңләгән исемнәр узгандай була. Аларның кайсылары әдәбият-сәнгать өлкәсендә атаклы, кайсы спорт мәйданында дан казанган, кайсы... Хәер, горурланыр эшләребез азмыни соң безнең?! Әлеге дә баягы, без кемнән ким? Бары үз кадереңне үзең санлап, киләчәккә ышаныч белән карап яши белергә генә кирәк.

# Макс Гатау

*Идел-Урал буйларының бәрәкәтле туфрагында татар һәм башкорт халкы күп гасырлар буе аралашып гомер иткән. Бу хәл мәдәниятебезнең төрле тармакларында чагылыш тапмый калмаган, әлбәттә. Язучылар, сәнгать һәм фән әһелләренең бер-берсе белән аралашып яшәүләре нәтиҗәсендә, бигрәк тә Бөек Ватан сугышына кадәр, кардәш халыклар тормышын тасвирлаган әдәби әсәрләр һәм фәнни хезмәтләр дөньяга килгән, теге яки бу тугандаш халыкның күренекле вәкилләренә атап әсәрләр иҗат ителгән. Түбәндә журнал укучыларга әнә шул туганлык, иҗади хезмәттәшлекнең ачык бер мисалы булган шигырь тәкъдим ителә. Аны 28 яшендә Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган татар шагыйре Макс Гатау (Гайнетдин Зәйнетдин улы Гатауллин) башкорт шагыйре Г. Сәләмгә (1910—1939) багышлап язган.*

*Макс Гатау хәзерге укучыга аз билгеле шагыйрь. Ул 1913 елда хәзерге Курган өлкәсенең Әлмән районына кергән Тозау авылында дөньяга килгән. Яшьли ятим калган Макс балалар йортында тәрбияләнә, мәктәпне тәмамлагач, Чиләбе өлкәсендәге авыл хуҗалыгы техникумында укый, аннан соң балалар йорты директоры була. 1937 елда Казан дәүләт педагогия институтына читтән торып укырга кергән М. Гатау халык авыз иҗатын өйрәнү, җыр-бәетләр җыю белән дә шөгыльләнгән. 1940-1941 елларда М. Гатау Курган өлкәсенең район үзәге Сафакүл авылында урта мәктәп директоры булып эшли. Укучыларга тәкъдим ителә торган шигырь Г. Сәләм вафат булгач, шул вакытта Сафакүл районында татарча чыгып килгән «Коммунист» газетасында (1939 ел) басылган.*

***Җәүдәт МИҢНУЛЛИН***

## Сәләмгә

Чишмәләргә барып су эчкәнне
Һич онытмыйм, Сәләм дускаем,
Төпләренә ятып ял иткәнне
Сагына кебек һаман куш каен.

Их, күңелле була торган иде
Ял иткәндә Урал кырында.
Яшьлек истәлеге булып алар
Яңгырады синең җырыңда.

Чишмәләргә барып су эчсәм дә,
Ял итсәм дә каен төбендә,
Син юк инде, тик җырларың гына
Онытылмаслар халкым күңелендә.

Үлдең, шагыйрь,
Бишьеллыклар аша
Кайнаганда көрәш утында,
Ә җырларың үлми сакланырлар
Кешелекнең алтын фондында.

*1939 ел.*

## Фәрит Хатипов

# КӨЙЛӘРЕБЕЗ, МОҢНАРЫБЫЗ...

Күңел чыңнары... Күңелнең тирән серләре... Аның сизелер-сизелмәс тибрәнешләре... Үтә катлаулы, нәзакәтле дөнья! Саксыз орындыңмы, чатнап китәргә, уалырга гына тора ул... Хәер, иң чыдамы да шул ук кеше җаны түгел микән әле? Халыкның бөтен гаме, барча хәсрәт-борчылулары аның аркылы үтә бит. Ул һәммәсенә түзә, сыгылмаска, бирешмәскә тырыша. «Рухи дөнья» дип исемләп, халык бу хәятның чиксезлеген таныган. Сәнгать аны бөтен тарихы буена үзе өчен иң кадерле дип санап килгән, аңа гүзәл әсәрләрен багышлаган.

Тоташы белән күңел төпкелләрен чагылдыручы сәнгать тармакларының берсе — музыка. Ул үз телендә дәрт-омтылышлар, тойгы-кичерешләр хакында сөйли. Кешенең кәеф-халәтен, моң-сагышларын гаять үтемле итеп әйтеп бирүдә музыканың башка бер сәнгатьтә дә булмаган мөмкинлекләре, тылсымнары бар. Шуңа күрә ул һәркемгә якын сердәш, мәңгелек юлдаш. Гомере буена ул кеше белән бергә атлый, янәшә бара. Моңсу мизгелләрдә дә, сөенеч-куанычы мөлдерәмә тулып, ташып торганда да адәм баласы җанын җырга ачып сала, хисләрен түгеп, юаныч таба. Ананың көйләп бишек тибрәтүе — йокы ритмы булдыру гына түгел. Җырына ул назын, мәхәббәтен, керсез хыялларын да сала.

Музыка халыкның иң мөкатдәс, газиз байлыкларыннан санала. Күңелгә ятышлы матур көй тыңлау җанга әйтеп бетергесез рәхәтлек, куаныч, ләззәт бирә, яшәешеңне ямьләндереп җибәрә, мәгънәле, бөтен итә. Шуңа да һәр яңа матур җырны сөенеп каршы аласың, күңелеңә беркетеп, тизрәк отып калырга омтыласың, гүяки аны кулдан ычкындырмаска, һәрчак файдаланырлык милкең итәргә тырышасың. Яңа матур көй оту — ул күңелгә хәзинә өстәлү, рухи баю дигән сүз.

Билгеле, җырны үз милкеңә әйләндерүдән уртак милли байлыкка һич тә зыян килми. Киресенчә, никадәр күбрәк кеше күңеленә барып җитсә, музыка шулкадәр тотрыклырак, яшәештә активрак була бара. Ул файдалануга карап кимеми. Урман-болыннар кичеп, елга-күлләрдә йөзеп, саф һава сулап рәхәтләнгән шикелле, кеше җырга да теләгән вакытында мөрәҗәгать итә, аны башкарып ләззәтләнә ала.

Музыка халык тормышында бик хөрмәтле урын били. Дәү агачның куәтле тамырлары кебек, җыр кешене туган ягы, халкы белән бәйли, аерылырга, ычкынырга ирек бирми. Ата-анага, кардәш-ыруга якынлык, туган җир гүзәллеге күңелгә тел белән, җыр белән бергә кереп тула. Музыка — Ватанның бик кадерле рухи бер өлеше ул. Туган як моңнары, халыкның теле-сөйләме туган туфрак катламнарына бик тирән сеңгән. Шуңа да туган җирдәй кадерле, газиз алар. Туган туфрак кебек, милли моңны да берни алыштыра алмый. Милли аңның саекмавында, милләтнең үзен, йөзен саклап калуда, халык буларак аны яшәтүдә музыканың да роле бик җитди.

Җырның эстетик йогынтысы төрле чаралар ярдәмендә барлыкка килә. Безнең көйләрнең сихри тәэсир көче — моңында. «Моң», специфик күренеш булгангамы, башка телләргә тәрҗемә ителми. Ул — безнең көйләрнең җаны, ин мөһим гүзәллеге. Бары тик моң гына кешенең халәтен, хисләр тирәнлеген төгәл, эстетик йогынтылы итеп әйтеп бирә ала.

«Моң»ны моңсулык, кәефсезлек, төшенкелек дип кенә аңларга ярамый. Моң аркылы күңелнең ул яклары да чагылырга мөмкин, билгеле. Ләкин шулай да бу төшенчә тирәнрәк мәгънә аңлатса кирәк. Ул психологик халәтнең бөтен төсмерләрен дә сурәтләүдә катнаша ала. Аны көйнең иң асыл сыйфаты, сокландыргыч үзенчәлеге, төп матурлыгы дип карау дөресрәк булыр.

Көй — ул барыннан да бигрәк тавышлар тибрәнеше, калынаюы, нечкәрүе. Ягъни төзү материалы итеп ул төрле югарылыктагы, төрле калынлыктагы авазларны файдалана. Музыка төп җиде аваздан оеша. Татар, башкорт көйләре биш тавышка — пентатоникага корылган. Әгәр шул биш тавышны рәттән гади генә яңгыратып барсаң, безнең җырларга охшаш аһәң килеп чыга. Әнә шул яңгыраш пентатоник көйләрнең нигезен тәшкил итә, һәм ул байтак халыклар тарафыннан гүзәллек, моң үрнәге буларак кабул ителгән. Без бу системаны бик еракта яшәгән милләтләр (шотландия, кытай һ. б.) музыкасыннан да колакка бер чалыну белән шәйләп алабыз. Аның яңгырашы таныш, якын тоела.

Пентатоник системада иҗат ителгән халык җырлары («Иске карурман», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Салкын чишмә» һ. б.) дәверләр буена халыкның хәтерендә саклана килгәннәр, аңа эстетик ләззәт биргәннәр. Бу системада композиторлар да бик матур көйләр чыгардылар. Мисал өчен Р. Яхинның «Керим әле урманнарга», «Китмә, сандугач», «Сорнай моңы»н искә төшерергә була. Шулардан «Керим әле урманнарга» хәзерге лирик җырлар рухында иҗат ителгән. Ә инде «Китмә, сандугач», бигрәк тә «Сорнай моңы» үзенең яңгырашы белән борынгы җырларны хәтерләтә. Киң сулышлы, талгын агышлы, фәлсәфи эчтәлекле бу озын җырлар кешенең ил, яшәеш, мәхәббәт турындагы уйларын, ваемнарын бик матур чагылдыра.

Биш тавыш... Алар җирлегендә чиксез күләмдәге һәм бер очракта да кабатланмый торган авазлар комбинациясен төзергә була. Моның шулай икәнлеген күп халыкларның шушы системадагы музыкаль байлыгы раслап тора.

Әмма үзенекен генә өстен күрүче кайбер белгечләрнең сүз сөрешеннән пентатониканы җиде тавышлы система югарылыгына менеп җитмәгән түбәнрәк система дип карау тенденциясе сизелеп-сизелеп киткәли. Бу очракта бер система икенче система позициясеннән карап бәяләнә, атны аңарда сыер сыйфатлары булмаган өчен хурлаган кебегрәк килеп чыга. Ләкин пентатониканың ни икәнен белү өчен аңа башка система җәһәтеннән түгел, бәлки аны үз позициясеннән карап билгеләргә, бөтен нечкәлеген, шигърияттен, моңын күңелең белән тоярга, сиземләргә кирәк. Кавказ табигате ноктасыннан караганда безнең урта полоса табигатенең дә фәкыйрьрәк күренүе ихтимал. Ләкин безнең үзебезгә аннан да хозуррак, ямьлерәк җир юктыр сыман. Шуның шикелле, пентатониканың да бүтән системада булмаган үз мөмкинлекләре, барыннан да бигрәк үз моңы бар. Шулай булмаган тәкъдирдә, ул күп халыклар мәдәниятендә әллә ничәшәр мең ел яши алмас иде.

Музыкаль яшәеш процессында аерым җырлар төшеп кала, яңалары туа, күпмедер дәрәҗәдә алмашыну процессы бара. Ә нигез — биш тавышлы система үзгәрешсез кала бирә. Тагын әле пентатониканың тик үзенә генә хас булган бик тирән сере дә, фәлсәфи мәгънәсе дә төсмерләнә.

Пентатониканы катып калган ябык система дип фараз итү дә дөрес булмас иде. Ул өстәмә чаралар кулланылуына да юл куя, моны табигый саный. Шуларның берсе — алтынчы аваз. Ул бик борынгы заманнарда ук безнең җырларга килеп кергә, алты тавышлы җырлар саф пентатоника белән янәшә иҗат ителә, үзебезнең милли музыка җирлегендә туа. Мисал рәвешендә «Гөлҗамал»ны күрсәтергә була. Күңелләрне тирәннән айкап ала, уйландыра, хисләндерә торган мәгънәле көй. Безнең чорда Илһам Шакиров тагын шундый ук борынгы, үзәк өзгеч сагышлы, тирән, ләкин сабыр кичерешләрне гаҗәп моңлы итеп сөйли торган «Ах, җаныем, җанашым» көен эзләп тапты һәм халыкка кайтарып бирде.

Алты тавышлы җырлар безнең музыка өчен очраклы күренеш түгел. Алар әле дә туа торалар. Соңгы елларда, мәсәлән, «Олы юлның тузаны» җырчыларыбыз репертуарында ныклы урын алды.

Бу традиция дә профессиональ композиторлар тарафыннан уңышлы дәвам иттерелә. Алты тавышка алар еш мөрәҗәгать итәләр. С. Сәйдәшевның «Без кабызган утлар», Р. Яхинның «Ядкяр», С. Садыйкованың «Җидегән чишмә», Р. Еникиевның «Кәккүк моңнарын тыңларга», М. Имашевның «Кыр казлары артыннан», Ф. Әхмәтовның «Иркәң буласым килә», Л. Батыркаеваның «Мин сине шундый сагындым» һ. б. җырлары алтышар тавыштан тора. Алтынчы аваз, гадәттә, җырның билгеле бер урынында килә. Кайбер көйләрдә ул пассив вазифа башкара, бик кыска вакытта гына ишетелеп кала, икенчеләрендә шактый актив, озак яңгырап тора, кат-кат ишетелә. Ләкин ул пентатониканың табигатен үзгәртми, аңа җайлаша, яраклаша. Шул ук вакытта көйгә яңа аһәң, яңа бизәк өсти, тәэсир көчен арттыра.

Бездә хәтта җиде тавышлы җырларны да очратырга мөмкин. Аларның да үрнәген иң әүвәл халык биргән. «Каз канаты», мәсәлән, «Ай былбылым», «Син сазыңны уйнадың» җиде тавыштан тора. Алар безнең музыкаль әсәрләр рәтендә үзенчәлеклерәк урын алып торалар.

Дөнья классикасында, үзебезнекеләрдән С. Сәйдәшев иҗатында шәрык аһәңнәрен гүзәл яңгыраткан байтак әсәрләр бар. «Син сазыңны уйнадың» җыры да шушы рухтарак

ижат ителгән. Анда Көнчыгыш моңнарының аһәңе чагыла, Урта Азия халыклары көенә тартымлык бар. Ил тормышы, халыклар яшәешендәге зур күренешләр, тарих, керәш, хис-кичерешләр турында җитди уйларга сала торган фәлсәфи-лирик әсәр ул. Бу җырны да, мәгълүм булганча, халык арасына И. Шакиров алып чыкты. Моның әһәмиятен мөстәкыйль классик әсәр ижат итүгә тиңләргә була.

Композиторлар иҗатындагы җиде тавышлы әсәрләргә мисал итеп С. Сәйдәшевның «Әдрән диңгез», Р. Яхинның «Ак җилкән», Н. Җиһановның «Өзелгәнсең сиреньнән» җырларын китерергә мөмкин. «Әдрән диңгез»нең үзгә яңгырашы тәүге ишетүгә үк сизелеп тора. Анда үзебезнең аһәңнәр шарык моңнары белән үрелеп, өр-яңа төсмерләр китереп чыгара. Н. Җиһанов, нигездә, җиде тавышлы җырлар язарга, көйләребезне икенче бер системага якынайтырга омтылды. Моның кайбер килешле генә үрнәкләрен дә бирде. Тик шулай да җырлары халык арасына тулаем кереп китә алмады.

Соңгы елларда җырчыларыбыз репертуарына бик матур, үзенчәлекле керәшен татарлары җырлары килеп керде. («Акрын кирәк, иплән кирәк», «Чибәр кызга», «Бер алманы бишкә бүләек» һ. б.). Алар безнең музыкага яңа моң төсмерләре өстәделәр.

Бездә профессиональ музыка, халыкның җыр иҗаты белән чагыштырганда, яшьрәк күренеш. Шулай булуга карамастан, ул милли мәдәниятебезне үстерүгә зур өлеш кертте. С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, Н. Җиһанов, З. Хәбибуллин, С. Садыйкова, Р. Яхин, Ф. Әхмәтов, Л. Батыркаева һәм башкалар музыкабызның офыкларын шактый киңәйттеләр, аны яңа бизәкләр белән баеттылар. Уңышлы әсәрләрдә профессиональ камиллек белән халыкчанлык ипле генә үрелеп килә. Җыр жанрында күңелгә хуш килердәй күп кенә әсәрләрнең иҗат ителә торуы халык музыкаль традицияләренең бай булуы белән дә аңлатыла.

Музыкаль тормышыбызда, болардан тыш, тагын үзешчән композиторлар да әһәмиятле эш башкарып киләләр. Алар җыр тудыручы халык талантлары белән профессиональ композиторлар арасында, уртадарак торалар. Бәлки, профессиональ авторларга якынрактыр да әле. Чөнки алар музыкаль әзерлекле, моңның закончалыкларын, хасиятен, нечкәлекләрен яхшы беләләр, көйне, моңны профессиональ дәрәҗәдә нинди дә булса инструментта уйныйлар. Аларның матур-матур җырлары күренекле артистлар репертуарын бизәп тора.

Шуның белән бергә, яңа көйләргә, яңа аһәңнәргә ихтыяҗ һаман да зур әле. Чөнки, беренчедән, халәт, кичереш төсмерләре чиксез. Музыка кеше моңының яңадан-яңа якларын ачарга бурычлы. Икенчедән, көйләрнең һәммәсе дә сакланмый. Хәтсезе онытыла, төшеп кала. Кызганычка каршы, түбән сыйфатлы үтмәс товар кебек, җанга берни дә бирми торган моңсыз-мамыксыз, речитативка охшаш җырулар табадан ишле генә төшә тора. Алар үзләренең килеш-килбәте белән иссез, ясалма чәчәкләрне хәтерләтәләр. Моң җитмәүдән җитди политик темага язылган җырлар да нык кына оттыралар. Аларга моң кирәкми, җырчылар, тыңлаучылар аларны җитди тематикасы өчен үз итәрләр, дип фараз кылу үзен аклап бетерми. Җитди теманың көе тагын да матуррак булырга тиешле.

Әүвәл бездә күмәк җырлар уртак бер тавыш белән башкарыла иде. Революциядән соң алар классик, профессиональ музыка үрнәгендә күп тавыш белән җырлана башладылар, полифоник яңгыраш алдылар. Алдарак без көй чыгаруда төрле югарылыктагы авазларның катнашуын күреп киткән идек. Бу очракта алар эзлекле рәвештә бер-бер артлы киләләр. Моннан аермалы буларак, полифоник музыкада төрле югарылыктагы берничә тавыш бер үк вакытта яңгырый, төрле югарылыктагы көйләр янәшә агылалар. Моның белән күмәк җыр тагын да матуррак яңгырашка ирешә.

Күп тавышлы җыр культурасын үстерүгә Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле зур өлеш кертте. Аның башкаруында көйләребезнең моңы кимеми генә түгел, яңа сыйфатлары, яңа мөмкинлекләре ачылып китә, җырлар мәгънәлерәк, тәэсирлерәк төс ала. Бу уңайдан Н. Вәлиева, Р. Зиннәтуллина дуэтының уңышлы эшчәнлеге турында да әйтеп китәсе килә. Алар, ике тавыш белән җырлап, көйләрнең нәфисләгән, моңын тагын да тирәнрәк ачу осталыгына ирештеләр.

Хәзер инде үзешчән хор, ансамбльләр дә берничә тавыш белән җырлыйлар. Бу юнәлештә Р. Гомәров җитәкчелегендәге «Саз» ансамбленең казанышлары игътибарга лаеклы. Ул полифониянең зур мөмкинлекләрен иҗади файдалана, җырларны нечкә зәвык белән иҗади башкара.

Музыкаль әсәрләр татар драма театрлары репертуарында да хәтсез урын били. Профессиональ драма артистлары да җырларны хәзерге сәнгать казанышлары югарылыгында, күп тавыш белән җырласалар, аккомпанемент та магнитофон язмасында бирелмичә, спектакль барышында турыдан-туры сәхнәдән яңгыраса, «тере» музыкаль авазлар ишетелсә, нур өстенә нур булыр иде.

Музыканың катлаулы төрләреннән опера, симфония санала. Опера әчтәлеге тоташы белән музыкаль башкару аркылы белдерелә. Итальян, француз, рус һәм башка халыклар

культурасында аның зур гына казанышлары бар. Бездә исә массаның рухи яшәешенә аның тирән үтеп керә алганы юк әле. Сәбәбе — музыкасына нәфислек, моң җитмәүдә, халыкның музыкаль зәвыгыннан ерак торуда булса кирәк.

С. Сәйдәшевнең симфоник оркестр өчен язган әсәрләре классик югарылыкта иҗат ителүләре, аңлаешлы, күңелне җәлеп итәрдәй тәэсирле булулары, нурлы моңы белән аерылып торалар. Ул үзенең симфоник музыкасын шартлы чаралар, авазлар җыелмасына кайтарып калдырмады, бәлки көйнең, моңның сихри куәтен тулысынча файдаланды, аларны симфония мөмкинлекләре белән баетты. Миңа калса, Ф. Яруллинның «Шүрәле», Н. Җиһановның «Кырлай» музыкасының да уңышы халык рухына якын, авазлаш булуда. «Шүрәле»дә без бию тактлары гына ишетмибез, аның буеннан-буена ягымлы көй, моң агыла. Тыңлаучы күңелен әнә шул әсир итә. Бу музыканың нигезендә халык аһәңнәре ята.

Музыка — коллектив хезмәт җимеше. Аның яме, гүзәллеге башкаручы иҗатында аеруча тулы ачыла. Җырларыбызның моңын, нәфислеген тыңлаучыларга җиткерүдә, югары зәвык тәрбияләүдә Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең роле зур. Бу коллектив өчен сәнгатьне халыкка якынайту, иң күркәм үрнәкләрен пропагандалау, югары профессионализм, көйнең аһәңен тулы саклау, даими эзләнү, иҗади омтылыш хас. Аның эшчәнлеге күпмедер дәрәҗәдә сәнгатьчә камиллек өлгесе итеп карала.

Музыкаль мохитка талант килү — рухи тормышта зур вакыйга ул. Моннан берничә дистә еллар элгәре Г. Сөләйманова, З. Басыйрова, Р. Ваһаповлар кулыннан эстафетаны Ә. Авзалова, И. Шакировлар күтәреп алган иде. Шул дәвер эчендә алар халкыбызның сөекле җырчыларына әверелделәр, ихлас мәхәббәтен казандылар. Безнең җырларны җиренә җиткереп башкару — нотадагы югарылыкларны алу, билгеләрне тавышка күчерү генә түгел. Аңа җан өрергә, тормыш сулышы бирергә кирәк. Бу мәгънәдә И. Шакировның бик тә табигый итеп, фальшька, ясалмалыкка юл куймыйча, көйнең моңын, тибрәнеш-борылышларын, нечкә бизәкләрен саклап җырлавы үрнәк кебек кабул ителә.

Моңлы җырчы шиксез көйләр сайламый, репертуарына халык күңеленә хуш килердәйләрен алырга тырыша. Г. Рәхимкулов, Ф. Кудашева, Т. Якупов, Ш. Әхмәтҗанов, Х. Бигичев, З. Сәхәбиева, Н. Василова, З. Җаббаров, З. Сөнгатуллина һ. б.лар матур җырларның абруен тагын да югарырак күтәрделәр, аларга пар канат куйдылар. Талант кулына килеп кергән җырны, уңдырышлы туфракка төшкән орлык кебек, бәхетле язмыш көтә. Г. Фарукшин, Л. Бичарина, А. Фәйзрахманов, Х. Тимергалиева, Г. Ибушев, Г. Сафиуллина, З. Шәрифуллина һәм башкалар моңарчы күзгә чалынмаган байтак җырларга игътибар юнәлттеләр, гражданлык хокукы бирделәр. Алар ничектер берьюлы балкып киткәндәй булдылар. З. Шәрифуллина, мәсәлән, карап торышка гади генә тоелган «Нигә яна йөрәгем» әсәрен халкыбызның яраткан җырына әверелдерде, аңа сәнгатьтә яшәү хокукы бирде. З. Шәрифуллина үзе дә ягымлы, куе күкрәк тавышы белән тиз арада киң популярлык казанды, тыңлаучылар күңелендә хөрмәтле урын алды. Шундый ук җылы сүзләрне башка бик күп талантлар хакында да әйтергә мөмкин. Һәркайсы матур тавышка ия, һәрберсенең үз манерасы, башкару стиле бар.

Шул ук вакытта рәсми-салкын, хиссез-моңсыз, иренеп җырлау үрнәкләрен дә еш кына ишетә торабыз. Кайбер талантлы артистларыбыз чит ил классикасын менә дигән итеп башкаралар, ә үзебезнең көйләрне шарж, пародия кебегрәк итеп тамак төбе белән җырлыйлар. С. Сәйдәшевнең «Әдрән диңгезе»н Г. Отц, мәсәлән, кайбер татар артистларына караганда матуррак, килешлерәк башкара. Бу хакта уйланырга кирәк. Музыка кебек нечкә нәрсәгә андый мөнәсәбәт массаның зәвыгын хөрмәт итмәү булып аңлашыла. Белгәнеңне, булдыра алганыңны җырлау мәслихәтрәк булыр шикелле. Кайбер иптәшләр музыкаль әсәрләрнең бөтенләй төссезләрен үз итәләр. Алар җырның тирән асылын, нечкәлекләрен, ароматын үзләштермичә генә репертуар төзиләр микән әллә, дигән шик туа күңелдә.

Татарча уку күрмәгән артистлар телендә байтак грамматик, мәгънәви, орфоэпик хаталар очрый. «**Айрылганны** алдан белдем, ялгыз күрдем кыр казын»,— дип җырлый бер иптәш. «Айрылганны» формасы үткән заманны белдерә. «Айрылган» булгач, аны алдан күрү мөмкин түгел. Дөресе — «Айрыласын алдан белдем...» Тел остасы иҗат иткән текстны үзгәртү, гадәттә, уңышка китерми.

Кайбер җырчылар ана телен җанлы сөйләмгә колак салу юлы белән түгел, китапта язган буенча гына өйрәнәләр кебек. «Карурман» урынына «кара урман» дип, «кигән киемең күрсәм дә...» урынына «кигән киемең**не** күрсәм дә...» дип әйтәләр, җыр ритмына артык иҗек китереп кыстыралар да, ничек сыйдырырга белмичә аптырап бетәләр, эткәлиләр, төрткәлиләр. Ахырда, икенче бер авазны, бу юлы инде законлы урынында утырганын, йотып калдыралар. «Көмеш тояк, **Чу**лпар атым», «тик табалмыйм, иркәм, **Хич** тә...», «Җырласам, елыйсым килә, **алла** гомерем аз микән», «түзә алмый күң**ге**л бер җырламый, **чайка**лганда көймәләр» дип ялгыш әйтүләр очрый. Шулай ук урынсыз җирдә пауза ясауларны да еш ишетергә туры килә. Табигыйлык, пөхтәлек җимерелә.

Инде радио, телевидение тапшырулары турында берничә сүз. Әүвәлрәк, шимбә-якшәмбедән кала, һәр кичне бер үк вакытта радиодан илле минутлык концерт тапшырыла иде. Радио тыңлаучылар моңа инде тәмам күнегеп беткәннәр, эштән кайтуга күңелләрен шушы дулкынга көйләп куялар иде. Соңгы берничә елда кичке моңнарга әллә ни булды: йә алар кайбер көннәрдә эфирга бөтенләй чыкмыйча калалар, йә кисеп-кыркып кына биреләләр. Кичке концерт дигәнебез ун-унбиш минутлык инструменталь музыка белән чикләнә. Ул да яраклашелгән вакытта түгел. Эстетик ихтыяҗ үсешенең хәзерге биеклегендә торган цивилизацияле зур халыклар тәүлек әйләнәсендә дистәләгән сәгатьләр буе үз музыкаларын тапшыралар, ә Татарстан радиосын тыңлаучылар шул унбиш минутлык инструменталь чыгыш белән канәгатьләнергә мәҗбүр. Татар соң кемнән ким? Радио эшчәнлегендә үзгәртеп кору тискәре якка китте. Ул, билгеле, эстетик ихтыяҗга җавап бирә алмый.

Радиодагы кадерле концерт вакытын бер үк эчтәлекле, исәпсез кабатланган хатлар уку ала. Радионың тыңлаучылар белән элемтәсенә берәү дә каршы килми. Ләкин инде хатлар тапшыру, исем-фамилияләр санау бик кирәк дип табыла икән, аларны концерт хисабына түгел, башка вакытта укырга кирәк. Музыка — бер нәрсә, хат — икенче нәрсә.

Телевидениенең дә атнага бер тапкыр гына кичкенә концерт күрсәтеп алуын берничек тә аңлап булмый. Кайчак ул да әле радио концерты белән бер үк вакытка туры килә.

Һәр икесенең программасында да әйбәт музыкаль чыгышлар белән уртачалары аралашып килә. Сәер хәл: «сәнгать осталары концерты», «лирик концерт» дип тәкъдим ителгәннәре чынлыкта уртача була. Чын мәгънәсендә затлы концертлар программаларда зуррак, хөрмәтлерәк урын алсын иде, дип әйтәсе килә.

Татарстаннан читтә яшәүче татар халкына культура хезмәте күрсәтү мәсьәләсе аерым сөйләшүне һәм, барыннан да мөһимрәге, кичекмәстән хәл итүне, практик чаралар күрүне сорый. Статистика мәгълүматларыннан күренгәнчә, безнең илебездә 5 миллионлап татар ТАССРдан читтә яши, илебезнең экономикасын, культурасын үстерүгә, оборона куәтен ныгытуга хезмәт итә. Әмма алар Казаннан тапшырыла торган радио концертларны тыңлаудан, магнитофон язмасына язып алудан мәхрүмнәр. Чөнки станциянең куәте бик чикле. Берничә йөз километрдан читтә Казан дулкыннарын тотып булмый. Әлеге миллионнар үзенең бер җырын ишетергә тилмереп, туган як моңнарына сусап яши. Ләкин бит хәзерге радио техникасы космик объектлар белән дә бәйләнешкә керергә, ныклы элемтә урнаштырырга мөмкинлек бирә. Казанның үзендә дә заманында бөтен дөньяга тапшыра торган куәтле «Интернационал» радио станциясе эшли иде. Димәк, Казан дулкыннарын еракларак тапшыру — ул техник мәсьәлә түгел, бәлки кешелеклелек, вөҗдан, бурыч мәсьәләсе. Монда халыкның рухи-эстетик ихтыяҗына колак салу, аны хөрмәт итү, практик эшкә керешү сорала. Бу эшне киләчәккә калдырмыйча, шушы арада хәл итәргә иде.

Ихлас теләк, инициатива булганда, татарлар яшәгән өлкә һәм республикалар үзләре дә бу юнәлештә байтак оештыру эшләрен башкара алалар. Аларның һәркайсында филармония бар. Шулар каршында татар концерт бригадалары төзелсә, үз төбәкләрендә гастрольләргә чыгу белән берәттән, алар җирле радио, телевидение буенча да даими музыкаль тапшырулар алып бара алырлар иде. Чарасына керешкәндә, кадрлар туплау, хәзерләү мәсьәләсен уртак көч белән хәл итәргә була. Күрше республика, өлкә җитәкчеләре бу бурычны үтәүгә ихтирам белән карарлар дип өметләнәсе килә. Чын интернационализм, киң күңеллелек, бар халыкны да тигез күрү концепциясе практик эштә сынала бит.

Ниһаять, яшьләргә музыкаль тәрбия бирү турында бер-ике сүз. Бу эшнең торышы бездә җитди борчылу тудыра. Татар телендә ясле, бакча, мәктәп күрмәгән балалар үз халкының көйләрен дә ишетми үсәләр, аһәңнәрен күңелләренә сеңдерә алмыйлар. Тел кебек үк рухи хәзинәнең бик мөһим өлешеннән мәхрүм калалар. Хәзерге буынның хәтсезендә инде татар музыкасына нигилистик мөнәсәбәт урнашып килә. Андыйлар татар музыкасын аңламый, аның түбән, ямен, моңын тоймый. Радио, телевидениедән үз көйләребез агыла башлады исә, алар тиз генә радионың «колагын» борып кую ягын карыйлар. Чөнки зәвыклары затлы, тирән моңнардан читләшкән, күңелләре карлыккан тавыш белән җырлаучының примитив такмазаларына җайлашкан, башка аһәңнәр үтеп керә алмаслык итеп томалап куелган. Алар ахыр чиктә үз халкының рухын тою сәләтен дә югалтып баралар. Мондый хәл гармоник шәхес тәрбияләүгә бик зур зыян сала, аның аңында үз халкына хөрмәт белән карау хисен җуя, интеллектуаль эрозия барлыкка килә. Тагын да җитдирәк, аянычрак нәтиҗәсе — патриотик тотрыклылык какшый. Яшьләребез эче куыш, мүртайган агачка охшап калмаслармы? Ныклымы, ышанычлымы алар? Күңелгә ирексездән әнә шундый сораулар, шик-шөбһәләр килә.

# Нурмөхәммәт Хисамов

## ДӘРДЕМӘНД

(ТОРМЫШЫ ҺӘМ ИҖАТЫ ТУРЫНДА ОЧЕРК)



Дәрдемәнд[1] иҗаты XX йөз башы татар әдәбияты тарихында аерым урын тота. Бу хәлне, табигый булганча, һәр тикшеренүче диярлек билгеләп үтә.

Шагыйрьнең иҗаты үз чорына хас барлык үзенчәлекләрне: XIX йөз азагы — XX йөз башы арасындагы мәгърифәтчелек идеяләрен, Россиядә беренче революциянең иҗтимагый — сәяси һәм фәлсәфи каршылыкларын, Октябрь революциясе алып килгән кискен борылышны — һәммәсен чагылдыра. Ә сәнгатьчә форма һәм шигъри эшләнеш өлкәсендә көнчыгыш поэтик традицияләрен, шул җөмләдән татарның үз язма һәм халык шигърияте традицияләрен дә, рус һәм Көнбатыш Европа шигъри мәктәбе үзенчәлекләрен бергә кушты, шушыларны тыгыз рәвешкә кертеп трансформацияләде. Кыскасы, ул XX йөз башының Г. Тукай, С. Рәмиев, М. Гафури иҗатларын эченә алган сәнгатьчә закончалыклар кысасында, әмма бу шагыйрьләрдән шактый аермалы, үзгәрәк идеяләр җирлегендә торып иҗат итте.

Дәрдемәнднең күләме ягыннан зур булмаган, әмма фәлсәфи-әхлакый эчтәлеге һәм шигъри осталыгының үзенчәлеге белән гаять зур әһәмияткә ия мирасы совет әдәбиятының бөтен тарихы дәвамында татар шигъриятен тикшерүчеләрдән берәүне дә битараф калдырмады. Берәүләр аңа кискен рәвештә кире бәя генә биреп, икенчеләре бары шигъри осталык җәһәтеннән генә аның әһәмиятен таныса, өченчеләре исә лирикасының җәлеп итү серләрен тулырак төшенергә тырышты. Әмма вульгар социологизм йөге барлык очракта да диярлек мәгълүм стереотиплар чигеннән чыгарга ирек бирмәде. Шунлыктан аның шигъърияте әдәбият белеме өчен асылда һаман чишелеп бетмәгән мәсьәлә булып кала. Аны тулырак аңлыйм дисәң, узган унъеллыкларда урнашып калган схемалардан тәвәккәл рәвештә баш тартырга һәм әсәрләрен җентекләп өйрәнергә кирәк.

---

[1] Шагыйрьнең моңарчы чыккан китапларында «Дәрдмәнд» дип язылган псевдонимын, бер хәреф өстәп, «Дәрдемәнд» дип язу нәрсәгә нигезләнә соң? Барыннан да элек, хәзерге орфография таләпләренә нигезләнә. Мәгълүм ки, гамәлдәге имлябызда ишетелгәнчә язу кагыйдәсе хөкем сөрә. Ә шагыйрьнең исеме телдә һәрвакыт «Дәрдемәнд» дип әйтелә. Монда традиция дә, сүзнең аһәңен саклау теләге дә чагылыш таба: «е» хәрефе төшеп калганда, кушма сүзнең беренче өлеше тартыкка бетсә, азакгы «д» авазы котылгысыз рәвештә саңгыраулаша. Язуга нярәп, хәзерге буын күп очракта шагыйрьне «Дәртмәнд» дип йөртә. Закир Рәмиевнең тәхәллүсенә килгәндә исә, язылыш кимчелеге гарәп әлифбасыннан яңалифкә күчкәндә, тәҗрибә җитмәү аркасында килеп чыккан, гарәптәге тартыкка сузык ялганмый калдырылган. Дөрес, шагыйрьнең үз шигырьләрендә ритм «Дәрдмәнд» дип язуны таләп иткән. Монысында инде гаруз поэтикасы чагыла, чөнки гаруз үлчәмендә иҗекләр тигезлеге, кирәк чакта тартык кына калдырып, икенче очракта сузыкларны саклап хәл ителә. Без, шуларны иста тотып, традициягә атышлы һәм аһәңне саклый торган «Дәрдемәнд» язылышын яңартырга булдык. (Редакция)

Хакыйкатькә бару юлында өзлексез киртә булып яткан берничә схеманы күрсәтеп үтәргә мөмкин. Беренче схема шагыйрьнең барлык идея һәм образларын примитив төстә гадиләштереп, аның иҗтимагый-икътисади хәленә бәйләүдән гыйбарәт. Икенче схема шагыйрьнең идея-сәнгатьчә үзенчәлеген үтә механик рәвештә XX йөз башы рус шигъри мәктәпләренә, аерып алганда, символизмга кайтарып калдыруда чагыла. Өченче схема исә Дәрдемәнднең шигъри идеяләрендәге пессимистик һәм фаталистик мотивларны абсолютлаштырудан тора. Шагыйрьгә тагылган «декадентлык» ярлыгы укучыларны шактый озак шомландырып килде.

Беренче схема безнең көннәргәчә диярлек барлык эзләнүләрне өстән басып килә. Анысы — егерменче еллар әдәбият белеме һәм тәнкыйте калдырган мирас. Бу юнәлеш тарафдарларыннан Ф. С.-Казанлыны һәм С. Мортазинны күрсәтергә мөмкин. Икенче схема Г. Сәгъди хезмәтләреннән башлана. Өченче схема, караш ноктасы буларак, әүвәл Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» очеркында урын алып, аннары Г. Нигъмәти хезмәтендә уздырылды, соңрак Г. Халит хезмәтләрендә яклау тапты.

Дәрдемәнд иҗатының үзенчәлекләрен намуслы рәвештә фәнни аңлатырга омтылучы кеше Г. Нигъмәти булды. Шагыйрьнең мирасын саклау һәм өйрәнүдә игелекле эшне М. Гайнуллин эшләде. Дәрдемәнднең татар шигырен үстерүгә керткән өлешен Х. Госман тикшерде, шагыйрьнең аерым шигырьләрен шәрехләү юнәлешендә тирән һәм ышандыргыч фикерләрне Й. Нигъмәтуллина әйтте. Г. Халитнең соңгы тикшеренүләре шагыйрь иҗатының идея-фәлсәфи эчтәлеген аңлатуда зур адым булды. XX йөз башы татар әдәбиятының идея-сәнгатьчә контекстында шагыйрьнең тоткан урыны И. Нуруллин хезмәтләрендә объектив һәм тулырак чагылыш таба.

Мөхәммәдзакир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев (Дәрдемәнд) 1859 елның 23 ноябрендә Оренбург губернасы Эстәрлетамак өязе Җиргән авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Аның атасы Мөхәммәдсадыйк Габделкәрим улы ул елларда мануфактура белән сәүдә итә. 1862 елда ул шул ук өяздәге Юлык авылына[2] күчеп килә һәм алтын приискысы ача. Алтын чыгаручы миллионер Рәмиевләр тарихы шуннан башланып китә.

Закир башлангыч белемне авылында ала, аннары абыйсы Шакир белән Орск өязенең Муллакай авылы мәдрәсәсендә укый, анда гарәп һәм фарсы телләре өйрәнә. Ул мөстәкыйль рәвештә кечкенәдән рус телен үзләштерә. Журналист И. Рәми язганча, шагыйрьнең әнисе Хәнифә Эстәрлетамак өязенең Явыш авылыннан Алмакай (Әлмөхәммәд) Дашков кызы булган.[3] Бу исә атаклы морза Дашковлар нәселе. Алар арасында русча белем алган кешеләр дә аз булмаган. Закирның кечкенәдән рус телен өйрәнүендә әнисе зур роль уйнаган. Шагыйрьнең кызы Зәйнәп Вәлиева сүзләре буенча, Дәрдемәнд әнисе кебек үк саргылт чәчле булып, үзенең тышкы кыяфәте белән, гомумән, аңа охшаган. «Вакыт» газетасы мөхәррире һәм шагыйрьнең биографиясен язып калдырган әдип Ф. Кәрими сүзләренә караганда, Закир Рәмиев русча камил сөйләшә һәм яза алган, рус әдәбиятын күп укыган.[4] Мондый күренеш ул чор татар тормышында киң таралган дип һич әйтеп булмас иде. Шагыйрь соңрак рус һәм төрек телләре аша Көнбатыш Европа әдәбияты, аның иҗтимагый-сәяси һәм фәлсәфи фикере белән тирән танышкан.

Укуын дәвам итү өчен, Закир Рәмиев 1880 елда Төркиягә китә, анда төрек теле һәм әдәбиятын өйрәнә, әдипләр, шагыйрьләр белән аралаша. Шунысына да игътибар итәргә кирәк, ул елларда төрек әдәбиятында төшенкелек хисләре өстенлек итә.

Россиягә әйләнеп кайткач, З. Рәмиев әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый, төрекчәдән хикәяләр тәрҗемә итә, шигырьләр яза. 1902-03 елларда аның берничә кыска шигыре «Тәрҗеман» газетасында басыла. Бу әле аның өйрәнчек тәҗрибәләре.

Шагыйрьнең чынлап торып күзгә бәрелгән беренче әсәре 1906 елда «Казан мөхбире» газетасында басылган «Каләмгә хитап» шигыре була. Анда ул үзенең эстетик кредосына караган төп принципларын бәян итә: каләмен ихласлыкка, «дөньяга килеп киткәннәр хәлен» язарга, золымга юлыккан, җәберләнгән кешеләр тавышына сизгер булырга чакыра. Ул үзенә «Дәрдемәнд» (сагышлы, моңсу) дигән тәхәллүс сайлаган. Бик күп тикшеренүчеләр бу фактның мәгънәсенә төшенергә тырышканнар, аны шагыйрь иҗатының, алар карашынча, әйдәүче мотивы — моңсулык һәм пессимизм белән бәйләп караганнар.

Безнең карашыбызча, тәхәллүс сайлауда ике момент роль уйнаган: Көнчыгыш поэзиясенең традиция көче, ягъни урта гасыр әдәбиятына хас этикет һәм иҗатының

---

[2] Риза Фәхретдинев үзенең «Асар» дигән энциклопедик хезмәтендә (14 том) бу авылның «чама белән моннан 200 ел элек» килеп утырган Казан татарлары тарафыннан нигезләнүе хакында әйтә. Хезмәт 1927 елда тәмамланган. Кара: Фәхретдинев Р. Кульязмалар мәҗмугасы. («Асар»ның IV өстәмә кисәге). т. 14. 31 бит. СССР Фәннәр академиясенең Башкорт филиалы фәнни архивында саклана.

[3] Кара: Дәрдемәнд әсәрләре. Казан, 1929, 9 б.

[4] Кәримов Ф. Дәрдемәнд.— Дәрдемәнд әсәрләре, 1929, 9 б.

төп аһәң үзенчәлеге. Мәгълүм булганча, урта гасыр Көнчыгыш поэзиясендә шагыйрьнең укучылар алдында үзен тыйнак, кечелекле тотышы әдәп кагыйдәсеннән саналган. Бу исә «Кол» (Кол Әхмәдне, ягъни Әхмәд Ясәвине һәм Кол Галине генә алыгыз), «Мискин», «Фәкыйрь», «Гариб», «Ярлы» кебек псевдонимнарда чагылган. Ә инде тәхәллүснең Дәрдемәнд иҗатындагы аһәң юнәлешенә бәйләнешен мәгълүм искәрмәләр белән генә танырга мөмкин, чөнки аның поэзиясендә яңгыраш һәм моң диапазоны гаять киң. Әйтергә кирәк ки, Тукай да мәхәббәт шигырьләренең берсендә үзен «Дәрдемәнд» дип атаган.

Закир һәм Шакир Рәмиевләрнең хатларыннан һәм Фатих Кәрими белән Риза Фәхретдинев истәлекләреннән күренгәнчә, агалы-энеле бу ике тынгысызның төп кайгысы газета һәм журнал чыгаруга ирешү булган. Шакир Рәмиев Истанбулга энесе Закир исеменә язган хатында хәрефләр сатып алу мөмкинлеге белән кызыксына. Соңрак нәшергә хокук алу һәм бу эшне юлга салу өчен аларга Оренбург һәм Петербург хөкемдарлары каршында озак бил бөгәргә туры килә. Бердә Дәрдемәнд 1905 ел революциясенә зур өмет баглый. «Вакыт» газетасының булачак редакторы Фатих Кәримигә 1905 елның 29 октябрендә язган хатында ул болай ди: «Гәзитә хосусында һичбер тәшәббестә булганыбыз (эшкә керешкәнебез) юк. Оныткан өчен түгел, бәлки мәркәздә әхвәле сәясиянең көн саен тәбдил кылмакда (яхшы якка алмашынуда) вә «явочный порядок» (халык массасының ачыктан-ачык чыгышлары) өмите барган саен куәт алмакда булган өчен. Хода кушып та, тизлекдә хөррият там галәбә тапса (тәмам җиңеп чыкса), «хәзерге хәлендә кабулына мөстар (кабул ителүенә мәҗбүр) булганыбыз күп «чара юк»лар, мәванигълардан (киртәләрдән) котылыр идек». Шул ук вакытта шагыйрьнең ачылуы ихтимал мөмкинлекләргә реалистларча сак каравы да күзгә ташлана. Һәрхәлдә, ул патша манифестына ул чаклы шаккатмый.

«Вакыт» газетасы Оренбургта — 1906 елның 21 февраленнән, «Шура» (Киңәш) журналы исә 1908 елның 10 гыйнвареннан чыга башлый. Бу — либераль юнәлештәге басмалар була. Әлеге басмаларда XX йөз башы татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре Фатих Кәрими һәм энциклопедист галим Риза Фәхретдинев мөхәррирлек итә. Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Шәйхзадә Бабич, Зәйнәп Сәгыйдә, Зариф Бәшири һ. б. шундый демократик әдипләр язышып тора. Габдулла Тукай да басылган. «Вакыт» газетасының демократик эчтәлекле аерым саннарына берничә тапкыр арест, ә наширенә штраф салына. Укучылар дөньясы Дәрдемәнднең шигъри



*Дәрдемәнд Оренбургның татар зыялылары һәм җәмәгать эшлеклеләре арасында. Алдагы рәттә, уңнан (утырганнар): Нурмөхәммәт казый, Гыйнаятулла казый, тарихчы Хәсәнгата Габәши, Оренбург мулласы Габделгалим хәзрәт. Икенче рәттә (басып торалар): Мәхмүд Госманов, князь Хәсән Акчурин, Закир Рәмиев (Дәрдемәнд), Гайсә мөрза Еникеев (Дума депутаты, музыкаль фольклор җыючы, көйләр авторы), Мәхмүд бай Хөсәенев, Габделхәмид Хөсәенев, Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинев.*

*(Р. Фәхретдиневнең «Әхмәд бай» китабыннан алынды. Оренбург, 1911).*

*165 биттә Дәрдемәнднең матбугатта чыкмаган рәсеме. 1900 еллар булырга тиеш.*

иҗаты белән, нигездә, «Шура» журналы аша таныша. Шушы матбугат үзәкләре һәм шагыйрь тирәсендә кочле әдәби мохит барлыкка килә. Дәрдемәнднең әдәби салонында ул еллардагы иҗат җәмәгатьчелегенең иң мөгътәбәр вәкилләре мәгънәви аралашу, әңгәмә һәм бәхәс өчен һәр җомгада очрашып, узара таныша, иман һәм фикер уртаклыгы таба, әңгәмә кора һәм бәхәсләшә торган булган.

Ф. Кәрими Дәрдемәнднең байлык тупларга керешү максатын ачкан сүзләрен китерә. Аның язуынча, шагыйрь моны «иҗатта матди исәпләргә бәйсез булу, күңелеңдә булганны ирекле әйтә алу» өчен зарур дип санаган.[5] Тикшеренүчеләр бу сүзләрне артык беркатлы дип бәялиләр һәм әлеге максатның чынлыгына шикләнеп карыйлар. Хәлбуки, Дәрдемәнд — әсәрләренең үтә ихлас булуы белән аерылып тора. Шагыйрь андый максатының дөреслегенә чын күңелдән инанган булырга мөмкин, әмма тормыш, икътисади кануннар яшь кешенең ниятләреннән көчлерәк булып чыккан, аны үзенең шартларына буйсынырга мәҗбүр иткән. Ә инде аның шигырьләрен кайбер муллалар һәм искелек тарафдарлары гаепләп сөйләвеннән зарлануы хак диярга нигез бар. Шагыйрь соңрак та алар хакында зәһәр-зәһәр һөҗүләрен (сатирик шигырьләрен) язып бастыра.

Дәрдемәнд иҗтимагый актив кеше булган. Ул I Дәүләт думасына Оренбург губернасыннан депутат итеп сайланган, II һәм III Дәүләт думасына сайлау вакытында сайлашучы вазыйфасын үтәгән, Оренбург шәһәр идарәсе әгъзасы булган, мөселман җәмгыяте хәйрияләре, ярлыларга ярдәм, ятимнәрне тәрбияләү комитетларында йә рәис, яисә әгъза булып торган, аларга даими рәвештә матди ярдәм күрсәткән, үз исәбенә чит илләрдә бернича студент укыткан, татар мәктәп һәм мәдрәсәләре өчен күпләп-күпләп дәреслекләр алып биргән.

1912 елда шагыйрьнең агасы һәм нәшер эшендә аның хезмәттәше, якын фикердәше Шакир Рәмиев фаҗигале төстә һәлак булган. Бу вакыйга татар матбугатында киң чагылыш таба. Шунысы кызык, наширнең вафаты уңае белән бирелгән телеграммалар арасында яшь Якуб Чанышевныкы да бар. Анда мәрхүмнең мохтаҗларга игелекле ярдәме санап үтелә.

Бу хәлләрдән соң газета-журнал нәшеренә караган мәшәкатьләр тулысынча Закир Рәмиев өстенә төшә. Шагыйрь ике басманы да, аларның идея һәм эстетик юнәлешләрен саклау шарты белән, берәр рәсми оешма карамагына тапшыруның юридик нигезләрен ачыклау белән шөгыльләнә.

Октябрь революциясе чорында шагыйрь читен хәлдә кала. Бу вакыйгага ул әзерлексез килә.

Шагыйрьдә элек гувернантка булган, соңрак исә Такташның кайнанасы Өммегөлсем Мансурова сүзләреннән күренгәнчә, Дәрдемәнд революциядән соң байлар белән аралашырга яратмаган. «Алар янына барсаң, һаман шул югалган байлыклары турында зарлану гына ишетәсең»,— ди торган булган. Күп вакытын ул гаилә эчендә һәм зыялылар белән аралашып уздырган.

Шагыйрь гражданнар сугышы беткәч тә газета һәм журнал нәшер итүне яңарту хыялы белән яши. Үлем түшәгендә яткан чагында хәлен белергә килгән Риза Фәхретдиневкә ул үзенең шушы ниятен әйтә һәм әдипнең журналга янә мөхәррирлек итәргә ризалыгын сорый. Тик аңа бу хыялны тормышка ашыру инде насыйп булмый — Оренбургтан кайтканда поездда салкын тидереп, ул 1921 елның 9 октябрендә Орск шәһәрендә вафат була. Г. Ибраһимов «Татарстан хәбәрләре» газетасына бу уңай белән язган мәкаләсендә шагыйрьне «уяну көгендәге әүвәлге йолдызлардан иде» дип бәяләп үтә.

Дәрдемәнд иҗатын тикшерүне каләмгә эндәшеп язган шигырьләреннән башлау кулай. Аларда аның иҗат мәсләге чагыла. Шагыйрьнең әүвәл басылган шигырьләреннән берсе «Каләмгә хитап» дип атала. Ул 1906 елда язылган.

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар — гаян ит,*[1]
*Килеп кичмешләр әхвәлен бәян ит.*
*Түгеп күз яшьләреңне бу кәгазьгә,*
*Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!*
*Бабалар кабре янында күңел зар,*
*Аталар рухының армандәсе*[2] *бар...*
*Кара туфрак тулы мәзлум нидасы*[3].
*Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы*[4]*?..*

Сүзлек: 1. ачып сал. 2. үтәлмәгән өмет. 3. зар-ыңгырашу. 4. корбан.

[5] Кара: Кәримов Ф. Дәрдемәнд. 10 б.

Күренә ки, ихласлык һәм нечкә күңел шагыйрь поэзиясенең иң тирән мотивлары буларак күтәрелә. Төп тема исә «дөньяга килеп киткәннәр хәлен сөйләүгә» кайтып кала. Иҗатының әйдәүче аһәңе буларак моңсулык, сагыш игълан ителә.

XX йөз башында милли тарихка игътибар көчәеп китә. Тукайның «Шүрәле» поэмасына керешендәге уйланулар бу яктан характерлы. «Бабалар кабере янында күңел зар» дигәндә шул ук мотивларны күрәбез. «Кара туфрак тулы җәберләнгән җаннар иңгырашуы»нда шагыйрьгә якынрак чор вакыйгалары белән тарихта ерак калган вакыйгалар кайтавазы уртак яңгырый. 1906 ел — царизм белән рәхимсез тарткалашу һәм канлы корбаннар чоры. Столыпин реакциясе алды, аның канлы җәзалары якынлашкан чак.

Каләм образына бәйле икенче бер шигырендә шагыйрь болай ди:

*Килки зарым,*[1]
*Юк язарым,*
*Чөн кабул итми базар...*

Сүзлек: 1. Каләмемнең зары.

Ягъни гавам (толпа) зәвыгына әсәрләр яза алмавын әйтә. Шагыйрь буларак, ул, чыннан да, күбрәк традицияләр өлкәсенә карый.

Шулай да үз халкына карата язмышның рәхимсезлеген күрә торып, аның хөкеме алдында Дәрдемәнднең итагатьле кол булып та каласы килми. Милләтенең аяныч хәлен уйлаганда аңарда көрәшче дәрте кузгала:

*Һөҗүм иткән фәләк җир-җир корып дам...*
*Ишет милләтнең ул фөрьяд вә зарын!*
*Сине бер хам тимер зан кылган ул хам...*
*Чыгар кыйндан каләм — тел зөлфекарын!*
*Мәгънәсе болай:*
*Язмыш җир саен тозак корып һөҗүм иткән...*
*Милләтнең ул ярдәм сорап ялваруын, зарын ишет!*
*Сине бер чи тимер дип уйлаган ул хам,*[1]
*Чыгар кыныннан каләмеңне — телнең изге кылычын!*

Сүзлек: 1. Язмышка карата әйтелгән нәфрәт сүзе.

Дәрдемәнд, шагыйрьлек бурычы турында уйланып, шулай ук каләмгә мөрәҗәгать итә «Кыйтга» («Өзек») шигырендә ул үзенең гамьле каләмен сабан белән чагыштыра, аңа җаннарны ачып, сүз энҗеләрен орлык итеп күмәргә куша, шагыйрьне илтеп күмгәч, туфракка чәчкән сүзләрен җан саклагыч тылсым-бөти итеп тагып йөриячәкләренә ышаныч белдерә. Шигъриятнең тагын да киңрәк мәгънәсе турында шагыйрь дөнья поэзиясенең бөек гуманистлары дәрәҗәсендә фикер йөртә. Каләм бу очракта чыра-пычак рәвешендә метафоралаштырыла.

*Караңгы төн исә якын-ераклар,*
*Хәзин*[1] *кальбемне вакла — як чыракълар:*
*Гарибләр,*[2] *шәмчыракъ*[3] *кургәндә юлда,*
*Дисеннәр: бер заман бар булган ул да...*

Сүзлек: 1. Кайгылы. 2. Чит җирләрдә йөрүче, юлчы. 3. Факел.

Икенче төрле әйткәндә, шигъриятнең бурычын шагыйрь кешеләргә юл яктыртып януда күрә. Шул рәвешле, каләм сурәте Дәрдемәнд поэзиясендә кайбер яклары белән Тукай «Пәйгамбәр»енә аваздаш гуманистик мәсләк мәгънәсенә ирешә.

Әле генә куздән кичергәнчә, шагыйрьнең иҗат программасында алгы планга «килеп киткәннәр әхвәлен бәян итү» куела. Шунысы кызык, яшь Дәрдемәнднең беренче шигырьләрендә үк үткәннәргә күз төбәү күренә. Ихтыярсыздан Ф. Кәрими истәлегендәге сүзләр хәтергә килә. Мин шагыйрьнең байлык туплау максатын күздә тотам. Тормыш уйлаганнан катлаулырак булып чыга һәм шагыйрьнең беркатлырак ниятләрен читкә тибәрә. Җитлегү елларының чынбарлыгын шат һәм кайгысыз үсмер елларына каршы куюын яшьлек идеалларының буржуаз дөнья кырыслыгы һәм катлаулы чынбарлык белән бәрелеш нәтиҗәсе дип кенә аңлап була. Дөрес, яшь кешегә хас булганча, аның табышы әле көр, сулышы киң, хөкем йөртеше гайрәтле. Әле аның шигырендә конкрет тормыш чынбарлыгы чагыла.

Хәзергесен үткәнгә каршы куеп, узган дәверләргә мөрәҗәгать итүе алга таба

тарихтан кырыс һәм дәһшәтле гыйбрәтләр алуга әйләнә, чагыштыру өчен сайлаган янәшәлекләр арасы тарих киңлегенәчә сузыла, һәм моңардан котылгысыз фәна, үлем, юкка чыгу турында нәтиҗә ясала. Нәкъ шуны инде тикшеренүчеләр фатализм дип бәялиләр. Әмма шагыйрьнең сәнгатьчә-фәлсәфи дөньясы, тормышны аңлавы һәм күрүе моның белән генә чикләнми. Без аңарда сәламәт, көр, якты мотивларны да күп табабыз.

Дәрдемәнд үзенең оппозитив фикерләвендә чик төшенчәләр белән эш итә. Кеше язмышының ул капма-каршы иң ерак чикләренә: яшәү һәм үлемгә күз сала. Г. Ибраһимов язганча, «вакыйгъдә үлем белән хәятның икесен дә эченә алган жиһан аңа үлем ягы белән күренә»[6]. Биредә ике факторның: якынлашып килүче тарихи зилзиләне тоемлау һәм Шәрыкънең фәлсәфи шигърияте, аерым алганда Гомәр Хәйям традициясенең аерылгысыз булып чагылуын күзәтергә мөмкин. Муса Җәлил, үсмер чагында яратып укыган шагыйрьләрен искә алганда, Дәрдемәндне Г. Хәйям кебек фарсы шагыйрьләре белән тикмәгә генә янәшә куймаган[7]. Яшәү һәм үлем темасы бу шагыйрьләр иҗатында үзәк темаларның берсен тәшкил итә. Дәрдемәнд биредә аеруча урта гасыр әзәрбәйҗан шагыйре Хаганига якын тора. Хагани исә үзенең «Мәдаин хәрабәләре» шигырендә «кайчандыр Җәмшидләр сафа сөргән сарайлар урынында Бәһрамнарга күләгә биргән җимерекләр генә калганга» көенә.

Дәрдемәнд тарих һәм галәм күләмендә фикер йөрткәндә аның күз алдына вәйранлык, үлем һәм юкка чыгу гына килеп баса. «Без» шигыре, мәсәлән, болай башлана:

*Гасырлар кичте китте... кичте еллар!*
*Нәбиләр,[1] падишаһлар сөрде дәүран[2]...*
*Гомерләрдер күчеп кәрван вә кәрван,*
*Килеп кичте җиһандан канча илләр!*

Алга таба шагыйрь болай ди:

*Исә җилләр, күчә комлар... бетә эз...*
*Дәрийгъ[3], мәхзүн күңел[4], без дә бетәбез!*

Сүзлек: 1. Нәбиләр — пәйгамбәрләр. 2. Дәүран — гомер, дәвер. 3. Дәрийгъ — аһ, үкенеч. 4. Мәхзүн — кайгылы.

Гомернең кыскалыгы, яшәүнең фанилыгы шагыйрьне гаҗизлеккә сала. Ул газап белән үзе һәм милләте өчен «мәңгелек яшәү чишмәсе» (чишмәи әбелхәят) эзли. 1908 елда ул дәфене (күмелер вакыты) җитсә дә, бүзләрен манарга өлгерә алмавын, чөнки милләт өчен яшәү чишмәсе эзләп гомер үткәрүен, ләкин аны таба алмавын яза («Бүзләрем маналмадым»). Бу үкенечкә сәбәп, әлбәттә, ул чор чынбарлыгында оптимизм өчен нигез булмауда гына түгел, шагыйрьнең аны күреп җиткермәвендә, субъектив факторда һәм гомернең тиз үтүчән кыскалыгында да.

Күренешләрне галәм күләмендә иңләве белән Дәрдемәнд Көнчыгыш шигъриятенә, аерым алганда Рудәки-Хәйям традицияләренә барып тоташа, Европа поэзиясендә исә Гетегә тартыла. Аның бер шигырендә сүз уенга чумган бала хакында бара, әмма шагыйрь карашы берьюлы аның гомер азагын да күреп ала.

*Тыя күрмә уен уйнар мәлендә,*
*Әҗәл эшләр эшен үз тәңгәлендә!*

И. Нуруллинның, иҗтимагый-тарихи юлсызлыктан чыгуны шагыйрь тормыш рәхәтләреннән эзли, дигән фикерендә хаклык бар[8]. Әмма беркадәр гадиләштерелгән, тулы булмаган хаклык. Тулырак аңлатманы бары шагыйрьнең фәлсәфи-әхлакый концепциясе яссылыгында гына табарга мөмкин.

Дәрдемәнд фаталистик гаҗизлектән котылу юлын мәхәббәт аша рухани-әхлакый үлемсезлеккә ирешүдә таба. Мәхәббәтне ул бу дөньяның кодрәт ияләрен үзенә буйсындырып килгән мәңгелек табигать кануны итеп аңлый. Шушы кануный хискә кушылып, аның лирик каһарманы да үлемсезлеккә ирешә. Атаклы «Хәят» шигыренең мәгънәсе шушындый. Тикшеренүчеләр бу әсәрнең фәлсәфи идеясе һәм аеруча аның исеме хакында бик күп баш ваталар. Шигырьнең метафорик символикасы, чыннан да, катлаулы, ләкин ул татар шигърияте һәм, гомумән, Көнчыгыш поэзиясе өчен принципиаль яңалык түгел. Шушындый катлаулы метафорик телне без — Низами иҗатында, төрки әдәбиятта исә Котб әсәрендә күрәбез. «Хәят» — Дәрдемәнд иҗатының иң гүзәл әсәрләреннән,

[6] Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. 5 т., Казан, 1978, 105 б.
[7] Җәлил М. Сайланма әсәрләр. Өч томда. 1 т., Казан, 1955, 4 б.
[8] Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. Казан, 1966, 67-68 б.

XX йөз башы татар поэзиясенең сирәк казанышларыннан берсе булып кала. Аның ритмы үтә музыкаль, аваз бизәме гаять бай, аңардагы психологик сурәт искиткеч нәфис.

Дәрдемәнд XX йөз башы татар шагыйрьләре арасында төрки-татар классик поэзиясе традицияләрен үз иҗатында тулырак чагылдырган сәнгатькәрләрдән санала. Ул классик шигъриятнең затлы, гали сүз байлыгыннан, фразеологиясеннән, әдәби этикетыннан бүтәннәргә караганда активрак файдалана. Бу исә чорның шигъри эзләнүләре фонында архаиграк булып та күренә.

Шагыйрьнең «Рәсем» дигән дүртьюллыгында Хәрәзмидән (XIV йөз) алган икеюллык тулысынча файдаланылып, татар халкының әхлакый тәҗрибәсе белән баетылган һәм шагыйрьнең үзенә хас әдәп хисенә өртеп бирелгән. Дәрдемәнд аны «Нәваидән» дип китерә[9].

Шагыйрьнең Котб «Хөсрәү вә Ширин»е белән танышлыгына да җитди дәлилләр бар. Моны без «Хәят» шигырендәге метафоралаштыру үзенчәлегендә дә күрәбез.

Дәрдемәнд:

*Югарыга ташны ыргыткан җүләрләр*
*Үз аңкау башларын тишеп үләрләр.*

Котб:

*Кеше кем күк таба таш атса, зинһар,*
*Теләр кем үз башын үк кыйлса азар. һ.б.*

Сәнгатьчә формасы һәм иҗтимагый-фәлсәфи эчтәлегенең үтә тыгызлыгы белән Дәрдемәнднең иң камил шигыре — ул аның «Кораб»ы. Әсәр «Шура» журналында 1908 елда, ягъни реакция чорында басылган. Тикшеренүчеләр аны Дәрдемәнднең фаталистик лирикасына кертәләр. Г. Халит, мәсәлән, шагыйрь 1905 ел революциясен «илгә һәм кешелеккә һәлакәт китерүче коточкыч стихия итеп саный», дип язды[10]. Тикшеренүчеләрнең җавап эзләгән төп соравы шундый: «Шагыйрь кораб образында кемне яки нәрсәне күздә тота?» Әлеге шигырьгә булган барлык шәрехләрнең нигезендә Дәрдемәнд шигърияттән артык гадиләштереп аңлау ята. «Кораб» шигырен шул чор шигъри процессыннан метафизик аерып кую чагыла. Бу кимчелектән Г. Халит хезмәтләре генә азат. Югыйсә кораб образы ул чорның күп шагыйрьләрен үзенә җәлеп иткән. Барлык очракта да ул татар милләтенең киләчәк язмышы турында уйлануларга бәйле рәвештә кулланыла. Тукай, мәсәлән, «Милләтчеләр» шигырендә:

*Көймә бата; йота торган балык өчен*
*Корбан булган мөрәүвәтле бер җан кирәк,*

— дип яза. Икенче төрле әйткәндә, халык шагыйре, милләтне һәлакәттән саклау өчен корбанга барырга кирәк, дип саный. Г. Камал исә «Милләт корабы» исемле шигырендә (1906 ел) башка кораблар арасында кыю һәм житез юл яручы милләт корабына якты киләчәк юрый. Дәрдемәнд «ил корабы» гыйбарәсен куллана. «Ил» сүзе аның әсәрләрендә еш кына «милләт», «халык» төшенчәсендә йөри. Кораб образы рухы белән Дәрдемәндкә аеруча якын рус шагыйре Фет иҗатында хәвеф тойгысына өртелә. Кешелек язмышы турында уйлаганда Көнбатыш Европа философиясендә бу образны фаталистик мәгънәдә Шопенгауэр куллана[11].

Ни генә булмасын, Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендә кешелекнең фаталистик һәлакәте идеясе ятмый. Ф. Кәрими язганча, шагыйрь төгәл сүзне тапмый торып, шигырен тәмамланган дип санамаган. Тикшеренүчеләр «Кораб» шигырендәге хәвеф мотивына күбрәк игътибар бирәләр, ул хәвефнең асылы турында исә баш ватмыйлар. Ә бит уйлап карасаң, заман һәрьяклап хәвефле. 1905 ел революциясе үзе хәвефле булмаганмы? Монда исә инде реакция котырына. Шагыйрьне корбан кирәклеге борчымый, ә нинди максат һәм нәрсә хакына корбан соралуы борчый:

*Нинди юллар,*
*Кайсы упкын*
*Тарта безне җан сорап?!*

Әлеге метафора нигезендә киң таралган легендадагы корабны һәлакәттән саклау өчен көймәдәгеләрнең берсен мифик балыкка яисә диңгез алласына корбан итү мотивы

---

[9] Тикшеренүчеләр Нәваиенең «Мөхакәмәт әл-лөгатәйн» әсәреннән чыганак итеп китерәләр. Анда урта гасыр төрки шагыйрьләренең әсәрләреннән үрнәкләр бирелгән. Кара: Татар әдәбияты тарихы. 1 т., Казан, 1984, 206 б.
[10] Халит Г. Габдулла Тукай. Казань, 1956, 65 б.
[11] Шопенгауэр А. Мир как воля и представление. Изд-во Маркса, 1968, 129 б.

ята. Андый легенда Г. Ибраһимовның «Диңгездә» хикәясендә дә китерелә. Дәрдемәнд үзен, ихтимал, корбаннар арасында күрә. Әмма шигырьдә куелган сорауның асылы шундый: корабны коткару өчен нинди көчкә корбан бирергә?

«Кораб» реакция елларында язылса да, шагыйрь аңарда революция һәм реакция чорын берләштереп иңли. Вакыт аралыгы образга камиллеккә ирешкәнче оешып утырырга мөмкинлек биргән. Үзенең образлы сыйдырышы белән, гомумиләштерүе, тәвәккәл-хәвефле аһәңе, новаторларча яңа строфикасы һәм сәнгатьчә-хисси тыгызлыгы ягыннан «Кораб» шигыре XX йөз башы татар шигъриятенең иң көчле әсәрләреннән берсе булып чыккан.

Иҗтимагый гаделлек темасы — Дәрдемәнд иҗатының үзәк темаларыннан. Шагыйрь аны төрле яклап куя һәм хәл итә. Традиция рухында хөкемдар һәм халык проблемасы алына, ягъни хакимиятле өстеннәр һәм мохтаҗ түбән катлау кешеләре мәсьәләсе. Гаделлекнең асылын шагыйрь хөкемдарның һәркемгә тигез игелегендә күрә. Үзенең идеалын ул Тәүраттагы мифик гадел патша — Сөләйман образында гәүдәләндерә. Ягъни яһүди, христиан һәм мөселман дөньясының сокланычы булган мисалга мөрәҗәгать итә.

*Килсә кулдан, шат кыйл һәр җанны,*
*Кем ханлык будыр,*
*Тәхет кыйл кырмысканың күңлен —*
*Сөләйманлык будыр!*

Чын бөеклек һәм гаделлекне шагыйрь кечкенә кеше турында кайгыртуга бәйли. Аның гуманизмы көчләүне дә кире какмый, мәсәлән, көчләүчеләргә карата көч куллануны хуплый. Дәрдемәнд үз даирәсеннән булган бераүгә кырыс һәм кинаяле гаепләү белән болай мөрәҗәгать итә:

*Ятимнәр күңлене кырдың, җимердең,*
*Көчең җитсә — бу зиндан ишеген ват!*
*Туган, алдауда мин синнән калышмам,*
*Күрим сине — йә, бу солдатны алдат!*

Үзен ул көчләүче итеп түгел, бәлки гөнаһсыз кырмыска итеп күрә:

*Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан...*

Афоризмга омтылуы һәм тезмәне идея-тематик яктан чәчмә белән тулыландырып баруда Дәрдемәнд Көнчыгыш шигъриятендәге «Гөлстан» авторы Сәгъдигә якын тора. Аның фарсы-таҗик шагыйреннән турыдан-туры алынмалары да бар. Чәчмә миниатюралар лирик каһарман образын, аның дөньяны күрүен тулырак аңлауга ярдәм итә. Андый әсәрләрдә әдип нечкә һәм киң күңелле шәхес, бүтәннәр бәхетен көнләшүдән өстен зат булып күз алдына баса («Габдуллабыз борынгы Габдулла түгел иде...» хикәясен генә алыйк). Чәчмәдә һәм шигырьләрендә шагыйрь дуслыкны дөньяның иң зур байлыгы итеп тасвирлый. Байлык, гомер һәм дуслык мотивлары каршылыгына корылган «Ни гамь бөлсәм...» шигыре бу яктан үзенчәлекле:

*Ни гамь бөлсәм, әгәр үлсәм, ни ваем,*
*Эчеп дуслык шәрабеннән исерсәм,*
*Булып дуслар белән берләктә даим,*
*Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм.*

Г. Халит бу шигырьне Г. Хәйямның «Ләззәтле яшәү өчен, ләззәт хакына яшә. Калганы барысы да — ышан — бары буш ыгы-зыгы»,— дигән юллары белән чыгыштырып: «Шулай ук Дәрдемәнд поэзиясендә дә лейтмотив буларак һаман да шул ике яклы фәлсәфә уздырыла — язмыш каршында бары да буш, көчсез, әмма шулай да бу дөньяда яшәү шатлыгын татып калырга кирәк»,— дип яза. Дәрдемәнд шигыре бу контекстта уңышсыз китерелгән. Болай шәрехләү шагыйрьне, берни уйламыйча, тормыш рәхәте генә кичереп яшәүче дәрәҗәсенә төшерә. Әлеге шигырь исә, киресенчә, гуманист шагыйрьнең гади эпикурчыдан өстенлеген гәүдәләндерә. Әхлакый кыйммәтләрне ул байлыктан югары куя. Байлык һәм нигъмәтләрнең ышанычлы түгеллеген тоя, әлбәттә. Әмма тормышны дуслар белән кичерү мөмкин чагында мондый ихтимал аны куркытмый. Бу шигырьне һәм шагыйрьнең теләсә кайсы бүтән әсәрен бары аның рухани-әхлакый, киңрәк алганда исә, гуманистик иманы яссылыгында карап кына дөрес бәяләргә мөмкин.

Үзенең мәгърифәтчел идеяләре, фәннең, гыйлемнең куәтен данлавы, кешенең танып белү сәләтенә соклануы, укытудагы торгынлыктан һәм кешенең дәрәҗәсен кимсетүче тәрбия ысулларыннан көлүе белән шагыйрь XIX йөзнең олы шагыйрьләре һәм татар иҗтимагый фикеренең күренекле эшлеклеләре белән авазда̄шлык таба. Бу өлкәдә, бигрәк тә афоризмнар белән эш итүдә ул Акмуллага якын тора. Шунысы кызык, шигъри форма, ритм һәм аһәң үзенчәлеген төрләндергәндә, шагыйрь төрки эпос тәҗрибәсенә таяна. Хис һәм сурәт бирелешенең аеруча нәфислеге белән күзгә ташланган «Видагъ» шигырендә бу нык сизелә. Дәрдемәнднең афористик тапкырлык өлгесе эзләп, «Идегәй» дастынына мөрәҗәгать итүе игътибарга лаек.

*Мөгезе бар куйның бары кучкар*[1] *түгел,*
*Очкан кошның бары да шонкар түгел,*
*Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк,*
*Чуканлаган*[2] *аксак ишәк тулпар түгел.*

Сүзлек: 1. Кучкар-тәкә. 2. Чукаңлаган-чатанлаган.

Әлеге шигырьнең барлык афористик фактурасы «Идегәй» текстыннан алынган. Шагыйрь аны шигъри иҗатка кайтарып калдырган. Дастанда әлеге афористик өзек болай яңгырый:

*Атның бары тулпар булмас,*
*Кошның бары шонкар булмас,*
*Ишәк дөя булмас,*
*Сыер бия булмас...*
*Бинең аты би булыр,*
*Колның аты кол булыр...*

Туктамыш хан Идегәйнең улы Норадынга шулай эндәшә. Бире дә иң мөһиме шул: татар халкының борынгы дастаны зур шагыйрьләр колагына чалына килгән, һәм алар аның колоритлы кисәкләрен шул рәвешле кәгазьгә терки барганнар. Дәрдемәнд шигыренең тирән байлыгы һәм үзенчәлеге исә татар шигыренең күп гасырлык төрле чыганакларын үзләштереп тыгызлаудан хасил булган.

Дәрдемәнд, табигать гармониясенә кушылып, яшәү мәгънәсенә һәм дөнья серләренә төшенергә омтыла. Бөтен тирәлекне панорам иңләве белән дә, реалистик төгәллеге ягыннан да, ритм-аһәң һәм калып-төзелеш төрлелеге белән дә аның табигать лирикасы XX йөз башы татар поэзиясенең кабатланмас күренеше булып кала. Бу лириканың фәлсәфи нигезен Г. Халит «пантеистик оптимизм» дип билгели. Шагыйрьнең табигатькә мөнәсәбәтен һәм лирик героеның табигать белән кушылу үзенчәлеген лирик пантеизм дип атарга мөмкин булыр иде. Бу цикл шигырьләрнең күпчелегендә темага импрессионистларча якын килү сизелә, икенче төрле әйткәндә, сәнгатькәрнең игътибары күренешләрне күбрәк шәхси хиссияте аша үткәреп кабул итүгә юнәлә. Мондый шигырьләр форма ягыннан да традицион поэзия кысаларыннан тулысынча азат дәрәҗәдә диярлек иркен төрләнүчәннәр. Алар йә таныш ритмик тезмәләрнең музыкальлеген саклаган хәлдә яңа строфик рәвеш ала, йә бөтенләй ирекле шигырь төсенә керә. Бу исә шулчаклы табигый һәм гади килеп чыга ки, укучы хәтта форма үзенчәлеген дә сизми кала. Әнә шулай талантлы рәвештә һәм күзгә артык ташланмыйча, шагыйрьдә милли шигырь яңарышы бара.

Менә берничә мисал.

*Ятам кайчакларны моңлап,*
*Һаваның тынлыгын тыңлап,*
*Килә өннәр колак чыңлап,*
*Диямен:*
*— Ни бу? Нидәндер бу?*
*Җавап урнына гөрли су,*
*Тирәклек тирбәнә, шаулый!*

Яки:

*Бу ул матур, бу ул куркәм,*
*Бу ул,*
*Бу ул — хуш исле яз!*
*Бу ул — хуш исле таң җиле...*

Беренче очракта каршыбызда тирән уйлануларның психологик сурәте калыкса, икенче очракта табигать яңарышыннан хозурланучы, тантана итүче шагыйрь җаны күз алдына килә. Мондый үрнәкләр соңрак шигырь формасын яңартуда Һади Такташ ясаган даһи тәҗрибәләргә, һичшиксез, этәргеч биргән булырга тиеш.

«Сеңеп җиргә...» дип башланган шигырь үтә нечкә күзәтү һәм сынландырулары белән импрессионистик төсмер ала. Анда табигатьнең бер халәттән икенче халәткә күчеше, әверелеш нечкәлекләре тасвир кылына. Елганың агуы, суларның ташларга бәрелеп чәчрәве, таулар арасыннан бормаланып, кубекләнә-кубекләнә узуы, яктыда дулкын-дулкын булып бөтерелеп пар-бу күтәрелүе, күз яше бөртегендә кояш нуры чагылып, аны алсу кан төсенә кертүе сурәтләнә, шагыйрь җанындагы киеренке драматизм чагыла.

Дәрдемәнд шигъриятенең үзәгендә туган ил мотивы ята. Аның шәхси һәм иҗади драмасы шушы мотив тирәсендә хәл кылына. Шагыйрь өчен изге булган ватан сүзе гаять киң сыйдырышлы: ул — туган җир төшенчәсен дә, киңрәк исә милләт һәм тулаем туган ил мәгънәсен дә үз эченә ала. Ул үзен иле язмышына бирекkән итеп күрә:

*Булырмы яз, исеп җилләр,*
*Килерме җәй, ачып гөлләр;*
*Җитәрме кыш, кичеп еллар,—*
*Диямен, сез, газиз илләр.*

Шагыйрьнең шушы темага язылган атаклы икенче бер шигыре икърарының сафлыгы, иҗтимагый аңының югарылыгы белән җәлеп итә:

*Атам-анам йорты өчен*
*Булса мең җаным фида,*
*Туган-үскән илем өчен*
*Соң тамчы каным фида.*

Дәрдемәнд, аерылгысыз булган «ватан» һәм «туган халык» төшенчәсен дилеммага әйләндереп, үз алдына үтә драматик сорау куя. «Гөрләгән сулар...»,— дип башланган шигырендә:

*Ни газизрәк, бу ватанмы?*
*Аһ, туган каумем газиз,— ди.*

Биредә татар халкының милли-тарихи язмыш үзенчәлеге, аның төрле җиргә таралып утырганлыгы, күпчелегенең борынгы милли үзәгеннән аерылган булуы чагылыш тапкан.

Октябрь революциясе шагыйрь алдына: «Син кем ягында?» — дигән сорауны бөтен кискенлеге белән куйды. Бу сорауга анык сыйнфый җавап сорала иде. Дәрдемәнд үз сыйнфыннан аерылган, җиңүче сыйныфка исә кушылып китә алмаган хәлдә, ике уртада торып кала. Ватан мәсьәләсендә ул үзенең тар сыйнфый эгоизмыннан югары күтәрелә алды. Шушындый драматик шартларда ул үзе өчен бердәнбер дөрес нәтиҗәгә килә:

*Илдә бер дус булмаса гәр,*
*Ил бөтен дошман түгел.*

Шагыйрь үз сыйныфына карата тарихның кырыс хөкемен ирләрчә кабул итеп, Октябрь революциясенә мөнәсәбәтен ап-ачык билгеләп. Социалистик революцияне ул илнең тормыш туе дип атый, яңа тормыш башлануы итеп саный. Алай гына да түгел, ул үзе шушы туйга «кияү» булырга әзерләнгән, әмма туйның үзе өчен уздырылмавын яхшы төшенә.

*Җиһан тормыш туен иткән чагында*
*Синең урның үлекләр аймагында.*

Тормышның яңа хуҗалары белән яманатлы булмас өчен, аның сазы бөтенләйгә тына.

*Дилең өчен телең булсын тозаклы*
*Йөз аклыгың өчен аузың йозаклы,—*

дип киңәш итә ул үз-үзенә.

Сәнгати күренеш буларак, Дәрдемәнд иҗаты төрле шигъри мәктәпләр һәм эстетик башлангычлар үрелмәсеннән хасил. Көнчыгыш-Көнбатыш синтезына аяк басканда, ул татар теленең сафлыгын да, фольклорга хас шигъри фикерләүне дә үзләштерә, үзенең шигъри палитрасын халык эпосы ритмнары һәм калыплары белән сафландыра, сөйләмнең интонацион мөмкинлекләреннән файдаланып, шигъри синтаксисны камил-

лаштерә. Форма, эчтәлек һәм мотивлар өлкәсендә, әлбәттә, аның нигез платформасы булып классик төрки шигырь кала. Шушы нигездәге Көнчыгыш башлангычын ул рус һәм Көнбатыш Европа поэзиясенә хас форма, алымнар һәм аһәң белән кушa. Татар җанлы сөйләм интонациясенә нигезләнүнең гамәлдәге тәҗрибәсе һәм конкрет үрнәкләре белән ул шигырь төзүнең үзенә кадәрге классик поэзия практикасына таныш булмаган рациональ юлларын күрсәтеп бирә. Мәсәлән, «Бүзләрем маналмадым» әсәрендә шигъри юлларның тулы синтаксик вариантыннан соң аның интонацион кыскартылган вариантын китерә:

*Кемгә васләт*[1], *кемгә өмид*
*Нигъмәтен бирде фәләк*[2].
*Мин өмиднең сул кулыннан*
*Бер сынык нан алмадым.*
*Кемгә васләт, кемгә өмид!*
*Мин сынык нан алмадым.*

Сүзлек: 1. Васләт-кавышу. 2. Фәләк-язмыш, тәкъдир.

Дәрдемәнд шигъри тәҗрибәсенең әһәмияте XX йөз башы һәм безнең көннәрдәге татар поэзиясе өчен гаять тирән булды. Лирикасының идея һәм мотивлары ул чор татар зыялыларының фикер һәм кичерешләренә күп яклап аваздаш яңгыраган. Үз чорында аларны Г. Ибраһимов та уртаклашкан. Сәнгатьчә эзләнүләре һәм, гомумән, шигъри культурасы белән Дәрдемәнд еш кына Тукайга якын тора, кайвакыт исә аның белән бәхәскә керә. Шигырьләрнең аваз бизәме, аһәңдәшлеге (ассонанс) һәм эчке рифмалар муллыгы ягыннан бу ике шагыйрь арасында уртаклык шактый. Монда үзара ярыш һәм бер-берсеннән өйрәнү дә чагыла булса кирәк. Менә үзенчәлекле берничә мисал.

Дәрдемәнд:

*Ил мөмәййез*[1], *аңлар ул тиз,*
*Син аны сизмәс, димә.*

*Җитте дәфнем вакты,*
*Кәфнем бүзләрен маналмадым...*

Сүзлек: 1. Мөмәййез,-сизгер.

Тукай:

*Үзләре сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән...*

*Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур,*
*Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур.*

Кыскасы, бу шагыйрьләрнең икесе дә шигырьне аваз ягыннан эшкәртүдә, ягъни инструментовка өлкәсендә, үтә нечкә осталыкка ирешәләр.

Дәрдемәнд яшь Исәнбәткә, М. Җәлилгә, Х. Туфанга, С. Хәкимгә бәрәкәтле йогынты ясаган, хәзерге татар поэзиясендә исә аның шигъри мәктәбеннән Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Гатауллиннар уңышлы файдалана.

# Мөхәммәт Мәһдиев

## РӘМИЕВЛӘР НӘСЕЛЕННӘН БЕРӘҮ

*Казан университетының гыйльми китапханәсендә библиограф Исмәгыйль Рәми белән байтак еллар бергә утырып эшләгән идек. Шул чорда (мин инде, әлбәттә, аның «Вакытлы татар матбугаты» исемле белешмәлек авторы икәнен белә идем) аннан тәрҗемәи хәлен язып бирүне үтенгән идем. Әдәбият тарихын өйрәнүчеләргә моны кызыксыз булмас дип уйлап тәкъдим итәм.*

### Үткәнем турында

Минем үткәнем кемгәдер кирәкkәннән түгел. Сез кыстап сораганга яздым. Юкса, автобиография язу — хезмәте дәү кешеләргә генә килешә икәнен белмим түгел.

Биографиямнең башы стандарт калыптан чыксын әле дип, кызык өчен аның очын әллә кая суздым. Тамыры Болгарга барып тоташа.

Шәҗәрәм (нәсел язуым) болай икән: мин — бәндәгез Исмәгыйль булам, миннән югары ягы — этием Габдулла бине Габделхалик бине Хәлим бине Сәлим (бусы заманында Сәлим ахун дип билгеле булган). Сәлим ахун Минзәлә ягыннан Зәй суы буендагы Тайсуган авылыннан күчеп, Эстәрлетамак каласына килеп утыракланган (1770 еллар тирәсе). Сәлим ахунның зөррияте (токымы) Эстәрлетамакта күптер. Югарыда күренгәнчә, ахунның Габделхалик дигән туруны (оныгы) бәндәгезнең бабасы була; ахунның бер улының улы Лотфулла, аның улы Сәгыйть (бусы инде шагыйрь Сәгыйть Рәми); ахунның бертуганы Исмәгыйльнең улы Габделкәрим, аның улы Садыйк, аның уллары Шакир белән Закир (бусы шагыйрь Дәрдемәнд була).

Рәми ләкабе кайдан килә?

Сәлим ахунның югары ягы болай — Сәлим бине Рәхимкол бине Урман бине Кабкай бине Юлай бине Колай бине Сөләйман бине Тимри бине Рәми бине Исхак бине Миргалидер. Соңгысы, Болгар шәһәре монгол баскынчылары тарафыннан харап ителгәч (1226 еллар), Болгардан Зәй тамагына тартылган.

Риваятьләргә күрә, Тимри бине Рәми дигәне Мәскәү патшалыгында (Иван III чорында) дәүләт хезмәтендә булып, ничәмә еллар тылмач буларак эшләгән, руслар арасында «Митрий Рамиев» димәкле шөһрәт булмыш. Рәмиев ләкабе (фамилиясе) шуннан калмыш. Рәмиевләрнең берсе турында Загоскинның «Юрий Милославский» исемле тарихи романында да сөйләнә.

Шулай булгач, бәндәгезнең «Болгари» дигән кушамат тагарга да хакы бар икән.

Шулаен шулай да, үзеңдә әллә ни хасият булмаса, нәсел-нәсәбең белән мактанып еракмы китәрсең!

Инде кирегә кайтып төшик. Мин 1895 тә Эстәрлетамак каласында тудым. Әтинең вафатын хәтерләмим. Ул бәләкәйдән әзрәк югары урта кул сәүдәгәр булган. Әтидән калган китаплар арасында Истанбул басмасы әдәби әйберләр, Казан басмасы «Диване хикмәт» (Ясәви), «Сөбат-эл-гаҗизин» белән «Бакырган», «Мөхәммәдия» (Чәләби), К. Насыйри «календарь»лары хәтеремдә. Моннан, заманасының әдәбиятын күзәтеп барган бер кеше булган икән, дигән хөласә (нәтиҗә) чыгарам.

Шулай, тудым. Тугач, нишлисең, гадәт буенча үстем. Ул чагындагы һәр татар баласыдай «Әлепти»дән сабак башлап, «Әптияк»кә күчеп, «Әмали» тәрҗемәсенә барып җиттем. «Әүвәл алдым бер куян тиресе, бәһасы булды 10 тиен көмеш», — дип язарга да өйрәттеләр. Аннан башлангыч 3 класслы рус-татар школасында укыдым. Яңа метод (ысулы җәдит) мәктәбендә рөшди 3 сыйныф укыгач, 1911 дә Эстәрледән киттем. Туган илдән читкә китүчеләрне: «Бәхет эзләргә китте», — дип озата иделәр ул чагында.

Мин Казанда. Учительская школага керү ниятендә йөрим. Ул елны школага Бубилар килеп тулдылар. Бу мәдрәсә жандармерия тарафыннан таратылган иде. Буби шәкертләренең хәзерлекләре безгә караганда кая югары булганга, алар белән ярышып булмады. Пансионатка (казна исәбенә) алар урнаштылар. Читтән йөреп (үз хисапка) укырга чама туры килмәгәч, байга контора хезмәтенә яллапдым. Кайберәүләр бай хезмәтен «Ашау байдан, үлем ходайдан» дип, кайгысы юк кебегрәк итеп сөйләсәләр дә, алай түгел. Тәүлегенә кимендә 12-14 сәгать эшне җилкә алай җиңелдән күтәрми.

Мәктәп тәрбиям әнә шуның белән тәкәнде.

Ел ярым чамасы байда эшләгәч, «Иртәнге 8 дән кичке 8 гәчә, күбесенчә 10 гача конторада утырып кеше күреп, дөнья танып буламы?» дидем дә, «Сәйяр» драма труппасына суфлер булып кучтем. Гастрольгә чыгу, төрле калаларны күрү, кешеләр белән танышу, гомумән, дөнья күрү мөмкинлеге мине кызыктырды. Шунда инде күпләр белән очраштым, таныштым. Исемнәре матбугат аша гына билгеле кешеләрнең барысын булмаса да, күпчелеген күреп белдем дисәм, ялган булмас. Шулай ил күреп, кешеләр белән очрашып, аралашып йөри торгач, ышкыла торгач, кулга төшкәнне укый торгач, системасыз булса да белем хасил иткәндәй булдым.

Миндиләрне халык «укымыйча мулла булган» ди.

Шулай тормыш мәктәбе биргәнне, ишеткән-күргәнне хәтер капчыгына салып йөргән чагында, 1914 елгы сугыш башланды. Ул көннәрдә труппа Мәкәрҗә ярминкәсендә иде. Призывка кайтырга кирәк иде. Артист Габдулла Камал белән: «Безне анда кайтсак та алалар инде, монда булса юл чыгым юк, арзанга төшәр», — диештек тә, Нижний-Новгород военский начальник идарәсенә бардык. Анда-а-а... кыямәт, запасларга мобилизация бара. Безнең белән сөйләшеп тә тормыйча, «илегезгә кайтыгыз» дип әйләндереп чыгардылар.

1915-1917 еллар — патша армиясендә (Уфада 103 полк штабында писарь).

1917-1922 еллар — Кызыл Армиядә (1 һәм 5 армия политбүлекләре янында чыккан фронт газеталарында эшләдем. «Кызыл яу», «Кызыл йолдыз», »Кызыл дөнья» газеталары).

1923-1925 еллар — Уфада чыккан газеталарда («Кызыл юл», «Урал», «Шәрыкъ ярлылары»).

1925-1936 еллар — Казанда Татарстан нәшриятында һәм «Кызыл Татарстан», «Чаян», «Яңалиф» редакцияләрендә.

1937-1942 еллар — мәгълүм «хаҗ»дә.

1942-1943 еллар — хезмәт армиясендә (Уралда — Алапаевск, Нижний Тагил шәһәрләрендә).

1944-1945 еллар — армиядә (Свердловскида, офицер составының хәзерлеген күтәрү буенча курслар штабында, тагын писарь).

1945 елда демобилизация белән Казанга кайттым.

1945-1957 еллар — Кайбычта район газетасында.

1957-1960 еллар — Дөбъяз районында пенсиядә.

Шуннан соң Казанда, язгалаштырам.

Тәмам.

И. Рәми.

1964 ел, декабрь.

*Исмәгыйль Рәмиев утызынчы елларда байтак кына сатирик хикәяләр язган кеше. Ул — библиограф иде. Аның татар культурасы, әдәбияты буенча төзегән белешмә-сүзлек кулъязмасы (бер мең бит чамасы) җитмешенче еллар алдыннан тикшереп фикер алышу өчен Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренә тапшырылган иде. Әмма кулъязма кулдан-кулга йөреп югалды. Исмәгыйль ага ул арада үлеп тә китте. И. Рәмиевнең 1965 елда «Истәлекләр. Татарча басма сүз» исемле китабы басылып чыкты.*

# «СЫНАТМАСКА КИРӘК, ҖЕГЕТЛӘР!»



*Нәкый Исәнбәт...*

*Татар халкы, аның мәдәнияты өчен башкарылган титаник хезмәте белән үз исемен мәңге онытылмаслык итеп тарихка, буыннар хәтеренә язган олы галим, олы әдип, хөрмәтле аксакал. Татарстанның халык язучысы.*

*Бу айда республикабыз җәмәгатьчелеге һәм киң илебез буйлап, дөнья буйлап чәчелгән бөтен татар халкы менә шушы фидакарь шәхескә 90 яшь тулу көнен билгеләп үтә. Шул уңайдан редакциянең әдәби тәнкыйть бүлеге редакторы Мансур Вәлиев әдип һәм галим Нәкый ага Исәнбәт белән әңгәмә уздырды. Укучыларыбызга шул әңгәмәне тәкъдим итәбез.*

—Нәкый ага, үзегез дә беләсез, хәзер бөтен ил милли мәсьәлә дип шаулый. Безгә дә әңгәмәбезне әнә шуннан башламый булмастыр... Сез инде 1899 елда, теге гасырның ахырында ук туган кеше. Үз гомерегездә әллә ничә революция кичергәнсез. Әллә никадәр үзгәртеп коруларны күргәнсез... Ә соңгы елларда ил эчендә барган вакыйгалар Сездә нинди уйлар уята икән?

— Халыкларның уянуын начар нәрсә дип әйтеп булмый. Алар иң гади хакыйкатькә ирешергә — үз язмышларын үз кулларына алырга телиләр. Чит илләр һәм андагы колонияләр хакында сүз барган вакытта без милли-азатлык хәрәкәтен бик яклыйбыз бит. Ә нигә ул хәрәкәтне үз илебез эчендә дә якламаска?! Һәр халык үз язмышын үзе хәл итсен! Моны Ленин шулай куйган. Мәсьәләне бары тик шулай куйганда гына гадел рәвештә хәл итеп була. Илдәге тынычлыкны да әнә шул юл белән генә урнаштырырга мөмкин.

— Ә мәсьәләгә якынрак килеп караганда?

— Нәкъ менә шул якынрак килеп карау җитми шул! Сүз күп, ә эш аз! Милли мәсьәләне үзгәртеп кору кирәклеге хакында югарыдагылар да сөйли, түбәндәгеләр дә сөйли. Сөйләмәгән кеше юк. Ә эшнең торышы һаман да бик, бик акрын үзгәрә. Күп тармакта бөтенләй үзгәрешсез кала хәтта.

— Нәрсәләрне күздә тотып әйтәсез микән?

— Милли культураның иң үзәк мәсьәләсе — мәктәп һәм балалар бакчасы. Ана телендә мәктәпләр һәм балалар бакчалары оештыру кирәклеге турында инде тонна-тонна кәгазь языдды, әллә никадәр чыгышлар ясалды. Ә асылда үзгәреш юк диярлек... Безнең үзебезнең бик яраткан оныгыбыз бар. Бер көнне балалар бакчасыннан: «Татарча сөйләшә башладык»,— дип бик сөенеп кайткан бу. Без дә сөендек моңа. Ә инде күпме вакыт ана теле өйрәнгәннәрен белешкән идек — 15 минут чамасы икән! Атнага 3 мәртәбә генә. Менә сиңа мә! Бәләкәй бала үзенең ана телендә шуның кадәр генә сөйләшергә тиешме?! Бу бит адәм көлкесе! Ана телендә тәрбия бирәбез диеп күз буяу гына ич ул!

---

* *Әңгәмәдә бәхәс уятырдай яисә килешүе кыен булган урыннар да бар. Төрле-төрле карашларга игътибарлы булу заманын истә тотып, Нәкый Исәнбәт фикерләрен кыскартмыйча һәм үзгәрешсез килеш бирәбез. (Редакция).*

— Нәкый ага, мәнә Сез «ана телендә тәрбия» дигән гаять мөһим мәсьәләгә килеп кагылдыгыз. Безнең хәзерге педагогика һәм ата-аналар баланы үз туган телендә тәрбияләмичә бик зур ялгыш ясыйлар бит. Кешенең меңләгән еллар буенча атадан балага күчә-күчә килгән геннары, күзәнәкләре — алар ана телендә аралашуга күнеккәннәр, шуңа ияләнгәннәр. Балага чит телдә эндәшеп, без аның эчендәге бик мөһим бер системаны бозабыз... Сез — халык күңелен нечкә аңлаучы һәм балаларга карата үтә сизгер әдип, галим — бу хакта ничегрәк уйлыйсыз?

— Менә сез, яшьләр, табигатькә генә күз салыгыз. Анда бит каенның үз холкы, имәннеке үзенчә, бөтән характер. Юкә исә бөтенләй икенче төрле... Боларны бер төрле итәргә тырышу бик зур ахмаклык булыр иде. Табигатькә карата әлегә андый ахмаклыкны эшләүче юк. Ә милләтләргә, халыкларга карата ник шундый ялгыш эш, табигатькә каршы эш эшләнә?! Халыклар, милләтләр дә — табигатьнең шундый ук гүзәл җимешләре бит. Аларны кысу, бетерү хокукы беркемгә дә бирелмәгән!

— Зур тормыш тәҗрибәсе туплаган хөрмәтле аксакал белән әңгәмә вакытында тагын бер четерекле мәсьәләне ачыклап китәсе килә. Соңгы вакытта матбугатта басылган мәкаләләрдә еш кына «уртак өй» дигән төшенчә кулланыла. Сез моңа ничек карыйсыз? Чынбарлыкта уртак өй була аламы?

— Брежнев чорында, милләтләрне санга сукмыйча, «совет халкы» дигән яңа терминн кертергә тырышу булган иде. Без хәзер инде бу ялгыштан котылып киләбез шикелле... Минемчә, әлеге «уртак өй» идеясе дә шул ялгышның. Шомбай сыман, тунны икенче ягы белән киеп, безнең каршыга яңадан килеп чыгуы шикеллерәк хәл. Бер дә бөтән түгел. Бер өйдә бит бер генә гаилә яши. Шәһәр вариантын алсак: анда да бер фатирда бер гаилә яши. Бер фатирда ике яисә өч гаилә яшәү — монысы инде аның гадәттән тыш хәл! Ул чагында инде юньле тормыш булмый. Сез әйткән «уртак өй» идеясе дә әнә шуңа алып бара. Анда бәхәс, тигезсезлек өчен бик күп мөмкинлекләр кала. Даими рәвештә канәгатьсезлек туачак андый өйдә.

— Шул уңайдан, безнең бик күп милләттәшләребез читтә яши бит. Аларның киләчәк язмышын Сез ничек итеп күрәсез?

— Иң элек мин шуны әйтергә тиешмен. Нигә шул хәтле дә чәчелгән бу татар халкы?! Туган-үскән җиреннән ни өчен алай җиңел аерылган ул?! Бу — минем өчен бер сер кебек... Ә инде читтә яшәүчеләрнең киләчәк язмышына килсәк, мин бу мәсьәләдә пессимист. Татарстанда Алабуга кебек зур заводлар төзелеп ятканда, мөмкинлекне файдаланып калырга кирәк. Безнең бәхетне Татарстан гына гарантияли ала дип уйлыйм мин.

— Сез җыйнап бастырган татар халык мәкальләре томына «Читнең чите корысын!» дигән әйтем бер дә юкка гына кертелмәгән. Меңләгән татарларның ачы язмышы чагыла бугай ул кайнар сүзләрдә. Нәкый ага, Сезнең хакта, фразеологик сүзлек төзегән, дип тә ишетә беләбез. Ул кайчан дөнья күрәчәк соң? Алтмышынчы елларда басылып чыккан өч томлык мәкальләр кебек, бусы да бик зур хезмәт бит инде аның...

— Әйе, Татарстан китап нәшрияты бу сүзлекнең чыгачагын үзенең 1987 елгы тематик планында ук хәбәр иткән иде инде. Ниһаять, якын арада сүзлекнең беренче томы дөнья күрер дип уйлыйм. Бусы сөенеч булса, бик күп материалның аңа керми калуы — минем өчен көенеч. Беренче томга, мисал өчен, 14 табак (340 бит) эшләгән эш керми калды. Икенче томына да 20 табак (480 бит) материалның сыймавы бар. Моны мин ничек аңлатырга да белмим...

— Шуның өстәвенә, басылмаган әйберләрегез тагын да бардыр әле...

— Алары да шактый. Башкорт халык авыз иҗаты буенча төзелгән калын хрестоматия бар. Татар халкының мифлары турында мәкаләләр күп. Шагыйрь Һади Такташ турында өч табак күләмендә истәлегем бар... Казан арты авылларында фольклор әсәрләре җыеп йөргәндә күргәннәремне тасвирлаган истәлекләр бар...

— Нәкый ага, уенын-чынын кушып әйткәндә, Сезнең хезмәтләрнең үзләрен бастыру өчен генә дә яңа бер нәшрият яисә журнал ачарга кирәк кебек күренә.

— Ә нигә, алар барысы да халыкка кирәкле әйберләр ич. Егерменче елларда татарның нәшриятлары, журналлары күп иде аның. Хәзерге сыман бер нәшриятка карап зар елау юк иде. Халык күңелен дөрес тәрбиялим дисәң, бүтән юл юк та! Моны инде аңларга вакыт.

— Нәкый ага, әйтик, татар халкының җан башына туры килгән периодик басмалар саны эстоннарныкыннан 40 мәртәбәгә азрак...

— Хәлне төзәтү өчен көрәшәсезме соң? Яшьләр бит алар көрәшергә тиеш! Сезне татар халкы ни өчен үстерде, укытты дип беләсез?! Матбугатлар оештырып үзен агартсын, тәрбияләсен өчен үстерә бит халык интеллигенцияне. Халыкны тәрбияләү — зыялыларның иң төп бурычы. Сез бу юлда кыю, тынгысыз булырга тиешсез! Курыкмаска тиешсез. Чөнки бу — сезгә халык тарафыннан, меңләгән, миллионлаган хезмәт ияләре тарафыннан йөкләнгән вазифа... Бездә кайчак интеллигенцияне дөнья бутап

йөрүче итеп күрсәтергә тырышу бар. Бигрәк тә югарыдан килгән түрәләр аны шулай итеп күрсәтергә тырыша. Ә интеллигенциянең андый миссиясе — бик борынгы чорда башланган хезмәт бүленешеннән үк килә. Эшче кеше заводта тир түгә, крестьян басуда эшли, интеллигент исә халыкның күңел дөньясын кайгырта. Моны аңламаган надан кеше генә зыялыларга кырын карарга мөмкин.

— Менә, бик озак көрәшкәннән соң, яшьләребез өчен «Идел» журналы булдыруга ирештек...

— Әйе, әйе, моңа мин дә бик сөендем. Нәҗибә апагыз белән без инде аның бер битен дә калдырмыйча укып чыктык... «Идел» — сугышка кадәр татар телендә басылган күпләгән яшьләр журналларының берсен яңадан торгызу булды.

— Ә хәзер язучыларыбыз әдәбият-сәнгать газетасы көтә инде. Үзенең «Әллүки» кушымтасы белән «Социалистик Татарстан» аны чыгару өчен бик әйбәт нигез әзерләде. Язучылар да, укучылар да «Әллүки»дә актив катнаша. Әдәби газета булса, ул халыкка тагын да активрак хезмәт күрсәтер иде...

— Яңарыш чорында милли матбугатны көчәйтү кирәк, әлбәттә. Һичшиксез, кирәк. Менә әле мин «Татарстан яшьләре»н күзәтеп барам. Бик кызык чыгаралар газетаны. Шуңа күрә тиражы да зур. Халык та ярата, димәк. Соңгы елларда «Социалистик Татарстан» да әйбәтләнә төште. Кыюлыгын арттыру хисабына әйбәтләнде ул. Безнең язучы һәм журналист җегетләр шуны онытмасыннар иде: талант белән кыюлык һәрвакыт янәшә йөри, алар — аерылмас бербөтен! Алга-артка, ян-якка да карап, халыкка да ярап булмый. Үз йөрәгең кушканны, үзеңнең халкың көткәнне яз син! Менә шунда инде ялгышмассың!

— Матбугат дигәннән, халкыбызның онытыла башлаган зур шәхесләре турында газета һәм журналларыбыз яңадан язарга керешә. Андый зур шәхесләрнең берсе — Гаяз Исхакый. Бу әдипнең әсәрләре дөньяга чыгуны Сез ничек бәялисез?

— КПСС өлкә комитетының беренче секретаре булып Ф. Табеев эшләгән елларда ук без, бер төркем язучылар, аның янына барган идек. Гаяз Исхакый әсәрләрен халыкка җиткерү кирәклеген партия җитәкчесенә кат-кат раслаган идек. Әмма аның җавабы бер булды: «Әле вакыты җитмәгән!»

Әдипнең катлаулы язмышына килгәндә исә, үткән чорда ялгышлар һәр ике яктан да ясалды. Ил башына менеп утырган Сталин үз илебездәге күпме талантларны суйды, дөньяны болгатты. Хәтта әле Брежнев чорында да никадәр намуслы иҗатчылар илдән китәргә мәҗбүр булды... Шуңа күрә матбугатта басылган кайбер мәкаләләрдә Исхакыйга кара ягулар белән мин килешә алмыйм. Вакыйгаларга шул чорның катлаулы контекстыннан чыгып карарга кирәк. Мин Исхакыйда гаеп юк дияргә җыенмыйм, ләкин шул ук вакытта аны гел кара төскә генә буярга теләүчеләр белән дә килешә алмыйм. Башка милләтләрдә аннан зуррак хаталанучылар да бар, ә аларга Исхакыйга ташланган кадәр гаеп ташланмый. Мине мәсьәләнең әнә шул ягы бераз сәерсендерә. Без гаепле кешеләрне гел татар арасыннан гына эзләмик инде, җегетләр!

— Ә шәхес культы еллары Сезнең язмышка ничек тәэсир итте?

— Иң башта шунысын әйтим: минем мулла малае булып тууымны гомер буе зур гаепкә санап килделәр. Сыйнфый дошман итеп күрергә тырышучылар да булды хәтта...

— Менә бүген без әлеге «сыйнфый дошман»ның татар халкы өчен никадәр эш эшләгәнен күрәбез. Утыздан артык сәхнә әсәре язган ул. «Уракчы кыз» белән «Син сазыңны уйнадың» һәм «Бормалы су» шикелле матур-матур шигырьләр тудырган ул. Дөнья һәм рус классикларыннан ничәмә-ничә зур әсәр тәрҗемә иткән ул. Татар халкының тел, әдәбият хәзинәләрен җыю, барлау, гыйльми өйрәнү һәм аларны системага салып, бастырып чыгару өлкәсендә армый-талмый эшләгән ул! Сугышка кадәр үк «Идегәй» дастанын халыктан язып алу һәм бастырып чыгару, татар халык мәкальләрен туплаган 3 томлык, табышмаклар һәм балалар фольклоры җыентыклары, якын арада басылачак 2 томлык фразеологик сүзлек — болар үзләре генә дә ни тора! Менә шуның кадәр эш эшләргә омтылган кешегә аяк чалучыларның үзләренең татар халкына каршы булулары ачыклана бит хәзер...

— Хәзер шулай ул, ә теге чакны бәйләнергә җай гына көтеп йөриләр иде... Аннары тагын «җидегәнчелек»тә гаепләү булды... Янәсе, без, бер төркем язучылар, җиде кешелек оешмага берләшеп, советка каршы көрәш җәелдермәкче булабыз икән... 1930 елда кулга да алындым. Укытып йөргән җирдән «Спартак» аяк киемнәре фабрикасына ишек алды себерүче булып эшкә китүем дә шул сәбәпле иде. Хәтта әле, анда эшләгән чагында да, берничә язучы фабрикага килеп, мине фаш итәргә йөрделәр. Ә фабрика яхшы эшләвем өчен миңа бүләкләр бирә иде... Чынлыкта булмаган әлеге «җидегәнчелек» арттан калмас кара сакал булды. Сугыштан соңгы елларда да аны еш кына исемә төшереп тордылар... «Идегәй» дастанын бастырган өчен мине милләтчелектә гаепләү булды. 1944 елда, дастан белән бергә миңа да «милләтче»

дигән мөһер сугылды. Хәзер «Идегәй» басылды, ә теге «милләтче» дигән мөһернең миннән һәм дастаннан һаман да алынганы юк әле.

— Хезмәтләрегезне бастырганда бигрәк тә чагылгандыр инде мондый ярлык?

— Чагылмаган кая! Сугыштан соң «Балалар фольклоры»н китап нәшриятына алып баргач, хәтта аны идәнгә үк атып бәрделәр. Озак еллар үтеп, анда Гарәф Шәрәфетдинов эшли башлагач кына бу китап турында сөйләшү мөмкин булды. Дөресрәге, Гарәф үзе чакырып алды мине...

— Кайбер кешеләр, бигрәк тә югары урында эшләүчеләр тарафыннан халыкның күңел җәүһәрләренә карата әнә шундый җинаятьчел мөнәсәбәт бездә озак вакытлар буена хөкем сөрде. Нәтиҗәдә, татар халкының бик күп гореф-гадәтләре онытылды, көндәлек тормыштан читләштерелде. Ул чакта, рәсми политика бик тиз арада илдәге бөтен милләтләрне бергә кушарга теләде, илдә бары тик бер генә милләт калсын өчен тырышты... Без менә хәзер, соңгы елларда бигрәк тә, яшьләребезнең кансызлыгы турында борчылып сөйләшәбез. Алар арасында җинаятьчелек нык артуга аптырыйбыз.

— Моңа бер дә аптырыйсы юк! Төрле милләт халыкларын бергә кушу, бергә бутау нәтиҗәсе ул. Татар халкын алыйк. Аның бала туганнан алып, кеше картаеп гүр иясе булуына кадәр — барысы өчен дә төрле йолалары эшләнгән. Ул йолалар гасырлар буена чарлана-чарлана килеп, инде һәр татар кешесенең канына тәмам сеңгән иде. Әлеге йолалар бала-чаганы да, яшьләрне дә, өлкәннәрне дә әхлакый кануннар йогынтысында тота иде. Һәр татар баласын үз милләтенең бер тере ботагы, бер матур яфрагы итеп тәрбияли иде алар. Кеше үзен һич тә очраклы бер зат итеп тоймый иде. Ул — моңа кадәр яшәгән нәселнең дәвамчысы иде. Ул — үзендә әнә шул нәселне дәвам иттерү өчен зур җаваплылык тоя иде. Әлеге җаваплылык тирә-юньдәге мохит тарафыннан тагын да көчәйтелә, арттырыла иде... Шуңа күрә — әлеге дә баягы дәвамлылык турында зур кайгырту булганга күрә — тормыш үзе дә тотрыклырак, кешелеклерәк иде. Матуррак иде. Яшьләр арасында хәзерге сыман массовый үтерешеп йөрүләр юк иде... Кыскасы, төрле милләт кешеләрен бергә бутаудан бер мәгънә дә күрмим мин.

— Милләтләргә үз гореф-гадәтләрен һәм матур йолаларын саклауга тагын бер нәрсә бик тә комачаулый бит... Соңгы елларда килеп чыккан зур-зур шәһәрләр, андагы яшәү шартлары комачаулый. Хәзерге шәһәрләр комфорт белән алдап, кызыктырып үзләренә бик күп, миллионлаган кешене җыйдылар да, тупладылар да — ахыр чиктә үзләре үк кешене үтерүче, җимерүче, төрле яктан таркатучы бер көчкә әверелделәр... Шуңа күрә без, бүгенге кешеләр, шәһәрләрне вакытлы бер күренеш дип кенә санарга тиешбез, минемчә. Аларны бит күпләп капитализм тудырды. Һәм алар, әлеге зур шәһәрләр, соңга таба дөресрәк, табигыйрәк яшәү рәвеше табылгач — бетә барырга тиешләр дип уйлыйм. Тормышның кешелеклерәк якка таба авышуы әнә шуны таләп итә. Хәзер дөньяда әнә шундый физик, әхлакый һәм рухи ихтыяҗ бик көчле. Экология ягын инде әйткән дә юк!

— Ерак киләчәкне көтеп тормыйча да шактый нәрсә эшләргә мөмкин. Мисал өчен, әйтик, шәһәр җирендә фатир биргәндә бер йортка бер милләт кешеләрен урнаштыру. Балтыйк буе республикаларында ул әнә шулай эшләнә. Яисә бу юнәлеш белән тагын да алга табарак китсәк — шәһәрдә татар бистәләре булдыру. Ул чагында бала-чага һәм яшь буынга халык тарафыннан контроль бик нык көчәер иде бит. Тәртип яхшырыр иде. Гасырлар буена чарланып килгән көчле тәрбия чараларын, гореф-гадәтләрне дә торгызу мөмкин булыр иде.

— Ул чагында, бәлки, шәһәрдә яшәүче татарларга үз телләрен югалту куркынычы да янамас иде. Мәктәпләр, бакчалар гөрләп эшләр иде үз телебездә! Шәһәрдә үскән татар малайлары, кызлары әдәбиятыбызга да күбрәк килерләр иде... Нәкый ага, шул уңайдан үзегезнең әдәби иҗат юлына ни рәвешле аяк басуыгыз турында әйтеп узмассызмы икән?

— Минем туган авылым Малаязда бик әйбәт мәдрәсә бар иде. Ул җәдитчә, яңа, алдынгы алымнарга көйләнгән мәдрәсә иде. Анда Габдрахман Ганиев дигән абый укытты. Ул үзе дә шагыйрь кеше, безгә сөекле шагыйребез Габдулла Тукай шигырьләрен гел укый иде. Үз шәкертләрендә әнә шулай бәләкәйдән үк туган телгә, шигърияткә зур мәхәббәт тәрбияләде.

— Нәкый ага, үзегезнең яшьрәк каләмдәшләрегезгә нинди теләкләрегез бар?

— Хәзер безгә уяныrга гына түгел, аякка торып басарга вакыт. Ә бу эш язучылардан башлана. Халыкның, милләтнең иң алгы сафында барырга кирәк. Тукайлар, Фатих Әмирханнар кебек! Әйдәгез, сынатмагыз, җегетләр!

# ДҮРТЕНЧЕ ДӘРЕС

*Урманнар артыннан*
*Һәм таулар артыннан.*
*Сап-сары болыннар буйлатып*
*Килә ак кыш бабай.*
*Ай суык, ай-ай-ай,*
*Давыллар, бураннар уйнатып.*

Гамил Афзал

Бала белән бу нәрсә? бу кем? кебек сораулар куеп, кара-каршы сөйләшүдән әкренләп аның сөйләмен оештыруга, ягъни ялгыз сөйләмгә күчәргә кирәк. Моның өчен аңа кечкенә-кечкенә хикәяләр, әкиятләр, шигырьләр укырга, башта аларның эчтәлеген бергәләп сөйләргә, аннан баладан сөйләтеп карарга була. Шулай ук төрле рәсемнәргә карап әңгәмә корырга да мөмкин. Шул ук вакытта кара-каршы сөйләшүне дә даими алып барырга кирәк. Һәм бу очракта күбрәк татар грамматикасы өчен үзенчәлекле булган тел күренешләре сайлана. Мәсәлән, татар телендә исемнәр тартым кушымчалары алып төрләнә.

— Бу кем?
— Бу минем әтием (әнием, апам, әбием).
— Ә бу кем?
— Бу синең кызың.
— Ә бу?
— Бу Илшатның әтисе.

Шундый ук юл белән: Алсу нишли? Куян кайда? Кар нинди? Болар кемнәр? Нәрсә зур, нәрсә кечкенә? кебек сораулар нигезендә сөйләшүләрне өзлексез дәвам итәргә кирәк. Мисал өчен, бу нәрсә? Бу — машина, бу — туп кебек сорау-җаваплардан соң болар нәрсәләр? дигән сорау куела. Болар әйберләр, уенчыклар дип нәтиҗә ясала. Шуннан соң кешеләргә күрсәтеп, болар әйберләрме? дип сорарга мөмкин. Җавап: юк, болар әйберләр түгел, болар — кешеләр. Шуннан соң кешегә, кешеләргә һәрвакыт кем? кемнәр? дигән сорау кую кирәклеге төшендерелә. Шунысын да истә тотарга кирәк, рус теле тәэсирендә балалар еш кына җәнлекләргә, кош-кортларга карата да кем? дип сорау куялар. Татар телендә исә кем соравы бары кешеләргә карата гына кулланыла.

**Авазларның дөрес әйтелеше**

Татар телендәге ы сузык авазының һәм б тартыгының әйтелешенә тукталыйк. Татарча ы үзенең сыйфаты белән шулай ук русча **ы** дан шактый аерыла. Русча ул авызны җәя төшеп һәм озынрак, сузыбрак әйтелә, ә татарча ул бик кыска (сулыш алган кебек кенә) әйтелә, авыз җәелми, хәрәкәтсез диярлек кала.

| *Русча* | *татарча* |
|---|---|
| сыр | сыр (складка) |

| | |
|---|---|
| тыл | кыл (щетина) |
| пыль | ындыр (гумно) |

б авазын аерым гына әйткәндә, ул нәкъ рус телендәге кебек, иреннәрне шактый каты йомып әйтелә. Ә сүз эчендә, татар сүзләрендә, иреннәрнең йомылуы йомшара, аваз иреннәрне йомар-йоммас кына әйтелә

бабай, әби, бит, бәби.

Бүгенге дәресне «Кеше әгъзалары һәм шәхси гигиена» темасына үткәрәбез. Түбәндәге яңа сүзләрне отып калыйк: а в ы з, б о р ы н, б и т, к ү з, к о л а к, т е ш.

а) Бала белән бергәләп курчак рәсеме ясала. Бала үзенең рәсемен тасвирлап бирә. Мин курчак ясадым. Курчакның аяклары һәм куллары бар. Менә уң кулы. Менә сул кулы, һ.б.

б) Хәзер шул ук тел күнегүләрен курчакның үзе белән кабатлыйбыз. Менә — курчак. Бу — аның бите. Бу нәрсә? Бу — бит. (Сүз берничә тапкыр кабатлана). Бу нәрсә? Бу — күз (ү авазының дөрес әйтелешенә игътибар ителә). Курчак күзен дә йома. Баладан курчак күзен йомдымы, әллә күзләрен йомдымы дип сорарга мөмкин. Бу нәрсә? — Борын. Бу нәрсә? — Авыз, теш, колак.

в) Бала үз әгъзаларын атап күрсәтә. Күзең кая? Кулларың кая? һ.б.

Шигырь укып эчтәлеге аңлатыла (Физкультминут үткәрергә мөмкин.)

*Ак куянкай утыра,*
*Колакларын селкетә.*
*Менә шулай, менә шулай*
*Колакларын селкетә.*

(Кулларны колак артына куеп селкиләр).

*Куян туңа башлагач,*
*Аякларын җылыта.*
*Менә шулай, менә шулай*
*Аякларын җылыта.*

(Ике кулны алга сузып, бер-беренә бәрәләр).

*Куян һаман да туңа,*
*Сикереп алу бик кирәк.*
*Менә шулай, менә шулай*
*Сикереп алырга кирәк.*

(Ике аяктан сикерәләр).

Куянны кемдер куркытты һәм ул урманга элдертте.

г) Кабаттан әңгәмә үткәрелә.

Бу — авыз (Борын күрсәтелә).

— Юк, бу авыз түгел, борын.

— Бу колакмы?

— Әйе, бу — колак, һ.б.

Шигырьләр уку һәм эчтәлеген сөйләү.

### ЙОМШАК СУ, ЙӨГЕРЕК СУ!

ҖӘВАД ТӘРҖЕМАНОВ ШИГЫРЕ

*Йомшак су, йөгерек су!*
*Син мине чиста ю!*

*Бер тап та калмасын,*
*Битләрем аллансын,*
*Кулларым агарсын...*
*Авызым елмайсын,*
*Колагым тыңласын.*
*Йомшак су, йөгерек су,*
*Барын да чиста ю.*

Хикәяне укыгыз, эчтәлеген бергәләп сөйләгез.

ГАСИМ ЛОТФИ

## ПЕСНӘК БЕЛӘН ӘНИСӘ

Кыш көне иде. Көннәр үтә салкынаеп китте. Суык бабай стеналарга суга, шарт-шорт итә. Тышка чыксаң, борынны чеметә.

Кошларның хәле бик авырайды. Аларга ашарга табу кыенлашты. Беркөнне Әнисәләрнең тәрәзәсенә сары түшле песнәк килеп кунды. Тәрәзә пыяласын чукырга тотынды.

— Әни, песнәк ник тәрәзәне чукый? — дип сорады Әнисә.

— Күрәсең ич, тышта нинди салкын. Аның ашыйсы килгән,— диде әнисе.

— Алайса, мин аны ашатыйм,— диде Әнисә, тәрәзәне ачты да аңа бер кисәк туңмай куйды. Песнәк бик шатланды. Канат кагып, Әнисәгә рәхмәт әйтте. Күз ачып йомганчы майны ашап та бетерде.

Шул көннән алып, песнәк бик ияләшеп китте. Көн саен бер вакытта тәрәзәгә килеп куна торган булды. Тора-бара ул ачык тәрәзәдән өйгә дә керә башлады.

**Фәһимә ХИСАМОВА,**
филология фәннәре кандидаты,
**Рәшидә БОРҺАНОВА,**
методист.

## *Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре*

# Дәрдеменд

*(1859—1921)*

دردمند

گورلەگەن سولار باشندا،
تڭلاغز، شوندا اوتەر-
يورسە سقتاپ تاڭ- سَحَرلر
موڭ-ساغشلاردان خيال.
ای توغان ايلنڭ هَوَاسی،
رنجيم، زنهار، كوتەر!
رنجيم، زنهار، كوتەر!
نی عزيزرەك- بو وَطَنمی؟
آه، توغان قاومم عزيز!
اول مُقَدَّس قان بلەن اول
ايزگی سوُتكە نی جيتەر!
سوُت قالر، وَطَن كيتەر!
سوُت قالر، وَطَن كيتەر!

آتام-آنام يورتی اوچون
بولسا مڭ جانم فيدا،
توغان-اوسكەن جيرم اوچون
سوڭ تامچی قانم فيدا.

Гөрләгән сулар башында,
Тыңлагыз, шунда үтәр—
Йөрсә сыктап таң-сәхрәләр
Моң-сагышлардан хыял.
И туган илнең һавасы,
Рәнҗемим, зинһар, күтәр!
Рәнҗемим, зинһар, күтәр!
Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аһ, туган каүмем газиз!
Ул мөкаддәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр!

* * *

Атам-атам йорты өчен
Булса мең җаным фида,
Туган-үскән җирем өчен
Соң тамчы каным фида.

*Журнал өчен текстны*
*Җәүдәт Миңнуллин*
*һәм Раиф Мәрданов әзерләде.*

# «КАЗАН УТЛАРЫ»НДА 1989 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


ТАТАРСТАН АССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЛАРЫ

**Ә. Н. Еникеевка «Татарстан АССРның халык язучысы» дигән мактаулы исем бирү турында.** № 7.
**Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының «Татар алфавитын латинлаштырылган алфавиттан рус графикасы нигезендәге алфавитка күчерү турында»гы Указына үзгәрешләр кертү турында.** № 10.

КПСС ӨЛКӘ КОМИТЕТЫ БЮРОСЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН АССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫ КАРАРЫ

**1989 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү турында.** № 6.

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Бәйрәмова Ф. **Кыңгырау.** Повесть. № 8.
Гаффар Ә. **Олы юлның тузаны.** Роман. № 11, 12.
Гыйләҗев А. **Яра.** Повесть. № 2.
Дәүли Н. **Сталинга хат.** Повесть. № 8.
Камалов Б. **Узган гомер бигрәк җәл.** Повесть. № 6.
Кашапов Г. **Убырут.** Повесть. № 5.
Латыйф Ф. **Аяклы каза.** Хикәя. № 11.
Мәһдиев М. **Бәхилләшү.** Моңсу повесть. № 1, 2.
Мөхәммәдиев Р. **Кенәри — читлек кошы.** Роман. № 4, 5.
Рәхимов Җ. **Ярсу.** Хикәя. № 8.
Садриев Ф. **Шаһзаманов эше.** Повесть. № 10.
Тимбикова К. **Табылдык хатлар сере.** Эпистоляр повесть. № 9.
Фәтхетдинов З. **Үлем әлмәге.** Роман. № 9, 10, 11.
Хафизова Р. **Зөләйханың сәгать чылбыры.** Хикәя. № 8.
Хәбибуллин М. **Илчегә үлем юк.** Роман. № 6, 7, 8.
Юныс М. **Европа ат сагына.** Повесть-сәяхәтнамә. № 3.
Яруллин Ф. **Иске йорт истәлеге.** Хикәя. № 8.

ШИГЪРИЯТ

Акъегет. **Тарала бөтнек исе.** Шигырьләр. № 12.
Афзал Г. **Яңа чорга киләм.** Шигырьләр. № 2.
Арсланов Н. **Каршыла.** Шигырьләр. № 3.
Баянов Ә. **Аллаларны бәреп төшердек без...** Шигырьләр. № 6.
Бохарай Р. **Тәнге ярда «Әллүки».** Шигырьләр. № 9.
Булатова К. **Шигырьләр.** № 11.
Вәлиуллин Р. **Бары алга, алга!..** Шигырьләр. № 9.
Гадел Ә. **Туган авылны сагыну.** Шигырьләр. № 10.
Галиев М. **Рух.** Шигырьләр. № 9.
Гәрәй Р. **Мизәлә шигырьләре.** № 4.
Гатауллин Р. **Остаз турында.** Шигырьләр. № 4.
Гыйбадуллин И. **Каен.** Шигырьләр. № 9.
Гыйләҗев И. **Тынлык эчтәлеге.** Шигырьләр. № 4.
Гыйззәтуллина Ф. **Иөрәк тавышы.** Шигырьләр. № 7.
Дәүли Н. **Гаепләү сүзе.** Шигырьләр. № 3.
Зыятдинова Ф. **Уйлану.** Шигырьләр. № 3.
Зөлфәт. **Өч баллада.** № 2.
Идиятуллин Р. **Белгән килеш.** Шигырьләр № 2.
Латыйп К. **Мин синеке.** Шигырьләр. № 3.
Маннапов Ш. **Үкенмәслек булсын.** Шигырьләр. № 7.
Моратов Г. **Атом-кирмән.** Фрагментлар. № 7.
Мәхмүдов Ә. **Мәхәббәт.** Шигырьләр. № 7.
Низамиев Р. **Кем баласы?** Шигырьләр. № 11.
Рәхим Г. **Кулга-кул тотынып.** Шигырьләр. № 6.
Сибгатуллин К. **Ашкын ат.** Шигырьләр. № 7.
Фәйзуллин Р. **Яңа шигырьләр.** № 11.
Харис Р. **Кәрван.** Шигырьләр. № 10.
Шабаев М. **Тор-рыйк... Тор-рыйк.** Шигырьләр. № 9.
Шакирҗанова Л. **Шәрык шагыйренә ияреп.** Шигырьләр. № 9.
Шәрифуллина Э. **Эзләдек, исем эзләдек.** Шигырьләр. № 10.
Яруллин Ф. **Көрәшләрдә билләр чыдарлык.** Шигырьләр. № 6.
Әгъләмов М. **Остаз.** Шигырьләр. № 3.
Әхмәтҗанов Р. **Тукайны эзлим.** Шигырьләр. № 8.
Әюпов Х. **Капка баганасы турында баллада.** Шигырьләр. № 9.
Әхсәнов И. **Ике шигырь.** № 8.
Әхмәдиев Н. **Васыять.** Шигырьләр. № 10.
Әхмәтҗанов Рәшит. **Карачкы.** Поэма. № 12.

А. С. ПУШКИННЫҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ

Пушкин А. С. **Мәгъдән базларында...** Шигырьләр. № 6.

## М. Ю. ЛЕРМОНТОВНЫҢ ТУУЫНА 175 ЕЛ

Лермонтов М. Ю. Болытлар. Шигырьләр. № 10.

## ДӘРДЕМӘНДНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Хисамов Н. Дәрдемәнд. № 12.
Мәһдиев М. Рәмиевләр нәселеннән бер рәү. № 12.

## РИЗАЭТДИН ФӘХРЕТДИНЕВНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Фәхретдинев Р. Болгар һәм Казан төрекләре. № 1.

## С. СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Рәмиев З. Вакыт җитәр, кояш чыгар! № 8.

## А. АХМАТОВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Ахматова А. Юатырга теләп... Шигырьләр. № 6.

## НӘКЫЙ ИСӘНБӘТКӘ 90 ЯШЬ

Сынатмаска кирәк, җегетләр! Язучы белән М. Вәлиев әңгәмәсе. № 12.

## СЕСПЕЛЬГӘ 90 ЯШЬ

Семендер Ю. Яңа чор җырчысы. № 11
Сеспель М. Шигырьләр. № 11.

## ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Мәҗитов З. Шагыйрьнең яралы җаны. № 1.
Кәрим Ф. Төрмәдә язылган шигырьләр. № 1.

## ӘМИРХАН ЕНИКИГӘ 80 ЯШЬ

Еники Ә. Халыкның күзен ача белү дә кирәк. № 3.

## ӘНВӘР ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Мингалим Р. Чорлар чатында. № 3.
Давыдов Ә. Буран. Шигырьләр. № 3.
Давыдов Ә. Ярослав Смеляковка Хат. № 3.

## ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Арсланов Н. Яшь дустым Фаил. № 6.

## ӘДӘБИ МИРАС

Гатау М. Сәләмгә. Шигырь. № 12.
Идегәй. Татар халык дастаны. № 1.
Исхакый Г. Башкорт бәхете. № 6.
Нуруллин И. Макталган һәм тапталган әдип. № 6.
Туфан Х. Төрле еллардан. Шигырьләр. № 6.
Әхмәдуллин А. Гаяз Исхакый әсәрләренең исемлеге. № 6.

## 1 ИЮНЬ — БАЛАЛАРНЫ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУ КӨНЕ

Миңнуллин Р. Ялгыз калгач. Шигырьләр. № 6.

## ОСТАХАНӘ

Бәдретдинов Х. Туфраксыз басу. Очерк. № 10.
Тимбикова К. Өметләнеп көтәбез. № 10.
Шаһимәрданов М. Өч чакрым юл. Хикәя. № 5.
Төхфәтуллин Р. Мансур Шаһимәрданов хикәясе турында. № 5.

## ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Батулла. Нотыкчы. Хикәя. № 8.
Галиев М. Ие шул... Хикәя. № 7.
Монасыйпов В. Тантана. Бурыч. Шикаять. Хикәяләр. № 8.
Синугыл Ә. Адәм әүлиясе. Шигырьләр. № 8.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Җомабаев М. Җил. Шигырьләр. № 12.
Година Н. Хикәят. Шигырьләр. № 12.
Мирзаев М. Шигырьләр. № 12.
Галимҗан Х. Шигырьләр. № 12.
Насыйбуллин М. Дуслык — зур байлык. № 12.
Шавкута А. Ахшам күләгәсе. Хикәя. № 12.

## ТАТАРСТАНДА БАШКОРТСТАН АССР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

Кәрим М. Исәнмесез! Инде без килдек... № 5.
Бәширов Г. Хуш киләсез, кадерле дуслар! № 5.
Кудаш С. Үкенәм. Шигырь. № 5.
Бикшева З. Кешечә. Шигырь. № 5.
Нәҗми Н. Ут күрше. Шигырь. № 5.
Гали М. Башкортстан таулары. Шигырь. № 5.
Киңҗәбулатова К. Тукайга. Шигырь. № 5.
Колмый Я. Телгә тел дошман түгел. Шигырь. № 5.
Рамазанов Г. Шигърият чишмәсе. Шигырь. № 5.
Атнабаев Ә. Маймыллар белән әңгәмә. Шигырь. № 5.
Сафин Р. Тальяным. Шигырь. № 5.
Кәримов М. Тирмә корам. Шигырь. № 5.
Игебаев Ә. Сукмагымнан адаштырма. Шигырь. № 5.
Әлибаев С. Үзенекен итә ел мизгеле. Шигырь. № 5.
Бикбаев Р. Кем гаепле? Шигырь. № 5.
Аралбаев К. Моң. Шигырь. № 5.

Тугызбаева Ф. **Уйладым мин.** Шигырь. № 5.
Хәлим А. **Энергия.** Шигырь. № 5.
Мифтахов Р. **Һай, Салават — җир күрке.** Шигырь. № 5.
Иосыпов Т. **Сагыш бураны.** Шигырь. № 5.
Әхмәт-Хуҗа Ә. **Башкорт теле.** Шигырь. № 5.
Юнысова Г. **Кымыз ясаучы кызлар.** Шигырь. № 5.
Хисаметдинова Р. **Буранбай.** Шигырь. № 5.
Асылгужа. **Кыңгырау чәчәкләренә.** Шигырь. № 5.
Котлыгилдина. **Кайгы, кая барасың?** Шигырь. № 5.

Солтангәрәев Р. **Үтәлмәгән васыять.** Хикәя. № 5.
Мөхәммәтҗанов Р. **Башкортстанда туйлашу.** № 5.

## ЭСТОН ЯЗУЧЫЛАРЫ БЕЗДӘ КУНАКТА

Валтон А. **Яшел биштәрле кеше.** Хикәя. № 10.
Руммо П.-Э. **Тыңлыйм болыт агышларын.** Шигырь. № 10.
Каплински Я. **Бик тә кысанайдың син, замана.** Шигырьләр. № 10.
Вааранди Д. **Кышкы төн.** Шигырь. № 10.
Сийг А. **Таш назы.** Шигырь. № 10.
Луйк В. **Ишекле көзгеләр.** Шигырь. № 10.

## ВЕНГР ШАГЫЙРЕ — «КАЗАН УТЛАРЫ» КУНАГЫ

Чех К. **Алтын — көмеш.** Шигырьләр. № 6.

## ПУБЛИЦИСТИКА

Алаев Ю. **Күңелләргә күпер салучы.** № 8.
Галиев Ф. **Авылым гадәтләре.** № 3, 4.
Зарипов М., Подольский А. **Кайры тун кайгысы.** № 1.
Зарипов И. **Сигезенче кое.** № 8.
Латыйпов Ф. **«Якты юл»ның йөзе якты.** № 7.
Паушкин Г. **Идел бит ул, Идел бит ул!** № 7.
Рафиков М. **Бүдәнә генә елыймы?** № 5.
Рәшитов Ә. **Намусыңнан сора.** № 4.
Рәшитов Ә. **Без кемнән ким?** № 12.
Рәхимов Җ. **Аккошлар Чалпыда кала.** № 10.
Табачник Д. **Генштабның үзендә.** № 8.
Хәсәнов М. **АЭС салды хафага.** № 6.
Шәймиев М., Зарипов М. **Мөстәкыйльлек.** (Татарстан АССР Министрлар Советы председателе М. Шәймиев белән язучы М. Зариповның региональ хуҗалык исәбенең киләчәге, яңача хуҗалык итү юлларын эзләү турында әңгәмә). № 3.
Эйди Т. **Якты нурлар эзләгез.** № 9.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәлиев М. **Тукай яшен узганда.** № 6.
Мостафин Р. **Тарих хөкеме. Суд тикшерүе материаллары буенча.** № 9.
Төхвәтуллин Р. **Дөреслек каян башлана?** № 11.
Ханзафаров Н. **Вакыт иләге — вак иләк.** № 8.
Ягъфәров Р. **Уйнагыз, нәниләр.** № 10.
**Яшьлегемдә яшьнәрмен** (Р. Зәйдуллин китабы турында яшь тәнкыйтьчеләр бәхәсе). № 9.

## БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

Арсланов Н. **Ачыктан-ачык әйтсәк.** № 1.
Байтимеров Р. **Мөгамәлә турында.** № 3.
Гайнетдинов М. **Ышаныч — талантларда!** № 3.
Гыйльманов Г. **Заман тойгысы бармы?** № 3.
Зөлкарнәев Ф. **Сабыр төбе алтынмы?** № 2.
Низаметдинов З. **Китап киштәләре өстебезгә ишелмәсме?** № 2.
Юнысов В. **Кая киткән тыйнаклык?** № 1.
**Заман һәм шигырь** (әдәби бәхәсне йомгаклауга багышланган редколлегия утырышыннан чыгышлар). № 5.

## БӘХӘСКӘ УКУЧЫ КУШЫЛА

Мозафин Г. **Әдәбият турында сөйлик!** № 3.
Нуретдинова Л. **Кара күмер калмасын.** № 3.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Абдуллин И., Надиров И. **«Татарика».** № 9.
Ганиева Р. **Тукай ялкыны яңара.** № 1.
Зәйнашева Г. **Гөлләр елы.** № 7.
Зәйнуллин Җ. **Борынгы дуслык эзләреннән.** № 8.
Мингалим Р. **Энем әйтсә — әйтә ул.** № 9.
Низамиев Р. **Чәчәкләр китерегез аңа.** № 3.
Сәхапов Ә. **Гүзәллеккә тугрылык.** № 10.
Сафиуллина Ф. **Яңа сүзлек.** № 3.
Урманчеев Ф. **Риваятьләр һәм легендалар.** № 9.
Шәрипов Р. **Юлдагы табышлар.** № 7.
Әгъзамов Ф. **Тормышның үзеннән.** № 8.
Әхмәтҗанов М. **Милли матбугатыбыз турында.** № 10.

## ИЛЕБЕЗ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘРЕ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

Василевский В. **Көмеш дага.** № 8.

## ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Ихсанова Л. **Язмыштан узмыш бармы?** № 6.

## ЯЗУЧЫ ТРИБУНАСЫ

Еники Ә. **Тәвәккәллек телим.** № 7.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Ахунов Г. **Бүгенге татар романы** № 5.
**Ышаныч зур!** Иҗади секцияләр җитәкчеләре белән әңгәмә. № 4.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XI СЪЕЗДЫ

Еники Ә. **Хәерле сәгатьтә.** № 11.
Миңнуллин Т. **Каләмебез, сүзебезне эшкә җигик!** № 11.
Харис Р. **Әйтәсе сүзебез соңгармасын.** № 11.
Миңнуллин Ф. **Кичермәсләр безне, кичермәсләр.** № 11.
Галиуллин Т. **Шигърияттә — халык язмышы.**
Әхмәдуллин Ә. **Дөреслеккә ирешү юлында.** № 11.
Кашапов Г. **Тешебез үтәме?** № 11.
Миңнуллин Р. **Балалар әдәбияты ни хәлдә?** № 11.
Фәттах Н. **Гаделлек — нигез булсын.** № 11.
Скороходов М. **Рус язучыларының иҗаты.** № 11.
Шәмси С. **Яшәү даирәбезне киңәйтик.** № 11.
**Татарстан язучыларының XI съезды резолюциясе.** № 11.

## УКУЧЫ СҮЗЕ

Вахитов Р. **Дуслыкның бөек көче.** № 6.
Ибраһимов А. **Ак тапларны киметә.** № 6.
Миначев М. **«Без дә хакның бәндәсе».** № 6.
**Укучы сүзе.** № 8.

## КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

Рамазанов Т. **Әдәбиятыбыз компасы.** № 5.
**Китаплар дөньясында.** № 10.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Кашапов Г. **Хәсән Туфанның үлем сорап язган хаты.** № 2.

## МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА

Алишев С., Мөлеков М. **Вәисевчеләр тарихыннан.** № 7.
Гарипова З., Әмирханов Р. **Ирекле җәмгыятьләрдән фәнни институтларга.** № 2.
Гарифуллин Д. **Тарихта үз эзе бар.** № 2.
Гыйззәтуллин И. **Ялкынлы ел авазы.** № 11.
Еникеев С. **Айтматовлар турында.** № 2.
Зәбиров Г. **Ата Салих белән әңгәмәләр.** № 11.
Ибраһимов Ф. **Әле дә күңел түрендә.** № 11.
Ибраһимова Ф. **Могтәбәр шәхес.** № 7.
Кайбицкая Г. **Беренче адымнар.** № 9.
Камалов Т. **Көнбатышка йөз белән.** № 9.
Кудрецкая Э. **Шагыйрьнең тылсымлы мохите.** № 4.
Кәримуллин Ә. **Америка галиме татарлар турында.** № 6.
Миңнуллин Җ. **Утызынчы елларда.** № 6.
Мәһдиев М. **Татар журналлары.** № 6.
Нәҗметдинов Т. **Бу эш ничек булды?** № 10.
Сәгадиев А. **Мәрҗани һәм гарәп философиясе.** № 7.
Таһиров И. **Кем ул Солтангалиев?** № 4.
Ханзафаров Н. **Галим архивы — хәтер сандыгы.** № 4.
**Н. Г. Чернышевскийның татарча кульъязмалары.** № 10.
Әмирханов Р. **Дәреслекләребезнең тирән тамыры.** № 8.
Әхмәтҗанов М., Ильясова Н. **Шиһабетдин Мәрҗани шәҗәрәсе.** № 7.
Үтәбаев Р. **Габделгалләм Фәезхан угылы турында.** № 7.

## СӘНГАТЬ

Исхакова-Вамба Р. **Сәйдәшев ничек язган?** № 7.
Сөләйманова-Вәлиева Г. **Татар ювелир сәнгате: үткәне һәм бүгенгесе.** № 7.
Хатипов Ф. **Көйләребез, моңнарыбыз.** № 12.

## ТАТАР ХАЛЫК МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

Гыйләҗев Р. **Думбра һәм саз.** № 4.
**Гөслә һәм ятаган.** № 6.
**Курай.** № 7. **Сорнай.** № 8. **Тальян гармун.** № 9. **Быргы.** № 11.

## БОРЫНГЫ БОЛГАРДА ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ 1100 ЕЛ

**Җан тынычлыгы — ышануда** (Мөфти Тәлгат Таҗетдин белән язучы Салих Маннапов әңгәмәсе). № 7.

## БЕЗГӘ ЧИТ ИЛЛӘРДӘН ЯЗАЛАР

Вәлиева Г. **Казанны сагыну.** № 8.
Еники Ә. **Көтелмәгән хат.** № 1.

## РЕПЛИКА

Миңнеханов И. **Бәяне дөрес бирик.** № 4.

## ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ ҺӘМ ЯЗУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Миңнуллин Җ., Мәрданов Р., Кадыйров Р. №№ 1-5, 9-12.

ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Хисамова Ф., Борһанова Р. Татар теле дәресләре. № 9-12.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Роза Хафизовага 60 яшь. № 2.
Флүн Мусинга 50 яшь. № 2.
Яхъя Халитовка 60 яшь. № 8.
Шәриф Хөсәеновка 60 яшь. № 10.
Шамил Рәкыйповка 60 яшь. № 11.

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Р. Рәхимовның тууына 50 ел. № 4.

ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Шаһиева Р. Татар келәме. № 2. Саба көмешчеләре. № 3. Китап бизәү сәнгате. № 4. Таҗлы шәмаил. № 5. Күн келәмнәр. № 7. Нур өстенә нур. № 9. Халык рухы җанлана. № 10. Асыл бизәкләр җыелмасы. № 12.
Цой В. Тамбур белән чигү. № 1. Укалы күкрәкчә. № 8. Тукылган рәсем. № 11.

Бер сорауга — бер җавап. № 6, 10.

Журналыбызны кайда күпме алдыралар. № 6.

Сәйдәш моңнары. Җыр. М. Хөсәен сүзләре, Ә. Бакиров музыкасы. № 6.

Культура тормышы көндәлеге. № 1-12.


## *Мәдәният тормышы көндәлеге*

### ИНСТИТУТ БӘЙРӘМЕ

24 октябрьдә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтының оешуына 50 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды. Җыелышта институт директоры профессор М. З. Зәкиев ярты гасыр дәвамында институт башкарган эшләр һәм коллектив алдында торган бурычлар турында доклад ясады.

КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре, КПСС өлкә комитеты бюросы члены Г. И. Зерцалов КПСС өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, ТАССР Министрлар Советының институт коллективын юбилей уңаеннан котлавын игълан итте.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы президиумы председателе, СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты В. Е. Алемасов филиал президиумы, партком һәм башка җәмәгать оешмалары исеменнән институт коллективын кайнар котлады һәм аңа гуманитар фәннәрне һәм халкыбызның культурасын үстерүдә яңа уңышлар теләде. СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең I дәрәҗәле дипломнарын тапшырды.

### ТАТАР КЫЗЛАРЫ КИЧӘСЕ

16-17 сентябрьдә Түбән Каманың Техника йортында «Татар кызлары» дигән зур әдәби-музыкаль кичә узды. Казаннан бер төркем күренекле язучылар һәм шагыйрьләр, галимнәр һәм сәнгать осталары, журналистлар килгән иде. Алар арасында РСФСРның атказанган культура хезмәткәре, «Казан утлары» журналының очерклар һәм публицистика бүлеге мөдире язучы К. Тимбикова, филология фәннәре кандидаты, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ф. Әхмәтова, шагыйрәләр Л. Шакирҗанова һәм Э. Шәрифуллина, композитор Л. Батыркаева, җырчылардан РСФСРның атказанган артисткасы В. Гыйззәтуллина, Татарстанның атказанган артисткасы Г. Казанцева, биюче Ф. Айзатуллова, «Социалистик Татарстан» газетасы хәбәрчесе Ф. Хуҗиәхмәтова бар иде.

Кызларыбыз тамашачыларны әдәбият сәнгать һәм культура яңалыклары белән таныштырдылар, үзләренең шигырьләрен укыдылар, җыр һәм биюләрен башкардылар.

### САЛИХ СӘЙДӘШЕВ ИСТӘЛЕГЕНӘ

27 сентябрьдә Казанның офицерлар йортында татар музыкасы концерты булды. Аннан килгән керем республикабыз башкаласында Салих Сәйдәшевкә һәйкәл салуга тотылачак.

Концертта РСФСРның халык артисты Р. Ибраһимов, ТАССРның атказанган артисткасы Ф. Хәсәнова, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе М. Әхмәтов һәм РСФСРның атказанган артисткасы Ә. Заһидуллина башкаруында композитор Салих Сәйдәшев, Александр Ключарев, Фәрит Яруллин, Рөстәм Яхин әсәрләре яңгырады.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Әдип Т. Әйди, шагыйрь Җ. Дәрзаман сентябрь аенда Чиләбе һәм Оренбург өлкәләрендә татар матбугатын укучылар белән очраштылар. Чиләбе, Магнитогорск, Оренбург шәһәрләренең мәдәнният сарайлары һәм китапханәләрендә, Коншак, Нагайбәк, Сакмар, Әсәкәй районнары авыл ларында чыгышлар ясадылар. Көньяк Уралда тамашачыларны Татарстанның мәдәни тормышы белән таныштыру, милли газета-журналларыбыз хакында сөйләшү Чиләбе һәм Оренбург өлкә телевидениеләре оештырган татарча махсус тапшыруларда дәвам ителде. Әдәби очрашуларда Чиләбе язучылары Р. Вәлиев, С. Гәрәева, «Татарстан яшьләре» газетасы хезмәткәре Ф. Низамова да катнашты.

## ЯҢА МӘДӘНИ ҮЗӘК

Чаллы шәһәрендә Азәрбайҗан мәдәни үзәге төзелде. Яшь калада 20 мең чамасы азәрбайҗан милләтеннән булган кеше яши. Кардәшләребез Татар иҗтимагый үзәге үткәрә торган политиканы яклыйлар.

Яңа төзелгән мәдәни оешма төп бурычларның берсе итеп түбәндәгеләрне куйды: шәһәр мәктәпләренең берсендә азәрбайҗан теле һәм тарихы, милли музыка дәресләрен кертү, азәрбайҗан музыкаль ансамблен оештыру, чәйханә, уку залы һәм китапханәсе булган мәдәният үзәге ачу, азәрбайҗан артистлары концертын оештыру. Хәзер шушы юнәлештә максатчан эш алып барыла.

## ҮЗ АНСАМБЛЬЛӘРЕ

Ленинград шәһәренең И. И. Газа исемендәге Культура сараенда өч ел инде татар җыр һәм бию ансамбле эшләп килә. Аны оештыруда хормейстер С. Абдулвалиев, балетмейстер И. Боровинская, музыкантлар Ш. Батыршин, С. Хәсәнов, А. Шәрәфиев башлап йөрделәр. Программаларны төзегәндә алар, татар фольклорына таянып, халкыбызның борынгы уеннарын, төрле йола бәйрәмнәрен сәхнәгә чыгарырга омтылалар. Н. К. Крупская исемендәге Ленинград культура институты укытучысы И. Боровинская берничә миниатюрадан торган «Кич утыру» дигән җырлы-биюле композиция куйды. Соңрак «Туган як моңнары» дип исемләнгән күренеш әзерләнде.

Ансамбль Ленинградта инде шактый популяр. Аның чыгышларын, Габдулла Тукайга багышланган кичәдә катнашуын тамашачылар зур шатлык белән каршы алдылар. Әлеге коллектив Ленинградта оешкан татар клублары белән тыгыз элемтәдә яши. Мәсәлән, «Энергетик» Культура йортында барлыкка килгән «Йолдыз» клубына йөрүче татар сәнгатен һәм әдәбиятын сөючеләр дә кичәләр уздырганда ансамбль члennарына еш мөрәҗәгать итәләр. Кыскасы, Ленинградта яшәүче татарлар тормышына бу коллектив матур бизәк өсти.

## УКУ — АНА ТЕЛЕНДӘ

Чиләбе өлкәсендә татарлар күп яши. Хәзер аларның культура ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерү һәм мәктәпләрдә ана телендә укытуга зур игътибар бирелә. Укытучы кадрлар һәм дәреслекләр белән Казан, Уфа шәһәрләре ярдәм итә. Бер ел элек Чиләбе педагогия училищесының үзендә дә ана телендә белем бирүче башлангыч класс укытучылары әзерләнә башлады. Ә быел исә мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре өчен кадрлар әзерләүче махсус группа ачылды.

Быел Уй районының кайбер мәктәпләрендә балалар татар телендә укый башладылар. Мондый карар ата-аналар һәм укучылар теләге буенча кабул ителде.

## ЛИТВАДАН ХӘБӘРЛӘР

Литвада 90 милләт вәкилләре яши. Аларның һәркайсы үзенең культурасын, көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, туган телен сакларга тырыша. Соңгы вакытта, бигрәк тә милли яңарыш чорында, бу юнәлештә шактый эш башкарыла.

«Без — Литва халкы». Революция музеенда ачылган күргәзмә шулай дип атала. Анда белорус, караим, әрмән, грузин һәм русларның уртак тормышы турында сөйләнә. Литва татарлары турындагы биш стенд аеруча игътибарны үзенә җәлеп итә. Фоторәсемнәрдә Литва татарларының көнкүреше, гадәтләре, зират һәм мәчетләре тасвирланган. Коръәннән күчереп алынган язу янында кешеләр озаклап тукталып торалар. Бирелә байтак кына китаплар да куелган, атаклы шәхесләрнең шәхси әйберләре урын алган.

Литва культура фонды каршында еврейләр, белоруслар, латышлар һәм литва татарлары җәмгыятьләре эшли. Литва татарлары үзләренең югалган культураларын, йола һәм гадәтләрен торгызырга булдылар. Шул максаттан 1989 елда Вильнюста, берничә дистә литва татары җыелышып, үз җәмгыятьләрен оештырдылар. Ул үзенә Вильнюс, Каунас төбәге, республиканың башка шәһәрләрендәге, шулай ук Белоруссиядәге татарларны берләштерә.

Җәмгыять күп кенә эшләр башкара. Тарих һәм этнография музеенда «Вильнюс Тедиминастан алып безнең көннәргә кадәр» дип аталган күргәзмә эшли. Монда литва татарларының гербларьі һәм башка истәлекләре саклана.

## ТУКАЙ УКРАИНЧА СӨЙЛӘШӘ

Мондый мөмкинлекне Киевның «Веселка» дигән китап нәшрияты тудыра. Күптән түгел бирелә 1990 елда басылып чыгачак китапларның исемлеге игълан ителде. Алар арасында Габдулла Тукайның «Сөй тормышны» дигән шигырьләр җыентыгы да бар. Бу китапта шагыйрьнең балалар өчен язган иң яхшы әсәрләре урын алган. 48 мең тираж белән басылачак ул җыентык украин балаларын татар әдәбияты үрнәге белән таныштырачак.

# АСЫЛ БИЗӘКЛӘР ҖЫЕЛМАСЫ

Бездәге бизәү сәнгатенең борынгыдан килгән иң халыкчан төре — корамалар тегү. Көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү нигезендә туган бу сәнгать килеп чыгышы белән тире, нәфис күн тегүгә һәм киез келәмнәр тукуга тоташа. Ата-бабаларыбыз мал-туарлары белән сахралар гизеп, күчмә тормыш алып барган чакларында аларның тирмәләрен шундый келәмнәр, борынгы төрки халыклар өс-баш, аяк киемнәрен дә шундый күн-тире кисәкләреннән теккәннәр. Бу материаллардан ясалган һәрнәрсә — төрле каплар, киез паласлар, ат япмалары, гаскәриләрнең киемнәре дә күн өстенә шакмаклы, өчпочмак рәвешендәге яки бүтәнчә бизәкләр белән корамаланган.

Безгә таныш булган гадәти корамалар төрле төстәге ефәк, атлас, сатин, хәтта киҗе-мамык тукыма кисәкләрен өчпочмак яисә шакмаклап кисеп, берберенә тоташтырып тегелә. Төрле төстәге вак кыйпылчыклар, үзләренең төс һәм бизәкләрен саклаган хәлдә, үзара «берләшеп» кетелмәгән композицияләр хасыйл итә. Вак-вак яссылыклар, бер-берсе белән бәрелешеп, гүя крестьян тормышының күпкырлы чагылышын сурәтлиләр.

Вак-төяк гади тукыма кисәкләреннән ясалган киез, юрган тышы, сандык, урындык япмалары гадиләр тормышына хас булса, энҗеле калфаклардагы, асыл күлмәкләрдәге корама-бизәкләр затлы парча, хәтфә тасмалар кулланып башкарылган була һәм инде шәһәр тормышына хас зәвыкны тасвирлый.

Корамадагы кисәкләр икенче бер тоташ тукыма өстенә беркетелмичә кыйпылчыкларның читләреннән тоташтырып кына тегелгәнлектән, аның калынлыгы үзгәрми, тукыма һич тә исраф ителми. Бу да — халык тормышының бер ягын күрсәтүче дәлил.

Кызганычка каршы, хәзер корама ысулының бу сыйфатын, ягъни әрәмшәрәмгә юл калдырмавын, рәссамнар санга сукмый. Алар бу сәнгатькә декоратив ысул, үзгә бер сәнгати алым буларак кына мөрәҗәгать итәләр. Бу очракта корама чаршау, ашъяулык, җәймәләр, халык ысулынча, калдык-постык тукыма кисәкләреннән җыелмый. Рәссамнар төрледән-төрле кисәклрдән махсус композиция төзиләр. Әсәр эскиз нигезендә иҗат ителә. Композицияләргә төрле бизәкләр, чигүләр дә өстәлә.

Мисалга Казанның истәлекле бүләкләр җитештерү фабрикасында чигү цехы осталары ясаган «Ак чаршау» (1983) әсәрен күрсәтергә мөмкин. Бу әсәр билгеле бер эчтәлеккә нигезләнгән. Гөл кебек балкып торган кыек шакмаклар, бәләкәй кыңгыраулардай тезелеп, аска төшә. Аларның хәтта серле зыңгылдавы да ишетелә сыман. Чаршаудагы көчле төсләр «гаскәре» исә алга, офыкка омтыла кебек. Корамадагы тамбурлап чигелгән бизәкләр исә нәгышле җирлектә шытып чыккан гөлләрне хәтерләтә. Чаршау, тулаем караганда, чәчәк аткан, тиздән җимеш бирәчәк җир-бакча образын гәүдәләндерә.

**Р. ШАҺИЕВА,**
Татарстан сынлы сәнгать
музее гыйльми хезмәткәре.

Тышлыкның дүртенче битендә: XIX йөздә Казан күренешләре. Борынгы открыткадан.

**Ю. ФИЛИМОНОВ** фоторепродукциясе.

## ЖУРНАЛНЫ АЛДЫРУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Журналның брак саны килгән очракта аны газета-журналлар нәшриятының техник контроль бүлегенә җибәрүегезне үтенәбез. Адресы: 420066, Казань, Декабристов, 2, Типография ГЖИ, ОТК.


Редакция журнал җибәрү белән шөгыльләнми.

Әгәр журналның теге яки бу саны килми калса, «Союзпечать»нең җирле бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу мәсьәлә редакция вәкаләтенә керми.

Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ